ШӘРИФ
ХӨСӘЕНОВ

ПЬЕСАЛАР

ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВ • ПЬЕСАЛАР

ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВ

ПЬЕСАЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1979

С(Тат)2
Х99

Хөсәенов Шәриф Нургалиевич

Х99 Пьесалар. Т. Миңнуллин сүз башы белән.

288 бит.

Бу җыентыкка Шәриф Хөсәеновның «Профессор кияве», «Зөбәйдә — адәм баласы», «Әниемнең ак күлмәге» кебек билгеле пьесалары — илебезнең күп кенә театр сәхналарендә уңыш белән бара торган әсәрләре тупланды.

Х $\frac{70600-078}{М132(03)-79}$ 116—79 С(Тат)2

© Төзү. Сүз башы. Татарстан китап нәшрияты, 1979.

ДРАМАТУРГНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ

1978 елның 9 январенда Казан театр училищесы студентлары «Зөбәйдә — адәм баласы» дип аталган диплом спектакльләрен тамашачыларга күрсәттеләр. Трагикомедиянең авторы — драматург Шәриф Хөсәенов.

Шул спектакльне карарга бардым. Дөресен әйтим, бу юлы театрга гадәттәгечә атлыгып, ашкынып чапмадым. Чөнки, беренчедән, уйнаучылар яшьләр, тәҗрибәсезләр, алар әле өлкән артистлар кебек җиренә җиткереп уйный белмиләр. Аларның уенын караганда онытылып карамыйсың, шактый гына кытыршылыклар күреп борчылып, уңайсызланып утырасың. Икенчедән, яшьләр башкарачак әсәр дә күптәнге, таныш әсәр — аның премьерасы 1965 елда ук Татар академия театрында булган иде. Ә трагикомедия үзе тагын да иртәрәк язылган. Мин әле аның яңа гына «табадан төшкән» чагын да бик яхшы хәтерлим.

1960 елда Шәриф Хөсәенов Мәскәүдә М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы Югары курсларда укый иде. Без — Щепкин исемендәге Мәскәү театр училищесы студентлары академия театры сәхнәсен шаулаткан «Профессор кияве»нең авторын күрү теләге белән ул яши торган тулай торакка барган идек. Шунда драматург заман яшьләре турында өр-яңа пьеса язып бетергәнлеген әйткән иде. Менә шул әсәрне укып чыкканнан соң, әллә ничә тапкыр караганнан соң янәдән карарга кирәк иде миңа. Кабатлап әйтәм, теләк зур түгел иде. Чөнки заманында ярыйсы ук яңгыраган шактый пьесалар, вакыт үтү белән, актуальлеген югалтып искерәләр: уйлатмыйлар да, җылатмыйлар да, көлдермиләр дә. Көлсәң дә авторның беркатлылыгыннан көләсең.

Бу юлы әсәр мине тетрәтте. Элек караганда ул кадәр үк тәэсир итмәгән иде кебек. Пьеса, искерәсе урынга, тагын да яңарган. Сәбәбе нидә?

Сәбәбе берәү генә: әсәр художник кулы белән язылган. Ә художник көннең кадагына сугам дип, бер-ике айда хәл итеп торган көнкүреш мәсьәләләрен проблема дәрәҗәсенә күтәреп көчәнми, аны кешенең күңеле, җаны кызыксындыра.

Әле генә унынчы классны тәмамлаган Зөбәйдә — тормышның шактый ук катлаулы сукмагына яңа аяк басып, тирә-ягына күзләрен тутырып карый-карый, сокланып, аптырап, каушап, ялгышып беренче адымнарын атлаучы адәм баласы. Сак булыйк, иптәшләр, үзебезгә атларга җиңел булсын өчен аны сукмактан читкә этәрмик, олы юлга чыгарга булышыйк аңа. Кешеләрнең Кеше икәнлегенә ышансын ул. Чөнки Зөбәйдә — адәм баласы. Адәм баласын бары тик адәм баласы гына Кеше итә ала. Бу борчылу — мәңгелек, Кеше яшәгәндә ул искермәячәк. Киләчәк Зөбәйдәләре яшәгән мохит башка булыр, кешеләр, хәзергегә караганда, күп мәртәбәгә камилрәк булырлар, әмма Зөбәйдәнең балалыктан олылыкка күчү вакыты барыбер уйландыра, сискәндерә торган вакыйга булып кала бирер.

Шәриф Хөсәенов үзен мактаганны өнәп бетерми. Иҗатына карата әйтелгән комплиментларны яратып җиткерми, дөресрәге, аларга ышанмый.

— Артык күпертә башладың, алдашасыңдыр,— ди.

Әлеге «күпертмәү», алдашмау аның иҗатына да хас. Драматургның геройлары сәхнә алдына чыгып намус, вөҗдан, мәхәббәт кебек бөек төшенчәләр турында күкрәк кага-кага купшы сүзләр сөйләмиләр, тегеләй яшәгез, болай гомер итегез дип тамашачыларга коры акыл сатмыйлар. Алар гади генә яши бирәләр: эшлиләр, ял итәләр, яраталар, яратмыйлар. Әмма әнә шул гадилекнең төбендә һәрвакыт зур фәлсәфә, тормышның сәнгатьчә дөреслеге ята.

Драматургның «Әниемнең ак күлмәге» исемле драмасын алыйк. Дөньяны шаккатырырлык, ах-ух килерлек вакыйга да юк сыман анда. Тормышта бик еш була торган хәл: балалары янына әниләре килә. Чыннан да, искитәрлек ни нәрсә бар? Кайсы ана үз балалары янына килми?

Драманың нигезендә гадәттән тыш фаҗига да юк шикелле: әгәр дә балалары янына килгән ана авыру икән, өлкән яшьтәге кешенең авыру булуы, хәтта үлеме дә табигый. Кем дөньяга мәңгелеккә килгән? Әйе, барысы да гадәти сыман. Ләкин ник соң әле шундый гап-гади тоелган әсәр кайбер «катлаулы» пьесаларга караганда ныграк тәэсир итә, күбрәк уйландыра?

1970 елда «Әниемнең ак күлмәге» (ул чакта әсәр «Әни килде» дип атала иде) спектаклен Татар дәүләт академия театрында карагач, бу сорауны мин үз-үземә биргән идем. Һәм 1978 елда Качалов исемендәге зур драма театрында рус телендә карагач та ул сорауны кабатладым. Әсәрне берничә кат укып чыгарга туры килде, тик драманың тәэсир итү көче кимемәде. Бәлки, минем өчен генә әсәр якындыр, минем күңел кичерешләремә тәңгәл киләдер? Алай дисәң, «Әни килде» спектакле Татар академия театрында, Әлмәт театрында биш йөздән артык уйналды, Советлар Союзындагы дистәләгән театр сәхнәләрендә куелып, уңыш белән барды һәм бара.

Мин сорауны кабатлавымны дәвам итәм. Нигә соң әле «Әни килде»не караган саен, укыган саен күбрәк уйландыра? Сорауга җавап, минемчә, әсәрнең үзе кебек гади. Кешенең иң зур бәхете — иң камил җан иясе булып дөньяга килүе һәм яшәве. Ә адәм баласы дөньяга килүе өчен әти-әнисенә бурычлы. Белгәнебезчә, һәрбер бурыч түләнергә тиеш. Ата-анага бурычны бары тик чын Кеше булып кына түләп була. «Әниемнең ак күлмәге» шул турыда.

Чын кеше микән без? Әтиләр, әниләр алдында, кешеләр алдында, ил-Ватан каршында намусыбыз чистамы, вөҗданыбыз сафмы? Бу борчылу — мәңгелек. Кеше яшәгәндә ул искермәячәк.

Киләчәк заман башка булыр, дөнья хәзергегә караганда күп мәртәбә камилрәк булыр, әмма чын кеше проблемасы һәрчак актуаль һәм уйландыра торган проблема булып кала бирер.

Шулай булгач, драматург Шәриф Хөсәеновның бүген безгә әйткән сүзе иртәгесе көн тамашачысын да уйландырачак.

Китапка кереш сүзне шундый ышаныч белән тәмамласак та ярыйдыр. Әмма тагын берничә сүз өстәп куймасам, күңел бөтен булмас төсле. Драматургның әйткән сүзен зур ихтирам белән кабул иткән хәлдә, аның әйтәсе сүзләрен дә тамашачылар түземсезлек белән көтәләр.

Туфан Миңнуллин

БИРНӘЛЕ КЫЗ

Комедия бер пәрдәдә

КАТНАШАЛАР:

Сара — Ветеринария институтын тәмамлаучы кыз.
Әсма — аның әнисе.
Гаяз — аның әтисе.
Бибинур — аның әбисе.
Азат — Сарага гашыйк үсмер.
Хәтимә — спекулянтка.

Гаязлар квартирасында бүлмә.
Сара һәм Бибинур.

Бибинур *(Сараны иркәләп)*. Күбәләгем лә син! Алтайга эшкә китәргә дип назначение алуга атна узмаган, ябыгып та өлгергәнсең. Күр инде бу чыраеңны — самовардагы шәүлә төсле *(авыр сулап)*. И алла! Без синең кызыбызны какмый-сукмый, җил-яңгыр тидермичә дигәндәй, кадерләп, иркәләп, Алтайга җибәрү өчен үстердекмени?! Тфү, алланың каһәре төшкән сүз! Исемә төшкән саен аркаларым чымыр-чымыр итеп китә. Инде бала үсеп җитте, инде мысыр күгәрченнәре шикелле гөрләшә-гөрләшә генә яшибез дип торганда, әллә ниләр уйлап чыгаралар бит... *(Сәгатькә, аннан тәрәзәгә карап ала.)* Хәтимә дә бик озаклады — рәт чыкмый, күрәсең. Син үзең җүләр булдың, Бибисара. Артыңнан күпме егетләр йөрде, шунда берәр кулайрагын сайлый белмәдең. Менә хәзер түшеңне генә киереп йөрер идең.

Сара *(ачулы)*. Әби! Кайчан син нервада уйнаудан туктыйсың! Такылдыйсың, такылдыйсың...

Б и б и н у р. Әстәгыфирулла, менә ишетмәсәң ишет бу хәзерге балалардан! Без аны үз яныбызда калдыру өчен аяктан яздык, ә ул...

Хәтимә керә.

С а р а (*шатланып*). Хәтимә апа! Исәнмесез! Тизрәк әйтегез, нинди хәбәр китердегез...

Х ә т и м ә. Юк, берәү дә алынмый. Менә акчагыз (*өстәлгә кечкенә генә төргәк куя*).

С а р а. Ә сез өч мең икәнен әйттегезме?

Х ә т и м ә. Кызык итеп әйтеп куйдың да инде, ике күзем. Әллә, синеңчә, өч мең бик зур акчамы?

С а р а. Зур түгел дә...

Х ә т и м ә. Ике күзем! Шундый зур эш бушка гына эшләнми ул. Бу (*акчага күрсәтеп идәнгә төкерә*) менә нәрсә. Алтайга китәсе кешене алып калу уен эш түгел ул.

С а р а. Әби, чыннан да, өч мең азрак шул.

Б и б и н у р. Ашыкма, күгәрченем.

Х ә т и м ә. Бәхәсләшмәгез, ике күзем, бәхәсләшмәгез. Мин бит сезгә зуррак акчага эшлим димәдем әле. Дөрес, мин бер бик зур кешегә кермәдем, акчам азрак булды. Әмма азрак өстәсәгез...

Б и б и н у р. Юк, безнең бүтән акчабыз юк, ни, кем Хәтимә.

С а р а. Әби! Алтайга китеп булмый бит инде.

Б и б и н у р. Ашыгып кына да булмый ул, күбәләгем. Ашыккан ашка пешкән, дигән борынгылар. Тиздән әниең кайтып җитәр,— киңәшербез.

Х ә т и м ә. Ихтыяр үзегездә, ике күзем, кыстамыйм. Минем үземә монын кадәр генә дә чумара юк бит аннан (*тырнак очын күрсәтә*). Әле тик үз кешеләр булганга гына. Картлар әйтмешли, йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

С а р а. Әби!

Х ә т и м ә. Алай эшкә китәргә булмагач, укытасыгыз калмаган аны. Нигә дип укыттыгыз соң?

Б и б и н у р. Сөйләп торасың тагын, Хәтимә, син дә! Хәзер укымаган кешегә пачут юк бит. Кызларга бигрәк тә. Хәзерге кызларга белем — бирнә бит ул. Әйе, әйе, бирнә шул. Хәзер бит берәр кызны кияүгә бирә башласаң, иң элек белеме күпме? — дип сорыйлар. Ә безнең

заманда бирнәсе күпме диләр иде. Шулай булгач, кыз бала өчен белем — бирнә була бит инде ул.

Хәтимә. Шулай, шулай. Бу елда егетләр кызларның укымышлы булганын яраталар. Бәлки, ул эшләвен дә эшләмәс, ә шулай да, тегенди-мондый вакытта белем булу зарар итми. Тик менә Ветеринар институтына биреп кенә хата эшләгәнсез. Канавал булып, ат печеп йөрү бер дә генә дә кыз бала эше түгел инде.

Бибинур. Сайланып тормадык инде, ни, кем Хәтимә. Бу елларда аның институтына керүе дә әҗәл бит. Турысын гына әйткәндә, ул безнең ыкты-шыкты гына бетергән иде. Мәктәпне дим. Ә монда үзенең әтисе эшли, доцент булып.

Хәтимә. Әәә... Бик ерак җибәреп ташласалар, матур түгел инде. Ул аларның, ялгышмасам, бердәнбер балалары бугай. Бәлки, тагы да маташтырып карарбыз, ә? Ятып калганчы атып кал, дигәннәр бит. Мин бер бик зур кешене беләм... Әгәр тагын бераз кушсагыз...

Бибинур. Акчага мин баш түгел, Хәтимә. Озакламый Бибиасма кайтып җитәр. Азрак утырып тор.

Хәтимә. Кайчан кайтып җитә бит әле ул. Минем вакытым юк.

Бибинур. Анда 500 сум бар инде барын, үземнеке...

Хәтимә. Юк, ул гына аз. Ул бик зур кеше. Бишмеңсез сөйләшеп тә тормый.

Бибинур. Ууу, юк, юк, юк. Андый сумага көчебез җитми.

Хәтимә. Ихтыярыгыз, ике күзем. Кыстамыйм.

Бибинур. Алайса, соңрак сугыл.

Хәтимә. Юк, кереп йөрмәм инде. Минем кырык эшем кырылып ята. Төшемлерәкләре бар.

Бибинур. Ай алла, без дә буш калдырмабыз, алла теләсә, башкарып кына чык. Бер-ике сәгатьтән әйлән.

Хәтимә. Булса — хәзер. Ник дип әйтсәң, ул зур кеше иртәгә Мәскәүгә китә.

Сара. Әй, тотармын да китәрмен шул Алтайга!

Бибинур. Әстәгыфирулла! Син нәрсә, күбәләгем, безне саргайтып үтермәк буласың мәллә?

Хәтимә. Ярый, сау булыгыз (*киткән кебек хәрәкәт ясый, ләкин китми*).

С а р а. Хәтимә апа, туктагыз! *(Күрше бүлмәдән тиз генә акча алып керә.)* Менә, тагын мең сум.

Б и б и н у р. Ай алла, Бибисара, әниеңнән башка...

С а р а. Синең эшең түгел *(Хәтимәгә)*. Җитәрме?

Х ә т и м ә. Юк, мин аның янына биш меңсез бармыйм. Биш мең.

С а р а. Азрак үзегездән өстәп торыгыз. Тиздән әтинең получкасы.

Х ә т и м ә. Юк, минем үземдә йөз сум да юк. Ә, әле бит әбиең 500 сум акчам бар дигән иде.

Б и б и н у р. Юк, мин аны бирмим. Болай да бик күп булды. Һич тә булмаса үзеңнән кушып торырсың.

Х ә т и м ә. Юк дип әйтәм бит инде сиңа.

Б и б и н у р. Синең кебек сәүдә кешесендә дә булмагач...

Х ә т и м ә. Иии, ике күзем, хәзер сәүдәдә әллә ни эш кырып булмый. Шулкадәр кысалар! Ике айдан бирле дүрт отрез драбым ята. Алучы юк. Һәр көнне магазинда бирәләр. Базарына чыгарга куркыныч,— каптырып кына алалар. Көннән-көн кысалар. Кайчан эләктерерләр инде дип, утлы табага баскан кебек йөрим. Аһаһай! Укымаган кешенең тормышын әйтмә инде. Аәрак белемең булса, шунда берәр магазинга продавца гына булып керер идең ичмаса... Эшкә урнашырга йөрим бит әле.

Б и б и н у р. Шулаймыни. Кая?

Х ә т и м ә. Бер магазинга, уборщица булып.

Б и б и н у р. Китсәнә, картың ничек риза булды?

Х ә т и м ә. Риза булмыйча тагын,— балыкка арык, тараканга ярык дигәндәй, безнең ишегә алла биргән инде ул. Милиция теңкәгә тия, эшкә кер, диләр. Ярар инде, товары кайтканын, тегесе-монысын дигәндәй, белеп кенә торасың. Ярый, хушыгыз, бары белән маташтырып карыйм әле. Сау булыгыз.

Б и б и н у р. Сау булыгыз. Аллага тапшырдык *(Хәтимә чыга)*. Дүрт мең тәңкә! Әниеңә ничек дип җавап бирербез?

С а р а. Нишлим соң инде мин! Безнең семьяда бер генә дә рәтле кеше юк бит. Әнә Розалия — китү турында уйлап та карамый. Чөнки абыйсы директор. Чөнки ул аны бирердә урнаштырачак. Ә мин!.. *(Елый.)*

Б и б и н у р. Чү, күбәләгем, тынычлан.

С а р а. Шулкадәр институтта укырга теләмәгән идем!

Шулкадәр кермәскә тырышкан идем! Барысына да әнисм белән син гаепле. Имеш, югары белем кызларга бирнә! Имеш, диплом алырга кирәк! Нәрсәгә ул миңа диплом?! Әнә ул! — сезгә булсын. Ә мине калдырыгыз. Теләсәгез ничек калдырыгыз! Мин канавал булып эшләмим!

Бибинур. Җитәр дим, күбәләгем, җитәр. И алла! Нигә бу хәзерге балалар шундый елак булалар икән?!

Әсма белән Гаяз керә.

Әсма *(ишек катындагы диванга утыра)*. Уф, арыдым! Гаяз, су керт әле! *(Гаяз чүмеч белән су кертә, Әсма эчә.)* Уф! Дүрт җирдә булдык. Гаязның танышларына кердек. Аннан замминистрның хатынының туганнан туган абыйсының хатыны янында булдык. Утыз бердә генә ди үзе — миннән дә яшь. Ә карап торырга миннән күп карт.

Сара. Булдымы соң?

Әсма. Әй, кешемени соң ул! Кызыбызны Казанда урнаштыра алсагыз буш итмәбез дип, авызымны ачарга өлгермәдем, күкерт шикелле кабынды да китте. Мине кем дип белдегез, минем гомердә дә андый пычрак эшкә катнашасым юк, мин фәлән дә, мин төгән! Гарьлегемнән җир тишегенә керергә җиттем. Әллә кем булган диярсең — борынын киергән.

Гаяз. Белмәгән кеше турында алай сөйләмә.

Әсма. Сөйләсәм! — өстенә пан-бархат кигәч тә син аны кем дип белдең. Аның бит туганнан туган абзасының сеңелесенең ире генә туз. Бусы шестерка.

Гаяз. Син үз аршиныңа үлчәмә.

Әсма. Фу, каян килгән зур туз!

Гаяз. Һәркем үз урынында зур.

Әсма. Зур булгач, нигә кызыңны Алтайга җибәрәләр соң? Алып каласың калган. Ул да кеше булып сөйләшә, ичмасам. Пешка!

Сара *(каты итеп)*. Җитте! *(Диванга капланып елый.)*

Әсма. Әй, шушының бер гадәтен сөймим: бер нәрсә булды исә еларга тотына. Син менә якынрак кил әле. Беләсеңме, мин нинди план корып кайттым? Сиңа, үскәнем, тормышка чыгарга кирәк.

Гаяз. Әйе. Минемчә, шуннан шәбе юк...

Ә с м а. Әй, «минемчә» дип утырган була тагын. Үземнең башыма килмәсә, кайчан белер идең. Я, үскәнем?

С а р а. Бу бит әллә ничек кенә...

Ә с м а. Берничек тә түгел. Тотасың да чыгасың.

С а р а. Кемгә? Урамга чыгып, миңа кияү кирәк, дип кычкырмассың бит.

Ә с м а. Тфү! Шушы яшьтән шундый хурлыкка төшсәң — шартларсың! Синең поклонникларың кая киттеләр соң әле? Артыңнан көтү булып йөриләр иде бит.

С а р а. Йөрсә! Әллә теге Фәриткә чыгарга кушар идеңме?

Ә с м а. Кайсы ул?

С а р а. Әнә теге, сөйли идем бит әле, өстенә кияргә рәтле костюмы да юк, аның белән кеше арасына чыгарга да оялам дип.

Г а я з. Ә теге лейтенант ничек булыр?

Ә с м а. Әй, ансы да эч пошырып тора, ичмаса. Лейтенант! Ул военныйлар хатын кадерен беләмени! Алма кебек хатыннарын тилмертеп айлар буе командировкада йөриләр.

С а р а. Ул өйләнгән инде.

Б и б и н у р. Ә Мансур?

С а р а. Ул да.

Ә с м а. Нәрсә «ул да»?

С а р а. Өйләнде.

Ә с м а. Һм... Ә Азат турында ничегрәк уйлыйсың?

Б и б и н у р. Кайсы ул, Бибиәсма, теге артистмы? Китсә, артист халкын бер дә мактамыйлар аны.

Ә с м а. Профан!

Б и б и н у р. Профан? Ансы кем тагын? Минем ул егетне күргәнем юк.

Ә с м а. Егет түгел, син ул профан. Тыгылып утырасың, ичмасам. Әйтер идем дә инде... *(Бибинур, хәтере калып, читкә китә.)* Я?

С а р а. Әллә ничек кенә.

Ә с м а. Син аның киләчәген кара, үскәнем. Ул бит берничә елдан татар театрының йолдызы булачак. Мин бу турыда бер генә кешедән ишетмәдем. Шундый талант! Ул сиңа гашыйк түгелме соң?

С а р а. Әйе, ләкин мин аны бик начар беләм. Без нибары өч тапкыр гына очраштык. Аннан мин аңа килмәскә әйткән идем.

Ә с м а. Җүләр син, акыллым (*кабаланып*). Нишлибез инде хәзер?

С а р а. Ул әле тагын килер. Ул шундый үзсүзле. Болай ул миңа ошый да үзе. Ул шундый яхшы танцевать итә!

Ә с м а. Әйтәм бит. Син аның Вронскийны уйнаганын күрсәң иде әле. О, менә ичмаса Вронский! Шундый мөлаем, шундый элегантный. Ә фигурасы. Менә ичмаса фигура! Син аның уйнаганын күргәнең бармы? Юк?!

С а р а. Чөнки мин татар театрын яратмыйм. Ул мине чакырды, ләкин мин бармадым.

Ә с м а. Сарочка! Син аның уйнавын барып күр әле. Ул бит искиткеч уйный. О, «Акыллылык бәласе»ндә чибәр ул. Ул бит бөтен шәһәрнең башын әйләндергән! Мин шикләнмим, ул тиздән лауреат булачак. Бөтен кеше шулай сөйли.

С а р а (*тәэсирләнеп*). Ул миңа үзенең мәхәббәте турында сөйләде. Көлеп үләрсең. Мин дөньядагы кызларны ике группага бүләм. Берсендә син, ягъни мин, ә икенчесендә барлык башка кызлар, ди.

Ә с м а. Шулай булгач.

С а р а. Ах, минем аны бүген үк китерәсем килә.

Ә с м а. Килмәсә, үзең барырсын.

С а р а. Үзем? Ә мин аның кайда торганын да белмим. Бары тик Театральный урамның теге башында торуын гына беләм.

Ә с м а. Театральный урамнын?! Димәк, аның квартирасы театр салдырган яңа йортта! Анда шундый комфортабельный квартиралар, диләр. Нинди шәп булачак! Менә дигән квартирасы, белеме. Алуын да аз алмый торгандыр. Өстәвенә киләчәге. Моннан да кулайракны көндез шәм ягып эзләсәң дә табалмассың.

Б и б и н у р. Бибиәсма! Әле Хәтимә булган иде. Без аңа дүрт меңгә тутырып җибәрдек...

Ә с м а. Шул спекулянткагамы? Кем рөхсәте белән?

С а р а. Мин үзем.

Ә с м а. Син! Гаяз! Гаяз!!! Әллә чукраклана башлаган инде. (*Күрше бүлмәгә кереп китә. Анда аның тавышы.*) Бу нәмәрсәнең кыяфәтен генә күрегез әле. Тор! Тор диләр сиңа. (*Чыга.*) Син монда шундый зур мәсьәлә хәл итәсең. Ә ул диванга утырган да рәхәтләнеп йоклый. (*Гаяз керә.*) Бар, хәзер үк Хәтимәләргә бар да, акчаны алып кайт. Дүрт мең.

Г а я з. Нәрсә әйтим?

Ә с м а. Берни дә әйтмә.

Б и б и н у р. Әллә үзем генә барып кайтыймы, Бибиәсма? Қияү арыгандыр.

Ә с м а. Нишләп арыган ди ул, тик йөрепме? Нәрсә тырпаеп торасың? Бар! *(Гаяз китә.)*

Б и б и н у р. Қияүне артык рәнҗетәсең, Бибиәсма. Чәй эчкәч тә өлгерер иде әле.

Ә с м а. Бик эчәсе килсә, әнә урамда морс эчсен. Қичә генә биш сум акча бирдем. Хайван! Декан була торып, үз кызын урнаштыра алмады. Самовар кайнаганмы?

Б и б и н у р *(кабаланып)*. Хәзер, су гына апчыгам да тергезеп җибәрәм. *(Чыга. Артта чиләк тавышы.)*

Ә с м а. Азат бүген килмәсә, иртәгә үзең барырсың.

С а р а. Әллә ничек кенә.

Ә с м а. Менә Алтайга китеп барсаң, әллә ничек булмас. Башка юл юк. Тормышка чыксаң — каласың, чыкмасаң — юк.

С а р а. Ул бит бала гына.

Ә с м а. Үсәр әле.

С а р а. Мин аны яратмыйм да.

Ә с м а. Юк нәрсә. Мәхәббәт белән мәңге яшәмиләр. Мәхәббәт кыз вакытта бушка театрга йөрү өчен генә кирәк, ә тормыш өчен анда күп җәбәлә юк. Менә безгә генә кара — яшибез бит *(көзге алдына килә)*. Газизә ханым шундый матур күлмәк кигән! — шундыйны беренче күрүем. Җиңнәрен күрсәң! *(Көзге алдында боргалана.)* Күр инде бу күлмәкне! — капчыкмыни. Бөтен фигураны бозып күрсәтә *(канәгатьләнеп)*. Ул миңа нибары утыз биш яшь бирде.

С а р а. Кем инде ул?

Ә с м а. Газизә ханым. Аның фигурасы шулкадәр шыксыз! Ә балалары — детдом диярсең. Аңламыйм, нәрсәгә дип кешеләр бишәр бала табалардыр? Бала күтәрү фигураны боза ич ул.

Ишек шакыйлар.

С а р а. Бу ул, Азат! Ишек шакуыннан таныдым.

Ә с м а. Ну, хәзер барысы да үзеңнән бәйле. Яхшылап сөйләш — бер атнадан туй ясарлык булсын. Қара аны, башка кандидат юк. Керегез!

А з а т керә.

А з а т. Исәнмесез!

Әсма. О, менә кем икән ул! Исәнмесез, алтыным, исәнмесез. Узыгыз. Яратам да инде шушы егетенне, Сара, бөтен иптәшләрең арасында шушысын аерып яратам. Ах, күрегез зинһар, киемен генә күрегез! Бар, үскәнем, тизрәк өстеңне алмаштырып чык *(Сара, Азатка баш иеп, курше бүлмәгә китә).* Утырыгыз. Я, утырыгыз инде, ялындырмагыз.

А з а т. Рәхмәт, мин озакка түгел.

Әсма. Ул ни дигән сүз тугыл! *(Сара киткән бүлмәгә ишарәләп.)* Атна буе күзен тәрәзәдән алмады. Сезне көтте.

А з а т. Мине?!

Әсма. Ә кемне булсын! Я, мин кызымның серләрен ачтым бугай. Театрга барабыз дидегезме?

А з а т. Әйе.

Әсма. Ах, мин дә театр яратам. Гомумән театр дөньясы кешеләрен. Бүген нәрсә бара?

А з а т. Бүген «Отелло»ның премьерасы. Бәлки, сезгә дә билет кирәктер?

Әсма. Ә аның музыкасы бармы соң?

А з а т. Юк.

Әсма. Биюләре дә юкмы?

А з а т. Биюләре дә юк.

Әсма. Алайса, ул күңелле түгелдер шул. Мин музыка яратам.

А з а т. Димәк, опера тыңларга яратасыз?

Әсма. Бик тә. Мин гомумән музыка яратам.

А з а т. Ә «Аида»га билет алдыгызмы?

Әсма. «Аида»га? Без аны карап төштек инде.

А з а т. Гастролер килә бит.

Әсма. Барыбер. Бер үк әйберне әллә ничә кат карау күңелле түгел ич ул!

А з а т. Яхшы музыканы тыңлаган саен тыңлыйсы килә.

Әсма. Юк, мин алай яратмыйм. Бервакыт шулай «Кармен»ны ике кат карарга туры килде; Москвага баргач. Испан композиторы Вердин музыкасы. Иптәшем барыйк дип тәмам теңкәмә тиде. Ә ул минем шундый кире! Сер итеп кенә әйтәм, кире булмагыз — кызлар кире егетләрне яратмыйлар. Нәрсә сөйли идем әле? Ә, «Кармен» турында икән. Мин гомумән бер пьесаны

ике кат карарга яратмыйм. Нәрсә буласын белеп утыргач, күңелле түгел ич ул. Әле ярый, тегениләре шәп иде. Э..., кем соң әле, Карменны яратучы?

А з а т. Хозе!

Ә с м а. Ийе, үгезләр сугыштыручы.

А з а т. Ә, алайса, Эскамильо инде.

Ә с м а. Ийе, шулай бугай шул. Әле ярый шул артист шәп уйнады. Менә ичмаса фигура! Шундый элегантный... *(Сара керә.)* Гафу итегез *(китә).*

Пауза.

А з а т. Сез бүген беркайчан да булмаганча матур.

С а р а. Чынлапмы?

А з а т. Билләһи менә *(пауза).* Күрәсез, тагын килдем. Сез килмәскә куштыгыз, ә мин килдем...

С а р а. Кирәкми ул турыда.

А з а т. «Отелло»га барабызмы?

С а р а. Мин бармыйм.

А з а т. Бүген премьера.

С а р а. Булса бит.

А з а т. Нигә сез шундый, Сара?

С а р а. Нинди бар.

А з а т. Сез миңа карата артык мәрхәмәтсез. Ни өчен, Сара? Юк, сезнең күзләрегез сүзләрегезгә караганда күбрәкне вәгъдә итә. Сез...

С а р а. Беләсезме, миңа син дип кенә эндәшегез.

А з а т. Әгәр рөхсәт итсәгез?

С а р а. Әйтегез, мин рөхсәт итәм.

А з а т. Их, Сара! Син мине яратсаң иде дә...

С а р а. Шуннан нәрсә булыр иде?

А з а т. Шуннанмы? Минем бөтен тормышым тоташ бер бәйрәмгә әйләнер иде *(Сара чыркылдап көлә).* Чынлап, Сара.

С а р а. Ә нигә ашыгырга! Минемчә, бәйрәм көтү начар эш түгел.

А з а т. Дөрес. Бәйрәм иртәсен көтү бәйрәм итүдән күңеллерәк. Серләреннән төннең алҗысаң, мәһабәтрәк була алсу таң *(пауза).* Сара!

С а р а *(назланып).* Нәрсә? Ә?

А з а т. Ох бу күзләр!

С а р а. Сез комплиментларга оста. Мин моны күптән беләм.

А з а т. Ә нигә инде «сез»?

Сара. Ах, мин онытканмын *(кечерәк пауза)*. Азат, син мине яратасыңмы?

Азат. Күргәнеңчә.

Сара. Ә син әйт. Нигә, сиңа читенмени?

Азат. Яратам. Яратам, Сара.

Сара. Бик тә?

Азат. Бик тә.

Сара. Ә миңа син ышанасыңмы?

Азат. Көләсез.

Сара. «Көләсез» түгел, «көләсең». Без бит килештек.

Азат. Барыбер. Сара, нигә син мине газаплыйсың?

Сара. Син үзең газаплангач, мин нишләтим.

Азат. Син үзеңне беркайчан да яратмаган кеше кебек тотасың.

Сара. Әйе, мин беркайчан да яратмадым.

Азат. Ышанмыйм.

Сара. Чынлап, чынлап.

Азат. Беркайчан да?

Сара. Беркайчан да.

Азат. Беркемне дә?

Сара. Әйе.

Азат. Хәзер дә яратмыйсыңмы?

Сара. Юк.

Азат. Ә мин күптән түгел бер роман укыдым. Анда хатын-кыз йөрәге мәхәббәтсез яшәми диелгән. Әгәр бу дөрес булса, синеке дә яратырга тиеш. Сара, ярат мине! *(Сара көлә.)* Көләсең. Мәхәббәттән көләсең!

Сара. Кайвакыт син чыннан да көлке буласың. Юк, юк, бүген түгел. Киресенчә, бүген син миңа ошыйсың. *(Азатның чәчләре белән уйный.)* Азат! Бел, мин нәрсә турында уйлыйм?

Азат. Син мине җүләр дип уйлыйсың.

Сара. Юк.

Азат. Минем яратуыма ышанмыйсың.

Сара. Юк.

Азат. Алайса, белмим.

Сара. Ә син бел.

Азат. Юк, белмим.

Сара. Алайса, мин үзем әйтәм. Беләсеңме, Азат, мин хәзер генә сине яратам бугай дип уйладым.

Азат. Кабатла, тагын бер генә кабатла, Сара!

С а р а. Я-ра-там. *(Азат Сарага текәлеп карый.)* Әнә бит син нинди! Әйтеп өлгермәдем — үбешергә дә үреләсең.

А з а т. Кичер, Сара, мин ялгышлык белән. Сара — мәхәббәтем минем. *(Оялып күзләрен каплый.)*

С а р а. Азат, әйт әле, син мине һаман да яратырсыңмы?

А з а т. Үлгәнче.

С а р а. Әгәр икенчене яратсаң?

А з а т. Юк, мин сине генә яратырмын. Минем өчен дөньяда син генә яшисең.

С а р а. Азатик! Шулай дип әйтергә ярыймы? Ә сиңа, Азатик, ничә яшь?

А з а т. Унтугыз.

С а р а. Чынлапмы? Син әле бөтенләй бала икәнсең.

А з а т *(ошатмыйча)*. Мин? Бала?!

С а р а. Юк, юк, бала түгел. Егет. *(Азатка сыена.)* Хыялым минем.

А з а т. ?!

С а р а. Әйе, син минем бердәнбер хыялым.

А з а т. Синең бердәнбер хыялың! Дөресме бу? Хыялланмаган идем. Минем белән театрга барырсың я булмаса йөрәк моңнарымны тыңларга иренмәссең дип хыялланган идем. Ләкин мондый сүзләрне ишетү турындагы уй башыма да килмәде. Синең бердәнбер хыялың! Дөресме бу?

С а р а. Ә нигә, мин дә синең хыялың түгелмени?

А з а т. Ялгышмыйсың, сөеклем.

С а р а. Һәм бердәнбер. Шулаймы?

А з а т. Алай ук түгел, билгеле...

С а р а. Ничек?

А з а т. Юк, андый хыяллар синең үзеңдә дә күп.

С а р а. Юк, минем бер генә хыялым бар. Һәм ул хыял — син.

А з а т. Ләкин синең башка хыялларың да бар.

С а р а. Минем бер генә хыялым бар. Синеке булу. Ә кем ул синең икенче хыялың?

А з а т. Юк, ул кеше түгел...

С а р а. Азатик дим, я, сөйлә инде.

А з а т. Минем театраль институт бетерәсем килә.

С а р а *(аптырап)*. Син бетермәдеңмени?

А з а т. Юк, мин училище генә бетердем.

С а р а. Ах, тукта (*йөрәген тота*). Ә нигә син, Азат, институтка китмәдең?

А з а т. Ничек әйтим инде? Туры килмәде.

С а р а. Азат, дим, сөйлә инде.

А з а т (*бераздан*). Материаль шартлар мөмкинлек бирмәде (*пауза*). Ләкин мин институт бетерәчәкмен. Барыбер бетерәчәкмен.

С а р а. Шушы синең хыялыңмы инде?

А з а т. Әйе. Аннан мин сәхнәдә үзебезнең замандашыбызны уйнарга хыялланам.

С а р а. Ә сиңа хәзерге пьесалардан роль бирмиләрме?

А з а т. Юк, мин андый образлар турында түгел, ә чын образ турында, кешеләрне дулкынландырырлык образ турында хыялланам. Аны караганда кешеләр көлсеннәр һәм еласыннар, шатлансыннар һәм горурлансыннар.

С а р а. Хыялый син... минем (*кечерәк пауза*). Азат, синенчә, без кайчан бергә тора башларбыз? Дөресрәге, мин кайчан туй ясарбыз димәкче идем.

А з а т (*төшенмичә*). Мин..., турысын гына әйткәндә, мин ни дип әйтергә дә белмим. Мин бүген бөтенләй көтмәгән идем. Мин хәтта уйламаган да идем...

С а р а. Икеләнмә (*пауза*). Ах, мин ничек берүзем яшәрмен!

А з а т. Ничек?

С а р а. Шулай. Тиздән минем бөтен институт дусларым таралып бетәчәкләр. Мин берүзем калачакмын.

А з а т. Ә син китмисеңме?

С а р а. Юк. Дөресрәге, мин теләгән идем Алтайга, ләкин мине җибәрмәделәр. Мине аспирантурада калдыралар.

А з а т. Нинди шәп!

С а р а (*чыркылдап*). Әнием, нигә кияүгә чыкмыйсың, бөтен дус кызларың чыкты, дип сукрана. Чынлап шулай, минем бөтен дус кызларым тормышта. Мин бөтенләй артта калдым.

А з а т. Алайса, күптән чыгарга кирәк булган.

С а р а. Кирәк тә бит, алучы юк. Мин шундый начар...

А з а т. Тыйнакланма.

С а р а. Юк, чынлап (*пауза*). Ах, бездә шундый күңелсез! Мин рәхәтләнеп берәр җиргә күчәр идем. Белә-

сенме, кайвакыт тору урынын алмаштыру да нервная системага яхшы тәэсир ясый.

Азат. Борчылма, Сара. Тиздән без бергә тора башларбыз. Озакламый минем квартирам булачак...

Сара (*шаккатып*). Синең квартираң юкмыни?

Азат. Әлегә юк. Ләкин тиздән булачак. Миңа вәгъдә итәләр.

Сара (*йөрәген тотып*). Ах, йөрәгем. Юк, юк, ул болай гына. Мин хәзер, әниемнең микстурасын эчәм дә басылыр. Гафу ит, зинһар. (*Әсма киткән бүлмәгә чыгып, шактый озак торып керә.*) Ә син кая торасың, Азатик?

Азат. Абыйларда.

Сара. Синең абыең да бармыни әле? Кем ул?

Азат. Әллә белмисеңме? Ул да артист. Без икебез дә бер театрда уйныйбыз. Һәм без бер-беребезгә шундый охшаганбыз...

Сара. Ә мин белми идем.

Азат. Әйе. Хәтта директор әйтә, киләсе сезонда Шекспирның «Хаталар комедиясе»н куябыз ди...

Пауза.

Сара. Азат! Әлегә син бездә дә тора алыр идең.

Азат. Беләсеңме, минемчә, син минем белән шаярасың гына.

Сара. Шаярам? Телисеңме? Үбәм (*үбә*).

Азат (*Сараны кочаклый*). Сарам минем! Әгәр яңа елга квартира бирсәләр...

Сара. Ах, йөрәгем...

Азат. Бәлки, тагын микстура...

Сара. Юк, юк, бетте, узды. Ләкин син мине шундый авырулы дип уйлый күрмә тагын. Ул минем бүген генә.

Азат. Әйдә, урамга чыгыйк, саф һавага.

Сара. Юк, кирәкми. Өйдә генә утырыйк (*пауза*). Беләсеңме, Азат, тыйнаксызлыгым өчен гафу ит. Мин беләм, ирләр кызларның тыйнак булганын яраталар. Ләкин мин бүген әйтергә тиешмен. Без, Азат, дөресрәге безнең туй, шушы атнада ук булырга тиеш. Беләсеңме ни өчен? Чөнки минем дус кызларым белән соңгы мәртәбә күңел ачасым килә. Син моңа ничек карыйсың?

Азат. Бөтенесе шундый тиз, көтмәгәндә булды. Төштәге кебек. Мин хәтта ышанып та житмим.

Сара. Ышан, иркәм. Мин сине, бары тик сине генә яратам.

Азат. Минем әле туй өчен акчам да юк...

Сара. Азатик, ничек оялмыйсың? Синдә искелек калдыгы!

Азат *(уйлап)*. Ярый, киңәшеп карармын.

Сара. Кем белән?

Азат. Абый белән.

Сара. Бичара! Бәлки, син кызлар янына да абыең белән генә йөрисеңдер. Ә минем янга сине әниең озата килмәдеме?

Азат. Минем әнием юк.

Сара. Юк? Я, сөйләшмик ул турыда. Ярыймы? *(Кечерәк пауза.)* Азатик, миндә идея! Безгә хәтта бергә торуның кирәге дә юк. Башта, әлбәттә. Беләсеңме, без язылышып кына куябыз. Һәм беркемгә бер сүз әйтмибез. Шәп бит? *(Азатның күкрәгенә сыена.)* Мәхәббәтем минем! Минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем. Беренче очрашуны хәтерлисеңме? Сез концерт белән безнең институтка килдегез. Азактан танцылар булды. Шунда без таныштык һәм бөтен кич буе бергә биедек. Соңыннан син мине озата бардың. Моңа инде ике ай вакыт үтеп китте. Мин ике ай газапландым! Ләкин мин сине аннан элек тә белә идем. Һәм мин сине беренче күрүдә үк яраттым.

Азат. Ә бу күптәнме булды?

Сара. Беренче мәртәбә мин сине сәхнәдә күрдем. Син искиткеч оста уйныйсың.

Азат. Син мине беренче мәртәбә нинди спектакльдә күрдең?

Сара. «Анна Каренина»да.

Азат. «Анна Каренина»? Ләкин ул спектакльдә мин катнашмыйм.

Сара. Ах, мин алай әйтергә теләмәгән идем... Мин әйтергә теләгән идем «Акыллылык бәласе»ндә дип. Чацкий ролендә?! Хәтерендәме, «Карету мне, карету!»

Азат. Ләкин Чацкийны мин түгел, минем абый уйный. Вронскийны да ул. Безнең фамилияләребез дә бертөрле.

Сара. Чыннан да, кайда күрдем соң мин сине...

Азат. Син мине «Галиябану»да күрдеңме?

Сара. Юк.

Азат. Ә «Ромео һәм Джульетта»да?

Сара. Юк әле.

Азат. Туктагыз! Ләкин мин башка бер спектакльдә дә уйнамыйм. Сез мине кайда гына күрдегез соң?

Сара. Ах, минем әчәсем килә. Әйдә, чәй эчик!

Азат. Минем килми.

Сара. Азатик дим, әйдә инде!

Азат. Рәхмәт, минем эчәсем килми.

Сара. Алайса, син мине гафу ит. Мин хәзер. Ә син альбом карый тор. *(Азатка альбом биреп чыгып китә.)*

Азат. Бөтенесе төштәге кебек. Әллә алдаша инде шунда *(альбом карый)*. Менә бит ул. Юк, мондый күзләр алдашырга тиеш түгел. *(Альбом эчендәге дипломны күрә.)* Диплом! Нинди матур! Сара инде институт бетергән. Ул нинди бәхетле! Юк, мин аңа лаек булырга тиеш. Мин дә укыячакмын. Минем дә шундый дипломым булыр. *(Диплом арасындагы направлениены күрә.)* Направление. Алтайга? Аңламыйм.

Бибинур чыга.

Бибинур. Нигә чәй янына утырмыйсың, улым?

Азат. Мин аш яныннан гына торып килдем, әби.

Бибинур. Аш ашка, урыны башка дигән борынгылар. Бер чынаяк чәйгә генә урын табыла ул. Әле шул диплом дигәннәрен карап утырасыңмыни?

Азат. Әйе, шуңа кызыгып утырам.

Бибинур. Болай матур инде ул үзе. Тик менә ул матур нәрсәнең арт ягы такыр икән шул.

Азат. Ничек?

Бибинур. Алтайны әйтәм, шундый җәһәннәм аръягына җибәрерлек булгач, аның матурлыгы пычагыма кирәкме! Ярый инде, ходайның рәхмәте белән, озакка сузмый гына язылышып куйсагыз, кияведнән аерып җибәрә алмаслар, алла теләсә. Кияүдәгеләргә бәйләнә алмыйлар, ди бит.

Азат *(аптырап)*. Сараның Алтайга китәсе килмимени?

Бибинур. Кемнең инде ата-анасын, туып-үскән, канат чыгарган өен ташлап, җир кырыена китәсе килсен! Шул Алтай зәхмәте чыккач, бәбкәм, ябыгып ук китте.

Бибинур китә.

Азат. Алтай. Алтай! Менә ни өчен ул язылышырга ашыга! Алтайга китмәс өчен. О, бу хакта уйлавы да куркыныч. Ул мине яратмый. Яратмый! Ә нинди оста уйный! Юк, яхшы актерлар тормышта сәхнәдәгедән күбрәк. Ә мин, мәхәббәтеннән күзе тонган җүләр, чак кына ышанмадым. Мәхәббәт! Кайвакыт син сукырларның да күзен ачасың, ә кайвакыт! — күзлеләрне күзсез ясыйсың. *(Сара чыга. Кулында шампанское бутылкасы.)* Тагын бер сүз һәм мин аның чын йөзен күрәчәкмен...

Сара. Азатик! Менә шуны гына ачып бир әле. Аннан соң керәбез, яме?

Азат. Рәхмәт.

Сара. Югыйсә әнием үпкәли.

Азат. Ә син әйт, аның әчәсе килми диген.

Сара. Мин дә.

Азат. Нәрсә син дә?

Сара. Үпкәлим.

Азат. Сара, әйт әле, син аспирантурада кайсы кафедрада каласың?

Сара. Мин..., ә... бу сине кызыксындырамыни?

Азат. Әлбәттә.

Сара. Биохимиядә.

Азат. Үзең дөньяда иң яратмаган нәрсәм химия дигән идең.

Сара *(чыркылдап көлә)*. Шулай дигән идеммени? Хәтерләмим. Әйдә!

Азат. Юк, мин кермим.

Сара. Кире беткән... ем минем!..

Азат. Сара! Мин сиңа әйтмәгән идем. Мин бит Алтайга китәм. *(Соңгы сүзләрдән соң Сара кулындагы бутылканы төшереп җибәрә.)* Сезгә ни булды? Әллә сезне Алтай куркытамы?

Сара. Ә, юк, киресенчә, мин үзем дә теләгән идем. Ләкин бу мөмкин түгел. Мине аспирантура җибәрмәячәк.

Азат. Уйнамагыз! Чөнки барыбер ышандырырлык чыкмый. Сез тамаша барганда мыегын югалткан актер кебек. Әйтегез әле, бүгенге уен нигә кирәк булды? Алтайга китмәс өченме? Сез бит мине яратмыйсыз.

Сара. Юкны сөйләмә, Азат. Мин сине яратам.

Азат. Яратасыз? Ә дәлилегез бармы?

Сара. Бар!

А з а т. Загска барып языламы? *(Тавышка Бибинур белән Әсма чыга.)* Юк, бу дәлил түгел. Сез мәхәббәтегезне башка дәлил белән исбатлагыз.

С а р а. Ә ничек? Я, әйт, Азат, ничек?

А з а т *(Сараның путевкасын сузып)*. Алтайга китеп.

С а р а. Ах, нервада уйнама, Азат! Мин сине яратам. *(Йөрәген тотып.)* Ах, йөрәгем...

А з а т. Йөрәк басылыр. Әниегезнең микстурасын эчегез. Хушыгыз! *(Соңгы сүзләрне әйткәндә Гаяз керә. Азат китә. Барысы да Гаязга карыйлар.)*

Г а я з. Хәтимәдә булдым. Аны спекуляциядә гаепләп кулга алганнар. Өйләрендә тенту.

П ә р д ә.

1954

ЧУЛПАН

Интеллигент яшьләр тормышыннан драматик сценалар.

Дүрт пәрдәдә, алты күренештә, пролог белән.

КАТНАШАЛАР:

Чулпан
Илдар
Марзия
Вилдан
Гомәр
Гөлназ
Фатыйма
Шәмсебану
Фәридә
Шамил
Хат ташучы

Пролог.

Зур йортның капка төбе. Көз. Баганадагы сәгать төн уртасын күрсәтә. Җил. Яңгыр. Тоныкяктыртылган тротуарда саргайган яфраклар. Подъездда яңгырда чыланып беткән Чулпан. Ул борчулы, тирә-якны күзәтүеннән кемнедер көтүе күренә. Вилдан керә.

Чулпан *(каршы төшеп)*. Вилдан!

Вилдан. Чулпан? Безнең капка төбендә, шундый соң!

Чулпан. Мин сине көтәм. Мин синең кайтканыңны ишеттем. Исәнме!

Вилдан. Исәнме.

Пауза.

Ч у л п а н. Мин көттем сине. Өйгә килерсең дип көттем. Монда кер, чыланасың. Нишләп килмисең? Күптән кайттыңмы?

В и л д а н. Кичә..., өченче көн.

Ч у л п а н. Син кайда булдың?

В и л д а н. Мин... менә монда, берәүләрдә... Көннәр бозылып китте, ә. Иртәдән бирле ява... Ярый, мин килермен, Чулпан.

Ч у л п а н. Иртәгә?

В и л д а н. Әйе. Вакыт булса...

Ч у л п а н. Аптырыйм мин сиңа. Элек «янымда син булганда, үземдә таулар җимерерлек көч сизәм», дия идең. Ә хәзер миннән качасың.

В и л д а н. Сабыр ит, Чулпан...

Ч у л п а н. Мин болай да сабыр итәм... Башта институтны бетерим дидең. Аннан минем дә укып бетерүемне теләдең. Менә мин бетердем. Врач булдым. Ә син тагын...

В и л д а н. Өйләнә алмыйм мин хәзер, Чулпан. Хәзер мине бер генә нәрсә борчый: диссертация.

Ч у л п а н. Ә кайчан яклыйсың?

В и л д а н. Язын.

Ч у л п а н. Димәк..., шуннан соң...

В и л д а н. Әйе.

Пауза.

Ч у л п а н. Элеккечә яратмыйсың син мине. Үзгәрдең, үзгәрдең син хәзер...

В и л д а н. Нишлисең бит. Tempora mutantur et nous mutamur in ilis *.

Ч у л п а н. Хәтереңдәме, Вилдан, Кабан күле буенда, теге зур тал төбендә утырган чаклар? Без шунда, йолдызлар белән чуарланган су өстенә карап, киләчәк турында хыялланырга ярата идек. Исеңдәме? «Әнә Чулпан йолдыз. Ләкин таң аткач, ул сүнәчәк. Ә син минем мәңге сүнмәс Чулпаным». Бу бит синең сүзләрең... *(пауза)*. Синең күңелең дә сүрелгәч, мәхәббәт юк нәрсә микәнни соң ул, Вилдан? Чын мәхәббәт китапларда гына була микәнни?

В и л д а н. Нигә? Мәхәббәт бар ул.

---

* Латинча — Заманалар үзгәрәләр, алар белән без дә үзгәрәбез.

Ч у л п а н. Мин бит синең Чулпаның, Вилдан, синең мәңге сүнмәс таң йолдызың. Я әйт. Күзләремә кара да әйт; алар элеккечә үк диңгез кебек тирән, күк төсле зәңгәр түгелмени?

В и л д а н. Хәтерең калмасын. Үзара гына әйткәндә, алар шактый уйсыз һәм мәгънәсез. Алар бернәрсәне дә аңлатмыйлар.

Ч у л п а н. Ә бу куллар? Алар да элеккечә йомшак түгелмени?.. Син бит ярата идең, Вилдан! Күңелең сүрелүгә нәрсә сәбәп?

В и л д а н. Син үзең гаепле, Чулпан. Мин сине яраттым. Институт бетергәч, аспирантурага керерсең, диссертация якларсың, кыскасы, минем идеалларымны аңлаучы юлдашым булырсың дип көттем. Ә синең бөтен башың шул чигешләрең, мулине җепләр белән тулы. Син гәүдәң белән медицинада, ә йөрәгең, күңелең белән әллә кайда йөрүче бер, извини за выражение, буш кыз. Син мине гафу ит, ләкин...

Ч у л п а н. Әйтеп бетер. Әйтеп бетер.

В и л д а н. Димәк, аспирантурага кермәдең? *(Чулпан башын селки).* Һәм җүләрлек эшләгәнсең.

Ч у л п а н. Мин анда нишлим! Фәнни эшкә минем сәләтем юк. Ләкин син әйтеп бетер. Яратмыйсың икән — яратмыйм диген. Аспирантура да фәлән дип сөйләнмә. Без бит килешкән идек. Әгәр кайчан да булса беребез яратмый башласа — яшермәскә, туп-туры әйтергә дип килешкән идек. Яшермә, барын да әйт.

Кечерәк пауза.

В и л д а н. Турысын гына әйткәндә, безнең юллар аерыла, Чулпан. Безгә бу эшкә нокта куярга кирәк. Теләсәң — дуслар булып калырбыз. *(Кечкенә пауза. Чулпанның терсәгеннән тотып.)* Әйдә, озатып куям.

Ч у л п а н *(кулын тартып алып).* Рәхмәт. Рәхмәт, мин үзем.

Берничә секунд хәрәкәтсез торганнан соң, Ч у л п а н китә. В и л д а н подъездга кереп югала. Җил һәм яңгыр котырына. Һавада саргайган яфраклар оча. Кайдандыр күңелле, дәртле музыка авазы килә.

П ә р д ә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

1 КҮРЕНЕШ

Чулпаннарның пөхтә җыештырылган өе. Радиода бик моңлы итеп җырлаган «Яз да була» көе ишетелә.

Чулпан һәм Фатыйма.

Яз да була, көз дә була,
Су читләре боз була.
Яшь чагында кемне сөйсәң, —
Күңелең шуңарда була.

Чулпан *(радионы өзә)*. Иртәдән бирле әллә нинди эчпошыргыч җырлар тапшыралар. Әллә инде Сабан туе көне икәнен дә онытканнар. Шприц кайныйдыр. Әйдә, ясыйк *(шкафтан бер тартма алып, ачып карый)*. Глюкозаң беткән. Алып кайтыйм әле.

Фатыйма. Акча да азайгандыр инде анда. Әллә сабыр итәсеңме?

Чулпан. Монда бар әле, әнкәй. Иртәгә пенсияңне дә китерерләр.

Чулпан чыга. Фатыйма радионы тоташтыра да түбенә үк утырып тыңлый.

Ишеттем мин кичә берәү җырлый,
Чын безнеңчә матур милли көй;
Әллүки, бәллүки,
Чын безнеңчә матур милли көй.
Түзәлмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Әллүки, бәллүки,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, әллүки!»
Әллүки, бәллүки,
«Бу көй була, диде, әллүки!»

Илдар керә.

Илдар. Исәнмесез!

Фатыйма *(радионы өзеп)*. Әйдүк, Илдар, узыгыз. Сау гына йөрисезме?

Илдар. Бик йотылып тыңлый идегез бугай. Бүлдердем.

Фатыйма. Зарар юк. Беткәндер инде, сәгать унике. Чыгып йөри алмыйм. Шулай өйдә генә тыңлап уты-

рам. Карагыз, утырыгыз инде, узыгыз. *(Илдар утыра.)* Марзия җырлады. Килештереп тә җырлый соң шул! — үзәкләрне өздереп ала.

Илдар. Марзия апа җырласа, җиренә җикерә инде ул. Чулпан кайда соң әле?

Фатыйма. Хәзер кайтып җитәр. Әптиккә киткән иде, глюкоза алырга, бер бетәшмәс авыру булдым инде.

Илдар. Глюкозаның файдасы бармы соң?

Фатыйма. Азрак бар.

Илдар. Азрак булгач, ярар. Авыруны потлап килә, мыскаллап китә, диләр бит.

Фатыйма. Китмәде ахры шул инде. Китәсе булса — унбиш елдан бирле мыскаллап та китеп бетәр иде. Инде мин эчкән дару! — юри-мырый әйткәндәй, пот кына түгелдер. Үлеп кенә китәсе бар да бит.

Илдар. Менә тагын!

Фатыйма. Туйдым кем, улым Илдар. Бу авырудан ничек туйганымны бер ходай гына белә. Таш ватарга, җир казырга риза, сәламәтлегем булса.

Илдар. Терелерсез әле, Фатыйма апа. Кызыгыз врач.

Фатыйма. Кызганам, Илдар, Чулпанны кызганам. Тормышларны алып бару җиңел түгел. Берүзе эшли. Бар тапканы даруга китеп бетә. Кыз кешенең чибәррәк киенеп йөрисе дә киләдер, киносына, театрына барасы да...

Илдар. Җайланыр әле. Менә Чулпанны кияүгә биреп куйсагыз, икәүләп эшли башласалар...

Фатыйма. Бер һәйбәт кенә кешегә чыгып, матур гына тора башлауларын күреп үләсем бик килә дә бит...

Марзия белән Чулпан керә.

Чулпан. Сез иртәләгәнсез, Илдар.

Илдар. Сәгать беренче. Сабан туеның кызган чагы.

Чулпан. Ә Гөлназлар һаман юк. Илдар, кереп чыгыгыз үзләренә. Китеп бармасыннар.

Илдар. Яхшы. *(Китә.)*

Чулпан. Утыр, Марзия апа. Мин әнкәйгә укол гына ясыйм.

Марзия. Ярый, ярый. Нихәл, Фатыйма апа, сәламәтлегең ничек?

Фатыйма. Ару гына. Үзең нихәл, артистка булып буламы?

Марзия. Белмим инде. Халык ярата кебек болай.

Фатыйма. Оста җырлыйсың. Борынгы көйләрне җырлый башласаң — халыкның бөтен үткәне, кайгысы-хәсрәте, моңы-зары күз алдына килә дә баса. Тавышың моңлы синең. Эчеңдә ниндидер моңың бар ахры.

Марзия. Дөнья булгач, төрле чак була инде. Моңайган чак та була. Әле менә апаларга кергән идем, Салават белән уйнап утырдым...

Фатыйма. Беләм, беләм, бик сөйкемле бала.

Марзия. Гаҗәп инде, һич кенә дә белмәгәне юк. Шулай, минем кайчан шундый матур балам булыр икән дип, уйланып утыра идем,— килде дә ике тезем не кочаклап: «Тәти апам, син нигә күңелсез, нәрсә турында уйлыйсың, тәти апам?»— ди. Каттым да калдым. Уйлаганны белә бит — өч яшьлек бала!

Фатыйма. Аптырама. Хәзерге балалар туганда ук җидееллык белем белән туа.

Марзия *(көлеп)*. Әллә шулай инде.

Чулпан *(икенче яктан)*. Әнкәй, кил!

Фатыйма чыга. Пауза. Чулпан керә.

Чулпан. Глюкоза ясадым. Кан басымы бик югары.

Марзия. Әйдә, терелт инде. Үз анаң. Әле нигә бик сөмсереңне койдың?

Чулпан. Әллә нәрсә генә, Марзия апа. Сабан туена да чыгасы килми.

Марзия. Фатыйма апа өченме?

Чулпан. Юк. Аның өчен мин күп җыладым. Инде күндем. Хәзер инде үлсә дә җылый алмам төсле.

Марзия. Вилданны юксынасыңмы? Файдасызга бит, Чулпан. Өйләнгән кеше өчен...

Чулпан. Ярата иде бит ул. Шундый ярата иде!

Марзия. Күрәсең, яратуы чаклы булган. Бергә укыганда яраткан. Аерылышкач — оныткан. Мәхәббәт өчен аерылышуны шулай диләр бит аны, ут өчен җил кебек, диләр. Көчлерәк янганын куәтләтә, пыскып кына ятканын сүндерә.

Чулпан. Күпме йөрдек! Мин икенче курста укый идем. Ул дүртенчедә. Марзия апа, әйт әле, бәгырем, әгәр дөньяда мәхәббәт дигән нәрсә булса һәм ул мине яратса, аспирантурага кермәвем өчен генә ташлар идемени?

Марзия. Ташламас иде. Чын мәхәббәт белән яратса, әлбәттә.

Чулпан. Бәйрәм бүген. Халык күңел ача. Ә минем күңелемдә сагыш, сагыш, сагыш. Юк, Вилданны яратудан түгел — инде мин аны онытгым диярлек. Үткәндәге бәхетле минутларны сагынудан. Яшәү шундый күңелле иде! Төннәр буе без шәһәр урамнарында йөри идек һәм шулай икәү, терсәккә терсәк куеп, кулга-кул тотышып, мәхәббәтебез яктырткан сукмак буйлап, бөтен гомеребезне үтәрбез кебек иде... Кайчак юри шат күренергә тырышам. Елмаям, көләм. Ләкин шул елмаю астында нинди әрнү ятканын берәү дә белми...

Артта шаулашкан тавыш ишетелә. Илдар, Гомәр, Гөлназ керә.

Гомәр. Исәнмесез, саумы сез, сәламәтме сез!..

Чулпан. Узыгыз, утырышыгыз.

Марзия. Шул мыегыңны кырып ташлачы, Гомәр. Бер килешми.

Гомәр. Гөлназ кушмый. Мыексыз үбешү тозсыз аш кебек, ди.

Гөлназ. И, әйтер идем дә инде,— бер юлга калып торсын.

Марзия. Чынлап. Озын борынлы кешегә мыек килешми бит ул.

Гомәр. Син инде минем борынга тимә, яме. Кызлар минем шул борынымнан һуштан язалар да.

Гөлназ. Җүләр дә соң инде! Көрәшкә кичекмибезме?

Чулпан. Көрәш дисәң — дөньяңны онытасың инде син.

Гомәр. Берәр җирдә сугышалар дисәң бигрәк тә. Карап тору өчен акча түләр *(киная белән)*. Ишеттегезме? Америкада хатын-кызлар өчен футбол командасы төзелгән. Тиздән бездә дә булачак. Гөлназ теләгенә ирешә. Центр нападения булачак.

Гөлназ *(җитди)*. Гомәр!

Чулпан. Бер Гөлназ бишкә ярылмас инде. Йөгерекләр секциясенә дә йөри.

Гомәр. Ташлады шул ул.

Гөлназ. Сезгә сөйләгәнем юкмыни әле? Яз көне эстафетада катнашкан идем. Чабып киләм — бер көтү ирләр җыелган. Шунда берсе: «Күр әле, күр. Юаны килә. Юанын гына күр әле»,— ди. И көлешә башладылар бер заман! Шартлыйм дип торам. Шуннан соң

ташладым *(Гомәргә).* Авызыңны җәймә. Юан булса да, апаң икенче разрядны иметь итә әле.

Гомәр. Ташлыйсың калмаган. Чемпион булыр идең.

Гөлназ. Көл, көл. Менә көзгә апаңны күрерсең әле. Бер биш килога ябыкмасам, алла теләсә.

Гомәр. Азрак ашапмы?

Гөлназ. И, мин хәзер дә чебеш кебек кенә ич. Күрдең ич, әнием өч йомырка куырган иде — көчкә ашап бетердем. Аннан май белән печтик батон ашадым инде. Бер стакан какао...

Гомәр. Әйтәм җирле ябыгып киттең. Ә менә Чулпан тазарган.

Чулпан. Сүз юктан әйтәсеңме соң?

Гөлназ. Ул гел шулай. Мине күргән саен ябыкkансың, ди. Сиңа — киресенчә.

Гомәр. Комплимент. Чөнки юан хатын-кыз ябыгуга, нечкәсе — тазаруга шат.

Марзия. Болай чәнчешеп йөргәнче, өйләнешсәгез инде.

Гомәр. Иртә әле. Шушы яшьтән муеныма муенчак киясем килми.

Марзия. Шулай да күз төпләренә каз тәпие төшкән.

Гомәр. Аның каравы йөрәк яшь.

Гөлназ. Язучылар шулайрак бит инде алар. Бөкреләре чыгып, кәкрәеп бетсәләр дә, «йөрәк яшь!» дип кычкыралар.

Гомәр. Шаярам, әлбәттә. Менә шушы хур кызы ризалык бирсә — көзгә, юк, язга өйләнәм. Шулай да, ялгыз тормышка ни җитә! Китсәң — «кая барасың?» диюче юк. Кайтсаң — «кайда йөрдең?» дип йөдәтмиләр.

Гөлназ. Җитәр. Син көйләп җибәрсәң — перпетуум мобиле кебек. Хыялларыгызны уйладыгызмы?

Илдар. Нинди хыяллар?

Гөлназ. Ә, сез бит безнең арада яңа кеше. Без, мәктәп дуслары, ел саен Сабан туенда очрашып, үзебезнең элекке хыялларыбызның ни дәрәҗәдә тормышка ашуы турында сөйләшәбез. Уйлап куегыз. Сезне дә сөйләтәчәкбез.

Гомәр. Илдарның хыялын үзем әйтермен.

Илдар. Актер кешенең хыялы билгеле инде. Шулай бит, Марзия апа?

Гомәр. Марзияның да хыялын беләм.

Марзия. Нәрсә?

Гомәр. Дуслар! Утызга житеп килүче кыз нәрсә турында хыяллана? Кияүгә чыгу турында, әлбәттә. Өстенә бастыммы? *(Марзия уңайсызланып, читкә борыла).* Алайса, мин сезгә туксан тугыз процент төгәллек белән Гөлназның хыялын әйтәм.

Гөлназ. Яле, яле.

Гомәр. Көзгә кадәр кемендә бер потка ябыгырга.

Гөлназ. Җүләр.

Гомәр. Миңа кияүгә чыгарга.

Гөлназ. Җүләр дә соң инде! Әйтерсең хатын-кызның кияүгә чыгудан башка хыялы булмый.

Гомәр. Алайса, нәрсә турында хыялланасың?

Гөлназ. Бернәрсә турында да хыялланмыйм. Кит моннан.

Гомәр. Гафу ит...

Гөлназ. Үләм шушы ирләргә! Берәр кыз кияүгә чыкмый торса — кияү юктан дип уйлыйлар. Үзегез соң!

Гомәр. Туктагыз. Ә Чулпан нәрсә турында хыяллана?

Чулпан. Хыялланып ни файда!

Гомәр. Дөрес түгел. Хыялсыз кеше — канатсыз кош.

Чулпан. Матур уйларга, матур хыялланырга, ләкин бернәрсә дә эшләмәскә мөмкин.

Гомәр. Ягъни?

Чулпан. Кайчак миндә шундый матур хыяллар туалар. Уйлап торсаң — исең-акылың китәр. Ә тормышта бөтенләй киресе.

Гомәр. Мәсәлән?

Чулпан. Мәсәлән, минем шундый матур өлгеләр чигәсем килә! — Һәркем яратырлык, күз явын алырлык өлгеләр. Һәм минем чигешләремне күргән кешеләр: «Синең башың мулине жепләр белән тулы. Син буш кыз», димәсен иде *(күзләре яшьләнә)*.

Гөлназ. Чулпан!

Илдар. Ни булды?

Чулпан. Игътибар итмәгез. Мин еш жылыйм.

Фатыйма *(ишектә)*. Бәрәңге пеште, кызым.

Гөлназ *(сикереп тора)*. Тозга ярып пешергән бәрәңгеме?

Чулпан. Тик хәзер түгел. Алып чыгабыз.

Гөлназ. Кабып кына карыйм. *(Чулпан артыннан чыга.)*

Гомәр. Әй-әй, син анда кабып карыйм дип, бөтен кастрюльны сосма *(чыга).*

Илдар. Марзия апа! Соңгы вакытта сез болытлы көн төсле.

Марзия. Анын каравы сез аяз.

Илдар. Әгәр үземне күптән кызыксындырган бер сорау бирсәм — җавап бирерсезме?

Марзия. Соравына карап.

Илдар. Театрда үзегезне хөрмәт итәләр. Җырлавыгызны халык ярата. Бу бит артист өчен чын бәхет. Ә сез...

Марзия. Кирәкмәс, Илдар.

Илдар. Юк, сез яшермәгез, Марзия апа.

Марзия. Нишләп сез миңа һаман апа дисез? Мин бит сездән ике генә яшькә олы.

Илдар. Ничек әйтим? Мин сезне, Марзия апа, кеше буларак һәм җырчы буларак шулхәтле яратам һәм хөрмәт итәм! — хәтта үз тиңем булсагыз да, минем сезгә апа диясем килер иде.

Марзия. Ә сез алай димәгез. Яме. Шулай ук андый сораулар да бирмәгез. Барыбер ярдәм итә алмассыз.

Илдар. Бәлки, итәрмен.

Марзия. Юк *(Илдарга текәп карап торганнан соң)*. Юк, юк.

Илдар. Марзия апа!

Марзия *(Илдарның күзләренә карап)*. Әгәр дә мин кемне дә булса яратсам, ә ул кеше минем дөньяда яшәвемә дә игътибар итмәсә,— сез ничек ярдәм итәрсез?

Илдар. Сезне яратмасамы? Иң элек мин ул кешене күрер идем...

Гомәр керә.

Гомәр. Малай, уралар анда бәрәңгене! *(Марзия тиз генә икенче якка китә.)* Бер карасаң — һич искитәрлек җире юк бу Чулпанның. Нәрсәсен табасындыр?

Илдар. Ә син минем күзләремне ал да кара, күрерсең.

Гомәр. Юк ла инде, матур түгел лә инде...

Илдар. Кысыр чәчәк тә матур. Миңа аның кешелеге кыйммәт.

Гомәр. Беләсеңме, мин ни өчен шулай дим? Ул әллә ничек, вакытыннан иртә олыгайган. Кызлар шикелле янып тормый.

Илдар. Якут ташы ут шикелле яна. Ләкин очкынны чакма ташыннан чыгаралар.

Гомәр. Чакма ташыннан ут чыгару өчен осталык кирәк шул. Ел буе өзгәләнеп йөрисең, очкыны күренми әле.

Илдар. Бәлки, күренер.

Гомәр. Бәлки. Ләгънәт төшкере бәлки! Күпме гашыйклар үзләрен шул бәлки белән юаталар. Күпме гашыйкларның йөрәген мәңге тормышка ашмаслык өметләр белән шул бәлки бәйли! Бәлки яратыр, бәлки онытмас, бәлки ташламас... Кәҗәләнгән саен көчлерәк яратасыңмы?

Илдар. Йөрәк шулай бит ул. Каршылык күп булган саен көчлерәк омтыла.

Гомәр (*стенадагы чигешләргә күрсәтеп*). Менә боларны ул чигә.

Илдар. Беләм.

Гомәр. Әйбәтме?

Илдар. Әйбәт кенәме соң! Биредә чын сәнгать.

Гомәр. Мещан сәнгате.

Илдар. Юк, син хаклы түгел. Ул чын художник.

Гөлназ, Чулпан һәм Марзия керә.

Гөлназ. Илдар! Чулпан Сабан туена чыга алмый. Фатыйма апаның хәле авырайды. Ашыгыч рәвештә канын алырга кирәк. Сез барыгыз, Гомәр. Мин азрак Чулпанга булышам. Куып җитәрмен.

Илдар. Чулпан!

Чулпан. Барыгыз!

Илдар, Гомәр һәм Марзия чыга.

Чулпан. Нишләп шулай эшләдең, Гөлназ — яхшы түгел бит.

Гөлназ. Шаулама. Менә хәзер күрерсең: ярата-мы — юкмы.

Чулпан. Алдау кирәкмәс иде.

Гөлназ. Җүләр, алдашу түгел бу, шаяру гына. Чулпан! Нигә син шулай, ә? Ул бит шундый яхшы,

шундый яхшы. Гомәр булмаса — минем үземнән дә артмас иде ул. Ул бит сине ярата, җүләр!

Чулпан. Күцел ятмый, Гөлназ. Артистлар турында әллә ничегрәк сөйлиләр бит.

Гөлназ. Ә беләсеңме ни өчен? Чөнки артист күз алдындагы кеше. Әгәр бер артист белән берәр нәрсә булса — аны бөтен кеше ишетәчәк. Шуннан китә гайбәт. Ә болай бер кеше кырык хатын алса да, аны тирә-күршесе генә белә. Белмим, белмим. Ничек шундый егетне яратмау мөмкиндер!

Чулпан. Йөрәккә кушып булмый.

Гөлназ. Кайчак кушасың да шул, алтыным. Йөрәк теләгәнчә генә яшәп булмый. Ирек бирсәң йөрәккә — утырырсың көрәккә, дип, белмичә генә әйтмәгәннәр. Сиңа нәрсә көтәргә? Вилдан очтымы? Очты. Кыз булып картаерга җыенмыйсыңдыр ич? Хәзер монастырьлар да юк. Ниһаять, синең кешелек алдындагы бурычың бар. Бала табарга, җирдә нәсел калдырырга тиеш син.

Илдар керә.

Чулпан. Сез китмәдегезмени әле?

Илдар. Юк. Ничек хәле?

Гөлназ. Әйбәтләнде. Канын алдык... Ярый, мин киттем. Сез килерсез бит? Илдар! Әйт әле, нинди ир син? Алып чык инде шуны бу тынчу һавадан (*чыга*).

Чулпан. Барыгыз. Сез дә китегез.

Илдар. Чулпан!

Чулпан. Әйе, шулай кирәк. Китегез.

Илдар. Тынычланыгыз, Чулпан.

Чулпан. Мин тыныч.

Илдар. Алайса нигә күзләрегез юеш?

Чулпан. Болай гына. Күзләр арыды. Алар бит көнгә чыккач бик күп карыйлар. Барыгыз. Сабан туена кичегәсез.

Илдар. Сездән башка анда миңа ни бар!

Пауза.

Чулпан. Илдар! Сез чыннан да мәхәббәткә ышанасызмы?

Илдар. Ә сез?

Чулпан. Юк. Һәм мин сезне кызганам.

Илдар. Яраткан кеше, аның мәхәббәте нинди генә өметсез булса да, кызганыч түгел. Ул бәхетле.

Чулпан *(көлеп)*. О, кызыл сүзләр! Андый әкиятләргә ышану өчен миңа инде егерме алты яшь... *(тәрәзәдән карап)*. Бүген көн матур... Нинди гүзәл болытлар, ийе? Кечкенә чакта алар миңа өй түбәсендәге кар көртләре булып тоелалар иде. Шуларны кул белән тотып карар өчен, мин әллә ничә тапкыр өй түбәсенә мендем. Минем шул көртләрдә йөрисем, ауныйсым килә иде. Көлке, ийе?

Илдар. Бу бит күптән.

Чулпан. Минем хәзер дә аларны тотып карыйсым килә. Ерактан алар шундый мәһабәт һәм йомшак... Кайчак тормышта да шулай була бит, кешеләр белән дә. Күрегез, нинди матур болыт! Ә читләре! Әйтерсең ука белән каеган. Мин шуларны һич кенә дә чигешкә күчерә алмыйм. Һәрвакыт, әллә ничек, таркалалар алар.

Илдар. Нинди нәни куллар! Шушындый кечкенә куллар һәм шундый йомшак күңел белән сез ничек операция ясыйсыз? Тере кешене кисәр өчен каты күңелле, кансыз булырга кирәк бит.

Чулпан. Минемчә, нәкъ менә шундый йомшак күңел белән кулга пычак тотарга кирәк тә *(кечерәк пауза)*. Хәер, сез хаклы. Хирургия — дәвалауның иң шәфкатьсез ысулы. Минемчә, пычак белән дәвалау киләчәктә бетәр. Галимнәр башка юллар, кешелеклерәк ысуллар табарлар.

Илдар *(Чулпанның кулыннан ала)*. Шулай... Димәк, сезнеңчә, мәхәббәт юк?

Чулпан. Нигә — бар ул. Ләкин мәхәббәт җыр кебек, яңа чакта гына матур була. Искергәч, аның кызыгы бетә һәм ул туйдыра, оныттыла. Чөнки яңалары чыга.

Илдар. Юк. Мәхәббәт — очсыз-кырыйсыз симфония. Ул бервакытта да туйдырмый. Киресенчә, аны тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Тыңлаган саен аны яхшырак аңлыйсың, яңадан-яңа гүзәллекләрен ачасың.

Чулпан. Файдасыз романтика. Күрәсен, актер халкы романтик була. Минем әнкәй дә шулай. Сез беләсезме? — Ул бит артистка.

Илдар. Фатыйма апамы?!

Чулпан. Ийе, ийе. Заманында ул бик яхшы җырчы булган. Минем белән йөкле чагында тавышын югалт-

кан. Шуннан соң барысының да асты-өскә килгән. Хәтта миңа эткәй тиешле кеше дә әнкәйне ташлап киткән.

Илдар. Чулпан! Расмы бу?

Чулпан. Ийе. Әнкәйнең музыкаль белеме булмаган. Башка һөнәре булмагач, ул җыештыручы булып эшли башлаган. Идән юып, мич ягып мине үстергән. Ул да шулай хыялый. Мәхәббәткә ышанып, гомер буе эткәйне көткән. Әнкәйнең сүзенә караганда, эткәй аны бик нык ярата булган.

Илдар. Төрле кешеләр була.

Чулпан. Менә күрәсез, мин инде институт бетердем. Әнкәй инвалид булды. Ә кайчандыр әнкәйне яратам дип антлар итеп йөргән эткәй тиешле кеше кайтмады. О, без күргәннәрне күз алдына китерү читен сезгә.

Илдар. Тиздән бөтен авырлыкларыгыз бетәчәк, Чулпан. Тик риза булыгыз.

Чулпан. Юк, Илдар. Минем өчен шундый фаҗигаләр кичергән анамның кеше почмагында торуын теләмим мин.

Илдар. Мин аны үз анам кебек яратырмын, Чулпан.

Чулпан. Бу бик аз. Бик күп һәм бик аз. Миңа карата сездән бу бик күп яхшылык. Ләкин анам алдында үземне аклар өчен бу бик аз. Мин аның һәрбер хәрәкәтен аңлыйм. Кеше өенә бару аны сөендермәячәк. Ул бит үз авыруыннан үзе оялa.

Илдар. Менә сез нинди! Шуның өчен дә шул сезнең күзләрегез моңлы.

Чулпан. Моңлы? Ә мина ни өчендер, синен күзләрең уйсыз һәм мәгънәсез, диләр.

Илдар. Кем әйтә?

Чулпан. Кешеләр. *(Илдар Чулпанның кулыннан ала, ул карышмый.)* Яхшы кеше сез. Сезнең белән миңа һәрвакыт җиңелрәк. Сез дә булмасагыз, миңа бик авыр булыр иде.

Илдар *(сакланып кына Чулпанны күкрәгенә кыса)*. Мин сезнең белән. Һәрвакыт сезнең белән, Чулпан. Сабан туена кичегәбез.

Чулпан *(уйлап)*. Әнкәй, без киттек... *(китәләр)*.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

2 КҮРЕНЕШ

Илдарлар квартирасында бай җиһазландырылган бүлмә. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Бераздан, язгы киемнәрдән, көлешә-көлешә Чулпан белән Илдар керә. Илдар Чулпанга чишенергә булыша.

Чулпан (*читкә тайпылып*). Кирәкми, кирәкми. Үзем чишенәм.

Илдар (*Чулпанга сокланып карап тора да үбә*). Чулпаным — таң йолдызым!

Чулпан. Илдар! Шул таң йолдызы дигән сүзне әйтмәсәң иде.

Илдар. Нишләп?

Чулпан. Куркам.

Илдар. Нәрсәдән?

Чулпан. Яратмый башларсың дип.

Илдар. Минме?! Ничек син башыңа китерә аласың! (*Чулпанны кочакларга килә.*)

Чулпан (*Илдарны этәреп*). Тсс! (*Күрше бүлмәгә күрсәтә.*) Әнкәйләр.

Илдар. Ярый. Син ашап ал, ял ит. Мин хәзер кайтырмын.

Чулпан. Кая барасың?

Илдар. Театрга кереп чыгам.

Чулпан (*көзге алдына килеп чәч толымнарын рәтли*). Илдар! Әгәр чәчемне көдрәләтсәм? Тарый-тарый теңкәм корый. Ачуланмассыңмы?

Илдар. Миңа дисәң, бөтен чәчеңне кырып ташла — анда да сүзем юк. Мин бит сине чәчең өчен яратмыйм.

Чулпан. Нәрсә өчен соң?

Илдар. Нәрсә өчен яратаммы?

Чулпан. Әйе.

Илдар (*уйлап*). Яратканым өчен. (*Яңадан Чулпанны үбәргә килә.*)

Чулпан (*читкә кагып*). Әнкәй! (*Фатыйма белән Шәмсебану икесе ике ишектән чыгалар.*) Күр: әнкәй дигән идем — ике әнкәй икесе дә чыккан. (*Фатыйма белән Шәмсебануның икесенә дә.*) Әнкәй, мин хәзер кайтып житәрмен, әнкәй. Чәчемне генә көдрәләтеп чыгам.

Шәмсебану (*ошатмыйча*). Йөр инде. Бер уңайдан тырнакларыңны да буят.

Фатыйма. Башта ашап аласыгыз бар иде, балалар.

Шәмсебану. Озак йөрмә. Иртәгә якшәмбе. Керләр җебетеп куярга кирәк.

Чулпан. Ярый, әнкәй. Барысы да булыр.

Чулпан белән Илдар китәләр.

Фатыйма. Пар күгәрченнәр кебек, алмаларым. Тфү, күзем тимәсен тагын.

Шәмсебану. И кодагый, әле башы гына. Һаман гөрләшеп тормаслар әле. Чукышкан чаклары да булыр.

Икесе ике ишектән кереп китәләр. Өченче ишектән Шамил белән Фәридә чыга.

Фәридә (*Шамилнең кулына сарылып*). Шамка! Шундый булма инде. Тагын аз гына утыр.

Шамил. Җитәр.

Фәридә. Тагын аз гына. Утыр минем шунда. (*Шамилны диванга утырта.*) Әллә бездә ошамыймы?

Шамил. Нишләп? Сездә яхшы.

Фәридә. Миңа ошамый. Артык тыныч. Ничә елдан бирле әтиемә шәһәрнең эченәрәк күчик, дим. Тыңламый...

Шамил. Сәгатең матур икән.

Фәридә. Матур?

Шамил. Әйе.

Фәридә. Сиңа ошыймы?

Шамил. Ошый.

Фәридә. Бик тә?

Шамил. Бик тә.

Фәридә (*сәгатен салып*). Мә.

Шамил. Нигә?

Фәридә. Ошагач — ал.

Шамил. Мин бит болай гына әйттем.

Фәридә. Шамка!

Шамил. Кирәкми.

Фәридә. Ал. Югыйсә ташлыйм. (*Диванга басып, форточканы ача.*)

Шамил. Фәридә, җүләрләнмә.

Фәридә. Ташлыйм.

Шәмсебану керә.

Ш ә м с е б а н у. Нәрсә тавышланасыз, балалар? Бу нишләвең, Фәридә?

Ф ә р и д ә. Әнием! Мин аңа сәгатемне бирәм, ә ул алмый. Үзе ошый диде.

Ш а м и л. Мин бит болай гына әйттем. Ул чыннан да матур.

Ш ә м с е б а н у. Алыгыз, ал, Шамил, баланың хәтерен калдырмагыз. Ул бит чын ихласы белән бирә.

Ш а м и л *(алып)*. Яхшы. Ләкин үз сәгатем булгач, мин аны кайтарырмын.

Ш ә м с е б а н у китә.

Ф ә р и д ә. Минем тагын бар. *(Комод өстендә актарынып сәгать ала.)* Матурмы?

Ш а м и л. Юк.

Ф ә р и д ә. Алайса, такмыйм *(сәгатьне кире куя)*.

Ш а м и л. Юк, юк. Мин бит юри генә.

Ф ә р и д ә *(кулына сәгать тагып, Шамил янына утыра)*. Менә шулай. Безнең семья зурайды хәзер.

Ш а м и л. Җингән ничек, ошыймы?

Ф ә р и д ә *(борынын җыерып)*. Юк.

Ш а м и л. Ни өчен?

Ф ә р и д ә. Әйт әле менә, Шамил. Институт бетергәч, аны аспирантурага чакырганнар. Кермәгән. Ахмак бит?

Ш а м и л. Үзендә талант сизмәгән, күрәсең.

Ф ә р и д ә. Барыбер ахмак. Белмим инде, мин аспирантурага эләгә алырмынмы.

Ш а м и л. Син нинди гә керергә телисең?

Ф ә р и д ә. Ниндигә булса да.

Ш а м и л. Ничек инде?! Синең берәр яраткан нәрсәң бардыр бит. Сине дулкынландырган нәрсәләр. Шулай булмаганда аспирантурада нәрсә бар!

Ф ә р и д ә. Диссертация. Миңа кандидатская диссертация кирәк.

Ш а м и л. Әниең кушамы?

Ф ә р и д ә. Что син! Мин бит самостоятельный кыз.

Пауза.

Ш а м и л. Ярый, миңа китәргә вакыт.

Ф ә р и д ә. Шамка!

Ш ә м с е б а н у чыга.

Ш э м с е б а н у. Нигә утырмыйсыз? Бездә күңелсез мәллә?

Ш а м и л. Күп утырдым.

Ш э м с е б а н у. Тагын утырыгыз. Сез бит чит кеше түгел.

Ф ә р и д ә. Тукта, азрак озатыйм.

Ш э м с е б а н у. Икенче килеп утырыгыз. Салих Баширович өйдә чакта.

Ш а м и л. Рәхмәт. Сау булыгыз.

Ф ә р и д ә белән Ш а м и л чыгалар. Ш ә м с е б а н у комод өстен җыештыра. Г ө л н а з керә.

Г ө л н а з. Исәнмесез!

Ш ә м с е б а н у. Әә, исәнмесез! Узыгыз.

Г ө л н а з. Рәхмәт. Ниләр бетереп ятасыз?

Ш ә м с е б а н у. Менә өй җыештырып йөрим. Бу елдагы киленнәр иркә була бит. Каенаналарына аркаланып, аркылыны буйга да алып салмыйлар.

Г ө л н а з. Өлгермидер, Шәмсебану апа. Эшли ич ул.

Ш ә м с е б а н у. Эшлим дип бит инде, авыру каенанага салынып яту да килешми.

Г ө л н а з. Сез авырыйсызмыни?

Ш ә м с е б а н у. Авырыйм шул. Авыруым бик куәтле минем. Бер кузгалса — менә шуннан башланып, менә шуннан, бөтереп-бөтереп бөтен тәкатемне ала. Авыруым бар минем. Врачлар гына таба алмыйлар.

Г ө л н а з. Тапмыйлармыни?

Ш ә м с е б а н у. Юк. Инде күренмәгән профессор калмады — таба алмыйлар.

Г ө л н а з. Нәрсә икән соң ул...

Ш ә м с е б а н у. Рак булмаса ярый инде. Әллә платныйга күренеп карарга.

Г ө л н а з *(елмаеп)*. Яшьләр ничек, тату яшиләрме?

Ш ә м с е б а н у. Яшиләр. Үзләренә ярагач — катышып йөрмим. Бер бик чибәр кыз тапкан идем дә — ошатмады.

Г ө л н а з. Хәзер яшьләр үзләре табалар шул инде.

Ш ә м с е б а н у. Табам дип инде, ата-әнкә сүзен дә этеп егарга ярамый.

Г ө л н а з. Нигә, әллә Чулпанны ошатмыйсызмы?

Ш ә м с е б а н у. Ошатабыз! Нишләп ошатмаска? *(Тавышын акрынайтып.)* Тик менә шунысы бар. Илдарга килгәнче бик таушалган булган ахры.

Гөлназ. Ай, юктыр, Шәмсебану апа, дөрес түгелдер.

Шәмсебану. Дөрестер, дөрестер. Ут юк җирдән төтен чыкмый. Әле беркөннәрдә бер хат килеп төште. Өйгә килгәч, адресын карамый гына ачкан идем — Чулпанга булып чыкты. Гыйшык хаты. Без синең белән биш ел йөрдек, фәлән дә фәсмәтән, дигән.

Гөлназ. Ышанмыйм. Сез тагын бу хакта Илдарга әйтмәгез, Шәмсебану апа.

Шәмсебану. Әйтәмме соң! Әйтмим. Яшәсеннәр. Әле хатын Чулпанга да күрсәтмәдем. Кыз чагында кемнәр белән йөрде икән соң ул?

Гөлназ. Яшь вакытта хат язышкан кешеләр була инде ул, Шәмсебану апа. Болай бик әдәпле, юаш кыз иде ул.

Шәмсебану. Менә шул юаштан юан чыга да инде ул. Безнең аумакайга ярады инде. Ярый, кайда сөйләшсәк — шунда калсын.

Гөлназ. Фатыйма апа өйдәме? Күреп чыгыйм әле *(икенче бүлмәгә уза. Фәридә керә)*.

Шәмсебану. Озаттыңмы?

Фәридә. Әә.

Шәмсебану. Ниләр сөйли?

Фәридә. Әллә нинди генә ул. Ошамый.

Шәмсебану. Ошамас менә тагын! Шундый егетнең күңеле булганда, авызыңны ачып тор тагын.

Фәридә. Габбас матуррак.

Шәмсебану. Ирләрнең матуры гулящий була аның.

Фәридә. Үзе ярлы. Тагып йөрергә сәгате дә юк. Бер җиргә барсаң — сәгать ничә дип аптыратып бетерә. Оялмый да.

Шәмсебану. Син аның түшенә карама, эшенә кара.

Фәридә. Эше дип, әллә кем түгел әле.

Шәмсебану. Доцентурага чакыралар ди бит. Үзе кандидат наук.

Фәридә. Шул гына инде.

Шәмсебану. Башлау өчен шул җиткән. Үзеңне аспирантурага урнаштырса начар булырмыни?

Фәридә. Әй, кирәсем килми лә минем аспирантурага.

Шәмсебану. Ә мин әйтәм, кирәсең.

Ф ә р и д ә. Ә мин әйтәм, кермим.

Ш ә м с е б а н у. Ә мин әйтәм, керәсең.

Ф ә р и д ә. Ә мин әйтәм, кермим!

Ш ә м с е б а н у. Ә мин әйтәм, керәсең! Җүләр! Хәзер һәркем шулай. Һәрбер яхшы ата-әнкә баласы кандидат наук була.

Г ө л н а з белән Ф а т ы й м а керә.

Г ө л н а з. Шәмсебану апа, шушы язуны Илдарга тапшырырсыз бит? *(Фәридәгә.)* Исәнмесез!

Ш ә м с е б а н у. Нәрсә ул?

Г ө л н а з. Берсекөнгә туган көнем...

Ш ә м с е б а н у. Ә, барырлар, барырлар.

Ф ә р и д ә. Гөлназ апа! Сез врач бит?

Г ө л н а з. Әйе.

Ф ә р и д ә. Сез эшегезне яратасызмы?

Г ө л н а з. Яратам.

Ф ә р и д ә. Медицинаны яратмаска мөмкинме соң! Ул бит кәгазьләр арасында дөмегеп утыру түгел.

Г ө л н а з. Ни өчен шулай дисез?

Ф ә р и д ә. Мин быел институт бетерәм, экономист булачакмын. Ә бу эшне минем җенем сөйми!

Г ө л н а з. Сезгә нәрсә ошый соң?

Ф ә р и д ә. Миңамы? Балалар. Менә шундый, әле сөйләшә генә башлаган балалар. Мин шундый яратам аларны.

Г ө л н а з. Алайса, балалар врачы буласыгыз калган.

Ф ә р и д ә. А, мин аларның авыруларын яратмыйм шул.

Ш ә м с е б а н у. Тыңламагыз, зинһар, шуны. Әле бала акылы чыкмаган.

Ф ә р и д ә. Нигә чыкмасын...

Ш ә м с е б а н у *(усал карап)*. Фәридә!

Г ө л н а з. Ярый, сау булыгыз. Мин хәзер ашыгам. Сау бул, Фатыйма апа.

Ш ә м с е б а н у Гөлназны озата чыга. Ф ә р и д ә комод өстендә актарына башлый.

Ф а т ы й м а. Артыңнан үзеңнекен җыеп куй, кызым. Җиңгәнә дә эш күп. *(Фәридә авызын турсайтып, комод өстен рәтли)*. Кая барып кайттың әле бик тиз генә?

Ф ә р и д ә. Күпне белмә. Болай да инде картайгансың.

Ф а т ы й м а. Ай алла, ярамаса әйтмә. Минем үз итеп кенә соравым, яратып кына. Алай тупас сөйләшмә, бәбкәм. Әдәпле бул. Егетләр дә әдәпле кызларны ярата.

Ф ә р и д ә. Яратырлар әле. Синең кызыңны яраттылар бит.

Ф а т ы й м а. Минем кызым әдәпле ул.

Ф ә р и д ә. Белмим шул. Кеше сүзе дөрес булса...

Ф а т ы й м а. Нинди сүз?

Ф ә р и д ә. Әнә бит, җиңгәм кияүгә чыкканчы бик крутить иткән иде...

Ф а т ы й м а. Әстәгыфирулла! Чулпан — синең җиңгәң. Җиңгә кеше турында алай сөйләү килешми.

Ш ә м с е б а н у керә.

Ф ә р и д ә. Килешми дә бит.

Ф а т ы й м а. Кит, кит. Оялмыйча юкны сөйләмә.

Ш ә м с е б а н у. Менә тагы! Аны без генә сөйләмибез лә. Бөтен шәһәр сөйли аны.

Ф а т ы й м а. Ай алла, кодагый! Бу ниткән сүз бу? Минем кызымның алай йөргәне юк. Мин аны алай тәрбияләмәдем.

Ш ә м с е б а н у. Каян беләсең инде. Кош оясында ни күрсә, очканда шуны эшләр, ди бит. (*Фатыйма елый.*) Җылап торасың тагын, и кодагый. Гомер буе ирсез яшәгәнсең. Булгандыр инде.

Ф а т ы й м а. Тәүбә диген, тәүбә диген, кодагый!..

Ч у л п а н белән И л д а р керә.

И л д а р. Нәрсә булды? (*Пауза.*) Әнкәй?

Ш ә м с е б а н у. Берни дә булмады, нәрсә миңа тасраеп карыйсың?!

Пауза.

Ч у л п а н (*Фатыймага*). Ни булды, әнкәй? (*Пауза. Фатыйма дәшми.*) Нигә җылыйсың?

И л д а р (*Фатыйма янына килеп*). Нәрсә булды, әнкәй?

Ф а т ы й м а (*бераздан*). Алар Чулпан турында начар сөйлиләр. Әшәке кыз булган диләр...

И л д а р. Кем әйтә?

Ф а т ы й м а. Ярабби! Картаймышлы көннәремдә нишетәселәрем бар икән...

И л д а р *(Шәмсебануга)*. Бу нинди гайбәт, әнкәй?

Ш ә м с е б а н у. Менә тагы? Ник гайбәт булсын ул.

И л д а р. Гайбәт!

Ш ә м с е б а н у. Ашамаган авызга аш ябышмый. Гайбәте түгел, гадәтедер.

И л д а р. Гайбәт!

Ш ә м с е б а н у. Кара, кара, әнкәсен гайбәтче итеп калдырмакчы була. Хатыныңны әнкәңә алмаштырасың, имансыз. Әнә бар, урамга чык та тыңла. Ансын да гайбәт дисәң — менә, мә! *(Күлмәк изүеннән конверт алып Илдарның битенә ташлый. Илдар белән Чулпан укыйлар)*. Әнә бит, өстенә баскач, төсе үк үзгәрде.

И л д а р *(үзен-үзе тыя алмыйча)*. Әнкәй!

Ш ә м с е б а н у. Әнкәй димә мина, оятсыз! Хатыныңны яклап, мине гайбәтче диден. Хәзер үк алдыма тезләнеп гафу үтен!

Ч у л п а н. Илдар!

И л д а р. Биредә андый сүзләргә бернинди дә нигез юк. Минем хатынымны кемнәрдер ярата икән — мин моны тыя алмыйм.

Ш ә м с е б а н у. Алмыйсың? Әгәр дә хатының чит кешеләргә гыйшык хатлары язса дамы? Әгәр дә хатының чит кешеләр белән...

И л д а р. Әнкәй!

Ш ә м с е б а н у. Шулай булса да тыя алмыйсыңмы? Син әнкәңне җәберләдең. Гафу үтен. Шушы минутта гафу үтен әнкәңнән! *(Башын югары күтәреп, кукыраеп басып тора.)*

И л д а р *(Шәмсебануның алдына килеп)*. Син әнкәй түгел — гайбәт капчыгы!

Ш ә м с е б а н у *(ачы аваз белән)*. Аааһ. *(Һушы киткәндәй, диванга ава һәм аяк-кулларын селкеп ята.)*

Ф ә р и д ә. Әни! Әнием! Су!!! *(Чулпан графиндагы суда тастымал чылатып, Шәмсебану янына килә. Фәридә телефонга ташлана.)* Скорая помощь! Скорая помощь!..

Ш ә м с е б а н у *(Чулпанны этеп җибәрә)*. Кит, шакшы! Арусыз кулларың белән тәнемә кагылма. *(Илдар Фәридә кулыннан трубканы тартып ала да рычагка куя. Пауза.)*

Ч у л п а н. Илдар!

Илдар. Сабыр ит, Чулпан. Бер генә минут уйларга бир.

Чулпан. Китим мин, Илдар.

Илдар. Ә, кая?

Чулпан. Әнкәй белән, бөтенләй. Болай яшәп булмый. Көн саен тавыш.

Илдар. Юк. Китсәк — бергә китәбез. *(Телефонга килә.)*

Чулпан. Нишлисең?

Илдар. Китәбез.

Шәмсебану. Бик килешә инде. Йөрегез кеше көлдереп, атаңның авторитетын төшерегез.

Илдар. Бездән көлмәсләр.

Шәмсебану. Китәләр имеш! Анда этиеңнеке кебек хәстәрләп куйганнар, ди. Әйләнеп кайтырга өлгерә алмассыз.

Илдар *(номер җыя)*. Кайтмабыз.

Шәмсебану. Кайтырсыз. Ашаган җиренә мал да кайта.

Илдар *(трубкага)*. Такси! Таксимы? Машина кирәк иде. Әйе, хәзер үк. Федосеевский урамы, житмешенче йорт. Квартира бер. Әйе, Вахитовлар. *(Трубканы куя.)*

Пәрдә.

3 КҮРЕНЕШ

Кечкенә генә, бөтенләй җиһазсыз диярлек бүлмә.

Марзия һәм Чулпан.

Чулпан. Менә шулай. Таксига утырдык та чыктык та киттек. Илдарны беләсең.

Марзия. Кайнар холыклы кеше.

Чулпан. Илдардан уңайсыз. Минем өчен шундый семьяны ташлады. Анда аның өчен ни теләсә шул бар иде.

Марзия. Ә син кадерен бел. Ул бит ярәтканга шулай *(бүлмәне карап)*. Кечерәк шул.

Чулпан. Кечкенә булса да аена егерме сум.

Марзия. Ачуым килә дә инде шушы бүлмә бирүчеләргә. Син үзең өчен алалмыйсың. Ә алар — болын кебек квартираны кулга төшерәләр дә, кеше кертеп,

кырын яткан килеш акча эшләп яталар... Күр әле, бер караганда культуралы гына семья бит. Илдарның этиләрен әйтәм.

Чулпан. Әткәйдә гаеп юк. Шул көнне үк чакыра килде.

Марзия. Ә сез кайтмагыз. Читен булса да, үз тормышыгызны корыгыз. Тормышны өр-яңадан башлау һәрвакыт шулай, читенрәк була ул. Шуңа карамастан, син бәхетле, Чулпан. Кызыгам мин сиңа. Ничек ярата ул сине! Их Чулпан, акыллым! Дүрт ел мин аны яраттым. Дүрт ел буе йөрәк мәңге барып җиталмәслек күлне күргән читлектәге аккош кебек талпынды.

Чулпан. Мин синең урыныңда булсам, Марзия апа, болай ут йотып йөрмәс идем. Тотар идем дә әйтер идем.

Марзия. Мин аны кичә дә күрдем. Балаларча керсез күзләрендә мөмкин булмаганны эзләдем, мөмкин булмаганны табарга тырыштым. Инде хәзер бетте.

Чулпан. Өйләнде мәллә? Күптәнме?

Марзия. Күптән түгел генә. Ярый, кайтырга кирәк. Сау бул.

Чулпан. Утыр азрак. Хәзер Илдар кайтыр.

Марзия. Юк, китәм. Сау бул. Бәхетеңнең кадерен бел, Чулпан.

Марзия чыга. Пауза. Ишек шакыйлар.

Чулпан. Әйе.*(Вилдан керә. Аның өстендә пөхтә тегелгән көрән төстәге костюм, Чулпан утырган урындыгыннан тора.)* Вилдан?!

Вилдан. Онытмагансың, димәк — таныдың. Исәнме, Чулпан *(Чулпанның кулына сузыла)*.

Чулпан *(кулын тартып ала)*. Исәнмесез. Сез кайдан?

Вилдан. Мәскәүдән. Диссертацияне якладым да туган якларга кайттым. Менә сине күрергә килдем. Синең бәхетле иреңне. Законлы никах белән!

Чулпан. Рәхмәт.

Вилдан. Утырырга ярыймы?

Чулпан. Юк, ярамый.

Вилдан. Син үзгәргәнсең. Бәлки, сөйләшергә дә теләмисеңдер?.. Диссертациямне уңышлы яклавым белән дә котламыйсың.

Чулпан. Сез эчкәнсез!

В и л д а н. Кызылны гына.

Ч у л п а н. Китегез.

В и л д а н. Син моны уйлап әйтәсенме, әллә горурлыгың белән генәме?

Ч у л п а н. Уйлап әйтәм. Мин беркайчан да уйламый сөйләшмим.

В и л д а н. Әйе. Димәк, шушында торасың, ә? *(Чулпанның өстәлдәге чигү эшен күреп.)* Һаман мавыгасыңмы? Син Чехов кебек. Чехов та: «Медицина минем законлы хатыным булса, әдәбият минем сөяркәм»,—дигән. Синең сөяркәң инде бу, ә?

Ч у л п а н. Моның әһәмияте юк.

В и л д а н. Мин музейда прикладной сәнгать күргәзмәсендә булдым. Синең дә чигешеңне күрдем. Уңыш белән котлыйм.

Ч у л п а н. Китегез. Хәзер Илдар кайта.

В и л д а н. Кайтсын. Бәлки, мин аны күрергә телимдер. Нигә әле син мине ирең белән куркытасың? Нәрсә, ашар мәллә ул мине? Минем күрәсем килә аны. Таныштырырсыңмы?

Ч у л п а н. Китегез.

В и л д а н. Син әйт әле менә. Син бәхетлеме?

Ч у л п а н. Бәхетле.

В и л д а н. Во! Димәк, мин хатын-кыз турында дөрес фикердә. О, хатын-кызга ышанырга ярамый. Аның йөрәге әбиләр шкатулкасы кебек — җыен чүп-чар белән тулы. Кайсы җирендә нәрсә ятканын һич белеп булмый. Бәхетле, димәк. Булсаң. Синең бәхетле булуыңа мин шат. Мин шат, Чулпан. Әйе. Акыллы эшләдең син, Чулпан. Төкерден дөньясына! Төкерден Вилданына, ә? Молодец син. Ә менә мин — ахмак.

Ч у л п а н. Китегез! Югыйсә мин үзем китәм.

В и л д а н. Миннән җирәнәсең инде, ә? Спирт исе килә. Це два аш пять о аш. Шулаймы? Ярый, китәм алайса. Бир кулыңны.

Ч у л п а н. Хуш.

В и л д а н. Юк. Син кулыңны бир, Чулпан! *(Чулпан кулын бирә.)* Әйе. Хәзер инде бу кул минеке түгел. Кайчандыр минеке иде бит ул, ә?..

Ч у л п а н. Җибәрегез! Мин кычкырам!..

В и л д а н. Кычкырма. Мин китәм. Нәрсәдер әйтергә теләгән идем — оныттым. Гафу ит, Чулпан. Сау бул.

Вилдан чыга. Чулпан ишекне бикләп ала да чигеше янына утыра. Берничә секундтан йөгереп тәрәзәгә килә һәм эриүле караш белән Вилданны карап кала, урынына утыра, кулына чигешен ала, шунда ук яңадан куя. Беравык уйланып торганнан соң, кровать янына килә һәм аның астыннан чемодан тартып чыгара. Чемоданнан бер карточка алып, ана озак һәм игътибар белән карап тора. Аның керфекләре юешләнә, ул менә-менә еларсымак. Ниһаять, кискен хәрәкәт белән карточканы ерта башлый, ә яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәри. Ишек шакыйлар. Чулпан ача.

Илдар белән Гомәр керә. Алар өр-яңа өстәл күтәргәннәр.

Илдар. Юкка бикләгәнсең, Чулпан. Әле безнең өйдә каракларга эш юк.

Гомәр. Исәнме, Чулпан! Яңа өйгә көчү белән!

Чулпан. Рәхмәт. *(Илдарга.)* Син нәрсә, актык акчага өстәл алдыңмы?

Илдар. Мин түгел, Гомәр.

Гомәр. Яңа өй бәйрәменә киләм дип көттем — чакырмадыгыз. Өстәлегез булмаган икән.

Чулпан *(өстәлне карап)*. Бик кыйммәттер инде бу. Расходлангансың.

Гомәр. Борчылма, Чулпан. Өйләнеп җибәрсәм — үзегезгә дә расходланырга туры киләчәк.

Чулпан. Күптән кирәк. Җүләрләнешеп йөрмәгез.

Илдар *(идәндәге карточка кисәкләрен күреп)*. Карточка ерттыңмы?

Чулпан *(тиз-тиз карточка кисәкләрен җыярга керешә)*. Иске ул. Үземнеке.

Гомәр. Я, кая куябыз? Менә шунда. *(Өстәлне бүлмә уртасына куялар.)*

Илдар. Чулпан! Кунакка чәй куеп җибәр әле. Мәсн яңа өй бәйрәмендә эчәрбез.

Гомәр. Самоварыгыз бармы соң?

Чулпан. Чәйнек бар.

Илдар. Каян килде?

Чулпан. Марзия апа китерде.

Гомәр. Маташма, Чулпан. Татар атын сатып, чәйнектән эчәр хәлем юк.

Чулпан. Яңа чәйнек.

Илдар. Үзең алып килгән өстәлгә утырып.

Гомәр. Чынаякларыгыз бармы соң?

Чулпан. Стакан бар.

Гомәр. Юк, эчмим.

Илдар. Биисе килмәгән аюның көе табылмый, диләр. Шушыдыр инде ул.

Г о м э р. Ашыгам. Ярый. Рэхэтен күрегез. Тормышыгыз шушы имэн өстэл кебек таза булсын.

И л д а р.
Ч у л п а н. } Рэхмэт.

Г о м э р. Яңа өй бэйрэмен мин кайтмыйча үткэрмэгез.

Ч у л п а н. Кая китэсең?

Г о м э р. Иҗат командировкасына. Яңа пьеса язам.

И л д а р. Һэм төп героен мин уйнаячакмын. Ул бик кызыклы пьеса булырга охшаган.

Ч у л п а н. Гомэр язса булдырыр инде ул.

Г о м э р. Как же! Минем бит исемем дэ чак кына Гомер түгел. Ярый, киттем. Сау булыгыз.

Ч у л п а н *(Гомэрнең артыннан карап кала)*. Кызык кеше.

И л д а р. Әйбэт малай ул. Талантлы малай. *(Тумбочка өстендэге чэчэклэрне күреп.)* Чэчэклэр?! Каян килде?

Ч у л п а н. Эштэ бирделэр. Ашказанындагы суентыдан кан китеп, аңсыз хэлдэ больницага китерелгэн егет турында сөйлэгэн идем бит. Мин аны бүген өенэ чыгардым. Э ул миңа букет хэстэрлэп куйган. Кулымны кысты да: «Рэхмэт, Чулпан Газизовна. Мине сез үлемнэн коткардыгыз»,— ди. Һэм белэсеңме, җылады да җибэрде. Шатлыгымнан үземнең дэ күзлэремнэн яшь чыкты.

И л д а р *(Чулпанны күкрэгенэ кысып)*. Менэ бит син нинди, Чулпан! Һэр яктан булдырасың. Әле күргэзмэдэ булдым. Синең чигешлэрең янында халык! Кайсы — өлгесен күчерэ, кайсы — соклана. Менэ күр дэ тор, үзеңэ премия бирэчэклэр *(сумкадан алмалар чыгара)*. Әнкэй кайда?

Ч у л п а н. Мунчага китте.

И л д а р. Үзен генэ җибэрмэслэр. Авыру кешене белмэссең.

Ч у л п а н. Хуҗа хатын белэн китте. Шулай күп аласың калмаган, Илдар. Акчага урын бик күп. Бэрэкэтлэп тотарга кирэк.

И л д а р. Акча булды әле. Мин эткэйне очраттым. Чакыра ул безне.

Ч у л п а н. Кайтмыйк инде без, Илдар. Ни булса да, үз оябызны корыйк.

И л д а р. Мин дэ шулай дидем. Э менэ йөз сум акча тэкъдим иткэн иде — анысын алдым. Менэ. Бүген үк чыгып, энкэйгэ кровать алабыз. Калганы — сиңа күлмэккэ.

Чулпан. Кирәкми. Минем күлмәкләрем бар әле. Син кеше арасында күбрәк буласың. Азрак җыярбыз да костюм тектерербез *(яктырып)*. Беләсеңме, күрән төслене. Балакларын менә болайрак, таррак итеп. Бик килешә ул.

Илдар. Кемдә күрдең?

Чулпан. Хәзер шулай тегәләр *(өстәл әзерли. Чулпан бердәнбер чынаякка чәй ясап Илдарга бирә. Үзенә стаканга ясый)*.

Илдар. Юк, чынаяктан син эч.

Чулпан. Син бит стаканнан эчәргә яратмыйсың.

Илдар. Яратам. Китер. *(Чулпан алдына чынаякны куеп, үзенә стакан ала.)* Балкашыклары кирәк. Менә шәйтан! Тормышны үзеңә кору шактый катлаулы икән. Әти-әни янында берсен дә белмисең.

Чулпан. Юк өчен борчылма. Булыр әле.

Илдар. Бәхеткә син шундый. Син булмасаң, мин моңа түзә алмас идем.

Чулпан. Мин булмасам, син бу хәлгә калмас та иден. Моңа мин сәбәпче.

Илдар. Чулпан! Актык ишетүем булсын. Барысына да мин үзем сәбәпче. Минем мәхәббәтем... Бүген майның унысы. Тагын сигез көннән гастрольгә. Ике ай синнән аерылып яшәргә! Бу бит Тантал газапларыннан да битәррәк.

Ишек шакыйлар. Фәридә керә. Ул дәшм',

Илдар. Әйдә уз, Фәридә.

Фәридә *(Чулпанның кочагына ташлана)*. Кичер, Чулпан апа!..

Чулпан. Ни булды?

Фәридә. Кичер, Чулпан апа. Абый, син дә кичер. Җүләр кыз мин.

Илдар. Я, я.

Фәридә. Бу бит минем аркада. Сез үзегез дә беләсез. Чулпан апа, матурым, кичер. Болай булыр дип һич уйламаганыем!..

Илдар. Димәк, вөҗдан китерде?

Фәридә. Мин бит болай булыр дип уйламаганыем. Ачу килеп торган чак иде. Ни әйткәнемне үзем дә белмәдем.

Илдар. Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетмәскә син диванамыни?

Фәридә. Сез киткәннән бирле әнкәй мине талый. Син башладың, сине яклап шулай булдым, ди. Абый дим! Чулпан апа! Әйдәгез, кайтыйк. Әнкәй дә чакыра.

Илдар. Юк, Фәридә. Без инде кайтмыйбыз. Ә болай кереп чыгармын. Иртәгә.

Фәридә. Сез дә булмагач, үләм ич мин ул өйдә. Чулпан апа, әйт инде, кичерәм диген!

Чулпан. Кичерәм. Син бит яшь әле. Бик күп нәрсәләрне аңламыйсың.

Фәридә. Ә син, абый?

Илдар. Кичерәм инде, кичерәм. Тукта балавыз сыгуыннан.

Фәридә *(чәчәкләрне күреп)*. Нинди матур чәчәкләр! Күпмегә алдыгыз?

Чулпан. Алмадым. Аны миңа авыру бирде.

Фәридә. Авырудан терелткән өченме? Менә бит нинди күңелле синең эшең, Чулпан апа! Сиңа авырулар килә, син аларны дәвалыйсың. Ә алар, терелеп савыккач, сиңа рәхмәт әйтәләр. Чәчәкләр бирәләр! Ә минем...

Чулпан. Эшли башлагач яратырсың әле.

Фәридә. Юк инде. Их, хыяллар, хыяллар! Кечерәк чакта матур хыяллана иде бит. Зур эшләр турында булмаса да, кешеләргә файда бирә, үзеңне канәгатьләндерә торган хезмәт турында. Ә мин аларга нәрсә бирәчәкмен? Әгәр мин ундүрт ел укып йөрмәсәм, кәгазьләр, цифрлар арасында казынып утырмасам, алар начаррак яшәр идемени?

Илдар. Һәр эшнең үзенә күрә шигърияте була. Кил утыр, чәй эч.

Фәридә. Эчмим. Минем институтка барышым. Әгәр икенче килсәм?

Илдар. Рәхим ит. Ләкин балавыз сыгарга түгел.

Фәридә. Ярый. Сау булыгыз *(китә)*.

Илдар. Менә бит ул нинди. Барысына да әнкәй гаепле.

Чулпан. Нишләп әнкәй генә булсын. Ә әткәй кайда? Ә син? *(Чәй эчәләр. Пауза.)* Илдар! Бу турыда мин сиңа әйтмәскә җыенган идем. Беләсеңме... Син кайтыр алдыннан биредә бер кеше булды.

Илдар. Кем ул?

Чулпан. Шул, хат язган кеше.

Илдар. Шул?! Ник килгән ул?

Чулпан. Кайнарланма. Мин аны чакырмадым.

Илдар. Кай арада китеп өлгерде соң ул? Мин аны.

Чулпан. Илдар, кызма. Утыр. Алайса, сөйләмим дә.

Илдар. Сөйлә. Ник килгән, ни сөйли — барын да сөйлә. Аннан, гомумән, ул нинди кеше?

Чулпан. Без аның белән бер институтта укыдык. Дуслар булдык. Кайчандыр мин аны яратам да кебек иде. Юк, бу күптән, җүләррәк вакытта. Килеп керде. Азрак кызмача. Берсе берсенә бәйләнмәгән сүзләр сөйли. Мин аны тыңламадым. Куып чыгардым.

Илдар. Рәхмәт, Чулпан. Миннән бернәрсәне дә яшермисең.

Чулпан. Ләкин аның тагын килүе бар. Куркам мин, Илдар!..

Илдар. Курыкма. Мин сине беләм һәм ышанам сиңа *(Чулпанны күкрәгенә кыса)*. Сине яратуымны аңлатыр өчен сүз юк!..

Чулпан. Адым саен «яратам» дип хисләреңне чәчмә. Сакла мәхәббәтеңне. Ул илһам чишмәсе.

Илдар. Кара, кара. Мәхәббәткә ышанмый торган кеше ниләр сөйли! *(Шашып, Чулпанны күкрәгенә кыса.)*

Чулпан. Акрын.

Илдар. Нәрсә акрын? Нәрсә акрын? Мин сине кочагымда сытып, изеп бетерәм хәзер!.. *(Яңадан Чулпанны кочакларга тели, ләкин ул кире кага.)*

Чулпан. Акрын. Безнең балабыз булачак.

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

4 КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә, ләкин ул хәзер шактый җиһазландырылган. Һәр җирдә тәртип.

Чулпан һәм Гөлназ.

Гөлназ *(Чулпанның чигеп беткән коверын карап)*. О, бу бит искиткеч килеп чыккан, Чулпан! Исеме ничек?

Чулпан. «Авыру янында». «Врач авыру янында».

Гөлназ. Чын рәссамнарың сокланырлык. Стенага

эләргә матур... Чулпан, син бүген әллә нәрсә генә — күңелсез дип әйтимме шунда.

Чулпан. Арыдым мин, Гөлназ. Эш күп. Өстәвенә бер авыруым үлде.

Гөлназ. Ничек?

Чулпан. Гемофилик иде. Талагына кан сауган. Операция өстәлендә ук һәлак булды. Бик коткарасым килгән иде шул авыруны.

Гөлназ. Син инде талакка операция ясыйсың!

Чулпан. Мин ассистент булдым. Бер уйласаң — без врачлар шундый көчсез әле, Гөлназ. Үлемне җиңү өчен бик күп, бик күп эшләргә кирәк әле. Бу бит шундый изге эш...

Гөлназ. Аспирантурага керергә җыенмыйсыңдыр бит?

Чулпан. Җыенмыйм. Ләкин фән өлкәсендә эшләүчеләргә сокланам мин. Алар минем өчен алла... (*тәрәзәдән карап*). Әллә ник әнкәй озаклады. Икмәккә киткән иде.

Гөлназ. Нигә син аны йөртәсең?

Чулпан. Үзе бит тыңламый. Шул әнкәй өчен өзгәләнүемне белсәң иде, Гөлназ! Сугыш вакытында шундый авыр чаклар була иде. Ачыга идек. Ә ул, мескен, карточкага чыккан икмәкнең үз өлешен дә миңа бирә, «син үсә торган кеше, сиңа күбрәк кирәк», дия иде. Әле дә күз алдымда: үзе ябык, үзенең күз төпләре шешенеп беткән булыр иде. Шулар искә төшкәч, тәннәрем чымырдый башлый... Ул минем өчен үзенең бөтен тормышын бирде. Үстерде, укытты. Бәлки, кызым үзе врач булгач, сәламәтләнермен дип өметләнгәндер. Бүген ничәсе соң әле безнең?

Гөлназ. Унҗидесе. Вакыт шундый озак уза! Кайта белмәде инде бу Гомәр дә.

Чулпан. Яратасыңмы?

Гөлназ. Алла белә. Әллә яратам, әлләияләштем генә. Хәер, ияләшү дә үзенә күрә мәхәббәт бит. Сагынам. Мин кайдадыр укыган идем. Якын кеше — сулый торган һава кебек. Янында чакта аны бар дип тә белмисең. Ә булмаса!.. Карале, Вилдан гипертонияне дәвалау өчен ниндидер препарат тапкан икән. Бөтен журналлар шул турыда яза. Үсә, чукынган.

Чулпан. Нишләп? Ул бик талантлы. Ул академик та булыр.

Г ө л н а з. Син уйлыйсыңмы?

Ч у л п а н. Уйламыйм, ышанам.

Г ө л н а з. Үкенә ди ул хәзер.

Ч у л п а н *(әрнеп)*. Гөлназ, ник әле син боларны сөйлисең?

Г ө л н а з. Оныталмыйсың, шулаймы? «Яшь вакытта кемне сөйсәң — күңелең шуңарда була» дип тикмәгә генә җырламыйлар шул.

Ч у л п а н. Үзен күрмәгәндә болай ук түгел иде.

Г ө л н а з. Түгел дип бит инде..., туктале. Каян синдә шундый уйлар, Чулпан?!

Ч у л п а н. Уйлар безгә буйсынмыйлар. Алар үзләре киләләр.

Г ө л н а з. Чулпан! Нәрсә сөйләгәнеңне ишетәсеңме син? Кешеләрдән оял ичмаса, менә бездән.

Ч у л п а н. Нәрсә ул кешеләр! Алар безгә тормыштагы адымнарыбызга карап бәя бирәләр. Ә йөрәк кешеләргә күренми.

Г ө л н а з. Йөрәк дип инде ул кадәр. Тик үкенеп йөрсен. Аңа шул кирәк... *(Сәгатенә карап.)* И, күпме такылдаганмын. Кайтыйм. Гомәр булмагач, кайтасы да килми. Өй буп-буш.

Ч у л п а н. Икенче кил, Гөлназ. Онытма. *(Гөлназ чыга. Чулпан өй эше белән мавыга. Пауза. Ишек шакыйлар.)* Кем ул? *(Вилдан керә.)* Тагын килдегезме?

В и л д а н. Әйе.

Ч у л п а н. Кабат әйтәм: мине эзәрлекләмәгез, Вилдан.

В и л д а н. Илдар кайтмадымы?

Ч у л п а н. Нәрсәгә ул сезгә?

В и л д а н. Их, Чулпан! Бер генә сәгатькә элекке Чулпан булып сөйләшсәң икән.

Ч у л п а н. Элекке Чулпан юк, Вилдан.

В и л д а н. Көнозын канаты сынган кош кебек йөрим дә, шушында киләм.

Ч у л п а н. Ә сез алай булмагыз. Сез бит югары оча торган кош.

В и л д а н. Авыр миңа, Чулпан. Әгәр син Илдар белән бәхетле булсаң — бәлки болай булмас иде. Ләкин сине шушы мохитта күреп... Күр инде бу бүлмәне: Биредә нинди бәхет торсын!

Ч у л п а н. Сез бәхетне үзегезчә аңлыйсыз.

Вилдан. Нинди ахмак мин! Икебезне дә бәхетсез иттем.

Чулпан. Китегез.

Вилдан. Куасың. Соңгы вакытта мин үземне сиңа өйләнмәвем өчен пинәли идем. Димәк, ялгышам. Әгәр син шулай тиз оныта алгансың икән...

Чулпан. Сезнеңчә, мин гомер буе көтеп утырырга тиеш идеммени? Яисә, яратмавыгызны белгәч, суга ташланырга, асылынырга? Юк.

Вилдан. Ә мәхәббәт, Чулпан?

Чулпан. Мәхәббәт. Элек без уйлаган мәхәббәт юк ул, Вилдан. Без мәхәббәтне аңламаганбыз.

Вилдан. Димәк, хәзер дә аңламыйм. Ирлегемне, горурлыгымны онытып, синең янга килләм. Каршыңа басып, шушындый сүзләрне тыңлыйм. Синеңчә, бу да мәхәббәт түгелме? Алайса, мине бирегә нәрсә китерә?

Чулпан. Эгоизм. Тормышка чыккач, башканыкы булгач, сездә шул хис уянган.

Вилдан. Дөрес түгел. Мин сине һәрвакыт ярата идем. Яңа мавыгулар, яңа тәэсирләр алдады мине.

Чулпан. Шулай гына микән. Безнең соңгы очрашуыбыздан соң, мин Илдарга чыкканчы, елдан артык вакыт үтте. Яңа тәэсирләрдән айну өчен кечкенә срок түгел. Ни өчен сез хатыныгызны ташладыгыз?

Вилдан. Чөнки сине яратам. Чөнки мин синнән башка яши алмыйм.

Чулпан. Нинди көлке!

Вилдан. Әйе, көлке дә, кызганыч та. Ләкин мин бу сүзләрне чын күңелдән әйтәм. Ялгыштым мин, Чулпан. Ул вакыт мин синең аспирантурага керүеңне теләгән идем. Минем хыялым сине үзем белән янәшә, фән эшчесе итеп күрү иде. Күңел сүрелүгә дә, ихтимал, шушы сәбәп булгандыр.

Чулпан. Бәлки, сез хаклысыз.

Вилдан. Юк, Чулпан, хаклы түгел. Кешенең тормыштагы урыны — күңеленә ошаган җирдә. Практик врач булып эшләү сиңа ошый икән — димәк, синең урының шунда. Алай гына да түгел. Сиңа медицинаның да ошамавы мөмкин. Син бит сәнгать кешесе. Энә белән могҗизалар эшлисең син. Ничек шуны күрмәгәнмен!— Акылым җитми.

Чулпан *(әрну белән)*. Кайчандыр сездән бу сүзләрне шундый көткән идем! Ниһаять, ишеттем. Тик соң.

В и л д а н. Соң түгел әле, Чулпан.

Ч у л п а н. Соң. Соң! Китегез, Вилдан.

В и л д а н. Мин сиңа шулкадәр чит, ерак. Хәтта «син» дип эндәшергә дә теләмисең. Әйе. Кич була, таң ата, һәр туган көн безнең арабызны ераклаштыра. Ә йөрәк...

Ч у л п а н. Йөрәк! Сездә генәмени соң ул йөрәк!..

В и л д а н. Чулпан!

Ч у л п а н. Китегез.

В и л д а н *(уйлап)*. Китәм. Ләкин бер үтенечем бар. Чулпан! Бу коверыңны сат.

Ч у л п а н. Җүләр сез.

В и л д а н. Күпме сорасаң да бирәм.

Ч у л п а н. Юк. Йөрәк каны һәм күз нуры белән сугарылган хезмәт бернинди бәягә дә сатылмый.

В и л д а н. Алайса, бүләк ит. Кайчандыр булган мәхәббәтебез хөрмәтенә. Ул миндә синең төсең булып калыр.

Ч у л п а н. Мин аны Илдарга атап чиктем. Минем өйрәнчек чигешләремә беренче булып ул бәя бирде. Минем дә беренче эшем аңа. Китегез. Минем барасы җирем бар.

В и л д а н. Кая барасың?

Ч у л п а н. Әнкәй кайтмый. Икмәккә киткән иде.

В и л д а н. Тышта җиләс. Өстеңә ки. *(Чулпан өстенә кофта кия.)* Ул гына юка. Пальто ки. Теге мин ярата торган пальтоңны.

Ч у л п а н. Юк ул.

В и л д а н. Кая китте?

Ч у л п а н. Туздырды.

Вилдан белән Чулпан икәүләп ишеккә баралар. Кулына сумка тоткан Фатыйма керә. Ул, Вилданны күреп, туктап кала һәм бер-ике минуттан чайкалып китә дә егыла: Вилдан белән Чулпан аңа ташланалар.

В и л д а н *(Фатыйманың кулларын күтәргәләп карап)*. Инсульт.

Ч у л п а н. Инсульт?! Әнкәй! Әнкәй бәгырем!!!.. *(Елап, Фатыйманың өстенә ташлана.)*

П ә р д ә.

5 КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә.

Ч у л п а н ялгыз. В и л д а н керә.

В и л д а н. Чулпан!

Ч у л п а н. Нәрсә кирәк сезгә?!

В и л д а н. Син! Миңа син кирәк, Чулпан!

Ч у л п а н. Ничәмә генә килсәгез дә, минем җавабым бер булачак: китегез.

В и л д а н. Кума мине, Чулпан. Әгәр кайчан да булса мине яраткан булсаң һәм ул мәхәббәт синдә кечкенә генә булса да бәхет китерсә — кума мине. Теләсәң нишлә минем белән. Ләкин аяк эзләрең суынырга өлгермәгән идәннәргә басып, синең сулышың катнашкан шушы һаваны сулаудан мәхрүм итмә. *(Чулпанның кулыннан ала һәм алдына тезләнә.)*

Ч у л п а н. Торыгыз. Ир хатынына мондый сүзләр сөйләргә сезнең хакыгыз юк.

В и л д а н. Хакым бар, Чулпан. Чөнки син иреңне яратмыйсың.

Ч у л п а н. Китегез. Мин больницага барам. Әнкәй үлем түшәгендә ятканда сезнең зарыгызны тыңларга вакытым юк.

В и л д а н. Арттырма. Әнкәң үлем хәлендә түгел.

Ч у л п а н. Ә бу сезгә ничек билгеле?

В и л д а н. Мин булдым анда.

Ч у л п а н. Больницада! Кем рөхсәте белән?

В и л д а н. Хәл белергә бардым.

Ч у л п а н. Ничек сез әрсезләнәсез! Мин сезгә анда барып йөрүне тыям.

В и л д а н. Ул хәзер сөйләшә. Кешеләрне таный.

Ч у л п а н. Сездә вөҗдан дигән нәрсәнең тамчысы да юк, күрәсең. Аның урынга ятуына да сез сәбәп. Сезне күргәч, минем сезнең белән булуымны күргәч, миенә кан йөгерде аның.

В и л д а н. Ихтимал. Шуның өчен мин үземнең гаебемне акларга телим. Яратасыңмы син әнкәңне?

Ч у л п а н. Яратсам.

В и л д а н. Телисеңме — мин аны үзем дәвалыйм.

Ч у л п а н. Нәрсә белән?

Вилдан. Үзем уйлап тапкан препарат белән. Дөрес, ул әлегә коточкыч кыйммәт. Ләкин синең анаң өчен *(басым ясап)*, синең өчен кызганмаячакмын. Ул терелячәк.

Чулпан. Сез йөрәкнең нечкә кылларында уйнамагыз.

Вилдан. Гомер буе авырып, тенкәсе корган бичараның. Якты дөньядан туйган. Врачлар берәр порошок биреп, үләргә булышсалар — рәхмәт укыр идем, ди. Җәфалама үзеңне, Чулпан. Бул миңа. Без апы терелтербез. Ә синең үзеңне мин алтынга маначакмын. Мин сине өрмәгән җиргә дә утыртмам. Теләсәң — врач булып эшләрсең. Теләмәсәң — тормышымның бизәге булып, өемдә утырырсың. Бередә синең бөтен хыялларың һәлак була. Чулпан! Яратасың бит син мине. Күзләрең, кашларың, иреннәрең, барысы-барысы шуны сөйли. Кил. Алдыңа килгән бәхеттән баш тартма.

Чулпан. Бәхет. Нигә инде дөньяда булмаган нәрсә турында сөйләргә!

Вилдан. Юк, бәхет бар, Чулпан. Исеңә төшер. Кайчандыр без бәхетле идек.

Чулпан. Мөмкин түгел. Анда Илдар — минем ирем. Соң, соң исеңә төшердең, Вилдан!

Вилдан. Соң түгел әле. Синең бөтен тормышың алда. Ә ул — теләсәң, җәннәт шикелле гүзәл булачак. Үзеңне һәлак итмә. Калдыр син бу тормышны, Чулпан, оныт. Бөтен үткәннәреңне оныт!

Чулпан. О, үткәнне онытырлык түгел, Вилдан!

Вилдан. Шуның өчен дә бит алдыңа тезләнәм. Кичер, Чулпан! Ташкын вакытында елга да ыргылып ярларыннан чыга. Ләкин ул яңадан үзенең элекке эзенә төшә. Кош та, гөлен ташлап, читкә оча һәм һавага күтәрелеп сайрый. Ләкин ул да үзенең гөленә кире кайта. Мин дә шулай. Син минем гөлем. Синнән башка тормыш юк миңа.

Чулпан. Юк! Юк, юк, юк. Ярабби, шушындый сүзләрне тыңлаган өчен ничек мине җир күтәреп тора!

Вилдан. Ялгызлыкның авырлыгын белсәң иде, Чулпан! Ялгыз булгач, уныш та, шатлык та, шөһрәт тә күзгә күренми. Уртаклашыр кешең булмагач, аларның нигә кирәге бар! Кая гына барсам да, кайда гына булсам да — күңелдә бушлык. Шәһәрнең һәр урамы, урамнарга җәелгән һәр таш синең белән булган бәхетле ми-

нутларны хәтерләтә. Кайсы гына бакчага кермим — мәхәббәтебезнең шаһитлары булган агачлар синең исемеңне кабатлыйлар...

Чулпан. Яратмыйсың син мине! Әгәр яратсаң — газиз анам үлем түшәгендә ятканда мине болай газапламас идең.

Вилдан. Кичер, Чулпан. Тик әйт, бер генә сүз әйт. Һәм мин китәчәкмен.

Чулпан. Мөмкин түгел. Безнең арабызда упкын. Упкын!

Вилдан. Нинди упкын ул? Әгәр сине миннән шул упкын гына аерып торса — әйт. Ул ничек кенә котырынып акса да, мин аны җиңәрмен һәм, дулкыннарын ярып, синең янга чыгармын.

Чулпан. Мөмкин түгел...

Вилдан. Чулпан!

Чулпан *(бераздан)*. Мин ана булачакмын. *(Пауза.)*

Вилдан. Ләкин аннан җиңел котылып була.

Чулпан. Син акылыңнан язган!

Вилдан. Нигә?

Чулпан. Гомердә дә! Гомердә дә мин моны эшләмәячәкмен!.. Иреннәрем кипте.... *(Вилдан тиз генә графиннан стаканга су агызып китерә. Чулпан бер генә йота да туктый.)* Бу су кайдан?

Вилдан. Графиннан.

Чулпан *(тагын берничә йотып)*. Бу су кайдан?

Вилдан. Графиннан.

Чулпан *(стаканны куеп)*. Ни булды миңа! Туганнан бирле эчеп килгән су да бүген әллә нинди, ачы.

Вилдан *(сарылып)*. Чулпан!

Чулпан *(Вилданның кочагыннан ычкынып)*. Ярабби! Мин сине яратам. Шуның өчен дә дөньяда иң изге нәрсәләр — газиз анам һәм туачак балам белән, мәхәббәтем белән, синең һәм үземнең мәхәббәтем белән ялварам. Мине җинаятькә сөйрәмә, кит...

Вилдан *(Чулпанга сарылып)*. Мәхәббәт җинаять түгел, Чулпан!

Чулпан. Ярабби!..

Вилдан. Без яратабыз! *(Тәмам хәлсезләнгән Чулпанны күкрәгенә кыса һәм иреннәреннән үбә.)*

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

6 КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә.

Вилдан ялгыз

Марзия *(ишектә)*. Мөмкинме? *(Керә.)* Хәерле көн!

Вилдан. Исәнмесез.

Марзия. Чулпан кайда?

Вилдан. Утырыгыз. Хәзер кайтыр.

Марзия *(утыра)*. Әллә сез яна квартирага күчтегезме?

Вилдан *(төшенеп)*. Ә, юк.

Марзия. Килешми, Вилдан.

Вилдан. Сез нәрсә турында?

Марзия. Бар иде вакыт. Чулпан сезне ярата иде.

Вилдан. Ул хәзер дә ярата.

Марзия. Шундый җәберне дә онытса — җүләр булыр.

Вилдан. Мәхәббәт оныттыра.

Марзия. Ә сез мәхәббәт белән уйнамагыз. Чулпан ир хатыны. Аның законлы ире бар.

Вилдан. Мәхәббәт законнарны үзе чыгара, үзе юк итә. Безнең йөрәкләребезне бәйләгән мәхәббәт җепләре загс дәфтәрендәге законлы язудан ныграк.

Марзия. Сез үзегезгә артык ышанасыз.

Вилдан. Мәхәббәтне анламасагыз, иптәш Абдуллина, башкаларны да хөкем итмәгез. Мин Чулпанны яратам. Ул минем бөтен тормышым, бар шатлыгым, сулый торган һавам. Чулпан да мине ярата. Бер-беребездән башка тормыш юк безгә.

Хат ташучы керә.

Хат ташучы. Сезгә телеграмма.

Вилдан кул куеп ала һәм телеграмманы ача. Хат ташучы китә.

Марзия. Ул бит сезгә түгел.

Вилдан. Борчылмагыз. Безнең серләребез юк. *(Телеграмманы укый. Төсе үзгәрә, ләкин үзен тыныч тотарга тырыша.)* Укыгыз. *(Телеграмманы Марзиягә суза.)*

Марзия. Кирәкми.

Вилдан. Укыгыз. Илдар кайта.

Марзия *(телеграмманы тартып ала да укый).* «Каршыла. Икенче август. Тукай пароходы» *(телеграмманы өстәлгә куеп, ашыгып чыгып китә. Вилдан ялгыз. Ул тагын бер кат телеграмманы укый да өстенә киенә. Яңадан утыра. Йөзендә борчу. Әледән-әле сәгатенә карый һәм нервланып, бармаклары белән өстәлгә бәргәли. Тора, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә. Чулпан керә. Кулында сумка һәм георгин чәчәкләре).*

Чулпан. Нишләп киенгәнсең әле? Чишен. Нинди матур чәчәкләр, ийе?

Вилдан. Каян алдың?

Чулпан. Магазиннан *(иснәп).* Тик бөтенләй иссез. *(Чәчәкләрне вазага утырта.)* Матурмы?

Вилдан. Юк-барга акча туздырырга яратасың син, Чулпан.

Чулпан. Вилдан! Аларның бәясе ике сум. *(Кечерәк пауза.)* Я, ярар. Үземнең акчам булгач та, мин сиңа бу ике сумны түләрмен. Яме.

Вилдан. Эш анда түгел, Чулпан. Безгә бик күп акча кирәк булачак. Синең пальтоң начар, күлмәкләрең юк.

Чулпан. Мин синнән бер нәрсә дә сорамыйм.

Вилдан. Син алай димә. Минем таныш-белешләрем, йөрешә торган кешеләрем галимнәр, югары катлау кешеләре. Мин сине аларга бу килеш күрсәтә алмыйм бит.

Чулпан. Ә син моны элек үк белә идең. *(Пауза.)* Әллә нинди син. Элек мондый түгел идең кебек. Әллә син үзгәргәнсең, әллә минем күреп җиткерелмәгән... Чишен. Юк өчен сүз куптармыйк. Һаман болай булмас әле. Тагын ярты ставка алырмын. Кирәк икән — көне-төне эшләрмен. Чәчем белән җир себерермен, ләкин синең битеңә кызыллык китермәм.

Вилдан. Акчаны табарга өйрәнгәнче, тота белергә өйрәнергә кирәк, Чулпан. Кил *(кесәсеннән кечкенә тартма чыгара).* Бу сиңа. Бриллиант кашлы алка. *(Чулпанның колагына алка тага һәм читкәрәк китеп, зур соклану белән, комсызланып карый.)* Менә! Хәзер инде бу алка янына яхшы күлмәк тә кирәк. *(Чулпанны күкрәгенә кыса.)* Ә нигә син шатланмыйсың, Чулпан? Яратам бит мин сине. Шуңа дөньядагы барлык хатыннардан чибәррәк итәсем килә *(үбә).* Яратасыңмы?

Чулпан. Синең өчен мин вөҗданны, оятны, намусны оныттым. Һаман азмы?

В и л д а н. Ышанам, Чулпан. Ышанам. Ә хәзер бер нәрсә эшлибез. Син әзерме?

Ч у л п а н. Синең өчен җанымны бирергә дә әзер мин. Нәрсә ул?

В и л д а н. Хәзер үк безгә күчәбез.

Ч у л п а н. Ләкин бүген әнкәйне алып кайтасы бар.

В и л д а н. Бәлки, кирәкмәс, Чулпан.

Ч у л п а н. Ничек кирәкмәс?

В и л д а н. Әнкәңне әйтәм. Беләсеңме, аның белән читен булачак безгә. Ул безнең кулларыбызны бәйләячәк.

Ч у л п а н. Ләкин син аны дәваларга тиеш.

В и л д а н. Булмый, Чулпан. Препаратка мин хуҗа түгел хәзер.

Ч у л п а н. Ләкин син сүз бирдең!

В и л д а н. Югарыдан санкция алмый торып, бер генә миллиграммын да туздырырга хакым юк.

Ч у л п а н. Аны барыбер алып кайту кирәк булачак. Һаман больницада ятмас бит.

В и л д а н. Нигә? Ята бирсен. Яисә, беләсеңме нәрсә, әйдә без аны хрониклар йортына урнаштырыйк.

Ч у л п а н. Үз кызы була торып хрониклар йортына, син нәрсә — акылыңдамы?

В и л д а н. Акылымда. Анда начар түгел. Аннан, күп яшисе калмаган бит инде аның. Үлә бит ул.

Ч у л п а н. Үлсә — үз кулымда үләр.

В и л д а н. Юк, Чулпан. Син аңла. Ул бит урыныннан да тора алмый. Ул безнең бөтен тормышыбызның ямен җибәрәчәк...

Ч у л п а н. Ярабби! *(Елап.)* Юк! Мең мәртәбә юк. Ниһаять, мин сине аңладым. Яратмыйсың син мине!..

В и л д а н. Чулпан!

Ч у л п а н. Эндәшмә?..

В и л д а н. Акрын. Син сүз бирдең. Синең өчен җанымны бирергә дә әзер, дидең. Инде тот сүзеңне. Мин сине яратам. Син минем хатыным булачаксың. Ләкин авыру анаң миңа кирәк түгел. Сайла — кем сиңа якынрак: анаңмы, сөйгән ярыңмы?

Ч у л п а н. Яратмыйсың син мине! Әгәр яратсаң — газиз анамны хрониклар йортына бирергә теләмәс идең. Мине тудырган һәм үстергән өчен анамны да яратыр идең.

В и л д а н. Юк, син әйт: кем кадерлерәк?

Ч у л п а н. Мин сине шашып яраттым. Ләкин һәрбер

акылсызлыкның чиге бар. *(Алкаларын салып идәнгә ташлый.)* Кит моннан!

Вилдан. Без бергә китәбез.

Чулпан. Юк.

Вилдан *(телеграмманы суза)*. Синең башка юлың юк.

Чулпан *(укып)*. Илдар! Бүген ничәсе? Ярабби, тиздән ул монда булачак. Нишләп телеграмманы соң китергәннәр!..

Вилдан. Каршы төшәргә җыенмыйсыңдыр бит? Әйдә.

Чулпан. Үлсәм дә!

Вилдан. Ярый, алып кайтырбыз әнкәңне. Әйдә. Азрак битеңне ю да...

Чулпан. Бу хурлыкны йөздән юар өчен Иделнең дә суы җитмәс!

Вилдан. Җитмәсә, Болакта юарсың. Әйдә.

Чулпан. Кит! Син мине алдадың. Ләкин тормышны алдый алмассың. Тормыш сиңа тиешле бәяне бирер.

Вилдан. Чулпан...

Чулпан. Югал моннан! Мин сине күралмыйм, ерткыч!

Чулпан үксеп, кроватька каплана. Пауза. Вилдан, идәндәге алкаларны алып, чыгып китә. Марзия керә.

Марзия. Син әле китмәдеңмени, Чулпан?

Чулпан. Ә, кая?

Марзия. Пристаньга. Телеграмманы күрдеңме?

Чулпан. Ә, әйе, әйе. Хәзер. Син гастрольдән кайттыңмыни?

Марзия. Без кичә кайттык... Ни булды сиңа, Чулпан?

Чулпан *(Марзиянең күкрәгенә капланып)*. Марзия апа!..

Марзия. Бая мин биредә Вилданны очраттым. Димәк, дөрес?

Чулпан. Бетте, барысы да бетте.

Марзия. Нишләп? Ул сине ярата бит.

Чулпан. Ярата! Йөрәксез кеше ярата беләмени!

Марзия. Сезнең мөнәсәбәтләр шулай ерак кердемени?

Чулпан. Сорама, Марзия апа, сорама, бәгырем! Ярабби, ничек ялгышырга мөмкин!..

Марзия. Их, Чулпан!..

Чулпан. Яратканмын бит мин аны. Мәхәббәт мине һәлак итте.

Марзия. Әйе. Мәхәббәттән акылсызлыкка бер генә адым. Ләкин ул адымны атламаска мөмкин.

Чулпан. Мөмкин түгел. Мин тырыштым. Мин аны ничә мәртәбә куып чыгардым!..

Марзия. Исеңдәме, Чулпан, Сабан туе иде? Син үзеңне иң бәхетсез кешегә санап, өйдә утыра идең. Шул вакыт Илдар килде һәм сине гөрләп торган тормыш эченә — Сабан туена алып чыкты.

Чулпан. Инде бу хурлыктан мине берәү дә алып чыкмас. Беттем, һәлак булдым... Инде ничек Илдарга күреним!

Марзия. Юк, Чулпан. Инде моннан соң Илдарның йөзенә карарга хакың юк синең. Мин синнән күп яшердем, җитәр. Мин дә Илдарны яратам. (*Чулпан шаккатып Марзиягә карый.*) Ләкин ул сине яратты. Шуңа мин мәхәббәтемне яшереп йөрдем. Ә хәзер — юк. Мин аны яратам. Илдар минем белән бәхетле булачак. Бар кит, Чулпан.

Пауза. Марзия чыга.

Чулпан (*Марзия артыннан*). Марзия апа!..

Зур пауза. Чулпан, кая барып бәрелергә белмичә, бүлмә буйлап йөри. Аннан, чынаякка су агызып, су эчә. Шул арада ишек ачылып китә һәм анда кулына чемодан тоткан Илдар күренә. Чулпанның чынаягы төшеп китә.

Илдар. Чулпан!

Чулпан. Илдар!

Илдар (*чемоданын ташлый һәм йөгереп килеп, Чулпанны күкрәгенә кыса*). Чулпан! Сине күрер көнем дә бар икән. Нәрсә, чынаяк та ватылдымы? Әйбер ватылса шатлыкка диләр иде, дөрес икән. Нигә каршы төшмәдең? Телеграмманы алдыңмы?

Чулпан. Ийе... Хәзер генә. Мин өлгермәдем.

Илдар. И, син бит тагын да матурлангансың, Чулпан! (*Чулпанны кочагына күтәреп әйләндерә һәм, үзенүзе белми, чәчләреннән, битләреннән, күзләреннән үбә башлый. Ул да булмый, Чулпанны каты итеп күкрәгенә кыса, ләкин шунда ук җибәрә.*) Онытканмын, Чулпан.

Юл буе уемда шул булса да, онытканмын. Кичер. Кем булыр икән? Кыз булсын. Йөзенә синең матурлыгың күчкән, синеке төсле ландыштан ак, мәктән алсу йөзле кыз булсын. Картлык синең битеңне җыерчыклар белән күмсә дә, матурлыгың кызыбызда саклансын. Тукта әле. Миндә аңа бер әйбер бар. *(Чемоданнан бик матур бала юрганы ала.)* Менә. *(Юрганны балага ошатып төрә дә сакланып кына күтәрә. Аннан шаян көйгә көлә-көлә бишек җыры җырлый.)*

Йокла, балам, алтыным,
Йокла, йөрәк ялкыным,
Кояштан якты йөзең,
Йокла, йокла, йом күзең.
Җанымның куанычы,
Күңелемнең юанычы,
Йокла, төшер керфегең,
Минем энҗе бөртегем.

(Шаркылдап көлеп, юрганны кровать өстенә ташлый.) Их! Дөньяда бүген миннән дә бәхетлерәк кеше бармы икән! Шатлыгымнан бөтен дөньяны үбеп чыгар идем.

Чулпан *(нәрсә әйтергә белмичә)*. Син инде бетереп кайттыңмы?

Илдар. Әйе. Иртәгәдән отпуск. *(Кесәсенә кереп.)* Минем сиңа да бүләгем бар бит әле. Нәрсә дип беләсең?

Чулпан. Белмим шул. *(Чулпанга сәгать күрсәтә, кулына такмакчы була.)*

Чулпан. Хәзер кирәкми, Илдар. Куеп тор.

Илдар. Нишләп?

Чулпан. Эш беткәч тагармын.

Илдар. Гомәр пьесасын язып бетергән бит. Пристаньга күтәреп төшкән *(чемодан чехолы эченнән пьеса чыгара)*. Менә ул. Ничек килеп чыккан икән... *(Пьесаны актара башлый.)*

Чулпан. Тукта..., чәй куйыйм.

Илдар. Кирәкми, Чулпан. Хәзер миңа чәй-мәй күренми. Башта пьесаны укыйбыз. Аннан — чәй. Бу бик кызык булырга тиеш. Мин аның героена гашыйк, Чулпан. Әгәр ышанып миңа тапшырсалар — мин аны шундый итеп уйнармын!

Чулпан. Алдан кычкырма. Синең әле андый зур рольләрне уйнаганың юк.

Илдар. Ә менә хәзер уйнаячакмын. Мин үземдә бетмәс-төкәнмәс көч сизәм. Чөнки мин бәхетле. Чөнки

мин яратам. Син менә шунда утыр, минем каршыма. Кил *(Чулпанны ике кулыннан ала).* И, үз күзләремә үзем ышанмыйм. Ниһаять, синең янга, Чулпаным янына кайттым. Мәхәббәтем канатларында очып кайттым мин, Чулпан! Кил, утыр.

Чулпан. Юк, кирәкми.

Илдар. Ник?

Чулпан. Кирәкми. Ярамый.

Илдар. Ярамаса яратабыз аны. *(Чулпанны кочакламакчы була.)*

Чулпан. Кирәкми...

Илдар. Җылыйсың! Ник?

Чулпан *(бераздан).* Бу хәбәрне ишетү сиңа авыр булачак, Илдар... Ләкин шулай кирәк...

Илдар. Әйтәсе сүзең булса — тизрәк әйт. Әллә ниләр уйлатып, мине газаплама.

Чулпан *(җәфаланып).* Кыскасы, мин китәм, Илдар.

Илдар. Кая китәсең?

Чулпан. Күзем кая караса — шунда. Ул... син киткәч, тагын килде. Һәм мин... алмаштырдым сине...

Илдар *(башына суккан кебек катып кала. Пауза. Исенә килеп.)* Чулпан мине ятка алмаштырган. Мөмкинме бу?! *(Кечерәк пауза. Чулпан ишеккә юнәлә.)* Ә бала?

Чулпан. Илдар...

Илдар. Тукта! Әгәр син китсәң — синең белән минем балам да китәчәк. Ул туар, үсәр. Ә кемнәр аңа ата булыр? Сабыр ит, бәлки, берәр юлы бардыр... *(Чулпан нәрсәдер әйтергә тели, ләкин әйтә алмый, түземен җуеп, ишеккә ташлана.)* Тукта диләр сиңа! Җанкашең янына ашыкмасаң — сабыр ит. Ятимлекнең нәрсә икәнен беләм мин. Көләсе килгән кеше көлсен. Ләкин мин, җирдәге ятимнәрнең санын арттырмас өчен, бу хурлыкны күтәрергә риза.

Чулпан. Илдар!

Илдар. Дәшмә!

Чулпан. Ярабби!..

Илдар. Тиздән балабыз туар һәм ул, кояш кебек балкып, синең корымлы йөзеңне яктыртыр.

Чулпан. Бала юк, Илдар!..

Илдар *(Чулпанның изүенә ябышып).* Бәлки, мин ялгыш ишеткәнмен. Кабатла.

Чулпан. Юк, ялгыш түгел.

Илдар. Ә кайда минем балам?

Чулпан. Биредә минем гаебем юк. Мин больницага ашыга идем, әнкәй янына. Ул мине мотоциклга утыртып китте. Юлда без егылдык...

Илдар (*Чулпанны этәреп*). Җирәнәм мин синнән...

Чулпан. Сиңа авыр, Илдар. Ләкин мин ышанам, син бу кайгыны зурныклык белән кичерерсең. Син көчле кеше...

Илдар. Юатма. Елга үзенең төче суын диңгезгә күпме генә койса да, диңгез суының ачысын киметә алмый. Минем хәсрәтем дә шулай: киң һәм ачы.

Чулпан. Ләкин син, бернинди давылдан да курыкмаучы кораб кебек, күкрәгең белән тормыш дулкыннарын ярып, алга — туп-туры үзеңнең максатыңа йөзәсең. Ә мин алай түгел. Минем бичара көймәмне дулкыннар кая теләсәләр — шунда ташлыйлар. Алар белән көрәшү чиксез авыр миңа. Ләкин мин өметемне өзмим. Кайчан да булса бер, зур читенлекләр белән булса да, мин дә үземнең максатыма йөзеп барып җитәрмен. Хуш, Илдар!

Чулпан китә. Илдар нәрсә әйтергә белми басып тора. Пауза.

Акрын гына пәрдә төшә.

1955

ЕГЕРМЕ ЕЛ ҮТКӘЧ

Бер пәрдәле драма

КАТНАШАЛАР:

Ана.
Төенчек күтәргән хатын.
Бала нәрткән хатын.
Хатын.
Ир кеше.

Автобус тукталышы. Өстенә түбә корылган утыргычта Ана утыра. Янында искереп беткән будильник сәгать. Вакыт — җәй. Төенчек күтәргән хатын керә.

Төенчек күтәргән хатын. Нихәл, әбекәй!.. (*Утыргычка килеп утыра.*) Ерак барасыңмы?

Ана. Мин баручы түгел, кызым, мин каршы алучы... Син кайсы авылныкы?

Төенчек күтәргән хатын. Петровкадан мин, район үзәгенә барам. Автобус тиз булыр микән?

Ана (*будильнигына карап*). Ярты сәгатьтән килеп җитәргә тиеш.

Төенчек күтәргән хатын. Культмагка якут кашлы йөзекләр кайткан дигәннәр иде, сатып бетермәгән булсалар ярый инде... Кемне каршы аласың?

Ана. Улымны каршы алам. Сугышта югалган улым кайта.

Төенчек күтәргән хатын. Ничек инде ул алай?

Ана. Менә шулай. Мин аны, бәбекәчемне, сугышта үлде дип саный идем. Бактың исә, үлмәгән икән. Исән-сау икән. Менә кайтып та килә, бәбекәчем.

Төенчек күтәргән хатын. Шул тиклем гомер үткәчме?!

А н а. Әйе! *(Төенчеген чишә-чишә.)* Сезнең Петровкада газета укымыйлар мәллә? Ишетмәдегезмени? *(Берничәгә бөкләнгән газета чыгарып, Төенчек күтәргән хатынга суза.)* Мә, укы... Менә шул җирен!

Төенчек күтәргән хатын *(укый)*. «Егерме ел үткәч... Бөек Ватан сугышы елларында иптәш Сидоров А. П. пленга төшә. Фашистлар Германиясе җиңелгәч, ул Америка Кушма Штатларына барып эләгә. Анда аны Америка разведкасына хезмәт итәргә үгетлиләр, ләкин ул баш тарта... Чит-ят илдә иптәш Сидоров уналты ел газап чигә, ләкин совет кешесенең рухын берничи кыенлыклар да сындыра алмый. Быел яз ул үзе турында Вашингтондагы Совет илчелегенә хәбәр итә. Күз тегәп көтеп алган көн килеп җитә — батыр якташыбыз үзенең туган иленә кайтты. Берничә көннән ул Имәнлек поселогына кайтып төшәчәк. Анда аның егерме ел буе күрмәгән семьясы яши...»

А н а. Дөрес санап чыгарганнар, рәхмәт төшкерләре! Арыш урагына төшкәч, нәкъ егерме ел була. Кырык беренче елның арыш урагы өстендә алганнар иде үзен. Унсигез яшь тулган гына иде әле.

Төенчек күтәргән хатын. И, нинди зур шатлыгың бар икән ләбаса, әбекәй! Күр инде! *(Газетаны карап.)* Рәсемен бастырып чыгармаганнар шунда.

А н а. Тиздән үзен күрәм, аллаһы теләсә!

Төенчек күтәргән хатын. Телеграмма суккандыр инде.

А н а. Нинди телеграмма?

Төенчек күтәргән хатын. Кайчан кайтып төшәсен әйтеп. Кайдан белеп килдең соң каршы алырга?

А н а. Ә мин, кызым, инде өченче көн көтәм. Газета килгәннән бирле. Автобус сәгать өчтә килә, ә мин инде иртәдән бирле утырам. Бәлкем, ул грузовой белән кайтып төшәр, белгән юк бит анысын. Газиз әйкәсен күрергә күңеле ашкына бит инде аның.

Төенчек күтәргән хатын. Телеграмма да сукмыйча кайтмас ул, әбекәй. Башта син телеграмма көт!

А н а. Нигә дип телеграмнар сугып торсын ул! *(Газетага күрсәтеп.)* Менә бит: берничә көннән Имәнлек поселогына кайтып төшәчәк, дигән.

Төенчек күтәргән хатын *(сокланып)*. Бәхетле ана икәнсең, әбекәй!

Ана. Бәхетле шул!

Төенчек күтәргән хатын. Фронттан яза идеме?

Ана. Кайдан?

Төенчек күтәргән хатын. Фронттан яза идеме дим, сугыштан!

Ана. Атна саен язып торды. *(Төенчегендә актарынып.)* Менә бит нихәтле! Менә бу зәңгәр конвертлысы — иң беренче хаты. Әле бусында сугышка барып та җитмәгән чагы, юлдан язган. Ә менә бу өчпочмаклысы — соңгысы. Кырык беренче елның егерменче декабрендә язган. Аннары немецлар килде, хатлар тукталды. Бер авыз сүз булмады. Бары кырык дүртенче елның мартында гына кәгазе килде, үзебезнекеләр кайткач.

Төенчек күтәргән хатын. Нинди кәгазь?

Ана. Нинди кәгазьләр килә иде соң ул елларда!

Төенчек күтәргән хатын. Кара печатьле кәгазьме?

Ана. Әйе! *(Төенчегеннән саргаеп беткән кәгазь кисәге чыгарып күрсәтә.)* Менә. «... Ленинград янында барган каты сугышларда сезнең улыгыз Сидоров Алексей Павлович батырларча һәлак булды...» Шулай язганмы?

Төенчек күтәргән хатын *(кәгазьне укып чыга да газета белән чагыштыра)*. Шулай. Тик газетада исеме белән этисенең исемен тулысынча язмаганнар икән...

Ана. Газетада урын аз шул анда...

Төенчек күтәргән хатын. И, нс китмәле хәлләр бар бу дөньяда! Үлем хәбәре дә килгән булган, ә ул сау-сәламәт килеш өйгә кайтып килә!

Ана. Син анысына гаҗәпләнмә, син менә нәрсәгә гаҗәплән. Кабере дә табылган иде бит! Өченче ел барып, үз күзем белән күреп кайттым. Ленинградтан ерак түгел бер авыл бар икән. Менә шул авылда мәктәп. Шул мәктәпнең ишек алдында бер кабер тапканнар. Укучы балалар карап торалар үзен — чардуган ясап куйганнар, чәчәкләр утыртканнар, су сибәләр... Ә ташка чокып, Сидоров Алексей Павлович дип бәбекәчемнең исемен язып куйганнар.

Төенчек күтәргән хатын *(сагая төшеп)*. Соң?

Ана. Бутаганнар, димәк. Азмыни халык кырылды! Азмыни дөньяда Сидоров фамилияле кеше — безнең

үзебездә генә дә ярты авыл Сидоров! Димәк, анда башка берәүне күмгән булганнар. Ә минем бәбекәчем исән! Менә кайтып та килә!.. *(Тирән сулап.)* Әтисе күрә алмады шул бу шатлыклы көнне...

Төенчек күтәргән хатын. Үлдемени?

Ана. Күптән! Фашистлар вакытында. Тазалыгы шәп түгел иде, күтәрә алмады.

Төенчек күтәргән хатын. Ул елларда күргәннәрне ходай күрсәтмәсен!

Ана. Нишләмәк кирәк! Шуның өчен сугыш шул инде ул. Исәндәдер... Син немецлар бар вакытта монда идеңме?

Төенчек күтәргән хатын. Юк! Мин эвакуациядә идем.

Ана. И-и, алайса, син берни белмисең... Китәр алдыннан әллә ничә җиргә ут салдылар, алланың каһәре төшәсе нәрсәләр. Бөтен поселоктан безнең Аргы як урам гына калды. Ә фабриканы бомба салып шартлаттылар... Хәзер инде поселокка карасаң, бу җирләрдә сугыш булган дип әйтерлек тә түгел. Әнә нинди фабрика салып куйдылар — карап туя алмассың. Ә юлның ниндиен салдылар! Бу җирләрдә окоплар иде ләбаса.

Төенчек күтәргән хатын. Юлны салуын салдылар да, автобуслары сирәк йөри...

Ана. Менә шул шул. Без гел канәгать итмибез, гел сукранабыз. Әле автобус сирәк йөри, әле кибеттәге икмәк искеребрәк киткән... Ә менә минем картымның үләр алдыннан әйткән актык сүзе шул булды: «Бер телем икмәк булса икән, әнисе. Бер телем икмәк булса, үзебезнекеләр килгәнче чыдар идем...» Йорт эчендә бер нәрсә калмады, барысын ризыкка алмашып бетердем... Менә кайта, бәбкәм, ә бит лисопедын сатканны белми. Өрҗәңа лисопедны биш кадак онга бирдем... Лисопед дисәң, үлеп китә иде инде, бәбкәм. Эштән йөгереп кайтып, аннан-моннан капкалап алыр иде дә лисопедына атланып чабар иде. Бервакыт мин җүләрне дә утыртып китте. Шук та иде соң инде яшь вакытта! Лисопедына менгезеп утыртты да урам буйлап чаптыра гына! Курыкканымны белсәң! Туктат, мин әйтәм, Алеша, йөрәгем чыгып төшә бит, дим. Ә ул, бәбкәм, мине менә шулай итеп кочаклаган да,— менә шулай,— курыкма, әни, чыгып төшмәс, ди. Бөтен урам бот чабып көлде үземнән! Ник җүләрләнеп утырганмын инде шуңа — исемә төшкәч, әле

дә булса хәйран калам... Үкенәм менә хәзер. Сатасы булмаган икән үзен.

Төенчек күтәргән хатын. Юк өчен картаеп утырма, әбекәй! Хәзер инде велосипед белән бала-чага гына уйный. Мотоцикл алыр.

Ана. Кайчан ала бит әле ул... Бүгенгә күрше малайныкын сорап торырмын инде. Аның лисопеды өр-яңа, гөлт итеп тора.

Төенчек күтәргән хатын. Анысы нәрсәгә тагын?

Ана. Ничек нәрсәгә? Әгәр дә аның лисопедка утырып поселокны әйләнеп кайтасы килсә? *(Пауза.)* Шулай да кайбер нәрсәләрс әле булса исән, бәбкәмнең. Чаңгысы да чорма башында эленеп тора. Аннары бер күлмәге бар. Ничек дип әйтәләр соң әле шуны? Матрослар кия торган юллы-юллы күлмәк. Яратып та кия иде соң шул күлмәген, бәбкәм! Мин аны сандыкта гына тотам. Бик ямансу көннәремдә алам да баш астыма куеп йоклыйм. Төшемә керсен дип.

Төенчек күтәргән хатын. Керәме соң?

Ана. Кайвакыт керә.

Сәхнәгә Бала ияртүән хатын керә. Ана белән Төенчек күтәргән хатынны күреп туктап кала. Берничә секунд юлга карап тора да бер кырыйга китеп чирәмгә утыра. Янына баласын да утыртып, аның киемнәрен тарткалап куя.

Төенчек күтәргән хатын. Ник монда килмисең?

Ана. Тсс!.. Ул да каршы алучы... Ире хәбәрсез югалды аның, кырык өченче елда.

Төенчек күтәргән хатын. Ә нигә эссе кояш астына барып утырды? *(Бала ияркән хатынга.)* Монда килеп утыр!

Ана. Тсс!.. Ничек дип әйтим инде сиңа... аның ире дә Сидоров иде бит. Исеме Андрей Петрович иде.

Төенчек күтәргән хатын. Соң, алайса...

Ана. Әйе, ул, бичара, ирем кайта дип уйлый.

Төенчек күтәргән хатын. Ә бала кемнеке?

Ана. Үзенеке.

Төенчек күтәргән хатын. Икенче иргә чыккан идемени?

Ана. Тсс! Юк аның ире.

Төенчек күтәргән хатын. Зинадан таптымыни?

Ана. Тсс! Еракка, урман эшенә китте дә ел дигәндә балага узып кайтты.

Төенчек күтәргән хатын. Күр әле оятсызны!

Ана. Без әле монда өчәү. Тагын бер кеше көтә. Анысының яраткан егете кайтмады... Әнә ул!..

Салмак кына атлап, Хатын керә. Өстендә ап-ак туй күлмәге, кулында чәчәкләр бәйләме. Хатын, күләгә шикелле, багана янына килеп баса да, чәчәкләрен күкрәгенә кысып, юлны күзәтә башлый.

Ана. Кияүгә дә чыкмады. Кыз көенчә картайды инде.

Төенчек күтәргән хатын. Алучысы булмагандыр. Сугыштан соң андыйлар күп.

Ана. Сорап йөрүчеләр булды. Үзе чыкмады. Яратуы көчле булган, димәк. Оныта алмый.

Төенчек күтәргән хатын. Әллә аның да егете...

Ана. Әйе, аның да егете Сидоров иде. Тегүче Афанасий малае Петр. Ә бу, бичара, газетада бутап язганнар, Сидоров П. А. диясе урынга Сидоров А. П. дип бастырганнар дип өметләнә. Өмет һәркемгә татлы, өметләнсен. Ул арада аның да Петясы кайтып килер, бәлкем. Бәлкем, минем Алешам аның турында берәр нәрсә беләдер. Күргәндер, очраткандыр, бәлкем. *(Будильникка карап.)* Сүз бозау имезә дигәннәр, сөйләшә торгач автобус килер вакыт та җиткән... Бер ай бер эш тә эшләтмичә ял иттерәм, бәбекәчемне. Аннары туй ясарбыз. Кыз күзләп куйдым инде.

Төенчек күтәргән хатын. Үзең тагын бигрәк өлгер икәнсең, әбекәй. Билгеле түгел бит әле, бәлки, әнә теге оятсызның ире кайтып киләдер.

Ана. Юк, бу минем улым кайта!

Төенчек күтәргән хатын. Бәлки, улыңның яраткан кызы булгандыр.

Ана. Юк! Сугышка киткәнче берәүне дә яратып өлгермәде ул! Яшь иде бит әле, унсигезе тулган гына иде!

Төенчек күтәргән хатын *(түбә астыннан чыгып, юлга карап ала. Бала иярткән хатын янына килә).* Ничек шулай килеп чыкты соң синең? *(Балага күрсәтеп.)* Ичмаса, бу нәмәрсәне табасың калмаган. Ирең

дә булмагач, нәрсәгә кирәк булды ул сиңа? *(Бала ияртkән хатын сөйләшәсе килмәүне аңлатып йөзен читкә бора.)* Күңелле хәл түгел. Күңелле хәл түгел! *(Ана янына килә.)* Бик тәкәббер нәмәрсә икән, сөйләшмәгән дә була.

Ана. Син кешене рәнҗетмә.

Төенчек күтәргән хатын. Рәнҗерлек булгач, нәфесенә хуҗа булсын иде!

Ана *(шелтә белән)*. Акрын дим! Әйбәт хатын, инсафлы хатын ул.

Төенчек күтәргән хатын. Зинадан бала тапкач, син миңа аның инсафын сөйләмә инде, әбекәй. Безнең авылда да шундый бер себерке бар, кеше ирләрен аздырып ята. Шулай да моның шикелле үк оятсыз түгел, бала тапмый. Күрәле, дөньяда булмаган хәл ләбаса бу! Зинадан туган баласын ияртеп, ирен каршыларга килгән! Бетте хәзер хатын-кызда оят. Берәү булса бу хурлыктан асылынып үләр иде! *(Бала ияртkән хатынга.)* Син әле, бәлки, ирең рәхмәт әйтер дип тә көтәсеңдер? Булдыргансың, гүзәлем, мин кайтканчы эшне киметеп куйгансың...

Бала ияртkән хатын. Житте сиңа!.. *(Баласын калдырып, төенчек күтәргән хатын янына килә.)* Синең балаларың бармы?

Төенчек күтәргән хатын. Бар!

Бала ияртkән хатын. Ирең дә бармы?

Төенчек күтәргән хатын. Булмаска! Мин синең шикелле зиначы түгел!

Бала ияртkән хатын *(җан әрнүе белән)*. Әйе, син зиначы түгел, синең ирең бар. Син ир белән торасың, көн саен иреңне кочаклап йоклыйсың һәм син зиначы түгел... Ә минем ирем юк. Ул сугышка киткәндә өйләнешүебезгә сигез генә көн иде. Китте дә юк булды. Мин аны унбиш ел көттем... Кайтмады... Ә минем бала табасым, ана буласым килде. Бала үстерәсем... Башларыннан сыйпап сөяр өчен, аның шатлыкларына шатланыр, көенечләренә көенер өчен. Мин дә кеше ләбаса!.. Минем дә башкаларныкы кебек кайнар йөрәгем бар... Менә ана! Үлгән хәбәре дә килгән, барып каберен дә күргән, шулай да көтә! Аның улы һәлак булган әлбәттә. Бу минем Андрюшам кайта. Ләкин ана да өметен өзми, көтә. Карт көнендә үлеп калган баланны

көтү шикелле генә дә юанычың булмаса, акылдан шашаргамыни?! Һәм ана көтә.

Төенчек күтәргән хатын. Соң, оятсыз...

Бала иярткән хатын (*бүлдереп*). Ә син кайчак төннәрнең ни тиклем озын булуын беләсеңме? Әйләнәсең, тулганасың, ә таң атмый да атмый. Һәм син бер ялгызың. Бүген ялгыз, иртәгә ялгыз, бер елдан соң да ялгыз. Гомер буе ялгыз!.. Зиначы дисең син. Юк, ирем алай әйтмәс. Ул аңлар. Менә кайтып кына төшсен. Без аның белән шундый итеп яшәрбез!

Ана. Юк, бу минем улым кайта! Минем Алешам! Мин аның исән икәнлеген белә идем. (*Төенчек күтәргән хатынны янына тартып.*) Беләсеңме хикмәт нидә? Бар шундый ике дога. Аларны тәкъдир ничек кенә итеп аерса да, барыбер бергә очрашалар! Менә шул догаларның берсен сугышка киткәндә улымның күлмәк изүенә теккән идем. Икенчесен чүлмәккә салып өй артына күмдем. Менә ни өчен кайта минем Алешам! Дога тартып кайтара аны!..

Хатын (*дулкынланып, шул ук вакытта югала да төшеп, алгарак чыга*). Килә!

Ерактан килгән автобус тавышы. Хатыннар күзләрен шул якка төбәп катып калалар. Шулай шактый озак вакыт үтә. Автобус тавышы якынайганнан-якыная. Каршы алучыларның йөзендәге киеренкелек көчәйгәннән-көчәя. Ниһаять, якында гына автобус туктаган тавыш ишетелә. Төенчек күтәргән хатын автобуска таба йөгерә. Кулына чемодан тоткан Ир кеше керә. Пауза. Каршы алырга килүчеләр телдән язып аңа карыйлар. Автобус кузгалып киткән тавыш. Ана кулындагы будильнигын төшереп җибәрә.

Ир кеше (*будильникны күтәреп алып Анага суза, сыны каткан Ана сәгатьне алмагач, утыргычка куя*). Ә сине мин таныйм кебек, әби! Син безнең мәктәп янында тора идең. Исемең... Паша түтәй! Шулай бит? Тик ул чакны син әле яшь идең. Картайгансың, Паша түтәй!.. (*Кулын суза.*) Я, нәрсәгә шулай хәйран калдың? Танымыйсыңмы әллә?

Ана (*дөньядан ваз кичкән тавыш белән*). Таныйм. Нишләп танымаска ди сине — таныдым. Сугышка кадәр мәктәп директоры булып эшләдең бит син. Аз гына вакыт. Бер елмы шунда... Әмма без монда сине бөтенләй онытканбыз... Безгә каладан килеп эшләгән тагын бер Сидоров булганны хәтердән чыгарганбыз... Сидо-

ров... Андрей Порфирьич. Онытканбыз без сине, Порфирьич, гаепкә алма.

Ир кеше. Гаҗәп түгел, Паша түтәй. Бик күп гомер үтте бит! *(Як-ягына карап, кемнедер эзли.)*

Ана. Әйе. Нәкъ егерме ел...

Ир кеше *(поселок ягына карап)*. Кара нинди зур булып үскән безнең поселок! Әнә тегендә, калкулыкта, мәктәпме ул? Яңаны салдылармыни? Ә тегесе больницамы? Анысы да яңа. Күрәм, сез монда сугыш булды дип тик ятмагансыз...

Ана. Сугышның эзе калмады инде, улым. Барысын яңадан кордылар...

Ир кеше. Я, тормышларың ничек, Паша түтәй? Исән-сау гына картаясыңмы?.. Минекеләр ничек, тазасаулармы?

Ана. Ничек дип әйтим инде... Кинәт кенә зиһенем таркалып китте — картаелган. Ух алла! Син, ичмасам, исемә төшер, кем иде соң синең җәмәгатең?

Ир кеше *(сагаеп)*. Наташа. Наталья Викторовна. Больницада врач булып эшли иде. Хәтереңдәме?

Ана. Хәтеремдә. Хәтеремдә, балам. Исемә төште... Әмма ул Наташа күптән инде... Бүтән врачлар хәзер бездә.

Ир кеше. Ә Наташа?

Ана. Әй улым!.. Кил әле, бер кочаклап сөйим әле, ичмасам, үзеңне! *(Ир кешене кочаклап, калтыраган куллары белән чәчләреннән сыйпый.)* Син дә картайгансың, балам... Ух алла!

Ир кеше *(түземен җуеп)*. Паша түтәй!

Ана *(күзләрен сөртеп)*. Юк бит инде синең Наташаң!

Ир кеше. Юк?!

Ана. Сугышка киткән иде бит ул да! Кайтмады ул. Менә шундый берәр могҗиза булып исән калса гына...

Ир кеше. Ә балалар? Балалар кайда?

Ана. Белмим, балам. Детдомга биргән иде. Хәзер кайдалардыр — белмим.

Ир кеше. Кайсы детдомга?

Ана. Алла белә!.. Немецлар килер алдыннан балаларны алып киттеләр...

Ир кеше. Кая алып киттеләр?

Ана. Белмим, балам! Белсәм, барысын да сөйләп бирер идем, берсен дә калдырмас идем.

Ир кеше *(башын учлап чемоданы өстенә утыра)*. Ә мин тагын бүген минем өчен дә сугыш бетә дип уйлаган идем...

Пауза.

Ана *(кабаланып)*. Аһ алла, күр инде мин карт җүләрне — каттым да калдым! Әйдә, бәбкәм, кайтыйк! Өйдә барысы дә әзер. Бәлешләр дә пешергән идем. Мунча ягып җибәрермен — ташып куйган суларым бар. Әйдә! Юл йөрү арыта бит ул...

Пәрдә.

1962

ТУГАН КӨНЕҢ КОТЛЫ БУЛСЫН, КАДРИЯ!

Телевизион фильм өчен сценарий

Экранда тез тиңентен генә күрсәтелгән аяклар. Ул аяклар каядыр ашыгалар — күрәсең, аларның хуҗалары эш кешеләре.

Аяклар, аяклар, аяклар. Алар уңга да, сулга да узалар. Алар ашыгалар.

Каядыр ашыккан аяклар арасында, салмак кына атлап килгән хатын-кыз аяклары, ирексездән, күзгә ташлана. Объектив шушы аякларга иярә.

Бәлки, бу аяклар берәр авыру хатынныкыдыр? Я булмаса, җир буенча бик озак еллар йөреп хәлсезләнгән берәр карчыкныкыдыр? Алай дисәң, алар әле шактый матур һәм таза күренәләр. Өйдә утырып алҗыгач урамда йөрергә чыккан берәр җилбәзәк кызныкы дисәң — мондый искереп беткән башмаклар киеп йөрергә чыкмыйлар.

Аякларны ирләр ботинкалары, хатын-кызларның нәфис башмаклары, бала-чага сандалетлары куып уза. Алар һәммәсе дә ашыгалар. Әмма объектив безнең игътибарыбызга тәкъдим иткән бу аякларның, күрәсең, ашыгыр урыны юк.

Объектив акрын гына өскә күтәрелә башлый. Менә без аяклар хуҗасының гади, ләкин зәвык белән тегелгән күлмәгенең итәген, беләккә аскан сумкасын, күкрәгенә кысып тоткан чәчәкләр бәйләмен һәм, ниһаять, йөзен күрәбез. Бу йөз яшь түгел инде. Шулай да еллар аның яшьлектәге матурлыгын сөртеп бетерергә өлгерә алмаганнар әле. Акыллы, чак кына моңсу күзләр безгә карап киләләр. Без аңлыйбыз, бу күзләргә бәхетне күп күрергә туры килмәгән.

Кешеләр, кешеләр, кешеләр. Хатынны узып, алар безгә каршы киләләр, кадрдан читтә югалалар.

Кафе, ашханә һәм магазиннарның витриналары.

Тротуар буйларында үсеп утырган агачларның яңа борынлап чыккан яфраклары.

Шәһәр сөреме кунып өлгермәгән биек-биек яңа йортлар.

Тормыш кайнап торган киң урам. Тротуарлар халык белән тулы. Асфальт җәйгән мостовойдан машиналар чаба.

Яңадан витриналар, яңадан тротуарлардагы кешеләр. Алар арасында әлеге хатын. Ул элеккечә акрын гына атлап килә. Уйчан һәм моңсу күзләре каршы очраган нәрсәләрнең берсенә дә игътибар итми.

Менә ул «Тукымалар» дип язылган магазин яныннан узып бара, магазин ишегенә карап туктап кала, берничә секунд уйланып тора. Тора да, ниндидер бер карарга килеп, магазин ишегенә таба борыла.

Менә ул инде магазинга килеп керде, төрле-төрле тукымаларның үрнәкләре эленгән зал буйлап килә. Күлмәклек тукымалар янында туктап, үрнәкләр карый башлый.

Хатын янына яшь кенә сатучы кыз килеп баса:

— Сезгә күлмәклек кирәкме? Ниндирәге кирәк? Кешелеккә кияр өченме?

— Ничек дип әйтим икән,— ди хатын, югала төшеп.— Бүләккә иде ул. Туган көне белән котлар өчен.

— Ничә яшьлек кешегә?

— Бүген кырык яшь тула аңа,— дип җавап бирә хатын, ниндидер тукыманы капшап.

— Ул ярамас, ул ярамас! — ди сатучы кыз, белдекле кыяфәт белән.— Бу — яшьләр өчен. Кырык яшьлек хатынның балалары буйга җиткәндер инде аның.

— Аның ире юк. Ул әле кияүгә чыкмаган,— ди хатын, югала төшеп.

— Карт кызмыни? Яшь булып кыланырга яратадыр инде ул. Алыгыз менә шуны! — Сатучы кыз эре-эре бизәкләр төшкән тукыма күрсәтә.

— Ул артык бизәкле булыр, сеңелем. Әгәр менә шушыны алсам?

— Алыгыз! — ди сатучы кыз бернигә дә исе китмәгән тон белән һәм чек яза башлый.— Чыра шикелле ябыктыр инде ул...

— Нигә алай уйлыйсыз?

— Карт кызлар шулай булалар ич алар!

— Юк, алай бик ябык түгел,— ди хатын, бераз аптырап.— Менә минем шикеллерәк кеше ул.

— Буйга зурмы?

— Буе да минеке чамасы.

— Ике метр ярым җитәчәк,— ди сатучы кыз, чек кәгазен хатынга сузып.— Кассага түләгез!

Хатын кассага барып акча түли, әйләнеп килә.

— Рәхим итегез!— ди сатучы кыз, кәгазьгә төрелгән күлмәклекне хатынга сузып.— Карт кызлар капризный булалар, ошатмас әле.

...Менә тагын безнең хатын урам буйлап килә. Хәзер ул тагын да акрынрак атлый. Әрнү тулы күзләре әллә кая, еракка карыйлар, алар бер нәрсәне дә күрмиләр. Үзенең сагышлы уйларына чумган хатын чәчәкләре белән төргәгән күкрәгенә кыскан да салмак кына атлый. Менә бу аны узып, аңа бәрелеп-бәрелеп үтеп китүче кешеләр, әйтерсең, бөтенләй юк.

Хатын, үзе дә сизмәстән, юан бер ханымга бәрелеп уза. Юан ханым юлыннан туктап хатынга борылып карый да, канәгатьсезләнү белән нәрсәдер әйтеп, кулларын бутый.

«Детский мир» магазины. Ишектән һава шарлары тоткан бер төркем балалар килеп чыга. Хатын, юлыннан туктап, чыр-чу килеп узып киткән балаларга карап тора. Чырае яктырып китә. Карашы белән балаларны озатып кала да туп-туры магазинга юнәлә.

Менә ул уенчыклар сатыла торган бүлек янында.

Объектив шүрлекләрдәге уенчыклар өстеннән шуыша. Бер генә секундка уенчык сервиз өстендә тукталып тора да зур гына курчакка күчә.

— Рәхим итегез! — ди сатучы, курчакны хатын алдына куеп.— Бу курчак «әни» дип әйтә белә. Яткырсаң — күзләрен йома.

Кадрдан читтә кычкырып елаган бала тавышы.

Хатын тавыш килгән якка борыла.

Әзер киемнәр бүлегенең прилавкасында өстенә апак ефәк күлмәк кигән кечкенә генә бер кызчык. Ул «Бу күлмәкне саласым юк!» дигәндәй итеп, куллары белән итәгенә ябышкан. Күлмәк чыннан да бик матур. Аны кигән кызчык очып китәргә талпынган күбәләк шикелле булып күренә.

Эре итеп: без күреп белгән хатынның соклану тулы йөзе.

— Синең җүләр буласың килми ич! — ди кызчыкның әнисе, күлмәкне салдырырга маташып.— Син бит минем акыллы кызым!

Ләкин кызчык тагын да катырак елый башлый. Күренеп тора: ул иске күлмәкле акыллы кызчык булганчы, яңа күлмәкле җүләр кызчык булуны өстенрәк саный.

— Ярар ла инде, салмасын,— ди сатучы хатын елмаеп.— Китерегез, искесен генә төрик!

Сатучы хатын кызчыкның иске күлмәген кәгазьгә төреп анасына суза. Ана кызын күтәреп алып тык иттереп идәнгә бастыра да, кулыннан тотып ишеккә таба тарта.

— Кире беткән кыз! Икенче вакыт бер әйбер алмыйм үзеңә!..

— Аласың! — ди кызчык тантаналы тавыш белән.

Безнең танышыбыз әзер киемнәр бүлеге янында.

— Шундый күлмәкләр тагын бармы әле сезнең?

— Сезгә ничәнче размер кирәк?

— Утызынчы.

Сатучы прилавкага күлмәк китереп куя.

Хатын, изге бер әйбергә кагылгандагы кебек, саклык белән күлмәккә кагыла. Җиңнәреннән тотып күтәрә дә сокланып карап тора. Яңагына тидереп ала. Елмаеп куя.

— Алыйм әле мин бу күлмәкне.

— Рәхим итегез! — ди сатучы хатын.

...Менә тагын без күреп белгән хатын халык тулы урам буйлап атлый. Ләкин хәзер инде аның йөзендә ниндидер шатлык, үз-үзеннән канәгатьләнү балкый. Әле генә бернинди максатсыз көчкә-көчкә сөйрәлгән аяклары тиз-тиз атлыйлар. Атламыйлар, очалар.

Ә баш очында күңелле итеп зур һава шары чайкалып бара.

* * *

Зур йортның ишек алды.

Ун-унбиш малай түгәрәк булып җыелган. Шау-шу, бәхәс. Түгәрәк уртасында ике малай иске автопокрышка тотып тора. Өченче малай тырыша-тырыша шул көпчәкнең эченә кереп утырмакчы була. Ләкин малай үсебрәк киткән — көпчәккә сыймый.

Янәшәдә түземнәрен җуйган ваграк малайлар таптана.

Кемдер көпчәккә сыймаган малайны читкә алып ыргыта.

— Хәзей минем чийат! Минем чийат! Минем дә космонавт булып кайыйсым килә! — дип үрсәләнә бер бәләкәй малай көпчәкне кочаклап.

— Сиңа тагын космонавт булырга!

— Булам! Мин дә космонавт булам!

Бер зуррак малай кулын селти. Әйдә, янәсе, булып карасын әле.

Бәләкәй малай йодрык аркасы белән борын астын ышкып ала да, бөгәрләнеп көпчәк эченә кереп утыра. Ике зур малай хәйләкәр елмаешып күз кысышалар һәм бар көчләренә көпчәкне этеп җибәрәләр.

Экран буйлап эчендә малай бөгәрләнеп утырган көпчәк тәгәри.

Дөньяның асты өскә килә: агачлар, йортлар, җир һәм күк йөзе бер-берсе белән кушылып әйләнә башлый.

Көпчәк киң капканы үтеп тротуар аркылы тәгәри.

Мостовойдан зур тизлек белән йөк машинасы килә.

Тротуардагы кешеләр югалып калалар. Алар арасында безгә таныш булган хатын.

Эре итеп: хатынның куркынган йөзе.

Ә көпчәк инде тротуарны үтеп урам аркылы тәгәри.

Йөк машинасы тагын да якыная төшкән.

Эре итеп: хатынның коты чыккан йөзе. Шулай берничә секунд үтә.

Хатын көпчәккә ташлана. Мостовойның уртасында көпчәкне куып җитә дә тротуар ягына таба төртеп аудара. Ләкин үзе егыла. Тирә-якка төргәкләр, чәчәкләр сибелә. Кулындагы һава шары очып китә.

Малай көпчәк эченнән бөке кебек атылып чыга да халык арасына кереп шыла.

Дөбер-шатыр килеп, чак кына хатынны таптамыйча, йөк машинасы узып китә.

Асфальтта — машина таптап узган тюльпан чәчәкләре.

Халык җыела. Һәркем нидер сөйли, нидер кычкыра — искиткеч ыгы-зыгы. Кемдер хатынны күтәреп торгыза. Кемдер төргәкләрен җыярга булыша.

Ниндидер егет тапталмыйча калган бердәнбер тюльпан чәчәген тантана белән хатынга суза.

Сыбызгы тавышы. ГАИ сотрудникы күренә. Кешеләр кулларын бутап, берсен-берсе бүлә-бүлә, нәрсәдер сөйлиләр. Аларның барысының бергә сөйләвеннән милиционер берни дә аңламый, күрәсең. Ул кулын күтәреп тагын бер сызгырта. Автопокрышка янына килә, аны тротуарга таба тәгәрәтә.

— Бу кемнеке? — дип сорый милиционер.

Ләкин аның соравына җавап бирүче кеше юк.

Хатын инде күптән үз юлы белән китеп барган.

Асфальт мостовойда машина таптап узган тюльпан чәчәкләре.

Өстә, бик югарыда аллы-гөлле һава шары чайкала...

Хатын үзенең юлын дәвам итә. Кулларында тузанга буялган төргәкләр һәм исән калган бердәнбер тюльпан чәчәге. Менә ул биш катлы зур йорт янына килеп җитә, ишеккә таба борыла.

Ишекнең бер ягына

Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы заводның тулай торагы

дип язылган такта кадакланган.

Хатын ишекне ачып эчкә атлый.

Хатын баскычтан күтәрелә. Салмак кына атлап коридор буйлап килә.

Менә ул рәттән тезелеп киткән ишекләрнең берсен ача.

Телеобъектив бүлмә ишеген эчке яктан күрсәтә. Ачылган ишектән бүлмәгә безнең танышыбыз килеп керә.

Кровать кырында бер карчык утыра. Ишек ачылган тавышка ул борылып карый һәм «Тсс!» дип кулын күтәрә.

Хатын бу хәлгә гадәти бер нәрсә итеп карый, акрын гына атлап икенче бер кровать янына килә. Төргәкләрен куя. Аяк очларына гына басып кухня ягына уза, сулы ваза тотып әйләнеп керә. Тюльпан чәчәген утыртып вазаны өстәлгә куя. Карчыкка карап бер мизгел уйланып тора да ванна бүлмәсенә китә.

Кадрда бүлмәнең карчык утырган почмагы. Гади генә итеп җыештырылган кровать. Стенада — багет рамлы фотография. Анда өч кеше сурәте: урта яшьләрдәге ир белән хатын һәм аларның артына баскан

яшь кенә егет. Кровать янында утырган карчыкка һәм рамдагы сурәткә карап, аларның икесе бер кеше икәнлеген төсмерләргә мөмкин. Моңа безнең игътибарыбызны юнәлтеп, объектив берничә мәртәбә әле карчыкка, әле стенадагы рәсемгә күчә.

Рам астында искереп беткән гитара эленеп тора.

Карчык тораташ булып каткан да, селкенергә дә кыймыйча, гитарага карап утыра. Йөзендә әллә нинди сагаю, әллә нинди яшерен сөенү. Кадрдан читтә бер өзелеп, бер тоташып, гитарада уйналган «Камаринская» көе ишетелгәләп куя.

Объектив безне бүлмә белән таныштыра. Менә беренче кровать. Ишек төбенәрәк куелган бу кровать рәтләп җыештырылмаган. Кровать өстендә яньчелгән бер мендәр,— күрәсең, кровать хуҗасының аны күпертеп торырга вакыты булмаган,— һәм волейбол тубы. Янәшәдәге тумбочка өстендә берничә дәреслек, көзге, хушбуй шешәләре, кершән тартмалары.

Икенче кровать беренчесенең нәкъ киресе. Ул челтәр һәм чигүле япмаларга күмелгән. Кровать өстендә зур-зур ике мендәр. Стенада әйбәт келәм. Келәмгә чигеп һәм бәйләп эшләнгән әллә нинди нәмәрсәкәйләр эленгән. Өстәрәк — зур түгәрәк сәгать. Тумбочка өстендә зур шкатулка.

Өченче кровать та пөхтә җыештырылган, ләкин икенчесе кебек үк күзгә ташланып тормый. Зур мендәр. Мендәргә сөяп зур гына бер курчак утыртылган. Стенадагы келәмгә төрле журналлардан ертып алынган бала-чага рәсемнәре беркетелгән. Ул рәсемнәрдән безгә су коенучы, комда уйнап утыручы яисә елмаеп торучы балалар карыйлар. Бу кровать без инде урамда ук күреп белгән хатынныкы.

Объектив безне яңадан карчык янына кайтара. Ул, кыймылдарга да курыккандай, һаман элекке кыяфәтендә утыра.

Бүлмәгә инде юынган, өс-башын алыштырган безнең танышыбыз керә. Карчыкка игътибар итмичә үзенең төргәкләре белән булаша башлый.

— Әллә бу юлы да ишетмәдеңме? — ди карчык аяныч тавыш белән.

Хатын берничә секунд карчыкка текәлеп карап тора. Карчыкның аяныч тулы карашын күреп, әйтә:

— Ишеттем. Бу юлы ишеттем, мама Лиза.

Мама Лиза. Ишеттең?! Димәк, син дә ишетәсең!.. Ишетсәң — әйт, бүген нинди көй иде?

Хатын аптырап кала. Күрәсең, ул бу сорауны көтмәгән иде.

— Минемчә, бүген дә «Рябинушка» иде, мама Лиза,— ди ул икеләнүле тавыш белән.

Мама Лиза *(күңеле китеп)*. Юк, бүген «Рябинушка» түгел иде шул. Бүген «Камаринская» иде! Менә нинди көй иде бүген... Күрәсең, син ишетмисең. Син мине юатыр өчен генә әйтәсең... Нинди хәл соң бу? Ни өчен мин ишетәм, сез — юк? Әллә... әллә мин шаша башладым микән, Кадрия?

Кадрия. Ишеттем, мама Лиза, чынлаптыр менә ишеттем! Тик менә нинди көй икәнлеген аерып өлгерә алмадым.

Мама Лиза. Аерып өлгерә алмадым! «Камаринская» белән «Рябинушканы» бутаган! Ничек инде аларны бутыйсың, ди!.. *(Пауза.)* Ох, уйный да иде соң Ванюша шул «Камаринскаяны»!

Кадрия бүлмәдән чыга.

Мама Лиза, «Камаринскаяны» уйнаган Ванюшасын күз алдына китергән сыман, уйга кала.

* * *

Кечкенә генә кызчык күтәреп, бүлмәгә Кадрия керә.

Кадрия. Яле, әйтеп кара әле, Гүзәлкәй. Нәрсә алып кайттым мин бүген сиңа?

Гүзәл. Китап.

Кадрия. Юк!

Гүзәл. Мороженое!

Кадрия. Юк!

Гүзәл. Курчак!

Кадрия. Юк! Юк! Белмәдең!

Кадрия Гүзәлне өстәл өстенә бастыра. Кровать өстендәге төргәкне алып сүтеп җибәрә.

Гүзәл *(шатланып)*. Әнекәем! Минамы бу?

Кадрия. Кемгә булсын!

Кадрия Гүзәлне чишендереп яңа күлмәк кидерә. Читкәрәк тайпылып сокланып карап тора.

Өстәл янына мама Лиза килә.

Кадрия кызчыкны шифоньер ишегендәге көзгегә таба борып куя.

Гүзәл. Ой, мин нинди матур булдым! *(Кадрияне кочаклап ала да чупылдатып үбеп куя.)*

Кадрия шифоньер эченә эленгән киемнәр кесәсеннән нәрсәдер эзли башлый. Апельсин табып ала, Гүзәлгә бирә.

Гүзәл (*шифоньер эченә күрсәтеп*). Нәрсә ул анда?

Кадрия. Кайда?

Гүзәл. Әнә тегендә, костюмда! Значокмы?

Кадрия. Бу — значок түгел, бу — орден, Гүзәл.

Гүзәл. Кемнеке ул?

Кадрия. Минеке!

Гүзәл. Миңа бир!

Кадрия (*елмаеп*). Аны кешегә бирергә ярамый.

Гүзәл. Нигә ярамый? Сиңа биргәннәр бит! Кем бирде аны сиңа?

Эре итеп: Кадриянең җитдиләнеп киткән йөзе.

Гүзәл. Кем бирде аны сиңа? Кайдан алдың?

Кадрия. Бу инде күптән булган хәл, Гүзәлкәем. Ул вакыт син юк та идең әле. Мин дә авылда яши идем. Сугыш бара иде.

Гүзәл. Сезнең авылдамы?

Кадрия. Юк, безнең авылда түгел. Сугыш бездән ерак иде. Ләкин аның безнең авылга да килүе ихтимал иде. Шуңа күрә без окоп казыдык.

Гүзәл. Нәрсә ул окоп?

Кадрия. Окоп — шундый бер чокыр ул. Солдатлар кереп яшеренә торган урын.

Гүзәл. Совет солдатлары куркак түгел. Совет солдатлары яшеренмиләр.

Кадрия. Фашист пулясы тимәсен өчен кайчак безнең солдатлар да яшеренәләр... Менә шуның өчен без окоп казыдык. Мин яхшы казыдым. Яхшы казыган өчен миңа орден бирделәр... (*Орден кадалган жакетын алып Гүзәл янына килә.*) Матурмы?

Гүзәл (*орденны бармагы белән генә тотып карап*). Матур... Иртәгә сугыш булса, мин дә окоп казыйм! Миңа да орден бирерләр. Беләсеңме, мин нинди тиз казыйм?

Кадрия. Җүләркәй! Сугышта куркыныч була.

Гүзәл. Юк, куркыныч түгел! Мин күп саен телевизордан сугыш карыйм. Бер дә курыкмыйм!

Кадрия. Чын сугыш куркыныч була, Гүзәл, телевизордагы кебек кенә түгел. Сугышта кешеләр үлә.

Гүзәл. Безнекеләр үлми!

Кадрия. Безнекеләр дә үлә. Олылар да, балалар

да үләләр сугышта. Менә мама Лизаның ире дә, улы да булган. Икесе дә сугышта үлгәннәр.

Эре итеп: мама Лизаның җитдиләнеп киткән йөзе.

Кадрия. Я, сөйлә. Бакчада нләр эшләдегез бүген?

Гүзәл. Биедек.

Кадрия. Син дә биедеңме?

Гүзәл. Әһе. Бу күлмәкне иртәгә бакчага киеп барырга ярыймы?

Кадрия. Ярый! Ничек итеп биедең? Күрсәт әле безгә!

Кадрия такмак әйтеп кул чаба башлый.

Гүзәл өстәл өстендә бии.

Авызларын мимылдатып, кул чаба-чаба, өстәл янына мама Лиза килә.

Ишек ачылып китә. Бүлмәгә яшь кенә хатын керә.

— Син тагын мондамыни әле! — дип кычкыра хатын бусагадан ук.

Гүзәл биюдән туктап хатынга таба борыла:

— Әнием, кара минем нинди матур күлмәгем бар!

— Кадрия, сиңа актык әйтүем: бу гадәтеңне ташла! — ди хатын баласы янына атлап.

Кадрия (*гаепле елмаеп*). Луиза!

Луиза. Күр әле — тәмам бозып бетерәсең бит баланы! Бер сүз әйтер хәл юк — Кадрия апа янына китәм дип куркыта башлый. Кем аның әнисе — синме, минме? (*Гүзәлнең өстендәге күлмәкне салдыра башлый.*)

Кадрия (*ялварып*). Баланы нәүмиз итмә инде, Луиза! Салдырма, калсын!

Луиза. Калмасын! (*Гүзәлнең күлмәккә чытырдап ябышкан кулларына суга. Гүзәл кычкырып елый башлый.*) Үкермә!.. Без хәерче түгел! Бердәнбер кызыбызны гына киендерерлек хәлебез бар! (*Гүзәлнең ефәк күлмәген салдырып алып, Кадриянең битенә ыргыта.*) Кеше баласын бозып ятма! Алай бик бала яраткач, кияүгә чык та, үзең тап!

Ярым ялангач Гүзәлне күтәреп чыгып китә.

Шапылдап ишек ябыла.

Кадрда кулына бала күлмәге тоткан Кадрия.

Объектив аның йөзен зур итеп күрсәтә. Ул йөз кыйшаеп калган. Тартышып-тартышып киткәләгән яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәри.

* * *

Стенадагы сәгать җидене күрсәтә.

Кадрия өстәл тирәсендә әбегәрләнә. Чиста ашъяулык ябылган өстәл өстендә бер шешә вино, берничә рюмка, алма һәм конфетлар тутырылган вазалар.

Кадриянең артына мама Лиза килеп баса. Иңбашына матур яулык каплый.

Кадрия (*мама Лизаны кочаклап алып*). Кирәкмәс иде, мама Лиза. Юкка расходлангансың.

Мама Лиза. Юкка түгел. Кырык яшь көн саен тулып тормый. Ошыймы?

Кадрия. Бик матур!.. Рәхмәт, мама Лиза!

Мама Лиза. Өстендә тузсын! (*Стенадагы рәсемгә карап.*) Минем Ванюша да май аенда туган иде бит. Сирень чәчәк аткан вакытта. Әтисе роддомга бер кочак сирень күтәреп килгән иде. Хәзер инде кырык бер яшь тулган булыр иде Ванюшага. Ни тиклем гомер узып киткән! Ә бит кичә генә булган шикелле... Шунысы гаҗәп, һич үзен олы кеше итеп күз алдына китерә алмыйм... Кунаклар булачакмы әллә?

Кадрия. Юк, мама Лиза, берәүгә дә әйтмәдем. Үзебез утырырбыз. Катюша гына кайтып җитсен дә... Никтер озаклады бүген Катюша.

Мама Лиза. Күрәсең, тегендә.

Кадрия. Шулайдыр, Миргаяз абыйлардадыр. Керләрен җебеттем дигән иде кичә...

Кадрия өстәлгә тастымаллар китереп куя.

Мама Лиза. Ошамый миңа бу эш, Кадрия! Яхшы түгел. Исән хатын өстеннән...

Кадрия. Син ни сөйлисең, мама Лиза! Кайдан алдың син бу сүзне?

Мама Лиза. Кеше сөйли.

Кадрия. Соң... без бит Катюшадан бөтен цех белән үтендек, мама Лиза! Миргаяз абыйның өендә дүрт баласы. Хатыны өч ай больницада ята. Без аны шефка алдык. Кешегә булышырга кирәк ләбаса инде!

Мама Лиза. Башкалар булышсын. Ирле хатыннар!

Кадрия. Ирле хатыннарның өйләрендә үз эшләре тулып ята. Катюша ялгыз хатын...

Мама Лиза. Катеринага килешми. Мин аны беләм, әлбәттә. Катерина ул синең кебек — кешегә җа-

нын өзеп бирергә тора. Ийе, ийе, сораучы булса — җанын да бирер, алмашка бер нәрсә сорамас. Ләкин кешенең авызына йодрык тыгып буламыни — чәйниләр!

Кадрия. Акыллы кеше чәйнәмәс, мама Лиза... Син тагын бу хакта Катюшаның үзенә әйтә күрмә. *(Өстәлдәге ашамлыклар өстенә ак тастымал яба да, кровате янына килә. Төргәкне сүтеп магазинда алган күлмәклекне чыгара.)* Менә, үземә бүләк алдым әле, мама Лиза. Туган көнемә. Матурмы?

Мама Лиза *(күлмәклекне капшап)*. Бик матур, бик килешеп тора үзеңә. Кыйбаттыр инде бу?

Кадрия. Кыйбат булса да алдым әле, мама Лиза. Үзең әйтеп торасың бит — кырык яшь көн саен тулып тормый дисең.

Күлмәклекне түшенә куеп көзгедән карый.

* * *

Ачык тәрәзә янына Кадрия баскан. Ул безгә арты белән тора, ләкин гәүдәсенең киеренкелегеннән безнең нәрсәнедер көтүен аңлыйбыз.

Стенадагы сәгать сигез туларга чиректе күрсәтә.

Кадрия сый-хөрмәт тулы өстәл янына утырып, кемне икәнен үзе дә белмәстән, кунак көтә.

Стенадагы сәгать суга башлый. Бер, ике, өч..., җиде, сигез.

Кадрия яңакларын учлап терсәкләренә таянган да өстәл артында йокымсырап утыра. Сәгать тугызынчы яртыга суга. Кадрия сискәнеп күзләрен ача, сәгатькә карап ала, урыныннан тора, тәрәзә янына килә.

Кадрда урамның Кадрия күргән өлеше. Тротуарлар халык белән тулы. Мостовойдан инде фаралары кабынган машиналар чаба.

Кадрия урамга карап тора.

Урам баганаларында утлар кабына.

* * *

Кадрда бүлмә ишеге.

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Ишек аз гына ачыла. Ишек ярыгында бер кызның башы күренә.

— Безгә керергә ярыймы?

Җавап бирүче кеше юк. Бүлмә буш.

Өйдә кеше юклыгына ышангач, кыз бүлмәгә бер егетне алып керә.

— Барысы әллә кая китеп беткәннәр. Утыр!

Кыз егетне волейбол тубы яткан кровать янына утырта. Кровать астыннан чемодан сөйрәп чыгара.

— Сине моңа тиклем бүлмәмә алып килмәгәнгә үпкәләми идеңме?

Егет елмаеп иңбашын сикертеп куя.

Кыз шифоньерны ачып куя. Аннан күлмәкләр, кофталар алып кровать өстенә ыргыта башлый. Шуларны ашык-пошык чемоданга тутыра-тутыра сөйләнә:

— Сине бүлмәмә чакырмавымның сәбәбе шул: безнең монда җыен тиле-миле тора. Әнә теге койкада — бер шашкан карчык. Гитараны күрәсеңме? Менә шул гитара аның сугышта үлгән малаеныкы булган. Бу тиле карчык гитара үзеннән-үзе җырлый дип саташа. Аңа бер үзенә аерым квартира бирмәкче булганнар, ире белән малае сугышта үлгән өчен. Бу ахмак алмаган. Имеш, миңа общежитиеда күңеллерәк!.. Ә менә бу койкаларда — ике карт кыз. Менә монысы җәмәгать эше белән саташкан. Көн саен әле җыелышта, әле утырышта була. Әле бүген дә шунда киткәндер. Ял көннәрен көнозын пластинка уйната. Әнә тегендә бер тумбочка пластинка җыйган, әллә нинди опералар да симфонияләр... Менә бу койкада — Катя исемле бер карт кыз. Аңа шәт инде илле дә тулгандыр. Шулай булса да мастер белән әйттерә. Мастерның хатыны больницадан чыгып тормый. Бу, балаларның өстен-башын карыйм дигән булып, тегенең белән... *(Мәгънәле итеп пырхылдап көлеп җибәрә.)* Оятсыз, шулай бит?.. Ой, моннан китүемә шул тиклем шатланам, шул тиклем шатланам!.. *(Егетнең муенына уралып.)* Син мине һаман шулай яратырсыңмы?

Егет *(кызны үбеп алып)*. Тизрәк җыен!

Бүлмәгә Кадрия килеп керә. Чит кешене күреп ишек төбендә туктап кала. Кыз йөгереп алга чыга:

— Таныш булыгыз, Кадрия апа! Менә бу — минем ирем!

Кадрия *(аптырап)*. Ирең?!

Кыз. Әйе, ирем. Мин кияүгә чыктым!

Егет Кадриягә таба борылып баш ия:

— Алик.

Кадрия (*гаҗәпләнүен дәвам итеп*). Бу ничек була соң инде? Синең бит берни дә әйткәнең юк иде!

Кыз. Ә нигә алдан ук кычкырып йөрергә!

Бүлмәгә мама Лиза керә.

Кадрия. Мама Лиза! Безнең Тамара кияүгә чыга икән ләбаса! Менә бу — аның егете.

Тамара. Егетем түгел, ирем! Без инде бүген загста да булдык.

Мама Лиза бу хәбәргә әллә ни исе китмичә кровать янына уза.

Кадрия. Инде син бездән китәсең дәме?

Тамара. Монда нишләп ятыйм! Аликларның өч бүлмәле квартирасы.

Кадрия. Кит инде, Тамара — бигрәк астыртын кыз икәнсең! Яхшымы-яманмы дигәндәй, бер бүлмәдә торабыз ләбаса! Шундый зур шатлыгыңны да безгә әйтмәгәнсең.

Тамара. Техникумда ике дус кыз белде — шул житкән.

Кадрия. Башка беркем дә белмәдеме? (*Уйланып сәгатькә карый. Сәгать инде тугыз тулып килә.*)

Тамара. Беркем дә!

Кадрия. Ә менә без белдек! (*Шук елмаеп туган көнгә дип әзерләнгән өстәлдән тастымалны тартып ала.*)

Эре итеп: Тамараның аптырап калган йөзе.

Эре итеп: ашамлыклар тулы өстәл.

Эре итеп: Аликның гаҗәпләнгән йөзе.

Эре итеп: йөзенә тантаналы елмаю чыккан Кадрия.

Эре итеп: хәйләкәр елмаючы мама Лиза.

Кадрия. Менә шулай, җаныем. Нинди генә астыртын йөрсәң дә, барыбер белдек!

Тамара белән Алик бер-берсенә сынаулы караш ташлыйлар: бәлки син сөйләнеп йөргәнсең?

Тамара. Аңламыйм. Заводта мин берәүгә дә әйтмәдем. Кайдан белдегез, Кадрия апа?

Кадрия. Белдек инде... Ягез, өстәл янына утырыйк.

Тамара. Алик, утырып торсак, өлгерербезме?

Алик иңбашын сикертеп куя. Сүзсез-нисез өстәл янына утырышалар.

Ишектә Катя күренә. Кулында берничә төргәк.

Катя. Мин соңга калдым бугай, Кадрия...

Кадрия (*Катяның сүзен бүлеп кулын күтәрә*). Тамараның туен уйныйбыз, Катюша!.. Тамара үзләренең загста булганлыкларын бездән яшергән иде, ә без барыбер белдек. Ничек белгәнне әйтмә. Кил тизрәк өстәл янына! Сине көтәбез!

Катя эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенде бугай. Төргәкләрен тумбочка өстенә куеп өстәл янына килә.

Алик (*Кадриянең шешә ача алмый азаплануын күреп*). Китерегез, үзем ачам!

Тамара. Менә ичмаса сюрприз! Алик, күр нинди сюрприз! Чыннан да, сезгә кем әйтте, Кадрия апа?

Кадрия. Кадрия апаңның изге тамыры бар аның... Мама Лиза, нишләп читтә утырасың? Бирегә кил!

Мама Лиза өстәл янына килә.
Өстәлдә вино салынган рюмкалар.

Кадрия. Ягез, иптәшләр, күтәрегез! Әйдәгез, яшьләрне яңа тормышка аяк басулары белән котлыйк! Бәхетле булуларын телик!

Катя. Бер-берсен яратышып яшәсеннәр! Тигез гомерле булсыннар!

Мама Лизадан башкалар эчәләр.

Тамара. Мама Лиза, син безнең бәхетле булуыбызны теләмисеңмени?

Мама Лиза. Мин эчмим ләбаса!

Кадрия. Әйтерсең, без эчкечеләр! Көне шундый, мама Лиза, эчәргә кирәк!

Мама Лиза бер йотып куя.

Тамара (*өстәл кыйнап*). Эчеп бетер! Эчеп бетер, мама Лиза!

Кадрия (*кровать өстеннән төргәк алып килә*). Синең сереңне без күптән белдек, Тамара. (*Төргәкне сүтеп, магазиннан алып кайткан төргәкне Тамарага суза.*) Сиңа күлмәккә!

Тамара. Әнекәчем! Ничек була инде бу? Шундый зур бүләк! Юк, мин алмыйм! Ала алмыйм мин мондый зур бүләкне!

Катя. Ничек инде алмыйсың! Бүләк сиңа дип алынган. Бүләктән баш тартмыйлар.

Тамара (*югалып калып*). Юк, юк! Алмыйм! Алик! (*Сорау белән Аликка карый. Алик иңбашын сикертеп куя. Теләсәң нишлә, янәсе.*) Билләһи, нишләргә белмим. Алсам да уңайсыз, алмасам да... Беләсезме, без сезне туйга чакырырбыз! Чакырырбыз бит, Алик?

Катя. Бүләк алмасак, чакырмас идеңмени?

Тамара. Юк ла инде, Катя! Әлбәттә, чакырыр идем. Мин сезне чакырырга җыена идем... Шулай бит, Алик, җыенган идек бит?

Кадрия. Туйга без бармыйбыз, Тамара. Чакырып мәшәкатьләнмә.Ә бүләкне ал!

Тамара (*бераз икеләнеп торганнан соң бүләкне ала*). Рәхмәт! Бик зур рәхмәт, Кадрия апа. Шулай ук, Катюша, мама Лиза! Рәхмәт сезгә... Ой, мин бит бөтенләй уйламаган идем! Көтмәгән идем! Мин бит сезне бик аз беләм. Күпме тордым әле мин бу бүлмәдә?

Кадрия. Дүрт ай ярым. (*Тамараның койкасына күрсәтеп*). Бу — бәхетле койка, монда килгән кеше озакка килми. Мин инде бу бүлмәдә сигез ел торам. Сигез ел эчендә бу койкада булган кызларны саный башласаң...

Тамара. Бик күпмени?

Кадрия. Бик күп!

Тамара. Ничә?

Кадрия. Ундүрт. Син ундүртенчесе идең.

Тамара. Барысы да кияүгә чыгып киттеме?

Кадрия. Барысы да... Әйдәгез, берәрне эчик әле!

Тамара. Ә нәрсә өчен эчәбез?.. Рөхсәт итегез! Үземә сүз әйтергә рөхсәт итегез!.. Алик, син нигә бер сүз дә әйтмисең?

Кадрия. Бәлки синең кияվең телсездер?

Катя. Чынлап та, теле юкмы әллә синең кияվеңнең?

Алик (*телен чыгарып күрсәтеп*). Менә бит!

Барысы да шаркылдап көлешәләр.

Тамара. Иптәшләр, туктагыз! Рөхсәт итегез! Мин тост әйтәм, рөхсәт итегез!.. Мин, иптәшләр... кыскасы, беләсезме нәрсә өчен эчәбез? Менә син, Кадрия апа... син, Катюша... кыскасы, сезгә дә кияү табылсын өчен эчик! Югыйсә...

Кадрия (*рюмкасын куеп*). Моның өчен эчмибез.

Тамара. Нишләп?

Кадрия. Чөнки ярдәм итмәячәк. Чөнки безнең вакыт узган инде.

Бүлмәдә уңайсыз сүзсезлек урнаша.

Мама Лиза. Туктагыз әле, үзем бер сүз әйтим!.. Балакайларым! Сез шундый яшьләр, шундый матурлар. Менә минем дә шундый улым бар иде, әнә ул, стенадан карап тора... Әйдәгез әле, дөньялар тыныч-имин булсын

өчен эчик! Җирдә гел менә сезнең шикелле матур, бәхетле кешеләр генә булсын. Безнең шикелле канатлары сынган ятимнәр булмасын.

Барысы да эчәләр.

Кадрия. Кызык син, мама Лиза. Дәшмичә генә торасың-торасың да телгә киләсең. Кара нинди итеп сөйләп җибәрдең — радиомыни!.. Тик кирәк түгел бу. Кеше хәлен кеше белми дигәннәр. Бүген яшьләрнең шатлыклы көне...

Мама Лиза. Шатлыклы көннәрендә дә онытмасыннар, бәхетләренең кадерен белсеннәр... Безнең дә бәхетебез бар иде, сугыш кына харап итте.

Тамара. Гафу итегез... Мин аңламыйм. Аңлап житкермим. Менә син, Кадрия апа. Яисә син, Катюша. Дөрес, сугышта күп кеше үлгән. Ләкин кайтучылар да күп булган бит. Ничек сезнең шулай килеп чыкты? Бик сайладыгызмы соң?

Кадрия. Нәрсәне сайладык?

Тамара. Егетләрне дим.

Кадрия. Сугыш башланган елны мин җиденче класста укый идем. Хәтеремдә, барысы егерме жиде укучы. Уңдүрт малай, унөч кыз. Ике-өч елдан малайлар сугышка киттеләр. Шиһапны гына алмадылар — күзләре начар иде... Менә шулай. Унөч егет китте, дүртесе әйләнеп кайтты. Шуннан нәрсә сайлыйсың.

Тамара. Син йөргән егет тә кайтмадымы?

Кадрия. Кайтмады.

Тамара. Кем исемле иде?

Кадрия. Исемен белмим.

Тамара. Ничек инде?!

Кадрия. Шулай. Мин егетемнең кайда туып үсүен дә, исемен дә белмим. Ләкин ул бар иде. Сугыш булмаса, без очрашкан булыр идек.

Эре итеп: Катя белән мама Лизаның таш кебек каткан йөзе.
Эре итеп: Тамараның житдиләнеп киткән йөзе.
Эре итеп: Аликның шактый уйсыз, эч пошуны аңлаткан йөзе.

Тамара. Әллә ничек, хыялый итеп сөйләдең син, Кадрия апа. Хыялый кеше икәнсең син... Ә син, Катюша? Синең егетең бар идеме?

Катя. Егетем! Минем егетем генә түгел, ирем бар иде!

Тамара. Ничек инде — ирең? Мин бит сине...

Катя Карт кыз дип уйлый идең — шулаймы? Юк, син апаң белән шаярма, сеңелем. Мин ирдә булган хатын. Минем ирем булды. Нәкъ дүрт сәгать.

Тамара Ой, сез әллә ничек итеп сөйлисез — тәннәрем чымырдап китте хәтта. Шушында бер бүлмәдә яшәп мин сезне бөтенләй белмәгәнмен. Ничек ул шулай булды, Катюша? Дүрт сәгать — ничек булды?

Катя. Шулай булды инде. Чәчәксез, виносыз. Хәтта бәхет-шатлык теләүчеләр дә булмады... Сугышка хәтле ул хәрби хезмәттә иде. Сугыш башланып китте. Каты яраланып госпитальгә эләкте. Мин бардым аның янына. Свердловскига. Врачлар миңа килеп төшкәч үк әйттеләр, өмет юк, диделәр. Снаряд аның аякларын, бер кулын өзгән иде. Эче яраланган, йөзе танымаслык хәлгә килгән... Минем килеп төшүемне ишеткәч ул бик уңайсызланды. Врачларына мине янына кертмәскә кушкан... Шулай да мин кердем. Мине күргәч аңын җуйды... Һушына килгәч мине куа башлады. Мине оныт, дөньяда минем барлыгымны оныт, синең өчен мин юк! — дип кычкырды. Тагын һушыннан язды... Врачлар мине куа башладылар... Менә шунда мин аның күңелен күтәрү өчен... ничек дип аңлатыйм инде... ну, сәламәтләнүгә өметен арттыру өчен, аңа кияүгә чыгарга булдым. Загстан кешеләр килде. Шунда палатада безне өйләнештерделәр... Ләкин ярдәм итмәде. Дүрт сәгатьтән ул үлде...

Тамара. Йа хода! Мин нинди кешеләр белән яшәгәнмен! Ни өчен сез бу хакта элегрәк сөйләмәдегез?!.

Катя. Нишләгән булыр идең?

Кадрия. Кирәкмәс темага сөйләшә башладык без, җәмәгать. Катюша, утыр әле, тутырыйк әле бер рюмкаларны!.. Нигәдер бик тыныч булып китте. Туктагыз, музыка уйнатам!.. *(Радиолага пластинка куя. Григның Сольвейг җыры яңгырый башлый. Канәгатьләну белән өстәл янына килә, яшьләрнең музыканы тыңламавын күрә.)* Сезгә бу музыка ошамыймыни?

Алик. Турысын әйтергә яраса — юк. Сездә берәр күңеллерәк нәрсә юкмы? Джаз, мәсәлән?

Кадрия. Джаз юк. Джазны мин аңламыйм. *(Музыканы туктата.)* Әйдәгез, эчәбез! *(Рюмкасын күтәреп.)* Сезнең исәнлеккә, яшьләр! Тормышыгыз мул булсын! *(Эчәләр.)*

Алик *(стенадагы гитарага таба атлап)*. Алырга ярыймы?

М а м а Л и з а *(Аликны гитара янына уздырмыйча).* Ә син уйный беләсеңме?

Т а м а р а. Белә, мама Лиза, белә!

М а м а Л и з а. Тсс! Тавышланмагыз!

Алик стенага эленгән гитараны алып өстәл янына утыра.

А л и к *(гитараның кылларын чирткәләп).* Чыгарып тондыр син бу калтырчаны, әби! Моның бит кыллары җитешми!

М а м а Л и з а *(гитараны кинәт тартып алып).* Синең үзеңнең кылларың җитешми! Уйный белмисең икән — кагылма! *(Зур саклык белән гитараны элекке урынына элеп куя.)*

Т а м а р а *(кабаланып).* Безгә китәргә вакыт, Алик! Син чемодан белән китапларны күтәр. Ә мин менә боларны комендантка ыргытып китәм... *(Кровате өстендәге юрган белән простыняларны төреп күтәрә.)* Ярый, гаепләп калмагыз. Бик зур рәхмәт сезгә, зурладыгыз. Бик зур рәхмәт! Мама Лиза, я инде, авызыңны турсайтма! Без яшь бит әле...

М а м а Л и з а. Сиңа егерме тулды. Ә аңа?

Т а м а р а. Аңа да егерме бер тулды гына әле. Без әле балалар гына.

М а м а Л и з а. Балалар! Минем Ванюшам унтугыз яшьтә сугышка китте. Үзе теләп! Егерме яшь тә тулмаган килеш һәлак булды. Аның инде ике медале бар иде! Балалар, имеш — егермене узгач!

Т а м а р а *(уңайсызланып).* Ярар инде, мама Лиза, шушындый көнне генә булса да безне ачуланма! *(Китә башлыйлар. Ишек төбендә туктап.)* Китәсе дә килми. Гаҗәп нәрсәләр сөйләдегез бит әле сез... Сау булыгыз!

К а д р и я. Сау булыгыз!

Алик белән Тамара китәләр.
Кадрда ялангач матрацлы кровать.
Кадрия берничә секунд буш кроватька карап тора да өстәл янына килә. Рюмкаларга сала.

К а т я. Синең Мәскәүдә туганың бар бугай, Кадрия. Разияга дару кирәк. Дигоксин яисә изоланид. Казанда юк.

К а д р и я. Язарбыз. Ничек соң?

К а т я. Начар. Мин әле бүген аның янына кереп чыктым. Шунысы начар — ул өметен өзгән. Ул үзенең үләсен белеп ята. Хәтта васыятен дә әйтте.

Кадрия. Нинди васыять?

Катя. Әгәр Миргаяз теләсә — балаларыма ана бул, ди.

Эре итеп: Кадриянең житди, ләкин тыныч йөзе.

Кадрия. Соң? Ни дип җавап бирдең?

Катя. Куркам, Кадрия. Алар дүрт бала, берәү генә түгел. Алар инде зурлар. Мин чит кеше аларга. Куркам. Мин инде хәзер әллә нишләдем. Корыландым.

Кадрия. Бәлки бу хәл үтәр. Бәлки син үзең дә үзеңне белмисеңдер. Нинди генә булса да, синең семьяң булачак. Шатлыгы, кайгысы. Өйгә кайтканда син хәзерге кебек буш өйгә түгел, сине көтеп торган кешеләр янына кайтачаксың. Кемнәргәдер кирәкле кеше булачаксың. Мин аңлыйм, бу чын бәхет түгел, шулай да... Шулай да бу бик зур нәрсә, Катюша. Ул арада бәлкем үзеңнең дә балаң булып куйса...

Катя. Юк, инде булмаячак. Соң инде!.. Менә дару табарга кирәк. Шушы рецептларны тыгып бүген үк хат язып сал, зинһар!.. *(Кадриягә капрон оеклар белән китап бирә.)* Менә, сиңа туган көн бүләге. Кибетләрдә йөрергә вакытым булмады, гаепләмә.

Кадрия. Рәхмәт. *(Катяны кочаклый.)*

Кадрда шәрә кровать.

Кадрия белән Катя кочаклашкан хәлдә шул кроватька карап торалар.

Кадрия. Менә Тамара да китте. Үзен дә яратмый идем, егете дә ошамады. Мин аңа чыкмас идем. *(Әрнү белән.)* Ха-ха-ха!.. Кара, шушы бер бутылка винаны эчеп бетерә алмыйбыз! Әйдәгез, эчеп бетерәбез!

Рюмкаларын тотып өчесе дә өстәл янына җыелалар.

Катя. Туган көнең котлы булсын, Кадрия!

Мама Лиза. Алла үзеңә уйламаган бәхетләрне бирсен!

Эчәләр.

Кадрия. Юк, билләһи, чынлап әйтәм! Менә мондый егеткә мин чыкмас идем... *(Шапылдап урындыкка утыра да өстәлгә капланып елый башлый.)*

Катя. Кадрия! Кадрия, ни булды?

Кадрия. Эх! Нигә шушы тиклем бәхетсез булып тудым икән?!

Катя. Кем бәхетсез? Синме бәхетсез?

Мама Лиза. Син исердең, Кадрия!

Кадрия. Кайдан исерим ди инде!

М а м а Л и з а. Исермәсәң — туэга язмаганны сөйләмә. Нишләп син бәхетсез әле? Күр нинди һәйбәт булмәдә яшибез! Тамагың тук, өстең бөтен. Хезмәтең мактаулы. Кем генә белми сине заводта! Һәммәсе белә. Һәммә кеше ярата һәм хөрмәт итә. Ни өчен без сине депутат итеп сайладык? Ятатканга! Ә менә туган көнеңне юкка яшерәсең. Кунаклар чакырырга иде. Килерләр, җылы сүз әйтерләр иде...

К а д р и я. Аһ, мама Лиза, бу бит башка нәрсә! Бу бит бөтенләй башка нәрсә!.. *(Катяны кочаклап.)* Катюша, син беләсең! Син бит беләсең, Катюша!.. Кырык яшь!.. Кырык яшь тулды миңа да, Катюша! Узды гомеркәем заяга! Буш чәчәк булып корып бетәм лабаса инде, Катюша!..

Ишек шакыган тавыш.

К а т я. Тынычлан! Тынычлан, Кадрия! Кемдер шакый. Әнә кухняга чык, салкын су эч! *(Кадрия кухняга уза.)* Керегез!

Булмәгә япь-яшь бер кыз керә. Бер кулында чемодан, икенче кулында урын-җир әсбаплары.

— Исәнмесез! — ди кыз кыю гына.— Мин Соловьева Люся. Сездә бер урын бушаган икән, мине бирегә торырга җибәрделәр.

К а т я. Менә ул урын. Рәхим ит!

Л ю с я *(бушаган койканы җыештырып)*. Ә сезнең исемегез ничек?

К а т я. Катя, Катюша. Ә менә аны Елизавета Николаевна дип йөртәләр. Без аңа мама Лиза дип кенә әйтәбез инде, үпкәләми.

Л ю с я. Ә сез, тетя Катя, кайсы цехтан?

К а т я. Икенчедән.

Л ю с я. Ә мин җиденчедән. Безнең цех сезнекеннән алда! Хәер, мин әле өйрәнчек кенә анда... *(Булмәгә Кадрия керә)*. Ой, әллә сез дә бу бүлмәдә торасызмы? Мин сезне күрүгә таныдым, сезнең портрет культура сараенда эленеп тора...*(Кроватен җыеп бетереп.)* Әйбәт кешеләр янына туры килдем әле. Югыйсә, беләсезме, мин иртән уяна алмыйм. Беренче сменада чакта гел соңга калам. Ә бер мәртәбә хәтта смена беткәнче йоклаганмын. Мастер мине сигез мәртәбә кисәтте инде. Сез мине иртән уятырсыз бит?

К а д р и я. Син ничек — даими торыргамы, әллә югыйсә...

Люся. Даими торырга, билгеле! Моңа кадәр мин кырык беренче бүлмәдә идем, иптәш кызым белән бер койкада йокладык... Ой, баштан ук гафу үтенеп куям, гаепкә алмагыз, зинһар. Йоклаганда минем тешем шыкырдый...

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Катя. Керегез!

Ишек аз гына ачыла. Анда яшь бер егетнең бөдрә чәчле башы күренә.

— Люсь, мин сине бер сәгать буе эзлим! — дип кычкыра егет. Ләкин егет сүзен әйтеп бетерергә өлгерми, Люся аның башын кире төртеп чыгара да ишекне ябып куя.

Люся. Ой, коточкыч тәрбиясез малай!

— Люська, кинога соңга калабыз бит! — дип кычкыра егет ишек артыннан.

Катя. Ни өчен эшкә соңга калуың беленде, болай булгач.

Люся. Сөйләрсез инде булмаганны. Беләсегез килсә, җенем сөйми шушы малайны! Беренчедән, тәмәке тарта, икенчедән —мактанчык, өченчедән...

— Люська, соңга калабыз бит инде! — дип кычкыра егет ишек артыннан.

Катя. Ярый, бар. Урыныңны бер юлга үзем җыеп бетерермен. Ләкин озак йөрмә, кара аны! Бездә монда коры. Сәгать унбергә кайтып өлгермәсәң — шакып та торма Кертмибез.

Люся. Ой, шул тиклем озак йөрергә сез мине кем дип беләсез, тетя Катя! *(Ишек шакыган тавыш.)* Ой, мәхәббәтсез!.. *(Кычкырып.)* Хәзер, хәзер! *(Ишек төбенә килеп җиткәч туктап кала.)* Әгәр бүген генә азрак соңга калсам — ярармы? Аз гына. Ярты гына сәгать?

Катя. Бүген — ярый.

Люся йөгереп чыгып китә.

Кадрия тәрәзә янына килә. Үрелеп аска карый.

Кадрда Кадрия баскан тәрәзә төбеннән күренгән тулай торак ишеге. Ишектән Люся белән егет чыга. Егет кызны култыклап алмакчы була, ләкин кыз аның кулына сугып җибәрә дә, җилкенә-җилкенә нидер әйтә. Икесе тротуарның ике кырыеннан китәләр.

Ачык тәрәзәдә Кадрия. Аның бер ягында Катя, икенче ягында мама Лиза.

Кадрия *(китеп баручы яшьләргә карап)*. Монысы да озак тормаячак.

1965 ел.

Талантлы яшь артистка
Рауза Уральскаяның
якты хатирәсенә

Автор.

ПРОФЕССОР КИЯВЕ

Комедия 4 пәрдәдә, 6 күренештә

КАТНАШАЛАР:

Хуҗин
Разия
Гөлсинә
Рөстәм
Абдул
Сергей
Сәлим
Зәйнәп
Фәйрүзә
Эдуард
Людмила
Алексей Степанович

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

1 КҮРЕНЕШ

Хуҗин өендә бүлмә. Каршыда һәм як-якта ишекләр. Сулда зур бер тәрәзә. Җиһазлар. Стеналарда берничә портрет. Өстәл. Тумбочка өстендә телефон. Пәрдә ачылганда сәхнәдә Разия ялгыз. Бераздан звонок тавышы ишетелә. Разия ишек ача. Култык астына төргәк кыстырып, Хуҗин керә.

Хуҗин *(төргәкне Разияга сузып)*. Магазинга керсәм, биреп яталар бит.

Разия. Һа, пан-бархат! Гөлсинәгәме?

Хуҗин. Кемгә дип уйлыйсың?

Разия. Гөлсинәгә, билгеле. Минем инде пан-бархатлар кияр вакытым узып бара. Һа, бигрәк тә һәйбәте туры килгән икән. Тик менә, һай, белмим, үзе ошатыр микән, Әхмәт. Теге вакытта әнә чернобурканы да алдырмады.

Хуҗин. Алмадыкмы соң?

Разия. Алуын алдык та бит, үзе белми әле. Кемгә генә охшап шундый табигатьле булгандыр инде бу бала.

Хуҗин. Без алыйк әле. Студентка чагында кияргә теләмәсә, укып бетергәч, врач булгач кияр. Аннан соң аның кияве кем булачак бит! Бүген Эдуардның атасын күрдем. Ул егет өйләнү турында уйланып йөри икән. Атасының тел төбе шулайга тарта.

Разия. Соң?

Хуҗин. Мин әйттем, Эдуардны яхшы белмәсәм дә, үзеңне яхшы беләм, алма агачыннан ерак төшмәгәндер, дидем.

Разия (*кызыксынып*). Ээ.

Хуҗин. Шуннан, мин әйтәм, әгәр балалар үзләре риза булсалар, без каршы түгел.

Разия (*йомшап*). И алла, шулай итеп бердәнбер йөрәк бәгыремнән дә аерылырмын микән! Ичмаса институт бетергәч тә түгел.

Хуҗин. Менә мин дә шуны әйттем шул. Кем, мин әйттем, Мәхмүт кордаш, әллә балалар укып бетерсеннәрме элек, яратышу-яратышмаулары да яхшырак күренер, мин әйтәм.

Разия. Ни ди соң?

Хуҗин. Бу нәрсәне ул да мәгъкуль күрде. Эдуард белән әйбәтләп сөйләшергә булды. (*Төргәк янына килеп.*) Син моны җыеп куй әле. Үзе күрми торса да ярар.

Разия. Кая куярмын икән инде тагын, теге сандыкка сыймый, болай да көчкә-көчкә генә яптым.

Хуҗин. Икенчесенә сал.

Разия. Инде икенчесен дә бикләп булмый, Әхмәт. Гөлсинә әллә ни уйлар. Әле бу сандык бикле булуга да оялып йөрим.

Хуҗин. Ә син аңа ачкычы югалган, диген.

Разия. Белмим инде, кемгә генә охшап шундый табигатьле булгандыр. Бер генә дә затлы әйбер алдырмый бит. Алган әйберләреңне дә җәфаланып, яшереп йөр инде шулай. (*Төргәкне күтәреп китә башлый.*)

Хужин. Шулай да, безгә аның балалык акылына карарга ярамый. Ни очрады шуны киеп йөрергә ул бит мужик кызы түгел, ул — профессор Хуҗин кызы!

Хуҗин үз бүлмәсенә кереп китә. Звонок. Разия ишек ачарга чыга. Артта аның тавышы ишетелә.

Разия. Өйгә керегез. Ул хәзер кайтып җитәр.

Рөстәм керә.

Йомыш Гөлсинәдә идемени?

Рөстәм. Әйе. *(Оялып.)* Без театрга барасы идек. «Алтынчәч»кә.

Разия. Ә-ә... Кара, әй, өйдә туры килмәде ләбаса. Бүген операда «Алтынчәч» барамыни?

Рөстәм. Әйе. Мәргәнне авылдашым җырлый.

Разия. Ә-ә... Сез авылданмыни әле? Онытып та торам, сез медицина институтында укыйсызмы соң?

Рөстәм. Юк, мин заводта эшлим.

Разия. Шулай укмыни инде?! Инженер?

Рөстәм. Юк, токарь.

Разия. Алаймы? Укыйсы итмәгәнсез икән алайса, укуны сөймәгәнсез икән.

Рөстәм. Эш сөюдә генә түгел бит, апа.

Разия. Ничек инде?

Рөстәм. Тормыш бит, укырга мөмкинчелек булмады. ФЗӨ мәктәбен бетердем. Хәзер эшлим менә, сигез ел инде. Әле быел кичке мәктәпкә кердем. Азрак укырга исәп.

Разия. Булдыра алгач укырга кирәк шул. Кара, шул гомердән бирле онытып торам, әй, утырыгыз инде.

Рөстәм утыра.

Укырга кирәк шул. Картлар, йөз ел яшә, йөз ел укы, дигәннәр. Гомер буе майга буялып йөргәнче, укып кеше булырсыз, ичмаса.

Рөстәм. Юк, эш анда гына түгел, апа. Укымаган кеше станокта да эшли алмый бит хәзер. Машиналар катлаулы.

Разия. Ә-ә, ничек соң, акыллым, бик авыр түгелме? Азрак акча төшереп буламы?

Рөстәм. Аптыраган юк алай.

Разия. Шулай да, күпме эшләп була соң, акыллым?

Р ө с т ә м. Мең, мең ярым... Әле сеңелләрне тәрбияләргә әнигә дә булышам.

Р а з и я. Яхшы, яхшы. Ни, сеңелләрегез дә бармыни әле?

Р ө с т ә м. Өчәү! Зурысы быел ун класс бетерә.

Х у җ и н (*күрше бүлмәдән*). Разия, син моннан берәүгә дә китап-мазар бирмәдеңме?

Р ө с т ә м (*торып*). Гафу итегез, мин эшегезне бүлдем, ахры.

Р а з и я. Озакламый кайтып та җитәр дә бит инде ул, әллә булмаса көтеп утырасызмы?

Р ө с т ә м. Юк, рәхмәт, апа. Мин бераздан сугылырмын. Хушыгыз. (*Китә.*)

Х у җ и н (*ишектә*). Безнең библиотекадан китап алган кеше булмадымы?

Р а з и я. Эдуард кына бер-ике китап алган иде, аңа үзең рөхсәт иттең.

Х у җ и н. Алайса ул алгандыр. Ул шул тема буенча доклад хәзерли.

Р а з и я. Эдуард дигәннән, бигрәк тә күп укый инде ул егет.

Х у җ и н. Ул малай бик өметле булып күренә миңа. Аннан менә дигән фән кешесе чыгарга тиеш.

Телефон шалтырый. Х у җ и н телефонга бара.

Әйе, ә, Алексей Степанович! Исәнмесез, әйе. Әйттем бит мин сезгә. Ярый, ярый. Ә нигә «хуш». Хәзер үзем барып җитәм. (*Шатланып трубканы куя, өстенә киенергә бара.*)

Р а з и я. Әле кая җыенасың?

Х у җ и н. Мин клиникага барып килим әле, Разия. Анда Алексей Степановичның тәҗрибәсе матур гына нәтиҗә биргән.

Р а з и я. Син тагын бигрәк инде. Яшьләр артыннан куып булмас инде ул. Хәзер самовар кайный, ял ит азрак.

Х у җ и н. Мин арымадым, кечкенәм.

Р а з и я. Анысын каян айкап чыгардың инде тагын? Алтмышка җиткән карчык кайдан килеп кечкенә булсын, ди, инде? Яшь вакыттагы шуклыкларны куярга вакыт.

Х у җ и н. Һе, син әби дә булып барасың, алайса. Иртәрәк җыенасың түгелме соң?

Р а з и я. Җыенмый тагын. Йөзгә хәтле яшәмәссең ич?! Картлык басып бара лабаса инде.

Х у җ и н. Ә, минемчә, юк әле, Разия, минемчә, картлык дияргә иртәрәк әле. Картлык! Һе! Картайдыкмыни соң инде без? *(Көзгегә карый.)* Әйе. Чәчләр коелып бара, сакал-мыеклар да агарган. *(Борылып.)* Әмма мин карт түгел әле.

Р а з и я *(көрсенеп)*. Күңел яшь булу белән генә эш бетсә иде... Сиңа инде 65 яшь тулды. 65 яшь! Кырык елдан артык аруны белми, талуны белми эшләү, баш вату. Ул еллар күпме көчне сыгып калганнар бит.

Х у җ и н. Шуннан?

Р а з и я. Мин синең өчен борчылам. Эшләгән кадәресенә канәгатьләнергә кирәк.

Х у җ и н. Ягъни, гади генә итеп әйткәндә, ничек була инде ул?

Р а з и я. Ул башлаган хезмәтләрне башкарып чыгу өчен ике гомер дә җитмәс. Кайберләрен куйсаң да ярар.

Х у җ и н. Ни сөйлисең син, Разия?!

Р а з и я. Син сәламәтлегеңне бетерәсең, мин үзеңне жәллим.

Х у җ и н. Жәлләмә! Минем жәл кеше буласым килми.

Р а з и я. Мин алай әйтергә теләмәгән идем...

Х у җ и н. Ахмак сүз сөйлисең син, ахмак сүз. Кара инде, ә! Синнән мондый сүзләрне һич кенә дә көтмәгән идем бит.

Р а з и я. Бетте, бетте. Мин дәшмим. Мин аңлыйм сине.

Х у җ и н. Юк. Мондый сүзләрне әйтә алгач, аңламыйсың син мине. Аңламыйсың. Уйлап кара әле менә: мин теге, хәтта Америка журналларында да телгә алынган эшемне моннан егерме биш ел элек эшләдемме? Егерме биш ел элек. Ничек шаулады дөнья? Нишлиләр иде ул вакыт? Казанында да, Мәскәвендә дә, Европасында да, Америкасында да, Хуҗин методы, дип кенә җиффәрәләр иде. Ә хәзер бетте. Оныттылар Хуҗинны. Янәсе, Хуҗин инде әйтәсе сүзен әйтеп бетергән кеше. Юк! Мин үземнең кемлегемне күрсәтергә тиеш. Шушы яңа хезмәтем белән бөтен дөньяны шаулатам әле мин. Аңладыңмы?

Г ө л с и н ә керә.

Р а з и я. Озакладың, кызым. Карының бик ачмадымы?

Г ө л с и н ә. Юк, әнкәй. Мин буфетта булдым. *(Булмәсенә уза.)*

Х у ж и н. Тормыш дигәнең менә шулай ул, кечкенәм. Кешелек дөньясы азгын. Син аңа сенсацияләрне биреп кенә тор. Шулай булмаганда сине бик тиз оныталар.

Р а з и я. Ләкин бу рәвешле син ерак бара алмассың. Синең бөтенләйгә фәнгә чумганыңа унбиш ел инде менә. Шул унбиш ел эчендә фән өчен ниләр генә корбан итмәдең син! Әдәбият укуны ташладың. Биш ел инде менә безнең театрга, киногa аяк басканыбыз юк. Беркөн әнә радиодан Бетховенның тугызынчы симфониясен тапшырдылар. Ә син тыңламыйча лабораториянә киттең. Элек син Бетховен музыкасын ишеткәндә дөньяңны оныта идең. Шулай ук Бетховеннан да туйдыңмыни инде син?

Х у ж и н. Бетховен — гений, Разия. Һәм минем Бетховен музыкасыннан туйганым юк. Әмма ләкин яшәү өчен көрәштә башкалар тарафыннан тапалып калмас өчен мондый нәрсәләрне генә корбан итәргә мөмкин. Бар әле, бар, баланың карыны ачкандыр. Ашат. *(Булмәсенә китә.)*

Р а з и я *(Гөлсинәнең ишегенә килеп)*. Гөлсинә, кызым! Чык әле бире. *(Бераз икеләнеп торганнан соң Хуҗин алып кайткан төргәкне өстәлгә куя.)*

Г ө л с и н ә чыга.

Кил әле бире. *(Төргәкне сүтә.)* Менә сиңа әткәң нәрсә алып кайткан.

Г ө л с и н ә *(күреп)*. Шундый нәрсәдер дип уйлаган идем аны. Әнкәй, нәрсәгә дип сез миңа шулкадәр әйбер җыясыз?

Р а з и я. Тсс. Әткәң ишетмәсен.

Г ө л с и н ә. Миң әткәйнең үзенә дә әйтәм...

Р а з и я. Тсс! Әйтеп кенә кара.

Г ө л с и н ә. Әнкәй, ничек сез аңламыйсыз. Мин бит әле студентка гына. Нәрсәгә миңа алай кабарынып йөрергә? Нәрсәгә миңа каракүл манто?!

Р а з и я. Ә, ә, аны сиңа дип алмаган ла.

Г ө л с и н ә. Яшермә, әнкәй, барысын да миңа дип аласыз. Миңа җыясыз. Ләкин нәрсәгә?! Ул манто, ул

исәпсез күлмәклекләр, ничәшәр меңлек алкалар. Теге сандыкта...

Р а з и я. Теге сандыкныңмы, ә, аның ачкычы әллә кая югалган әле.

Г ө л с и н ә *(сәер карап)*. Әнә, комод тартмасында ята. Ул чернобурканы...

Р а з и я *(сискәнеп)*. Ә, анысы сиңа түгел, кызым.

Г ө л с и н ә. Кемгә?

Р а з и я. Ә, ни, аны әтиең алган иде.

Г ө л с и н ә. Әткәй алган шул, алмаска кушкач та алган.

Р а з и я. Юк ла инде! Аны әткәң алган иде... Бүләккә алган иде, кешегә.

Күзләре белән очрашалар.

Г ө л с и н ә *(көлеп)*. Әнкәй! *(Разияны кочаклап үбеп ала.)* Үзең алдаша да белмисең.

Р а з и я. Синең белән, бала, белгәнеңне дә онытырсың. Кемгә генә охшап мондый булгансың. Әткәң ул үзеңне яратканга шулай эшли. Безнең бит башка балабыз юк. Бердәнбер кызыбызны да курчак иттереп киендермәгәч, без кемне киендерик.

Г ө л с и н ә. Ә мин курчак булырга теләмим, әнкәй. Минем үземнең иптәшләрем шикелле, гади буласым килә.

Х у җ и н чыга. Гөлсинә үз бүлмәсенә китә башлый.

Минем янга килүче булмадымы, әнкәй?

Р а з и я. Килгән иде...

Г ө л с и н ә *(бүлеп)*. Эдуардмы?

Р а з и я. Юк, заводтан, ди.

Г ө л с и н ә. Ә, Рөстәмдер, алайса.

Р а з и я. Әйе, әйе, бераздан әйләнергә булып китте. «Алтынчәч»кә чакырасы бугай.

Г ө л с и н ә. Кызганыч, минем вакытым булмаячак. *(Керә башлый.)*

Х у җ и н. Нинди Рөстәм әле ул?

Г ө л с и н ә. Безнең курс шефка алган заводтан, әткәй.

Х у җ и н. Инженермы?

Г ө л с и н ә. Юк, токарьмы шунда, слесарьмы,— яхшылап үзем дә белмим. *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Х у җ и н. Токарьмы шунда, слесарьмы шунда?!

Р а з и я. Әйе, токарь, ди. Бик чибәр егет. Укый гына алмый калган, мескен.

Х у җ и н. Нишләп йөри ул монда?

Р а з и я. Театрга чакырырга килгән дим ич, аннан башка йомышы да бардыр. Шефлык итү буенча Гөлсинә җаваплы бит. Шуңа килә торгандыр.

Х у җ и н. Ә ни өчен ул театрга чакырырга килгән?

Р а з и я. Ә ни булган, ди, килсә! Чибәр кызларны шулай чакыралар инде аны.

Х у җ и н. Чибәр кызлар үзләренең заводларында беткәнмени аңа?

Р а з и я. Син ни сөйлисең, Әхмәт?

Х у җ и н. Ни ишетсәң, шуны сөйлим. Шефлык хакында алар институтта да сөйләшә алалар, театрга бармыйча да.

Р а з и я. Син әллә бу эшкә гыйшык кушылган дип уйлыйсыңмы?

Х у җ и н. Әлбәттә.

Р а з и я. Китсәнә! Студенткага, өстәвенә, профессор кызына өмет салып йөрергә башына тай типмәгәндер. Китче, кит! Бик һәйбәт егеткә охшаган ул. Бер дә андый кеше төсле түгел. Тузга язмаганны сөйләмә.

Х у җ и н. Мин үзем дә бу нәрсәне башыма сыйдыра алмыйм. Әмма, белмәссең. Хәзерге яшьләр үзләре турында бик эре фикердә булалар. Эдуардның килгәне бармы?

Р а з и я. Узган шимбәне килгән иде.

Х у җ и н. Гөлсинә белән аралары ничегрәк икән, кызыксынганың юкмы?

Р а з и я. Болай әйбәт кенә күренә, Гөлсинәне бик тә ярата бугай. (*Көлә.*) Ул көлүләре, ул сөйләшүләре әллә нинди генә инде менә. Гөлсинәне күрдеме инде, мәк чәчәге кебек кып-кызыл була.

Х у җ и н. Аның гына яратуы аз. Гөлсинәнең дә яратуы кирәк.

Звонок. Э д у а р д керә.

Э д у а р д. Исәнмесез. Исәнмесез, Әхмәт ага!

Р а з и я. Әле хәзер генә үзегезне искә төшереп тора идек. Гомерегез озын буласы икән.

Э д у а р д (*шат*). Мине?!

Х у җ и н. Сез анда минем монографияне алып киткәнсез, ахры.

Эдуард. Әйе, ул миндә, Әхмәт ага. Мин аны берничә көннән укып бетерермен.

Хужин. Ярый, ярый, укып бетерегез.

Гөлсинә чыга. Хужин, Разия китәләр.

Гөлсинә *(шат)*. Эдуард! Исәнме, Эдуард. Син миңа шулкадәр кирәк идең.

Эдуард *(шатланып)*. Мин?!

Гөлсинә. Беләсеңме нәрсә: бер-ике сәгатьтән без үзешчәнлек концерты белән колхозга китәбез. Ә аккордеончы малаебыз авырып киткән. Менә шуның урынына сине чакырырга уйлаган идек.

Эдуард *(көлеп)*. Сез, ахрысы, гастроль биреп йөрүче профессиональный актерлар булып киттегез.

Гөлсинә. Кирәк бит, Эдуард. Комсомол шулай куша. Ох, беләсеңме, алар ничек яхшы каршы алалар! Барганыңа һич үкенмәссең.

Эдуард. Бу нәрсә, агитировать итүме?

Гөлсинә. Син ризадырсың бит?

Эдуард *(уйлап)*. Мин бара алмыйм.

Гөлсинә. Нишләп?

Эдуард. Беренчедән, миндә ангина. Икенчедән, кичә мин уң кулыма егылдым. Бармагымның буыннары авырта.

Гөлсинә. Эх, син!

Эдуард. Юк, чынлап. Кичә институттан кайтканда егылдым.

Гөлсинә. Ышанам, ышанам. *(Эдуардның кулын баскалап карый)*. Авыртамы? Авырта? Юк?!

Эдуард. Менә бу буыннары.

Гөлсинә. Бәрелгәнсең. Примочка ясарга кирәк иде. Ясадыңмы?

Эдуард. Алай каты авыртмый да ул үзе, ләкин аккордеонда уйнап булмый.

Гөлсинә. Без тагын бар өметебезне сиңа куеп торган идек. Бәлки шулай да барырсың, Эдуард? Ә? Безнең концерт өзелү алдында тора бит.

Эдуард *(ирония катыш)*. Өзелсә, билетлар сатылмагандыр бит әле.

Гөлсинә. Шаярып сөйләшмә әле, Эдуард, хәзер вакыты ул түгел. Алайса, бара алмыйсың?

Эдуард. Бара алмыйм.

Гөлсинә. Нинди кызганыч...

Эдуард *(үпкәле)*. Миңа да кызганыч. Сиңа әле колхозга барырга кирәк, әле заводка. Сиңа комитеттагы эшең кадерлерәк. Ә мин синең өчен барыбер.

Гөлсинә. Әйе, комитеттагы эшем миңа кадерле. Ләкин син минем өчен барыбер түгел.

Эдуард *(бүлеп)*. Барыбер булмаса, кал минә бүген. Бер тапкыр бармаган өчен әллә ни эшләтмәсләр. Синнән башка да кеше табылыр.

Гөлсинә. Ни сөйлисең син, Эдуард! Бу мөмкин түгел.

Эдуард. Хәзер бит җәй түгел инде, сентябрь бетеп бара. Салкын алдырып кайтырсын әле.

Гөлсинә. Без автобус белән барабыз.

Эдуард. Автобус белән барсаң да...

Звонок. Разия ишек ачарга чыга.

Гөлсинә. Алайса иртәгә килерсең, яме?

Эдуард. Нәрсәгә?

Гөлсинә. Ну... Берәр җиргә барырбыз.

Рөстәм белән Разия керәләр.

Рөстәм. Исәнмесез!

Гөлсинә. Исәнмесез. Узыгыз, Рөстәм. *(Эдуардка.)* Иртәгә җидегә килерсең, яме?

Эдуард. Җидегәме?

Разия. Китәсез дәмени, Эдуард? Нишләп бик тиз?

Эдуард Миндә субфебрилитет, Разия ханым.

Разия. Нәрсә булган алай?

Эдуард. Angina catarrаlis. Ну мин китим әле. Хушыгыз.

Гөлсинә *(ишеккә кадәр озата килеп.)* Мин көтәрмен, Эдуард, ярыймы?

Эдуард китә.

Нишләп узмыйсыз, Рөстәм, узыгыз, утырыгыз.

Рөстәм. Рәхмәт, мин узып тормыйм. Беркөнге вәгъдәгез буенча, Гөлсинә, мин сезне «Алтынчәч»кә чакыра килгән идем.

Гөлсинә. Миңа әнкәй әйтте. Тик гафу итегез, Рөстәм. Безнең вакытыбыз юк. Без агитбригада белән колхозга чыгабыз.

Хужин чыга.

Р а з и я. Бүген вакыты юк шул, акыллым, әле минем иптәш егете дә чыгып китте. Бергә укый торган, институтгагы. Сез үзегез генә барып тыңлагыз инде, алай авылдашыгыз да җырлыйсы булгач...

Х у җ и н. Менә тагын. Егет кеше театрга ялгыз йөри димә инде! Заводта менә дигән кызлар аһ итеп торалар булыр әле. Шулай бит, энекәш, сер бирмә үзләренә, әйт шулай.

Г ө л с и н ә. Сез ачуланмагыз инде, Рөстәм, яме?

Р ө с т ә м. Юк, нишләп ачуланыйм. Мин тик вәгъдәгез буенча гына килгән идем.

Г ө л с и н ә. Барырбыз дигән идем дә шул, күрәсез — эш чыкты.

Р ө с т ә м. Ярый, ләкин вәгъдәгез көчендә кала. Хушыгыз.

Р а з и я. Хушыгыз, акыллым.

Х у җ и н. Хуш, энекәш.

Г ө л с и н ә. Рөстәм! Бер генә минутка туктагыз әле. Сез аккордеонда уйный беләсез бит?

Р ө с т ә м. Ну, шуны да белү дисәң. Кычкыртам инде шунда.

Г ө л с и н ә. Юк, минем сезнең уйнаганыгызны ишеткәнем бар. Сез әйбәт уйныйсыз. Беләсезме нәрсә: безнең аккордеончыбыз авырып китте. Шуның урынына бара алмассыз микән? Башка һич кешебез юк.

Р а з и я. Кит аннан, кызым. Кешенең театрга барасы бар лабаса.

Р ө с т ә м *(уйлап)*. Мин бик теләп барыр идем дә, иртән сәгать алтыда сменага.

Р а з и я. Алай лабаса. Ул бит сезнең кебек түгел, эш кешесе.

Г ө л с и н ә. Беләсезме, без аннан төнен кайтабыз. Автобус белән.

Р ө с т ә м *(уйлап)*. Алай булганда, мин риза. Кайчан китәбез?

Г ө л с и н ә. Тиздән автобус килеп җитәчәк. Ә хәзер, безнең иптәшләр менә монда, күршедә генә җыелалар,— мин сезне шунда озатып куям. Азрак репетиция ясый торырсыз. Концерт өзелә дип котым очкан иде. Менә бәхет!

Чыгалар.

Р а з и я. Бу нәмәрсә икән, Әхмәт? Алдан уйлап куелган эш микән, яисә болай гына микән?

Х у җ и н. Ә сиңа барыбер түгелмени? Әйе. Моның нәтиҗәсе шәп булмас. Әйдә, карыйк әле, кая киттеләр икән?

Тәрәзәдән карыйлар.

Күрден, култыклап та өлгергән.

Р а з и я. Ярабби, хур булабыз лабаса!..

Х у җ и н. Беренче мәртәбә өйгә килгән кеше белән култыклашып чыгып киттеләр бит, әl Таныштырырмы дип бер сәгать янында басып тордым. Юк. Кем булуын, нинди кеше икәнлеген әйтү юк, әткәсе белән таныштыру юк.

Р а з и я. Ул кадәр кайнарланма әле син, Әхмәт. Култыкласа култыклаган инде. Аннан гына кызыңның укасы коелмас. Алар бит күршегә генә керәләр.

Х у җ и н. Күршегә керәләр! Аннан колхозга китәчәкләр. Ул һәрвакыт шулай башлана. Профессор кешенең өенә килеп йөрергә ни калган аңа бирелә? Гөлсинәгә бүген үк әйтергә кирәк. Очраган бер кешене өйгә китермәсен. Бу постоялый двор түгел.

Г ө л с и н ә керә.

Г ө л с и н ә. Нәрсә булды, әткәй?

Пауза.

Х у җ и н. Син, кызым, безнең бердәнбер балабыз. Бердәнбер куанычыбыз. Синең әллә гамендә дә юктыр. Әмма безнең үзенә тин булырлык, туган итеп семьяга кабул итәрлек кеше очраса ярар иде, дип уйламый калган көнебез юк.

Г ө л с и н ә *(елмаеп)*. Әткәй...

Х у җ и н. Син аның хәтере калыр дип уйламыйсынмы?

Г ө л с и н ә. Сон мин колхозга бармый кала алмыйм бит инде, әткәй.

Х у җ и н. Колхозга барырга кирәк. Әмма ләкин бу эш икенчесенә сабак булсын. Эдуардның киләчәге бар аның, ул, институт бетергәч, аспирантурада калачак. Кеше булачак ул! Ә бу малай кем! Акны карадан аера белмәүче...

Гөлсинә. Бөтенләй юк өчен борчыласың, әткәй. Күңелдә юк нәрсәне уйлап борчыласың.

Разия. Кызым, бәгырем, без бит сине менә бу завод малаен яраткансың дип белдек.

Гөлсинә (*көлә*). Әнкәй, ниләр генә уйлап бетермисез сез! Очраган бер кешене яратып йөрергә мина бит унөч яшь түгел.

Хуҗин. Һай, рәхмәт, бәбкәм, шатландырдың. Рәхмәт. Безгә ачуланма, кызым, син әле яшь, бик күбесен аңлап житкермисең. Кара инде, ә! Курыкканга куш күренә дигәннәр, ниләр уйлап бетермәдек бит. Әллә каян килгән бер малай белән профессор кызы арасында нәрсә булсын соң инде! (*Чыгып китә.*)

Гөлсинә Әткәй, кайбер нәрсәләрне син үзең дә аңлап бетермисең шул.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

2 КҮРЕНЕШ

Эшчеләр торагында якты һәм пөхтә җыештырылган бүлмә. Тәрәзәләр. Дүрт койка Бер койка янында Рөстәм утыра. Ул китап укый. Өстәл артында Сәлим нәрсәдер яза. Каршыдагы койка янында Абдул чемодан актара. Сергей йоклый.

Абдул. Дуслар! Хәзерләнергә вакыт. Кичә башланырга бер генә сәгать калды. (*Чемоданнан бик күп галстуклар чыгара.*) Рөстәм, син ничек уйлыйсың, әгәр мин бүген менә бу галстукны таксам, ә?..

Рөстәм (*карамыйча*). Әйбәт булыр.

Абдул. Әйбәтлегеи үзем дә беләм лә мин аның. Юк шул, батмый. Ни күлмәккә охшамаган, ни костюм белән под цвет түгел. Ә бусы ничек булыр икән... Рөстәм?

Рөстәм (*урыныннан калкып һәм укуында дәвам итеп*). Таптым! Таптым, Абдул!

Абдул. Тсс... Нәрсә шулкадәр кычкырасың?

Рөстәм (*Абдул янына килеп*). Менә кара: Ленинград токаре Борткевич яза. Менә бит эш нәрсәдә икән!.. Болай булгач, бөтен гаеп синдә булып чыга.

Абдул. Ә?!

Рөстәм. Әйе, әйе. Бөтен гаеп синдә һәм синең станогыңда. Вибрация янәшәдә синең станок эшләүдән туа икән. Ә мин никадәр баш ваттым. Болай булгач, үзеңә башка урын табасың.

Абдул. Әбиеңә сәлам әйт, яме. Миңа син комачауламыйсың, телисең икән, урыныңда эшли бир. Әгәр мин сиңа комачауласам, станогыңны күтәрәсең дә, рәхим итәсең.

Рөстәм. Син шаярып сөйләшмә әле.

Абдул. Мин шаярмыйм. Әгәр вибрация идән аша күчә икән, димәк, безнең завод шартларында югары тизлек белән кырдыру мөмкин түгел.

Рөстәм. Нигә мөмкин булмасын? Моның өчен башка станокларны күчерү җитә.

Абдул. Син, егет, мәхәббәт артыннан куа-куа акылыңнан яза башладың, ахры. *(Рөстәмнең маңгаена тукып.)* Син менә моның белән уйлап кара әле: бер станок яхшырак эшләсен өчен калганнарын чыгарып ташлаганны кайдан ишеткәнең бар синең? Якын көннәрдә мин дә тизлекне 500 метрга җиткерсәм, ә? Башкалар да. Һәр кешегә бер цех булмас бит. Беләсеңме нәрсә: син башта яхшылап укы әле. Укып бетер. Борткевич нишләгән, ничек яза?

Рөстәм баскан килеш комсызланып укый.

Син бер генә минутка туктап тор әле. Менә шушы галстукны гына өтеләп алыйм, кырые бөгәрләнгән икән. *(Урындыкка басып, лампочкада галстук үтүкли.)*

Рөстәм. Тукта, Абдул, тукта. Менә тыңла: «Берничә көн үтте. Станокка астына ике рәт имән араталар түшәлгән бетон фундамент ясалды. Ике йөз миллиметр калынлыктагы торф белән аралаштырылган күмер катлавы станокны әйләнә-тирәдән аерды. Тирбәнүләр тукталды».

Абдул. Во! Укып бетер дидем бит. Ә синең акылыңнан элек авызың кычкыра. Имеш, сезнең станокларны күчерергә кирәк. *(Галстук үтүкли.)* Син җавап бирмәдең әле миңа. Менә шушы галстук ярар бит, ә?

Сергей *(урыныннан)*. Мин сиңа һаман әйтәм, Абдул, сиңа берьюлы икешәр галстук тагарга кирәк.

Берне алга, берне артка. Шулай итмәгәндә синең галстукларыңны улларың да тагып бетерә алмаячак.

Абдул. Ярар, ярар. Яссы мәзәкләр белән вакыт уздыра торган чак түгел. Кич булды. *(Көзге каршысына килеп галстук тага.)* Нишлим соң инде, матуррак галстук күрсәм, сатып алмый түзә алмыйм шул.

Пауза.

Безнең кичәгә студенткалар да киләсе бит. Чибәррәк булып тору яхшы.

Сергей. Зәйнәбе булмагач, нинди бизәнә! Кара аны, Зәйнәп кайткач, барын да әйтәм.

Абдул. Исем китте! Минә син ичмаса пропащий человек. Авылдагы хатыныңнан куркып, кызлар белән танцевать итәргә дә базмыйсың. Ә минем нәрсә! Зәйнәп минем хатыным түгел бит әле. Тор, әйдә, клубка халык жыела башлады. *(Галстугын тагып бетерә дә тормый яткан Сергейның өстеннән юрганын тартып ала.)* По-о-одъ-ем! *(Сергейның аякларыннан алып чана бөгә.)*

Сәлим. Акрынрак мөмкиндер бит.

Абдул. Түбәнчелек белән гафу үтенәм. *(Сәлим янына килә.)* Их, Сәлим! Үтәр еллар. Үзеңнән соң бик зур ижат мирасы калдырып син үләрсең, ә, юк, синең йөрәгең тибүдән туктар.

Сәлим *(әсәрләнеп)*. Тибүдән туктар!

Абдул. Нәрсә язасың әле син? *(Сәлимнең бер кәгазен алып читкә йөгерә һәм кулларын бутыйбутый укый.)*

Йөрәгемдә кайнар ялкын кайный,
Эсселегеннән башым әйләнә.
Йөрәгемне шашкын хисләр талый,
Рәхәтеннән телем бәйләнә.
Минем йөрәк тибә синең белән,
Ул йөрәктә гөлләр үсәләр.
Йөрәгемнән чыккан сәламемне
Таңгы жилләр сиңа илтәләр.

Во! Менә ичмасам чын йөрәктән чыккан сүзләр! Биредә йөрәк дигән сүз үзе генә дә... биш жирдә кабатлана!

Сергей *(юынырга чыгып барышлый)*. Бал, бал дигәннән авыз балланмый, Абдул. *(Чыга.)*

Абдул. А-а, чак кына онытмаганмын, Сәлим. Бая синең янга бер кыз килгән иде. Фәйрүзә исемле.

Сәлим сискәнеп китә.

Сәгать җидедә тагын керергә булып китте.

Сәлим. Минем барасы җирем бар.

Абдул (*Сәлимнең киенүен күреп*). Барасың булса, башта урыныңны рәтләп җый.

Сәлим. Җыйган бит.

Сергей керә.

Абдул. Ул җыю түгел, Сәлим! Сережа, давай, староста булсаң, староста бул, җыйдыр. Юкса син монда конкурста беренче призны алам дип көн-төн тырышасың, ә ул... Беркөнге санкомиссия вакытында да синең тумбочкаңда беспорядок таптылар. (*Сәлим урынын төзәтә.*)

Сергей. Яхшылап җый. (*Сәлим яңадан урынын рәтли.*) Мендәреңне рәтлә.

Абдул (*кул селтәп*). Ярар, Сережа, калдыр. Даһи кешеләр шулай сәеррәк булалар инде ул.

Рөстәм керә.

Рөстәм. Син ничек уйлыйсың, Сергей, бүгенге кичәгә Гөлсинә килер микән?

Сергей. Белмим шул, аларның хәзер имтихан вакыты бит.

Рөстәм. Ул бүген соңгы имтиханын бирде.

Сергей. Каян шундый төгәл мәгълүматлар?

Абдул. Һе, ул бит Гөлсинә турындагы бөтен мәгълүматны җыя. Өстәвенә көн аралаш үзе очрашып тора. Әле институттан кайтканын, әле өйдән чыкканын сагалый. Имеш, случайно гына очрашалар.

Сергей. Шулай да, Рөстәмнең эшенә зыян килгәне юк. Узган ел син Зәйнәбең артыннан йөргәндә, хәлләр башкачарак иде бугай.

Абдул. Булса булгандыр тагын. Мин кызларга ошыйм дип, тиремнән чыгып төшә белмим. Булмас нәрсә артың белән койма җимерсәң дә булмый инде ул.

Сәлим. Мин сезгә бу турыда биш ай элек әйткән идем бугай. Беләсеңме, Рөстәм, мин сиңа дус итеп

әйтәм: Гөлсинә белән синең эш пешмәячәк. Уйлап карагыз. Уйлап карагыз! Кем ул Гөлсинә? Гөлсинә — студентка, ул, әйтергә кирәк, биш минуттан врач булачак кеше. Моның өстенә аның этисе. Профессор тикле профессор кешенең кызына гашыйк булып йөрү — бу — ахмаклык. Ахмаклык кына да түгел, бу... э... ничек әйтергә инде сезгә, татарча сүз таба алмыйм, бу — нигезсезгә воображать итү. Бу — иллюзия. Син бит надан бер токарь!

Сергей. Юк. Токарь гына булсак та, без үзебезне бер кешедән дә ким санамыйбыз. Без шул ук профессорлар белән бер юлдан йөрүче совет кешеләре!

Сәлим. Бу бик еш әйтелә торган сүзләр. Мондый сүзләр белән шигырь язсаң, трафарет фразалар белән язуда гаепләячәкләр һәм, мин сиңа гарантия бирәм, ул шигырьне басмаячаклар. Конкретнорак?

Сергей. Конкретномы? Конкретносы шул: кичә Рөстәм гади бер токарь иде. Бүген исә ул, кичке мәктәптә уку өстенә, заводның танылган стахановчысы да. Ә иртәгә, тели икән — ул студент, берсекөнгә — инженер.

Сәлим. Ышанам, ышанам. Ул Гөлсинә белән танцевать итәр өчен танцага өйрәнде инде. Әгәр яраттырасы килсә, мин шикләнмим, инженер да булыр.

Рөстәм. Туктагыз әле, иптәшләр. Минем сезгә өмет өзелде дигәнем юк бит. Минемчә, Гөлсинә кебек кызның игътибарына лаек булу өчен, сигез ай вакыт күп түгел.

Абдул. Булса кызу чагында була инде ул. Ә син әле аңа яратам дип тә әйтә алмыйсың. Менә мин үзем. Бер ай эчендә менә дигән интеллигентканы кулга төшердем. Үземнең Зәйнәпне.

Сәлим *(көлеп)*. Ох, интеллигентка! Медсестра — интеллигентка!

Абдул. Ярар, ярар. Медсестра гына булса да, врачлардан күбрәк белә әле ул. *(Дәртләнеп.)* Их, шәп нәрсә дә соң бу мәхәббәт! Икәүдән-икәү берәр аулак урында каласың, әйтик, җәен. Төн. Айлы төн!.. Агачларда сандугачлар сайрыйлар...

Сергей. Ялганлыйсың! Сандугачлар төнлә сайрамыйлар.

Абдул. Сайрыйлар! Билләһи, сайрыйлар — минем үземнең ишеткәнем бар. Әйе. Күктә ай йөзә... Бер генә

дә җил юк. Кругом агачлар!.. Ә агачларның яфраклары синең бәхетеңнән көнләшкән кебек сөйләшәләр, сөйләшәләр, сөйләшәләр...

Сергей. Ну, син бигрәк инде. Җил булмаганда, яфраклар сөйләшмиләр.

Абдул (игътибар итми). Ә янында ул. Менә син сакланып кына аның биленә кулыңны саласың. Йомшак!.. Ә йөрәк дөп-дөп, дөп-дөп, дөп-дөп. Аның тибүе авыз аша ишетелә. Шуннан син аны куеныңа кысасың да кайнар иреннәреннән үбәсең... (*һавада үбеп күрсәтә*). Ах!.. Менә ичмаса мәхәббәт. Ә синең нәрсә?! Бер үпкәнең дә юк бит әле.

Рөстәм. Моның өчен җирлек кирәк.

Абдул. Ә күпме мөмкин? Күпме мөмкин? Сигез ай бит инде! Бушка вакыт уздыруың булды.

Рөстәм. Юк. Мин вакытымны бушка уздырмадым. Хәтта Гөлсинә мине беркайчан да яратмаса да, мин ул вакытны кызганмаячакмын. Гөлсинәгә булган мәхәббәт минем күзләремне ачты һәм мин дөньяга, тормышка икенче төрле карый башладым. Мәхәббәт минем тормышымны тулыландырды, тормыш юлымны яктыртты һәм мин әлегә кадәр күреп, аңлап җиткермәгән нәрсәләрне күрә, аңлый башладым. Гөлсинә! Бу исем хәтергә төшү белән мин үземне канатлар үскән кебек хис итәм. Әгәр станокта эшләгәндә күз алдыма аның йөзе килсә, мин үземдә әллә нинди бер көч сизә башлыйм...

Сәлим. Син кайсыдыр романның бөтен бер главасын ятлагансың! Кызганычка каршы, андый илаһи мәхәббәтләр тормышта очрамыйлар. Бу бары тик художник фантазиясе генә. Иллюзия! (*Чыга башлый.*)

Абдул. Син нәрсә, чыннан да китәсеңме?

Сәлим. Әйе.

Абдул. Ә теге кыз килсә?

Сәлим. Килсә, бүген шагыйрьләр секциясендә поэмасын тикшерәләр, дип әйтерсең.

Сергей. Нинди кыз ул, Сәлим?

Сәлим. Да, бер кыз шунда. Кайчандыр дус булган идек.

Сергей. Ә хәзер?

Сәлим. Хәзер бер кем дә түгел.

Сергей. Ничек инде?

Сәлим. Ничек инде, ничек инде! Сезнең ни эшегез бар?

Абдул. Әйе. Шундый күтәрелеп килә торган шагыйрь авыл кызлары белән чуалып йөрмәс бит инде.

Рөстәм (*җирәнеп*). Шагыйрь!..

Абдул. Ә нәрсә кирәк тагын сина! Берничә шигыре басылып чыкты, хәзер әнә поэма яза. Кеше шулай үсә инде ул. Менә бит:

> Юк картаю бездә!
> Һәрберебез дә,
> **Һәрбер кеше дәртле, яшь, көчле!**
> Безнең йөрәкләрдә...

Сәлим (*бүлеп*). Во всяком случае, поэзиягә анализ ясау синең эшең түгел. Синамы соң шигъри әсәрнең нәфислеген аңлау! Биредә бит күпме эчке рифма гына бар. Бу поэмада, әйтергә кирәк, алтмыш проценты яңа рифма!

Абдул. Беләм, беләм. Синең рифмач кына икәнлегеңне яхшы беләм. Ә менә «әсәрләреңдә» шарлатанлыктан башка нәрсә күрмим.

Ишек кагалар.

Да!

Фәйрүзә (*ишектә*). Мөмкинме?

Абдул. Пожалуйста, пожалуйста. (*Рөстәм белән Сергейга.*) Ну, сез барасызмы, юкмы? (*Чыгарга ишарәли.*)

Фәйрүзә (*керә*). Исәнмесез, иптәшләр. Кая болай, барыгыз да?

Абдул. Сез безне гафу итегез, билгеле. Но безнең срочно барып киләсебез бар. Без хәзер.

Сергей. Узыгыз, уз. Сәлим, урын бир!

Абдул, Сергей, Рөстәм чыгалар.

Фәйрүзә (*Сәлимгә ташлана*). Шулхәтле сагындым мин сине, Сәлим, күрешмәгәнгә ун ел кебек. Бу арада хатың да булмады.

Сәлим. Мин язмаган идем.

Фәйрүзә. Ник язмадың? Вакытың булмадымы? Мин синең шигырьләреңнең һәммәсен җыя барам. Кара, син чәчләреңне көдрәләткән икәнсең бит, күрми дә торам. (*Бармаклары белән Сәлимнең чәчләрен туз-*

гыта.) Нинди килешә! Сиңа ни булды, Сәлим, авырмыйсындыр бит?

Сәлим. Минем барасы җирем бар. Бүген язучылар союзында минем поэмамны тикшерәләр.

Фәйрүзә *(канатланып).* Язучылар союзында?! Синең поэмаңны? Тукта әле. Шатлыгымнан башым әйләнеп китте. Менә бит, менә бит нинди шатлык. Ә нигә син шулай күңелсез, Сәлим? Нигә синең күзләрең шулай? Нәрсә булды синең күзләреңә? Сәлим?! Син нәрсәнедер миңа әйтергә теләмисең. Әллә... ни өчен хат язмадың син, Сәлим?!

Сәлим. Кирәге булмаганга.

Фәйрүзә. Ә?!. Мөмкин түгел, моның булуы мөмкин түгел!

Пауза.

Син минем белән сөйләшергә дә теләмисең? Бу — әдәпсезлек, Сәлим.

Сәлим. Бәхеткә каршы, мин синең характеристикаңа мохтаҗ түгел.

Фәйрүзә. Син шаярасың, Сәлим, шулай бит. Ләкин бу — артык усал шаяру.

Сәлим. Юк.

Фәйрүзә. Шаярмыйсың? Ә вәгъдәләрең?

Сәлим. Ах алла! Зрә кызык кеше икәнсең син. Шушы көнгә кадәр безнең юлларыбыз уртак түгеллеген аңламагансың.

Фәйрүзә. Әйе, мин аңламыйм, Сәлим. Аңлат миңа.

Сәлим. Җәл, җәл. Мин синең турыда болай ук уйламаган идем. Соң уйлап караганың юкмы: син кайдадыр авылда. Ә мин — шәһәрдә. Ничек итеп без тормыш кора алыйк?!

Фәйрүзә. Син бит мине дә шәһәргә аласы идең.

Сәлим. Ә биредә кем булып эшләрсең син? Техничка булыпмы?

Фәйрүзә. Ә ни булган, барыбер түгелмени?

Сәлим *(көлеп).* Син һаман да шулай икәнсең әле. Я, миңа вакыт.

Фәйрүзә. Алай булганда, мин иртәгә килермен. Мин әле Казанда бер атна торачакмын. Без терлекчеләрнең республика киңәшмәсенә килдек... Бәлки миңа сине озата барырга кирәктер. Юлда сөйләшербез.

Сәлим. Шушы сөйләшү җитмимени инде?

Фәйрүзә. Сәлим!.. Бәгырем... Син бит мондый түгел идең. Син бит мине ярата идең. Беркемгә дә бирмәм дигән идең. Син бит...

Сәлим. Менә тагын! Ничек син аңламыйсың: безнең арада нинди уртаклык бар? Аң-белем уртаклыгымы, теләкләр уртаклыгымы?! Мин быел кичке мәктәпне бетерәм. Аннан университетка керәчәкмен. Моннан тыш мин...

Фәйрүзә. Син масаясың, Сәлим?

Сәлим. Ә син кем? Кем син?! Син бит бозаулар караучы бер кыз!

Пауза. Бераздан Фәйрүзә, елап, йөгереп чыгып китә. Ашыгып Абдул керә.

Абдул. Нишләдең? Нишләттең син аны, Сәлим?

Сәлим *(чыгарга килә)*. Җибәр.

Абдул. Юк, нишләдең син?

Сәлим. Нәрсә эшләсәм дә сиңа отчет бирергә җыенмыйм.

Сергей белән Рөстәм керәләр.

Сергей. Әле китте дәмени?

Абдул. Әнә, елап чыгып китте.

Сергей. Ничек? Сәлим?

Сәлим. Кара, ни дип миңа бәйләндегез соң әле? Китә икән — китә бирсен. Анда сезнең ни эшегез бар?

Сергей. Их Сәлим, масаям диген, ә! Оят түгелме?

Сәлим. Беләсеңме, нәрсә, Сергей, кем-кем, әмма синең урыныңда булсам, мин дәшмәс идем. Нигә соң үзеңнең хатыныңны авылда тотасың?

Сергей. Сәлим!

Сәлим. Казанга алып килер җире булмагангамы? Шулай бит?

Сергей. Сәлим!

Сәлим. Юк, чыннан да. Нәрсә дип мине чорнап алдыгыз соң әле сез? Кызы чибәр икән, рәхим итегез. Әәә, юк шул, үзегезгә дигәч, бик исегез китми шул. Барыгыз да шулай бит, минем кебек. Син кеше күзенә күрсәтергә оялып, хатыныңны авылда тотасың. Син тагын. Нигә соң үзең кочегаркага түгел, ә студентка, профессор кызына гашыйк булдың? Өметен сузган булып йөри әле тагын. Әллә эш чыгармын дип уйлый-

сыңмы? Теләсәң, бүген гарантия бирәм, Гөлсинә сиңа әйләнеп тә карамаячак. Менә күрерсең.

Рөстәм яшьләрдән аерылып бер кырыйга китә.

Абдул. Ә караса?

Сәлим. Ә син тыгылма, яме. Тыгылма олылар сөйләшкәндә, башың яшь әле. Әнә үзеннән кәтүгенне бел, Зәйнәбеңне.

Абдул (*җилкенеп*). Минемме кәтүк? Минем Зәйнәпме?

Сергей Абдулны читкә ала.

Ә нигә кәтүк дип әйтә ул?

Сергей. Юк, син хаклы түгел, Сәлим. Хаклы түгел.

Сәлим канәгатьсез караш ташлап чыгып китә.

Абдул. Тукта әле, нигә ул Зәйнәпне кәтүк дип әйтә?

Ишек шакыйлар.

Да!

Гөлсинә керә.

Гөлсинә Ярыймы?

Абдул. Һоо, безнең шефлар килә! Әйдәгез, әйдәгез! Без сезне көтәбез. Нәрсә, үзегез генәме?

Гөлсинә. Исәнмесез! Людмила килмәдеме әле?

Абдул. Юк.

Сергей. Сез мине гафу итегез. Мин клубта кайбер хәзерлек эшләрен үткәрә торыйм әле. (*Китә.*)

Абдул. Рөстәм, мин дә шулай итим әле. (*Китә.*)

Рөстәм. Сезне, нәрсә, имтиханнарны биреп бетерү белән котларгамы? Отличнога?

Гөлсинә. Рәхмәт.

Пауза.

Рөстәм. Көн суыкмы?

Гөлсинә. Әә.

Пауза.

Р ө с т ә м. Буран чыкмаганмы?
Г ө л с и н ә. Юк.

Пауза.

Р ө с т ә м. Бүген бер утыз градус бардыр.
Г ө л с и н ә. Ээ.

Пауза.

Р ө с т ә м. Әйдәгез, клубка керәбезме?
Г ө л с и н ә. Хәзер. *(Борчылып.)* Әллә ник Людмила озаклады.
Р ө с т ә м. Килер әле.
Г ө л с и н ә *(Рөстәмнең китапларын күреп)*. О, күпме китаплар! *(Берсен алып.)* «Югары тизлекләрдә». Бу нәрсә?
Р ө с т ә м. Ул эш буенча.
Г ө л с и н ә. Атаклы новаторлар яза. Өйрәнәсезме?
Р ө с т ә м. Азрак караштырам.
Г ө л с и н ә. Әллә скоростник булырга җыенасызмы? Кара, минутына 1138 метр. Сез дә шулай эшлисезме?
Р ө с т ә м. Юк, минем әле 500 метрга да тулганы юк. Белем җитми.
Г ө л с и н ә. Ә дәресләр ничек, Рөстәм?
Р ө с т ә м. Бара. Әле кичә мәктәп директоры белән сөйләштем. Курыкмасаң, җиденче класска күчерәбез, ди.
Г ө л с и н ә. Сез теләмәдегезме?
Р ө с т ә м. Читен булыр шул. Бигрәк тә математика.
Г ө л с и н ә. Ә сез күчегез. Авырга туры килсә — булышырбыз.
Р ө с т ә м. Сез?
Г ө л с и н ә. Әйе.
Р ө с т ә м *(шатланып)*. Димәк, күчәргә?
Г ө л с и н ә. Әлбәттә.
Р ө с т ә м. Яхшы. Тик сүзегезне онытмагыз.

Л ю д м и л а керә.

Л ю д м и л а. Менә бит ул кайда чүкердәшеп утыра! Килмәгән булсаң — мин сиңа күрсәтә идем инде, Гөлсинә.

Г ө л с и н ә. Нәрсә күрсәтә идең?

Л ю д м и л а. Кино — менә нәрсә. Эдуардка нәрсә дидең?

Г ө л с и н ә. Нәрсә дидем?

Л ю д м и л а. Анысын үзең яхшырак беләсең булыр инде.

Г ө л с и н ә. Әйбәтләп сөйлә әле, Люда. Ни булды?

Л ю д м и л а. Безгә Эдуард килде. Килде дә, Гөлсинә заводка бармый, мине әйтергә җибәрде, ди.

Г ө л с и н ә. Эдуардмы?

Л ю д м и л а. Әйе.

Г ө л с и н ә. Дөрес түгел. Мин аны бүген күрмәдем дә. Шуннан?

Л ю д м и л а. Шуннан мин сезгә йөгердем. Доклад синдә бит. Уф, шундый йөгердем! Халык җыелганмы?

Р ө с т ә м. Карап керимме? (*Китә.*)

Л ю д м и л а. Нинди симпатичный малай, әйе бит?

Г ө л с и н ә. Әйе, башта алар бар да симпатичный.

Л ю д м и л а. Син нәрсә, Гөлсинә?

Г ө л с и н ә. Әгәр берничә ел элек миңа Эдуард турында бер генә начар сүз әйтсәләр дә, мин ышанмаган булыр идем.

Л ю д м и л а. Нигә, Эдуард начармы әллә? Ул әйбәт егет. Үзе отличник. Яхшы иптәш тә.

Г ө л с и н ә. Ә бүген аның сиңа ялганлавы яхшы иптәш эшеме соң?

Л ю д м и л а. Һи, аптырагансың икән. Мин аны кичердем инде.

Г ө л с и н ә. Ул минем белән дә шулай.

Л ю д м и л а. О, бередә нәрсәдер бар. Гөлсинә! Син Эдуардны яратмыйсың!

Г ө л с и н ә. Кызганычка каршы, мин аны яратам. Шуңа авыр да. Яраткан кешенең кимчелекләрен күрүдән дә авыр нәрсә юк.

Л ю д м и л а (*текәлеп*). Ә син... Рөстәмне яратмыйсыңмы?

Г ө л с и н ә. Каян алдыгыз сез моны? Әткәй белән әнкәй шулай. Инде син.

Л ю д м и л а. Син аны, белеме булса, яратыр идең. Шулай бит?

Г ө л с и н ә. Кызык сөйлисең дә инде. Ул бит укый. Ул унынчы классны бетерәчәк. Аннан соң институтка

керсә... Ләкин мин аны барыбер яратмыйм. Ул миңа ошый, ләкин яратмыйм.

Людмила. Беләсеңме, Гөлсинә, Рөстәм сине ярата.

Гөлсинә. Мин моны беләм.

Людмила. Соң, моңа ничек карыйсың?

Гөлсинә. Берничек тә.

Людмила. Шулай да, Рөстәм турында син ничегрәк уйлыйсың?

Гөлсинә. Мин аның турында яхшы фикердә. Ул акыллы, тырыш. Чибәрлеге дә бар. *(Яктырып.)* И, син аны белмисең әле, Люда. Үзенең станогы янында эшләгәндә, беләсеңме, нинди матур ул?! Синең аны эшләгәндә күргәнең бармы? Юк?! Юк, син ничек булса да цехка кереп, аны эшләгәндә күр әле. Карашы шундый җитди, йөзе ниндидер горур рухлану белән балкый. Минем беркайчан да шагыйрьнең йөзен иҗат иткән чагында күргәнем юк. Ләкин, минемчә, ул нәкъ шундый, эшләгән вакытта Рөстәмнеке кебек булырга тиеш.

Людмила. О, синең гашыйк булуың мөмкин!

Гөлсинә. Кит әле...

Людмила. Син үзең дә белмисең, җүләр кыз. Син Рөстәмне яратасың!

Рөстәм керә.

Рөстәм. Башлыйбызмы, кызлар?

Гөлсинә. Әйе, әйдәгез.

Чыгалар. Ишектә Абдул очрый. Ул Рөстәмнең җиңеннән тотып кала.

Абдул. Карале, Рөстәм, неужели минем бу галстук каз тизәгенә охшаган?

Рөстәм. Кем әйтә?

Абдул. Күркә Фәтхи. *(Галстугын чишә.)* Чорт с ним, башкасы да бетмәгән. *(Чемоданнан икенче галстук эзли.)* Я, әйттеңме?

Рөстәм. Нәрсәне?

Абдул. Яратканыңны.

Рөстәм. Юк.

Абдул. И жебегән авыз. Без тагын, аларга мешать итмик дип, коридорда катып беттек. Ни турында гына

сөйләштегез соң, һава торышы турындамы? *(Ишек шакыйлар.)* Да!

Эдуард керә.

Эдуард. Исәнмесез!

Рөстәм. Исәнмесез! Рәхим итегез, узыгыз, утырыгыз.

Эдуард. Рәхмәт. *(Абдулга кул бирә.)* Эдуард Сабирский, медицина институтыннан.

Абдул. Абдул Абдуллинский. Нигә исегез китте?

Эдуард. Исем-фамилиягез бер төрле булганга. Безнең татарда сирәк очрый торган хәл. Хәер, медиклар әйтмешли Nulla regula sine exeptione, ягъни, һәрбер кагыйдәнең чыгармасы була.

Абдул. Шулай шул, бер төрле. Дөресрәге, минем исемем Абдул түгел, Отелло.

Эдуард. Кызык.

Абдул. Кызык шул. Теләсәгез, мин сезгә үземнең исемем турында гаҗәп бер тарих сөйли алам.

Эдуард. Кызганычка каршы, минем вакытым юк. Миңа, беләсезме, Гөлсинә кирәк иде. Аны кайда очратырга мөмкин?

Рөстәм. Ул клубта, әйдәгез, мин дә шунда керәм.

Эдуард. Ах, клубта... Беләсезме, әгәр мөмкин булса, сез аны бирегә җибәрегез әле.

Рөстәм китә.

Абдул. Сөйлимме?

Эдуард. Нәрсәне?

Абдул. Үземнең ничек итеп Отеллодан Абдуллага әйләнүем турында.

Эдуард. Әгәр кызык булса, рәхим итегез.

Абдул. Кызык кынамы соң! Ул тарих сезнең үзегезгә дә кагыла әле. Утырыгыз. Беләсезме, минем әтиләр куйган исемем Отелло. Әйе, әйе, бер дә исегез китмәсен, Отелло! Шекспирның трагедиясен укыганыгыз бармы?

Эдуард. Әйе.

Абдул. Ул Отелло гарәп булган бит, мавр. Ә гарәпләрдә, миңа билгеле булганча, Отелло дигән исем юк. Аларда шуна охшаган Габдулла белән Гатаулла гына бар. Димәк, Отелло шул Гатаулланың яисә Габ-

дулланың инглизчә бозып әйтелеше генә булып чыга. Менә шуңа төшенгәч, хурлыгымнан ярылырга җиттем дә, икенче көнне үк исемемне Габдуллага алыштырдым.

Эдуард. Ә кай җире белән миңа кагыла инде бу?

Абдул. Әле сез аңламадыгызмыни?! Мин әйтәм, без туган елларда көнбатыш алдында баш ию, чыннан да, кизүгә әйләнгән булган. Ну, сезнеңчә итеп әйтсәң, эпидемия димме инде шунда. Безнең әти-әниләр, көнбатышка охшарга тырышып, безгә әллә нинди исемнәр кушканнар: Отелло, Фердинанд, Альберт, Альфред... Эдуард. Ә чынлап карасаң... ул тәти исемнәр шул Габдулланың гына бозып әйтелеше икән. Карагыз аны, сезнең исемегез дә шулайрак булмасын!

Гөлсинә керә.

Пока, Эдуард.

Абдул чыга. Пауза.

Эдуард. Исәнме, Гөлсинә. Сессияне тәмамлавың белән тәбрик итәм үзеңне.

Гөлсинә. Рәхмәт.

Пауза.

Эдуард! Син Людмилага нәрсә дидең?

Эдуард (*елмаерга теләп*). Ә-ә... Мин уйлаган идем, синең белән киногы барырга. Син китеп өлгергәнсең икән.

Гөлсинә. Юк, син миңа Людмилага ни сөйләгәнеңне әйт!

Эдуард. Ну, мин аңа шуны әйттем: ул бүген бара алмый, эше бар, дидем.

Гөлсинә. Ә кем кушты сиңа? Үз иптәшеңне алдарга оялмыйсың, ә?

Эдуард. Алдау шундый буламыни? Мин бит бүген синең биредә эшең юклыгын белә идем.

Гөлсинә. Ничек эшем булмасын, ә доклад?

Эдуард. Докладны син ясамыйсың.

Гөлсинә. Ясамасам?

Эдуард. Я, ярар, булган — беткән, гафу ит.

Гөлсинә. Әле бирегә ник килдең син?

Эдуард. Әйтәм бит, киногы барабыз. Сәгать тугызга.

Гөлсинә. Мин бармыйм, Эдуард.

Эдуард. Билетлар алынган.

Гөлсинә. Мин бармыйм.

Эдуард. Картинасы шундый яхшы, заграничная.

Гөлсинә. Юк!

Эдуард. Шулай булма инде, әйдә!

Гөлсинә. Мин бармыйм, анлыйсыңмы шуны — мин бармыйм.

Эдуард. Гөлсинә! Син мине яратмыйсың?

Гөлсинә *(сискәнеп)*. Мин? *(Борыла.)* Болай булгач, белмим шул...

Пәрдә.

3 КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Яз. Тәрәзәдә кояш уйный. Пәрдә ачылганда Рөстәм белән Гөлсинә өстәл артында дәрес өйрәнәләр.

Рөстәм *(өметсезләнеп, карандашын куя)*. Юк, аңламыйм, Гөлсинә.

Гөлсинә. Ә монда аңламаслык бернәрсә дә юк. Исеңдәме, үткән теорема буенча ДЕ, МА плюс АВ ның яртысына тигез иде. Шулай бит?

Рөстәм. Шуннан?

Гөлсинә. Шуннан...

Рөстәм *(Гөлсинәнең кулыннан тотып)*. Тукта! *(Җиңеләеп.)* Димәк, ДЕ параллель АС га һәм ДЕ, МА плюс ВС ның яртысына тигез.

Гөлсинә *(Рөстәмнең язып бетерүен көтеп)*. Менә шуны исбат итәргә кирәк иде дә.

Рөстәм *(сокланып)*. Гаҗәп фән бу геометрия, Гөлсинә! Беренче карауда бернәрсә дә аңлатмый торган сызымнардан әллә нәрсәләр китереп чыгарып була. Сиңа геометрия ошый идеме?

Гөлсинә. Ошый иде, мин хәтта чертежник булырга да хыялланган идем.

Рөстәм. Ә нигә врач буласы иттең? Әтиең куштымы?

Гөлсинә. Юк.

Рөстәм. Шулай булгач?

Гөлсинә. Ошау гына аз бит, Рөстәм. Миңа бик күп нәрсә ошый: сәнгать, музыка, архитектура. Ләкин

хезмәтең максималь файдалы булсын өчен, шул эшкә талант та кирәк.

Рөстәм. Син үзеңдә медицинага талант бар дип уйлыйсыңмы?

Гөлсинә. Мин үземдә нинди дә булса зур талант бар дип уйламыйм. Ләкин медицина миңа бар нәрсәдән дә артык ошый.

Рөстәм. Медицина миңа да ошый. Авыру кешегә ярдәм итү — бу чын изге эш... Ә токарьлык эше сиңа ошыймы, Гөлсинә?

Гөлсинә. Әйбәт эш.

Рөстәм. Минемчә дә. Хәзер бит станоклар нинди! Эшләмәгән җирдән эшлисең килер.

Гөлсинә. Сиңа станокта эшләү бик тә ошыймы?

Рөстәм. Бик тә. Цехка кереп станогымны күргәч, йөрәк ешрак тибә башлый. Мин, күптән аерылышкан дустымны күргән кебек, станогым янына ашыгам һәм тизрәк эшли башлыйм. Үзем кырдырам, ә күз алдыма... Әйтеп бирә белмим инде, сүз җитми...

Гөлсинә. Алайса сиңа, укып бетергәч, станогыңнан аерылу читен дә булыр әле.

Рөстәм. Нинди аерылу?

Гөлсинә. Соң, син бит унынчы классны бетерергә уйлыйсың. Аннан институтка керсәң... Инженер булгач, токарь да була алмыйсың бит инде.

Рөстәм. Мин инженер булырга җыенмыйм, Гөлсинә.

Гөлсинә (*аптырап*). Ничек?! Әле син урта мәктәпне бетерәсе идең бит?

Рөстәм. Әйе, минем исәп урта мәктәпне бетерергә. Ләкин станогымнан аерылырга уйламыйм мин.

Пауза.

Нигә аптырашка калдың? Минемчә, унъеллык белем белән токарь булып эшләүдә искитәрлек нәрсә юк.

Гөлсинә. Юк, минем исем китми, ләкин мин икенче төрлерәк уйлаган идем. (*Тәрәзәгә борыла.*) Көн нинди матур, ә! (*Тәрәзә янына килә.*) Кояш нинди!

Рөстәм. Егерменче апрель. Тиздән май җитәчәк. Ә анда имтиханнар...

Гөлсинә. Куркасың, әйе?

Рөстәм. Юк, курыкмыйм. Шулай да азрак борчылам. Тугыз ел өзеклек бит.

Гөлсинә. Ә син борчылма, син имтиханнарыңны уңышлы бирәчәксең.

Рөстәм. Син моңа ышанасыңмы?

Гөлсинә. Әйе, мин ышанам сиңа...

Рөстәм (*текәлеп*). Гөлсинә! (*Кулыннан алып.*) Әгәр бер генә сүз әйтсәм, Гөлсинә, ачуланмассыңмы?

Гөлсинә (*кулын тартып алып*). Әем, кирәкми. Әйтмә, Рөстәм. (*Тәрәзәгә борылып.*) Кара, кара, сыерчыклар килгән. Әнә! Әнә теге агачка кара. (*Форточканы ача.*) Сайрый.

Рөстәм. Яз житте, тиздән агачлар да яфрак ярырлар. Күңелле булачак.

Пауза.

Гөлсинә. Рөстәм! Әйт әле: әгәр җаның теләгән кадәр яшәргә мөмкин булса, син күпме яшәр идең?

Рөстәм. Теләп ни файда, барыбер ярдәм итмәячәк.

Гөлсинә. Ә шулай да. Әгәр ярдәм итә торган булса?

Рөстәм. Белмим шул.

Гөлсинә. Шулай да.

Рөстәм. Әгәр дә минем яшәвем кем өчендер кирәк булса һәм мин үземнең тормышым белән халкыма нинди дә булса файда китерә алсам...

Ишек шакыйлар.

Әйе.

Зәйнәп. Мөмкинме? Исәнмесез. Абдул өйдә юкмы әллә, Рөстәм абый?

Рөстәм. Алар хәзер керерләр, Зәйнәп, утырып тор.

Зәйнәп. И, вакытым азрак иде шул. (*Утыра.*)

Рөстәм. Бик ашыксаң, чакырырга мөмкин. Алар спорт залында гына.

Зәйнәп. Мөмкин булса, Рөстәм абый...

Рөстәм китә.

(*Радиоалгычны күреп.*) Ә, шушы икән инде. Өченче көн Абдул колагымны тондырып бетерде бит. Һай мак-

тана да инде җаным! Бүлмәбез чисталык ягыннан общежитиеда беренче, шуның өчен приемник белән бүләкләделәр, ди.

Гөлсинә. Мондый бүләк белән мактанса да урынлы.

Зәйнәп. Юк, Гөлсинә апа. Минем Абдул бигрәк тә инде. Әгәр тыңлаучы булса, мактанып кына торыр иде менә.

Гөлсинә. Синең Абдул? Син аны яратасың, әйе?

Зәйнәп (горур). Әйе! Ә нигә, Гөлсинә апа, синеңчә, Абдул начармыни?

Гөлсинә. Ник начар булсын. Абдул — уңган егет. Кичке мәктәптә дә укый.

Зәйнәп. Менә шул укуы эчемне пошыра да шул...

Гөлсинә. Нигә?

Зәйнәп. Ул укыр да укыр. Институтка да керәм, ди, әнә. Институтны бетерсә,— аннан ул мине яратмас, Гөлсинә апа.

Гөлсинә. Әгәр хәзер яратса, минемчә, алай эшләмәс. Ул сине яратамы соң?

Зәйнәп (көлә). Ярата гынамы соң! Ул миннән башка өч көн дә яши алмый. Чынлап шулай.

Гөлсинә. Ә үзең ничек соң?

Зәйнәп. Үзем — үзем инде. Тик, беләсеңме, Гөлсинә апа, минем яратканлыгымны син тагын Абдулга әйтмә, яме? Мин аңа яратмыйм, дим.

Гөлсинә. Ә нигә шулай алдыйсың? Килешми бит.

Зәйнәп. Килешкәне киртәдә менә. Шулай да шаярмагач, егетләр белән йөрүдә ни кызык бар! (Уйлап.) Гөлсинә апа, институтта укуы бик читенме?

Гөлсинә. Җиңел түгел.

Зәйнәп. Әгәр, Гөлсинә апа, мин дә институтка керсәм, укый алырмынмы икән?

Гөлсинә Ни өчен? Медсестра булып эшләү начармыни?

Зәйнәп. Начар түгел дә бит, тик минем күбрәкне беләсем килә. Менә, мәсәлән, Әхмәт ага йөрәге авыру кешегә суны аз бирергә куша. Ни өчен шулай ул?

Гөлсинә. Чөнки күп суны бөерләр аша бүлеп чыгару өчен йөрәккә зур көч куярга кирәк. Авыру йөрәк өчен бу зарарлы.

Зәйнәп. Юк... Хәзер мин аны үзем дә беләм. Йөрәк кенә түгел. Шундый нәрсәләр бик күп. Минем

барысын да үземнең беләсем килә. Тик миңа врач булудан куркыбрак торам әле. Булдыра алмам кебек. Нинди күп белергә кирәк бит, һай, җаным!.. Аннан менә Абдул. Мин аның характерын беләм. Инженер булгач, мине яратмас ул, Гөлсинә апа.

Гөлсинә. Алай, син аңа лаек булырга телисең. Бик матур уй. Укырга теләгең булгач, керәсең генә.

Зәйнәп. Шулай дисеңме, Гөлсинә апа, җаным, булдыра алырмын дисеңме?

Гөлсинә. Ә нигә булдырмаска! Синең кебекләр укыйлар бит.

Зәйнәп. Һай җаным, алайса, быел ук керәм. Тик, Гөлсинә апа, бу турыда Абдулга әйтмә, ярыймы?

Сәлим *(керә)*. Исәннәрме, кызлар!

Зәйнәп. Исәнме, Сәлим абый. Сәлим абый! Кичә кызыл почмагыгызга кергән идем *(көлә)*, анда сине ясаганнар, газетада.

Сәлим *(чишенә)*. Стена газетасындамы? Мин бит алар шикелле скоростник түгел, ясый бирсеннәр.

Зәйнәп. Ә менә Абдул Борткевич методын бик тиз үзләштерде. Хәзер ул 700 метрда эшли. Рөстәм абый да шулай.

Сәлим. Абдул бит ул, Рөстәм ни кыланса, шуны кылана. Ә үзенә башларга дисәң...

Зәйнәп. Һай җаным, минем Абдулмы? Юк инде, Сәлим абый, син үзең 200 метрда утырасың икән, утыра бир...

Сәлим. Мин генә утырмыйм.

Зәйнәп. Ләкин кешегә сүз әйтмә.

Гөлсинә. Я, Сәлим, поэзиядәге уңышлар ничек?

Сәлим. Әлегә бер көе. Поэманы һаман басмыйлар.

Гөлсинә. Әнә ничек! Нишләп басмыйлар икән соң алар?..

Сәлим. Әй, алар минем белән генә түгел инде. Анда редакциядә шундый кешеләр утыралар — алар һәр яшь талантны штыклап каршы алалар.

Гөлсинә. Шулаймыни?!

Сәлим. Но мин унывать итмим. Мин хәзер шигырьләремне русча яза башлыйм һәм туры Москвага җибәрәм. Тик менә русчаны бик үк белеп бетермим әле.

Зәйнәп. Сәлим абый, берәр нәрсәңне укып күрсәт әле, ә!

С ә л и м. Укып күрсәтергәме? Нәрсә укыйм икән соң сезгә. *(Кесәсеннән кәгазь алып.)* Менә «Яшьлек турында»гы циклдан:

Ни тели йөрәк, нәрсәдә теләк,
Нәрсәне теләп тибә яшь йөрәк,—
Барын эшлибез, житә көчебез,
Чөнки чыныгып үскән кеше без.
Безнең яшьләрдәй дәртле һәм өлгер,
Кайда да булса бармы тагын бер!?

Ничегрәк?

З ә й н ә п. Әйбәт.

С ә л и м. Гөлсинә! Әйтегез әле. Сезгә минем шигырьләр ошыймы?

Г ө л с и н ә. Мина? *(Уйлап.)* Әгәр хәтерегез калмаса...

С ә л и м. Юк, турысын әйтегез.

Г ө л с и н ә. Хәтерегез калмаса, мин әйтәм. Мина сезнең шигырьләрегез ошамый.

С ә л и м. Сәбәбе?

Г ө л с и н ә. Менә сәбәбен әйтә алмыйм. Ниндидер салкынлык димме, телегез ярлы димме шунда...

С ә л и м. Дөрес, тел ярлырак булу дөрес.

Г ө л с и н ә *(гаҗәпләнеп)*. Ә ничек соң сез, үзегез чынлап сөйләшә белми торып, шагыйрь булырга, халыкны өйрәтергә уйлыйсыз?

С ә л и м. Ә мин тел өстендә эшлим. Мин көзгә университетның филология факультетына керәм. *(Бүлмәне күрсәтеп.)* Бу обстановкада мин бит вакытлыча гына. Юк, сез аның нечкәлегенә төшенеп житмәдегез әле, Гөлсинә. Бу бит буквально рифмалар изобилиесе! Биредә эчке рифмалар...

С е р г е й, А б д у л, Р ө с т ә м керәләр. Сергей белән Абдул жинел спорт киемнәреннән. Абдулның кулында карточкалар.

А б д у л. Һоо! Минем песнәк борын килгән! Әйттем бит, килмичә чыдый алмыйсың, дип әйттем бит. Ник килдең?

З ә й н ә п. Һай жаным! Әллә сине сагынды дип белдеңме? Бик хажәтең бар иде. Менә приемнигыгызны күрергә килдем. Кая әле, нәрсә ул? *(Абдулдан карточкаларны ала.)*

Абдул. Бу абзаң була. Завод күләмендә рекорд куям! *(Гөлсинәгә.)* Исәнмесез.

Зәйнәп *(бер карточканы алып калып, калганнарын бирә).* Мә!

Абдул. Китер әле. Бик ямьсез чыккан ул. Икенчесен, чибәррәген бирермен.

Зәйнәп. Һа-ай җаным, үләм ич! Чибәр кисәге, имеш, уф. Син бит тормышта йөз өлеш ямьсезрәк. Әгәр шушындагы кебек булсаң, мин сине яратыр да идем.

Абдул. Ярар, ярар. Сандугач баласы кебек күп сайрый башласаң, мин яратмам да. Ә хәзер, дуслар, миндә идея! Приемник уйнатабыз! Кем каршы? Единогласно. *(Приемник янына җыелалар.)* Һоо, хат бар! *(Карый.)* Сережка, синең карчык яза. *(Хатны Сергейга бирә, приемник өстендәге төргәкне алганда, эченнән ефәк отрезны төшерә.)*

Зәйнәп *(отрезны алып).* Ай-яй, әллә берәрегез өйләнергә җыенамы? Күлмәклек алгансыз.

Абдул. Менә мин өйләнәм. Миңа кияүгә чыксаң, шул күлмәклек үзеңә була, ошыймы?

Зәйнәп. Әйбәт. *(Күзгедән карый.)* Гөлсинә апа, килешәме?

Абдул *(отрезны тартып алып).* Килешүен килешә бугай да, сиңа дип алмаган шул әле ул. Мә, Рөстәм, җыеп куй. Аннан, бик ошатып куйса, я кияүгә чыгыйм, дип аптырата башлар.

Зәйнәп. Кемгә дип алдың аны, Рөстәм абый?

Рөстәм. Минем унынчы класста укучы сеңелем бар бит әле, синең кебек.

Сергей. Иптәшләр! Минем балам бар!

Абдул. Балаң бар?

Сергей. Әйе, кыз бала! *(Хатын тотып яшьләр янына килә.)*

Сергейны күтәреп алалар да һавага чөяләр. Шау-шу. Котлаулар.

Абдул. Ну, Сережка, хәзер син җәмгыять өчен югалган кеше. Малай дисеңме?

Сергей. Кыз бала, Абдул, кыз!

Абдул *(кәефе китеп).* Малай түгелмени? Һи...

Зәйнәп. Һай, җаным, кыяфәтен генә күр әле, Гөлсинә апа! Ничек итеп шуны яратырга кирәк?!

Абдул. Житте. Болтовняны туктатырга! *(Приемникны боргалый.)*

Диктор. Без эстрада концерты тапшырдык. Ярты минуттан соңгы хәбәрләр.

Абдул. Яңгырыймы?

Диктор. Казан сөйли. Соңгы хәбәрләр тапшырабыз. ТАССР авыл хуҗалыгы алдынгыларына Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемне бирү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указы. Колхоз терлекчелеген үстерүдә зур уңышларга ирешүләре өчен Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемне бирергә һәм Ленин ордены белән бүләкләргә:

1. Галәветдинова Фәйрүзә Сабир кызын — Татарстан АССР Яңа Елга районы «Таң» колхозы фермасының бозау караучысын.

Сәлим *(аптырап)*. Бозау караучысын?

Абдул. Стоп! *(Приемникны туктата.)* Бу бит, бу бит кыш көне Сәлим янына килгән Фәйрүзә!

Рөстәм. Сәлим янына килгән Фәйрүзә?

Абдул. Әйе, шул Фәйрүзә. *(Барысы да Сәлимгә карыйлар.)*

Сәлим. Һич аңламыйм. Нәрсә бу? Иллюзияме?

Абдул. Во! Күрдегезме, дуслар! Болай булгач, Фәйрүзә синең борынга чиертте, Сәлим. Аны хәзер бөтен ил беләчәк. Ә синең поэмаңны кайчан басарлар әле. Әллә терсәкне тешләргә дә исәп бармы?

Сәлим чыгып китә.

Син ничек уйлыйсың, Сережа? Әгәр хәзер Сәлим гафу үтенсә, Фәйрүзә кичерер микән?

Сергей. Әйтүе читен. Мәхәббәт — курчак түгел. Үзе белән уйнаганны яратмый.

Зәйнәп. Һич аңламыйм.

Абдул. Ә монда аңлыйсы да юк. Сәлим авылда вакытта бер кыз белән дус булган. Менә шул кызны хәзер герой иткәннәр.

Зәйнәп. Соң, әйбәт булган.

Абдул. Булган сиңа! Сәлим аның белән эшне бетергән иде шул инде. Шагыйрь булдым дип һаваланган иде. Менә хәзер, кәкре каенга терәттеме Сәлимне! *(Сәлимнең папкасын алып.)* Киләчәкнең әдәбиятчы галимнәре халкыбызның бөек шагыйре Сәлим Галәвинең тормышы һәм иҗат юлы турында фәнни хезмәтләр

язганда, аның шундый хәлгә төшүен белеп, хәйран калырлар... *(Зәйнәпкә.)* Әйдә.

Китә башлыйлар.

(Үзләре белән бара башлаган Сергейга.) Ну, хәзер син атакай булдың бит инде, Сергей Митрофанович, безнең белән сикереп йөрмәссең.

Сергей. Әйдә, әйдә, мин дә барам.

Абдул *(исенә төшереп)*. Кара, кара, нинди җиңел котылмакчы була. Бала тугач, нишләргә кирәклеген белмисеңмени?

Сергей. О, оныта да язганмын. Телеграмма сугарга кирәк.

Абдул. Тагын нәрсә кирәк?

Сергей. Бүләкләр алырга...

Абдул. Тагын?

Сергей. Кайтып килергә.

Абдул. Тагын?

Сергей *(уйлап)*. Тагын...

Абдул. Ә синең баланңны кем юар?

Сергей. Әәә. Була ул, Абдул. Иртәгә үк эшлибез.

Абдул. Юк, бүгенге эшне иртәгә калдырма син. Бүген юабыз.

Сергей. Бүген бит...

Абдул. Бүген, бүген. Әйдә, берәр сумка ал, үзем дә булышырмын. *(Сергей сумка ала.)* Ю-ю-юк, ул кечкенә, зуррагын ал. Әнә минекен. *(Тумбочкасыннан зур сумка алып Сергейга тоттыра. Абдул, Сергей һәм Зәйнәп чыгалар. Пауза.)*

Гөлсинә. Ярый, Рөстәм.

Пауза.

Рөстәм! Беләсеңме, синең мәктәпне бетереп станокта эшләргә теләвеңә мин чыннан да ышанмаган идем... Аңламаган идем. Ләкин хәзер мин аңлыйм. Мин аңладым. Һәм мин сине менә шуның өчен, шундый гади булуың өчен, юк, юк, гади түгел, юк,— ә шундый, шундый... ну менә шундый булуың өчен яратам да!..

Гөлсинә йөгереп чыгып китә.

Рөстәм *(аның артыннан)*. Гөлсинә!..

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

4 КҮРЕНЕШ

Клиника бакчасы. Артта клиникадан бакчага ишек һәм баскычлар. Алга таба ике ягына куе булып куаклар үскән юл үтә. Сулда биек булмаган рәшәткә. Эчтәрәк як-якка сузылган аллеялар күренә. Алда, куаклар белән уратылган ачыклыкта, Гөлсинә белән Людмила утыралар. Алар дәрес өйрәнәләр. Яннарында китап һәм дәфтәрләр. Гөлсинә китаптан укый. Людмила, уйга чумып, карашын еракка төбәгән.

Гөлсинә. Бу очракта кичекмәстән операция кирәк. *(Китабын яба.)* Кабатла әйдә.

Людмила *(сискәнеп)*. Ә?

Гөлсинә. Дәвалау методларын кабатлап чык. Син нәрсә, тагы хыялланып утырдыңмы?

Людмила. Мин ишетми калдым, Гөлсинә.

Гөлсинә. Сиңа ни булды, Людмила?

Людмила. Мин хыялландым, Гөлсинә. Синеке кебек зур һәм матур мәхәббәт турында, кешене матур итә, бәхетле һәм көчле итә торган мәхәббәт турында хыялландым. Менә Рөстәм белән сиңа карыйм да үземнең ялгызлыгымны ныграк тоя башлыйм. Сез чын бәхетле кешеләр! Мин, мөгаен, беркайчан да алай ярата алмам.

Клиника ишегеннән Рөстәм күренә. Аның артыннан йөгереп Зәйнәп чыга, өстендә ак халат.

Мин китәм, Гөлсинә.

Гөлсинә. Иртәгә керерсең, яме. *(Озата.)*

Зәйнәп. Әй-яй-яй, иптәш, кая барасыз? Ә, Рөстәм абый икән. Исәнме, Рөстәм абый!

Рөстәм. Исәнме, Зәйнәп. Гөлсинәләр кайда икән, белмисеңме?

Зәйнәп. Әнә. Әле ярый клиника аша узуыңны күрүче булмады.

Рөстәм. Күрсә ни булган?

Зәйнәп. Бу бит клиника бакчасы. Очраган бер кеше кереп йөргәч, ни була ул! Икенче вакыт син, Рөстәм абый, клиникага кереп тә йөрмә. Коймa башыннан гына, менә моннан. *(Китә.)*

Гөлсинә. Я, бирдеңме, тизрәк сөйлә.

Рөстәм. Биш.

Гөлсинә. Молодец инде! Нәрсә эләкте?

Рөстәм. Бер сорау электричестводан. Ом законы.

Гөлсинә. Белдеңме соң?

Рөстәм. Әйе. Аннан — жылылыкның конвекция ярдәмендә таралуы.

Гөлсинә. Анысын беләә иден. Кара, синең ике генә имтиханың калган бит.

Рөстәм. Аларын бирәм мин анын. Курыкканым физика иде.

Гөлсинә. Әһә, курыккансың! Ә миңа курыкмыйм дигән идең. Ник ялганладың, ә? Ник ялганладың? *(Рөстәм кулын Гөлсинәнең биленә куярга тели.)* Син нәрсә, акылыңнан яздыңмы әллә? Эткәй бирерә.

Рөстәм. Ояласыңмы?

Гөлсинә. Оялам да, куркам да.

Рөстәм. Куркасың?

Гөлсинә. Әйе.

Пауза.

Беләсеңме нәрсә, Рөстәм. Әлегә кадәр мин сиңа әйтмәгән идем... Беләсеңме... минем синең белән дус булуыма эткәйләр каршы бит.

Рөстәм. Сәбәбе нәрсә инде анын?

Гөлсинә. Алар... алар сине... юк, сорама, Рөстәм. Мин әйтмим. Мин әйтә алмыйм.

Пауза.

Рөстәм. Мин беләм. Алар мине үзләренең кызларына тиң санамыйлар.

Гөлсинә *(башын селкеп Рөстәмнең сүзен раслый).* Ә син борчылма, Рөстәм. Мин эткәйгә аңлатырмын. Ул аңлар.

Пауза.

Рөстәм *(тузгып яткан дәфтәрләрне күреп).* Иртәгә нәрсәдән бирәсең?

Гөлсинә. Хирургия.

Рөстәм. Читенме?

Гөлсинә. Юк.

Рөстәм. Син хирург булырга телисеңме?

Гөлсинә. Юк, мин невропатолог булам.

Рөстәм. Нервопатолог?

Гөлсинә. Нервопатолог түгел, невропатолог. Нерв авырулары врачы.

Рөстәм. Ә нигә нервопатолог түгел?

Гөлсинә. Ну, просто алай диминләр, невропатолог диләр.

Рөстәм. Ничек инде просто! Син миңа аңлатып бир. Ул бит нерв дигән сүздән ясалгандыр.

Гөлсинә. Нигә шулай төпченәсең син?

Рөстәм. Беләсем килә.

Гөлсинә. Ә мин үзем дә белмим.

Рөстәм. Белмисең? Ай-яй. Ә үзе, невропатолог булам, ди.

Гөлсинә. Мин сиңа икенче әйтермен, яме.

Рөстәм. Ярый. Ә теге имтиханыңны ничек бирдең, терапияне?

Гөлсинә. Бишкә.

Рөстәм. Үзең, белмәм, дип курыккан идең.

Гөлсинә. Юк, мин белмәм дип түгел, авыруга диагноз куя алмам, дип курыккан идем. Безгә бит имтиханда авыру бирәләр. Шуның нәрсә белән авыруын белергә кирәк.

Рөстәм. Белдеңме соң?

Гөлсинә. Белдем. Беләсеңме, нинди авыру эләкте? Нефрит.

Рөстәм. Нефрит? Нәрсә соң ул нефрит?

Гөлсинә. Менә, мин сиңа хәзер лекция укыйммы әллә! Просто бер авыру шундый, бөерләрдә була торган. Әгәр бик беләсең килсә, мин сиңа дәреслек бирә алам, укырсың.

Рөстәм. Сезнең дәреслекләрегезгә кереп батсаң!

Пауза.

Син ниндидер матур уй уйлыйсың. Әнә күзләрең сөйли. Нәрсә турында уйлыйсың?

Гөлсинә. Беләсеңме, Рөстәм, беләсеңме... Элек мин, укып бетереп, кайдадыр эшкә китүемне күз алдыма да китерә алмый идем. Дус кызлардан, әткәй белән әнкәйдән аерылып, шәһәрне, өйне, менә шушы бакчаларны ташлап, кайдадыр эшкә китү минем башыма сыймый иде. Мин эч пошудан, сагынудан үләрмен кебек иде.

Рөстәм. Ә хәзер?

Гөлсинә. Ә хәзер алай түгел. Мин хәзер врач бу-

лып нинди дә булса берәр районга эшкә китүдә искитәрлек бер нәрсә дә күрмим. Әгәр минем белән син булсаң, мин хәтта әллә кая, Камчаткага китәргә дә риза.

Рөстәм (*Гөлсинәне якынрак кыса*). Гөлсинә! Хәтерлисеңме, бервакыт миннән күпме яшәргә теләвемне сораган идең?

Гөлсинә. Әйе.

Рөстәм. Әгәр теләсәң, мин хәзер җавап бирә алам.

Гөлсинә. Күпме яшәр идең?

Рөстәм. Әгәр мөмкин булса, мин йөз ел, ике йөз ел яшәр идем.

Гөлсинә. Һо, син бигрәк инде. Минем үземнең дә бик озак яшисем килә... Әйдә, киногга барабыз, Рөстәм.

Рөстәм. Минем заводка барып киләсем бар иде, инженер Сергей Иванович янына. Бер эш буенча.

Гөлсинә. Нинди эш ул?

Рөстәм. Эш дип, эш тә түгел ул үзе.

Гөлсинә. Шулай да, нәрсә соң ул?

Рөстәм. Мин үзем дә яхшылап белмим әле аны, Гөлсинә.

Гөлсинә. Шулай да?

Рөстәм. Станокта зур тизлектә эшләгәнне күргәнең бар бит инде синең. Менә шул чакны йомычка күп ясала, ә арчу өчен вакыт күп китә. Менә миңа бер уй килде.

Гөлсинә. Нинди уй?

Рөстәм. Минемчә, кискечнең формасын аз гына үзгәртсәң, йомычка вакланып чыгачак һәм аны арчу өчен станокны туктатып тору кирәкмәячәк.

Гөлсинә. Чынлап сөйлисеңме син, Рөстәм? Ышанасыңмы син моңа?

Рөстәм. Менә, ышанып житмим шул әле. Шул турыда Сергей Иванович белән киңәшергә уйлаган идем.

Гөлсинә. Бар, хәзер үк бар. Ә иртәгә имтиханымны биргәч, мин сиңа килермен. Юк, әгәр эш булырлык булса, бүген үк кереп әйт, яме. Мин көтеп торам. Әйдә, озатам.

Бакча эченә кереп китәләр. Сәхнә буш. Бераздан клиникадан Хуҗин белән Разия чыга.

Разия. Шушы имтихан вакытлары җитсә, өйгә дә төшеп тормыйлар, мескеннәр. Көне буе укуда. Инде бу

имтиханнарын үзеңә бирәселәр. Ул кадәр тырышмасалар да яраган булыр иде.

Х у җ и н. Нәрсә, әллә үз кызыбызга, белмәсә дә, бишле куярга кушар идеңме?

Р а з и я. Ел буе укып та белми түгелләрдер инде, Әхмәт, беләләрдер. Шушындый эсседә ничек итеп башка керсен. Шуна, туктале, мин әйтәм, мороженое илтеп ашатыйм үзләренә, хәл кереп китсен.

Гөлсинәләр утырган җиргә килеп җитәләр.

Ай алла, кая киткәннәр болар бөтен әйберләрен ташлап? *(Карый.)* Теге Гөлсинә түгелме соң, Әхмәт?

Х у ж и н. Ул. Ә тегесе кем, янындагысы?

Р а з и я. Анысы Рөстәмгә охшаган дип әйтимме?..

Х у җ и н. Рөстәм?! Инде монда да килгәнме? Гөлсинә шул малай белән чуалмасын дип ничә әйттем мин сина.

Р а з и я. Ничек итеп кешегә әйтәсең, Әхмәт. Әлләни уйлавы бар.

Х у җ и н. Аның ни уйлавы мине һич кызыксындырмый.

Р а з и я. Инде, Әхмәт, Гөлсинә бала түгел лабаса, үзенең күңеленә ошагач, ярар тагын.

Х у җ и н. Нәрсә, инде сине дә үз ягына авыштырып өлгердемени? Кызыбызның киләчәк бәхете турында кем кайгыртырга тиеш соң, синеңчә, ә? Күңеленә ошаган! Күңелгә ошаган күп булыр ул. Яшь кешенең күңеле күбәләк кебек. Аңа кешенең тышкы матурлыгы ошый тешә. Ә матурлык туйда гына кирәк, диләр картлар. Шундый, күрергә матур, акылга такыр кешеләрдән кызыбызны саклау — безнең бурычыбыз. Моны миннән аталык бурычым таләп итә.

Г ө л с и н ә керә. Ул шат.

Г ө л с и н ә. Әнкәй! Мороженое китердеңме әллә, әнкәй? Людмила китте бит.

Р а з и я. Нишләп алай иртә китте соң әле?

Г ө л с и н ә. Без инде кабатлап бетердек. Аннан Рөстәм дә килгән иде.

Тузып яткан китапларны җыярга керешә. Пауза.

Хужин. Ике бозауга кибәк аерып бирергә хәленнән килмәгән бер кеше синең бердәнбер кызына ау корып йөри бит, ә!

Гөлсинә. Син кызынны кем дип беләсең соң, әткәй?

Хужин. Менә сина кирәк булса! Шушы яшеңә җитеп, үзеңнең кем икәнлегеңне белмисеңмени әле син? Бер елдан син уналты еллык белеме булган интеллигентка — врач булачаксың.

Гөлсинә. Рөстәм дә урта мәктәпне бетерәчәк, әткәй.

Хужин. Шуннан институтка да керәчәк, димәкче буласыңмы? Әнкәсе, син ничек карыйсың моңа: хатыны тәрбиясендә, янсә аннан да шәбрәк, хатынының атасы тәрбиясендә институт бетерү яхшы эш бит, ә!

Гөлсинә. Рөстәм кеше тәрбиясенә мохтаж түгел, әткәй. Ул әле әнисенә дә булыша.

Хужин. Менә, менә. Аның бар тапканы шул әнисенә булышуга китеп бетәчәк тә.

Разия. Кара әле, әткәсе. Рөстәм акчаны күп таба торган егет.

Хужин. Синеңчә аның акча табуы белән эш бетәмени? Бу сүзләрең белән син үзеңнең артталыгыңны гына күрсәтәсең. Акча белән генә хәзерге тормыш тулы була алмый. Хәзер рухи ихтыяҗлар, культура ихтыяҗлары алда тора. Ә Рөстәм бу нәрсәләргә җавап бирми.

Гөлсинә. Синеңчә, токарь булу кимчелекмени, әткәй?

Хужин. Мин алай димим. Әмма ләкин мин үз кызымның андый кешеләрдән ераграк булуын телим. Мин кызымның бәхетле булуын телим.

Гөлсинә. Әгәр кызыңның бәхетле булуын теләсәң, әткәй, үтенәм синнән, үз бәхетемне үземә табарга ирек бир.

Разия *(өметсезләнеп)*. Гөлсинә!..

Хужин. Культура дәрәҗәсе тигез булмаган җирдә көчле гыйшык булмый. Ул коры мавыгу гына була һәм тормыш белән беренче очрашуда ук уалып ватыла. Бу хакыйкатьне аңларга вакыт инде сиңа.

Разия. Борынгылар, мәхәббәт җәмал теләмәс, дигәннәр.

Хужин. Мәхәббәт белән мәңге яшәп булмый. Мәхәббәт — сөт ул. Ә сөт — тиз ачый.

Гөлсинә. Шулай да, әткәй, мәхәббәт кешене бәхетле итә. Әгәр менә син әнкәйне яратмаган булсаң, бәлки андый зур эшләр эшли дә алмас идең.

Хуҗин. Эһе. Күптәннәнме балалар ата-аналарының гыйшык һәм башка шундый мөнәсәбәтләренә анализ ясый башладылар?

Гөлсинә. Гафу ит, әткәй, ләкин бу шулай бит, дөрес бит.

Хуҗин. Алай, син гыйшыкны зур эшләргә рухландыручы нәрсә, дисең. Әйтик, бу сүзләрдә хаклык булсын, ди. Әйтик, сез шушы малай белән бергә кушылдыгыз, ди. Әйтик, синең мәхәббәтең аны рухландыра, ди. *(Мыскыллап.)* Тимер кырыргамы? Акылың белән уйла; аның хезмәте өчен рухлану кирәкмени?

Пауза.

Икегез дә медик булып, шунда, минем янда гына булуга, миңа ярдәмләшүгә ни җитә! Максатлар төрле булган җирдә семья тормышы кызыклы булмый.

Гөлсинә. Максатлар безнең бер, әткәй. Безнең икебездә дә бер омтылыш — илебезне тагын да матуррак, тагын да баерак итеп күрү булачак.

Хуҗин. Әмма ләкин сезнең арагызда нинди уртаклык?

Гөлсинә. Нигә син Рөстәм турында шулай начар уйлыйсың, әткәй? Аның бер генә кешедән дә ким җире юк. Дөрес, ул әле күп нәрсәне аңлап бетерми, аңа әле үз өстендә күп эшләргә кирәк. Ләкин анда, әткәй, белемгә омтылыш гаять көчле. Әгәр син аның белән яхшылап сөйләшсәң...

Хуҗин *(бүлеп)*. Сөйләшмим. Хәтта күрергә дә теләмим. *(Кискен борылып китә.)*

Гөлсинә. Әткәй!

Разия. Дорфа сөйләшәсең, Гөлсинә! Артык та дорфа сөйләшәсең. Ата булган кеше белән алай сөйләшмиләр аны. Без этинең күз карашыннан куркып тора идек. Кая ул гыйшык турында әрепләшү! Әз генә оят белер идең ичмасам. *(Китә.)*

Гөлсинә *(ялгыз)*. Тагын аңламады. Ничек соң аңа аңлатырга?! Ничек соң аңлатырга, ничек соң аңлатырга?!

Пауза.

Эдуард керә.

Эдуард. Гөлсинә!

Гөлсинә. Син?! Син ник килдең?

Эдуард. Мин артык түзә алмыйм, Гөлсинә. Мин бөтенесен беләм. Мин кызганам сине!

Гөлсинә. Кызганасың?!

Эдуард. Әйе, мин кызганам сине. Әйдә, ачыктан-ачык сөйләшик, боргаланмыйча гына.

Пауза.

Мине безнең дуслыкның суынуы борчый. Син Рөстәмне яратасың! Боргаланма, турысын гына әйт.

Гөлсинә. Әгәр яратсам?

Эдуард. Алайса мин сине кем дип тә әйтә алмыйм. Без өч ел дус булып йөрдек. Күпме вакытыбызны бергә уздырдык. Бергә күпме кинокартиналар, спектакльләр карадык. Син шул дуслыкны боздың.

Гөлсинә. Ә, минемчә, Эдуард, безнең арада чын дуслык булмаган. Без аңсыз рәвештә мавыкканбыз гына. Дуслык бер-береңне яхшылап өйрәнгәндә була. Нәрсә соң берләштерде безне? Шул, үзең әйткәнчә, кино, театр, бер институтта уку,— һәм менә бетте. Син мине гафу ит, Эдуард, ләкин бу шулай.

Эдуард. Ялгышмасам, син һәртөрле гафу үтенүләрне яратмый идең. Синең шундый дуслыкны бозуың...

Гөлсинә. Нинди дуслык турында сөйлисең син, Эдуард? Безнең арада бернинди дуслык булмаган. Дуслык — чын күңелдәнлек булган җирдә. Ә синдә мин моны күрмәдем. Мин сине аңлый алмадым. Син мине аңларга теләмәдең. Юк, без дуслар булмаганбыз. Һәм беркайчан да була да алмабыз.

Эдуард. Ничек син аңламыйсың! Син культуралы. Син белемле. Ә кем ул Рөстәм? Шулмы сиңа пар? Үзең уйлап кара. Сиңа бит аның белән кеше арасына чыгарга оят булачак. Врач була торып берәр рәтлерәк кешене тапмаган дип үзеңнән көләрләр бит. Ул бит кара эшче...

Гөлсинә. Җитте!!. Мин сине тыңламыйм. Вак җан! Сиңамы соң аңларга! Мин менә шундый кешене яратам да шул!

Пәрдә.

5 КҮРЕНЕШ

Шул ук бакча. Вакыт кич. Өсләренә пижама кигән авырулар әрлебирле йөренәләр. Бераздан клиника ишегеннән Хуҗинны култыклап Алексей Степанович чыга. Алексей Степановичның өстендә ак халат.

Хуҗинның кулы бәйләүдә.

Алексей Степанович. Сез йончыгансыз, Әхмәт Закирович... Кислота икәнен күреп торасыз бит.

Артларыннан йөгереп Разия чыга.

Разия. Ни булды?

Хуҗин. Син ник килдең әле?

Алексей Степанович. Зыянлы түгел, Разия ханым.

Разия. Ай алла, ник әйтмисез? Ни булды соң, ни булды?

Алексей Степанович. Кулы пеште, кислотада.

Утыргычларның берсенә утырталар.

Хуҗин. Кара син аны. Бәла аяк астыннан чыга диләр. Иң җаваплы вакыт җиткәч кенә...

Разия. Киткән вакытта ук күңелем сизгән иде аны. Шуңа өйдә дә утыра алмадым.

Алексей Степанович. Сез йончыгансыз, Әхмәт Закирович. Сезгә берәр ял йортына барып кайтырга кирәк.

Хуҗин. Юкны сөйләмәгез, зинһар. Унбиш еллык хезмәте нәтиҗә бирергә торганда, нинди кеше ял йортына китсен?!

Алексей Степанович. Белмим шул. Нәтиҗә бирер микән...

Хуҗин. Менә-менә! Иң якын хезмәттәшем дә минем эшемә шулай бармак аша карагач, мин ничек уңышка ирешим?

Алексей Степанович. Эзләнүләрне бу юнәлештә дәвам иткәндә, белмим шул, Әхмәт Закирович. Бу турыда мин генә әйтмим.

Хуҗин. Һәр кешене тыңлый башласаң!

Алексей Степанович. Ләкин фән башкалар белән хисаплашырга теләмәгән «геройларны» да яратмый. Бер көн бу хакта партбюрода да сүз чыкты.

Хуҗин. Нинди сүз?

Алексей Степанович. Безнең лаборатория турында.

Хужин. Соң?

Алексей Степанович. Профессор Хужин лабораториясе унбиш ел нәтиҗә биргәне юк, Хужин соңгы вакытта үзенең тәҗрибәләреннән башканы күрми башлады дип.

Хужин. Кем әйтте?

Алексей Степанович. Сезнең өчен барыбер түгелмени?

Хужин. Димәк, сезгә, Алексей Степанович, шул җитә калды?

Алексей Степанович. Бөтенләй юк.

Хужин. Шулай-шулай. Кемдер безнең эшебезне тәнкыйтьләгән дә, сез инде икеләнә дә башлагансыз. Әмма фән икеләнүләрне яратмый, Алексей Степанович. Фәннең җимешләре генә татлы, ә тамырлары ачы. Һәм ул җимешләрдән авыз итү өчен унбиш ел вакыт күп түгел. Моны сез үзегез дә беләсез. Унбиш ел! Димәк, сез, юлдагы авырлыклардан куркып, кулларыгызны төшерәсез. Бу нәрсә, пессимизм түгелме?

Алексей Степанович. Түгел. Бу бары тик үткәннәргә аек күз белән карап, алга юл билгеләү өчен тукталу.

Хужин. Эһе! Димәк, Хужинга, үзе белән ничә ел бергә эшләүче доцент...

Алексей Степанович. Әйе, ышанмый.

Хужин. Аның каравы Хужинга Фәннәр академиясе ышана.

Разия. Аның болай кинәт хәлсезләнеп китүе ял итмәүдән генә түгелдер инде, Алексей Степанович. Бу араны өйдә дә зур хәсрәт бар бит әле. Бер завод малае кызыбызның башын әйләндергән.

Алексей Степанович *(җитди)*. Башын әйләндергән?

Разия *(еламсырап)*. Әйе, яраткан шул.

Алексей Степанович. Һе... Сез моңа борчыласызмы, Әхмәт Закирович?

Хужин. Борчылмыйча! Бала бит — бәгырьне әрнетә.

Алексей Степанович. Бик начар нәрсәмени?

Хужин. Сорап торасыз тагын. Токарь бит ул, токарь, тимерче!

Алексей Степанович. Анысы, Әхмәт Закирович, йөрәк жылыңны биреп эшләгәндә, һәр эш мактауга лаек. Минемчә, Гөлсинә кебек кыз яратырлык булгач, ни житте кеше түгелдер әле ул.

Хужин. Юк инде!.. Юк инде, Алексей Степанович. Уйлап карагыз әле менә: кияү була-нитә калса, безгә дә киләчәк бит инде ул. Буш араны кияү кеше белән такылдап утырасы да килә, фәлсәфә сатып. Ә андый кеше белән ни турында фәлсәфә сатасың! Ул синекен белми, син аныкын. Әнә, күрәсезме, килеп тә житкән. Өйгә килеп йөреп саруны кайнатуы гына житмәгән, инде монда да килә башлады. Мин китәм.

Алексей Степанович. Әхмәт Закирович!

Хужин. Юк, мин аны күрергә теләмим. Күрә алмыйм мин аны, Алексей Степанович. *(Китә.)*

Алексей Степанович Хужинны куып житеп култыгыннан ала, чыгып китәләр. Рөстәм белән Гөлсинә керәләр.

Гөлсинә. Бирелә нишләп утырасың, әнкәй?

Рөстәм. Исәнмесез.

Разия. Исәнмесез. Гөлсинә! Минем сиңа сүзем бар. *(Рөстәмгә.)* Гафу итегез.

Гөлсинә. Син шунда Сергейны эзли тор, Рөстәм.

Рөстәм китә.

Нигә бирегә килдең, әнкәй?

Разия. Аны ни дип монда алып килдең? Әткәнне үртәр өченме?

Гөлсинә. Аларның иптәшләре бирелә, әнкәй, операция булды.

Разия. Артык узынып киттең әле син, Гөлсинә. Әткәң сиңа зыянга әйтми. Ул сине бәхетле итәргә тырыша. Ә син әткәңне аяктан егылырлык хәлгә китердең. Күз алмасы кебек кызыңның әллә кемнәр белән чуалуы,— әйтергә генә ансат. Ата булган кешенең бәгыре дә эренидер шул.

Гөлсинә. Инде син дә шулай сөйлисеңме, әнкәй?!

Разия. Әткәң бүген лабораториядә кулын кислотада пешергән.

Гөлсинә. Ә?

Разия. Барысы да шул башы миңгерәгәннән. Әткәңнең тәжрибәләрен күпме кеше күзәтеп тора. Ә син,

аның ачышын тизләтү өчен үзең булышасы урында, вакытлы-вакытсыз борчу саласың. Сиңа шуны аңларга вакыт инде, бала! *(Күзләрен сөртә.)*

Алексей Степанович белән Хужин керә, Гөлсинә йөгереп чыгып китә.

Хужин. Сез оста сөйлисез, билгеле, Алексей Степанович, шома сөйлисез. Әмма ләкин минем үземдә дә сезгә карата бер сорау туа: болай бик шома сөйләгәч, мин әйтәм, барысын да аңлагач та, нигә дип ике кызыгызны да инженерларга бирдегез икән?

Алексей Степанович. Теләкләре, Әхмәт Закирович. Мин аларның теләкләренә каршы килмәдем.

Зәйнәп *(ишектә)*. Алексей Степанович! Сезне сорыйлар. *(Китә.)*

Алексей Степанович. Мин хәзер. *(Китә.)*

Хужин белән Разия бакча эчендә югалалар. Икенче яктан өстенә пижама кигән Сергей белән Сәлим керәләр.

Сергей. Алай, поэмаңны басачаклар?

Сәлим. Басалар. Редакторы Гайнул Шаһиди.

Сергей. Шаһиди? Теге... синең белән пивнушкаларга кереп йөрүче Шаһидимс?

Сәлим. Соң, бераз күңелен күрмичә булмый инде ул.

Сергей. Болай булгач, поэмаңның басылачагына ышанам, әлбәттә.

Клиника ишегендә Зәйнәп белән Фәйрүзә күренәләр.

Зәйнәп. Сезне белмәү ярыймы соң, Фәйрүзә апа! Сезне хәзер бөтен Татарстан белә.

Сәлим Фәйрүзә!?

Сергей китә.

Зәйнәп. Безнең Әхмәт ага авырып китте бит әле, Фәйрүзә апа.

Фәйрүзә. Ничек? Әле бакчада диган идегез бит?

Зәйнәп. Бакчадасын бакчада ул, ләкин авыруы да дөрес. Ул кислотада кулын пешерде.

Фәйрүзә. Акыллым, шулай булгач, мин аны ничек борчыйм? Юк, әле мин Казанда берничә көн булам. Икенче килермен.

З ә й н ә п. Йомышыгыз нәрсә иде соң, Фәйрүзә апа?

Ф ә й р ү з ә. Йомышым бик зур минем, акыллым. Минем эти авырып китте. Шул турыда киңәшим дигән идем.

З ә й н ә п. И, Фәйрүзә апа, җаным! Алай булганда, сез Алексей Степанович белән генә киңәшегез!

С ә л и м *(каршы төшеп)*. Фәйрүзә!

Ф ә й р ү з ә *(чигенеп)*. Сәлим!?

З ә й н ә п. Исәнме, Сәлим абый.

С ә л и м *(Зәйнәпкә китәргә ишарә ясый һәм, кыяркыймас кына килеп, Фәйрүзәнең кулыннан ала)*. Исәнме, Фәйрүзә, каян болай җил ташлады?

Ф ә й р ү з ә. Исәнме!

С ә л и м *(тотлыгып)*. Мин сиңа хат язган идем... Безнең монда бер иптәш ята... Мин синең белән аңлашырга теләгән идем, Фәйрүзә.

Ф ә й р ү з ә. Минемчә, безнең аңлашасы нәрсәләр аңлашылып беткән инде.

С ә л и м. Шулай булма инде. Герой булдым дигәч тә теге син... Син күпкәме Казанда? Бәлки бүген берәр җиргә барырбыз... Фәйрүзә?.. *(Кулына үрелә.)*

Ф ә й р ү з ә. Җибәр.

С ә л и м. Үткәндә булган дуслык хакына, Фәйрүзә, мәхәббәт хакына. Бер генә минутка. Фәйрүзә! Кичер мине, мин сине элеккечә үк яратам.

Ф ә й р ү з ә. Юк.

С ә л и м. Синнән башка мин яши алмыйм.

Ф ә й р ү з ә. Мин ышанмыйм. Мин сиңа мәңге ышанмаячакмын.

С ә л и м. Син моны күрерсең, Фәйрүзә. Мин моны тормышта исбатлармын.

Ф ә й р ү з ә. Юк. Син ялгышасың.

С ә л и м. Фәйрүзә!

Ф ә й р ү з ә. Әйе, әйе. Хәтереңдәме, мин сиңа килгән идем. Ул вакыт син икенче төрлерәк сөйләшә иден.

С ә л и м. Мин ялгышканмын, Фәйрүзә. Мин сине бозау караучы гына булганга күрә...

Ф ә й р ү з ә. Мин хәзер дә бозау караучы.

С ә л и м. Юк, син бозау караучы гына түгел хәзер, син хәзер Герой!

Ф ә й р ү з ә. Мин хәзер дә бозау караучы. Кышын син сөйләшергә дә теләмәгән шул ук бозау караучы. Герой исемемнән башка миндә бернинди үзгәреш юк. Ул вакыт мин сиңа ошамый идем. Ни өчен соң син мине

хәзер генә ярата башладың? Нәрсә соң сине, һавалы шагыйрьне, бозау караучының алдына килергә мәҗбүр итте?! Бәлки сиңа минем Герой исемем генә ошыйдыр? Әйе, әйе. Син минем үземне түгел, ә Герой исемемне, даньмны гына яратасың, Сәлим!

Сәлим. Тиздән минем дә поэмам басылачак, Фәйрүзә. Миңа да дан киләчәк. Без икебез дә...

Фәйрүзә. Мескен. Синең шул шигырьләр язуың да данга омтылудан гына килеп туган.

Сәлим. Шулай барысы да беттемени инде, Фәйрүзә? *(Укый.)*

О, Фәйрүзә! Еллар кочагында
Минем йөрәк туктар тибүдән.
Ләкин калыр даным. Шул чагында
Исемем төшмәс халык теленнән.

Фәйрүзә, сөеклем, кичер мине!

Фәйрүзә. Юк. Үткәнне кайтарып булмый, Сәлим. Кит. Кит.

Фәйрүзә китә башлый, Сәлим аның артыннан бара.

Сәлим. Фәйрүзә!

Фәйрүзә. Мин сине күрәлмыйм. Күрәлмыйм! *(Китә.)*

Сәлим аның артыннан бара. Сергей белән Рөстәм керә

Сергей. Мин булмагач ярамасмы соң?

Рөстәм. Юк шул, син булмагач, аның бар кызыгы китә. Без бит яңа кискечләрне бөтен бригада белән сынап карарга уйлыйбыз.

Сергей. Берсекөнгәме?

Рөстәм. Әйе.

Сергей. Белмим шул, чыгарырлар микән.

Рөстәм. Бүген мин көн буе яңа кискеч белән эшләдем.

Сергей. Ничек?

Рөстәм. Эшнең темпын үзгәртмәгәндә дә хезмәт җитештерүчәнлеген өч процентка арттырып булачак.

Сергей. Яхшы! Котлыйм үзеңне, Рөстәм. Чын күңелдән котлыйм.

Хуҗин белән Раэия узып баралар.

Рөстәм. Исәнмесез.

Сергей. Хәерле кич, профессор!

Хужин. Хәерле кич, туган, хәерле кич, я, хәлләр ничек?

Сергей. Рәхмәт, хәзер әйбәтләнде.

Хужин китәргә тели.

Профессор, минем сезгә бер үтенечем бар иде: миңа иртәгә чыгарга ярамасмы?

Хужин. Иртәгә? Ә, юк, юк. Иртәгә ярамый. Кая ашыгасыз?

Сергей. Безнең бер иптәш новаторлык ясады. Шуны бригада күләмендә сынау булачак.

Хужин. Ярамый.

Сергей. Бик күп яттым бит инде, профессор. Шушы авыру аркасында бер имтиханымны да бирергә өлгермәдем.

Хужин. Әле сез укыйсыз дамыни?

Сергей. Әйе.

Хужин. Кайсы институтта?

Сергей. Кичке мәктәпнең тугызынчы классында. Нигә гаҗәпләндегез? Безнең бөтен бригада укый.

Хужин. Әнә ничек! Кичке мәктәпне бетереп кем буласыз соң инде сез?

Сергей. ВУЗга керә алам.

Хужин. Анысы яхшы, билгеле. Укыган кеше хур булмый. Тик менә болай, бөтен кеше дә укый башласа, якын киләчәктә кара эшчеләр бөтенләй калмый алайса!

Сергей. Ничек инде?! Дөрес, безнең яшьләр укыйлар, ләкин аларның күбесе киләчәктә дә профессияләрен алмаштырырга җыенмый. Хәзерге станокларда эшләү, бу бит инде сез әйткән кара эшче хезмәте генә түгел, профессор. Ул хезмәт югары техника белән, катлаулы исәпләүләр белән бәйләнгән.

Хужин. Димәк, сез ВУЗ бетереп станокта эшләргә телисез? *(Көлә.)*

Сергей. Гафу итегез, профессор, сезнең шундый элементар нәрсәләрне аңламавыгыз мине гаҗәпләндерә.

Разия *(кабаланып)*. Безгә кайтырга вакыт, ахры, Әхмәт.

Хужин *(ирония белән)*. Бәлки сез аңлатырсыз, ә?

Сергей. Бик рәхәтләнеп.

Хужин көлә.

Сез көләсез? Бу чыннан да көлке.

Рөстәм. Һәм кызганыч.

Хуҗин. Нәрсә кызганыч?

Рөстәм. Профессор Хуҗинның шулай сөйләве.

Хуҗин. Ә... син... сез каян килеп чыктыгыз әле?

Рөстәм. Бакчадан.

Хуҗин. Ә бакчага?

Рөстәм. Бакчага урамнан.

Хуҗин. Ә сез минем белән авызыгызны ерып сөйләшмәгез, яме. Сез нәрсә, клиника бакчасын нәрсә дип белдегез?

Рөстәм. Гафу итегез, нәрсә әйтергә теләвегезне аңламыйм.

Хуҗин. Аңламыйсызмы? Алайса шул: бу сезгә Лядской садик түгел...

Рөстәм. Гафу итегез, профессор...

Хуҗин. Бу сезгә Лядской садик түгел. Хәзер үк күземнән югалыгыз!

Рөстәм. Ул кадәр кызмагыз, профессор. Үзегезне кулга алыгыз.

Разия. Әхмәт, дим, сина кайтырга вакыт.

Хуҗин. Мин сезнең бакчадан чыгып китүегезне көтәм!

Рөстәм. Мин китәм. Ләкин урынсызга тон күтәрү килешеп бетми, профессор.

Хуҗин. Мин сезнең белән сөйләшергә теләмим!

Рөстәм. Мин дә. Чөнки бу хәлдә сезнең белән сөйләшү өчен врач булу, невропатолог булу кирәк. Икенче сөйләшербез.

Хуҗин. Сөйләшмәбез.

Рөстәм. Юк, сөйләшербез әле. Сау булыгыз, апа. *(Китешли.)* Тиз терел, Сережа. Хуш.

Хуҗин Ул сезнең янга килгәнме?

Сергей. Әйе.

Хуҗин. Бүгеннән соң мин сезнең янга кемнең дә булса килеп йөрүен катгый рәвештә тыям.

Сергей. Аның килүенең сәбәбе бар, профессор. Ул миңа үзенең шатлыгын уртаклашырга килә.

Хуҗин. Нинди шатлык?

Сергей. Әлеге новатор егет шушы бит инде. *(Китә.)*

Разия. Син артыграк кызып киттең бугай, Әхмәт. Рөстәмне новатор булды ди ләбаса.

Хуҗин. Соң, булса?

Р а з и я. Алай димә әле син, Әхмәт. Гыйбрәт алсаң, гыйбрәт бар. Әле беркөн Людмила сөйләп торды. Шул заводта бер шагыйрь бар икән. Менә шул шагыйрь бер кызга, син бозау карауччы гына, син миңа тиң түгел дип әйткән икән дә, ди, ике айдан шул кыз Герой булган, ди. Ленин ордены да биргәннәр үзенә. Рөстәмне тимерче генә дибез дә менә... Аның белән дә шундыйрак нәрсә булуы мөмкин бит. Хәзерге кешене һич кенә дә белеп булмый, көне белән үсә.

Х у җ и н. Энә нәрсә турында сөйлисең икән син. Әмма мине аның новаторлыгы кызыксындырмый. Юк-бар данга кызыгып кыз бирә торган Хуҗин тумаган әле.

Рәшәткә башыннан А б д у л төшә.

Син нәрсә рәшәткә башыннан йөрисең? Кем син?

А б д у л. Беләсезме, сез безнең урынны алгансыз. Нәкъ сәгать тугызда шушы утыргычта мине бер кыз көтәргә тиеш иде. Сез күрмәдегезме?

Х у җ и н. Сезгә кем кирәк?

А б д у л. Анысы секрет, билгеле. Нәрсә, сезнең кулыгыз авыртамы соң? Шушы больницада ятасызмы? Ә сез бармакларыгызны хәрәкәтләндереп торыгыз, менә болай. Югыйсә катып калуы мөмкин. Операция булдымы?

Р а з и я. Аның кулы пешкән, кислотада.

А б д у л. Шулаймыни? Беләсезме, минем биредә бер танышым бар. Врач. Сез шуның белән генә киңәшегез. (*Колагына.*) Юкса аларның профессорлары тегеләйрәк ди бит.

Х у җ и н. Ничегрәк ди?

А б д у л. Ну, бик кара, бик иске фикерле кеше ди.

Х у җ и н. Кем әйтә?

А б д у л. Үзем беләм. Беләсезме, минем бер иптәшем бар. Менә шул моның кызын яратып йөри. Кыз да ярата. Шаулатып туй ясарга гына кирәк. Ә бу профессор, кызымны профессорга гына бирәм, дип әйтә, ди.

Х у җ и н. Кызы шәптер, димәк.

А б д у л. Аннан шәбрәкләр бар! Аннары, әгәр ул холкы белән атасына да охшап куйса...

Клиника ишегендә З ә й н ә п күренә.

һоо, әнә ул! Кил әле монда, кил. Менә бу авыруны беләсеңме? Нигә син ана бармакларын хәрәкәтләндереп йөрергә кушмыйсың?

Хуҗин. Ну сине! *(Зәйнәп куркып артка чигенә.)*

Зәйнәп. Абдул!

Абдул. Юк, бу кыз, валлаһи, врачтан күбрәк белә, честное комсомольское.

Хуҗин. Синең валлаһи катыш честное комсомольскоеңа ышанып булмый, иптәш.

Зәйнәп. Абдул!

Абдул. Ярар, ярар, күп сөйләнеп торма. Син менә шуңа җавап бир. Ни өчен соңгы вакытта һаман соңга калып чыгасың? *(Сәгатенә күрсәтә.)* Күрәсеңме? *(Зәйнәпне култыклый да, Хуҗинга баш иеп, китә башлый.)*

Хуҗин. Туктагыз әле, сез кая?

Абдул. Мин әйттем бит инде, сез безнең урынны алгансыз. Димәк, безгә, сездәй картларга хөрмәт йөзеннән, биредән китәргә һәм башка берәр аулак җир табарга кирәк. Бакча зур бит.

Хуҗин. Күрсәтермен мин сезгә зур бакча. Хәзер үк чыгып китегез. Бу сезгә парк мәллә! Ә сиңа, кызый, бүгеннән ары клиника бакчасында егетләр белән свидание билгеләсәң, кара аны, выговор язармын. *(Разияны култыклап чыгып китә.)*

Зәйнәп. Юк, Әхмәт ага, бетте. *(Абдулга.)* Нишләдең син, ә!? Бу бит безнең профессор!

Абдул. Ә?!

Зәйнәп. Әхмәт ага бит ул. Гөлсинә апаның этисе.

Абдул. Менә син, ә... недоразумение артыннан недоразумение.

Зәйнәп. Һай җаным, синең белән йөрсәң дә шул...

Абдул *(Зәйнәпне күтәреп алып утыргычка утырта)*. Беренче июльдән мин отпускта... Арчага кайтабыз, яме.

Зәйнәп. Ник?

Абдул. Ник, ник! Әйтерсең белми. *(Үбеп ала.)* Миңа кияүгә чыгасың киләме?

Зәйнәп. Һе, аннан мин сиңа күренергә дә оялырмын, наверно. Карама инде шулай. *(Битен Абдулның куенына яшерә.)*

Абдул. Алайса чыгасың килә?

Зәйнәп *(башын күтәрмичә)*. Әә.

Абдул. Һаа, каптыңмы! Ә мин сине алмыйм.

Зәйнәп. Һай җаным, бик барам дип тә тормыйм бит әле. Нишләр икән дип кенә әйттем.

Абдул. Юк, серьезно. Миндә бер идея бар. Сиңа институтка керергә кирәк.

Зәйнәп. Ник?

Абдул. Бөтен кешенең хатыны интеллигентка да студентка. Рөстәмнең дә врач була.

Зәйнәп. Ә мин медицина институтына заявление дә бирдем инде, эх!

Абдул. Ә нигә минем рөхсәттән башка йөрисең?

Зәйнәп. Йөрсә, мин синең хатыныңмы соң?

Абдул. Булмаса, булырсың. *(Зәйнәп клиникага керә башлый.)* Я, кайтабызмы Арчага? *(Зәйнәп ризалык белдереп башын селки.)* Язылышабызмы? *(Зәйнәп ризалык белдереп башын селки.)*

Артта аяк тавышлары.

Зәйнәп. Кемдер килә.

Абдул. Әйдә тизрәк. *(Рәшәткә аша урамга сикермәкче булалар. Ләкин Зәйнәп егылып төшә.)*

Абдул *(Зәйнәп янына иелеп)*. Авырттымы?

Зәйнәп *(чәчләрен то**к**алап)*. Прическам бозылмадымы, Абдул?

Гөлсинә белән Рөстәм күренә. Зәйнәп белән Абдул икенче якка йөгерәләр.

Гөлсинә. Минемчә, бүгеннән соң сиңа әткәйнең күзенә күренергә кирәкми. Тынычлансын. Ул бит унбиш елдан бирле зур фәнни проблема өстендә эшли. Ул хәзер чиксез зур ачыш алдында тора. Әгәр әткәй бу ачышын ясаса, бу, беләсеңме, нәрсә булачак, Рөстәм?

Рөстәм. Белмим, бу хәлдә ул ачышын ясый алыр микән?

Гөлсинә. Аңа бездән зуррак кешеләр ышаналар.

Рөстәм. Юк, үзен каплаган кабыктан чыкмый торып, ул зур ачыш ясый алмаячак. Аңа булышырга кирәк, Гөлсинә.

Гөлсинә. Бәлки син булышырсың?!

Рөстәм. Кайбер нәрсәләрдә, ихтимал, мин дә.

Гөлсинә *(читкә борылып)*. Син үзеңне артык зурга саный башладың, Рөстәм.

Рөстәм. Юк, мин үземне зурга санамыйм, Гөлсинә.

Гафу ит. *(Бераздан.)* Беләсеңме, без аның белән икәү сөйләшик.

Г ө л с и н ә. Моның белән без аны аяктан егачакбыз.

Р ө с т ә м. Безгә аның белән сөйләшергә кирәк, Гөлсинә.

Г ө л с и н ә. Кирәкми, Рөстәм. Әгәр, әгәр, мине аз гына булса хөрмәт итсәң, алай эшләмә. Шулай бит, эшләмәссең бит, Рөстәм?..

Р ө с т ә м. Бу шулай кирәк, Гөлсинә. Безнең мәхәббәтебез өчен генә түгел, синең этиеңнең уңышлары өчен дә шулай кирәк. Башкача мөмкин түгел.

Г ө л с и н ә. Ләкин барыбер булмаячак. Син эткәйне белмисең. Бер киреләнсә, аны һич җиңеп булмый.

Р ө с т ә м. Ә безнең мәхәббәт аны җиңәчәк, Гөлсинә. Җиңәчәк. *(Үбәргә тели. Гөлсинә читкә борыла.)*

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

6 КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге бүлмә. Өй эче кояш яктысы белән тулы. Өстәл артында Х у җ и н белән Р а з и я, чәй эчә-эчә, шахмат уйныйлар.

Р а з и я. Шах, шах, шах.

Х у җ и н. Һмм... Ә мин болай йөрсәм, ни әйтерсең? *(Маңгаена кунган чебенгә суга.)*

Р а з и я. Бик әйбәт.

Х у җ и н *(чебенне куып)*. Ух, бу чебеннәрне!

Р а з и я. Аларга үзем дә аптырадым инде. Каян гына кереп тулалардыр.

Уйныйлар.

Х у җ и н. Бар әле, шуларга кәгазь куй әле. *(Разия икенче бүлмәдән бер китап алып керә дә ерта башлый.)* Кара, нигә китап ертасың?

Р а з и я. Әйбер төрә торган китап ич ул.

Х у җ и н *(китапны алып)*. Сәлим Галәви. «Яшьнәсен яшьлек!» Поэма.

Р а з и я. Аны Гөлсинә укырга дип алган икән дә, ошатмады.

Х у җ и н. Ошатмагач китапны ерталармы?

Р а з и я. Начар булгач, ертмыйча... Китап шүрлекләрендә болай да чүп-чар күп. *(Китап битләренә дару сылый да тәрәзә төбенә куя.)* Йөрдеңме? И шушы, синең белән уйный башласаң, тәмам аптырыйм. Сузасың, сузасың... *(Тәрәзә артында мотор гүелди башлый.)*

Х у ж и н. Фу, чәнчелеп китәсе нәрсә, тагын дөберди башлады. Каршыда шушы йортны сала башлаганнан бирле тынычлык күргәнем юк. Көне-төне дөберделәр. *(Йөри.)*

Р а з и я. Ул йортны салуның бер яктан файдасы да булыр әле аның, Әхмәт. Кышың бөтен карны шуннан китереп өя бит. *(Йөри.)*

Х у ж и н. Аның файдасын салып бетергәч күрерсең әле син. Анда бит йөздән артык квартира булачак. Ул халыкның чыр-чуына чыдап кара син. *(Йөри.)*

Р а з и я. Мин синең филеңне алам, Әхмәт.

Ә х м ә т. У-һу-һу... бүген бигрәк эссе. *(Чәй эчә.)*

Р а з и я. Пәрдәләрне төшеримме соң?

Х у ж и н. Төшер әле, төшер. Тавыш та азрак басылыр. Салкынча да булыр. *(Разия тәрәзәне томалый. Бүлмә эче ярым караңгылана.)*

Р а з и я. Я, тизрәк йөр, аннан клиникага барып кайтасың бар түгелме соң?

Х у ж и н. Анда мин бүген бармаска уйлап торам.

Р а з и я. Әллә ни эшең булмаганда бу эсседә йөрмәсәң дә була шул.

Х у ж и н. Әле иртә белән генә телефон аша сорадым. Кроликның хәле яхшы, ди.

Р а з и я. Ии, Әхмәт!.. Әгәр дә мәгәр, бу ачышың барып чыкса, бөтен дөнья шаулаячак лабаса. Бөтен дөнья!

Г ө л с и н ә кайта.

Г ө л с и н ә. Уф, шулкадәр эссе!

Х у ж и н. Соң Маркизга дип киткән кеше сәгать унбергә кайтып киләме инде?

Г ө л с и н ә. Әй, әллә нәрсә генә шунда. Настроением дә юк, эссе дә.

Х у ж и н *(йөри)*. Мә, күңелең булдымы?

Р а з и я. Пешкан минеке.

Уйныйлар.

Шах, шах.

Хуҗин. Кара, тәмам бәйләндең син минем корольгә.

Гөлсинә. Биредә синең бер ходың бар инде барын.

Разия. Әй, әйтмә. Кирәкми, әйтмә. *(Гөлсинәне өстәл яныннан куа.)* Әнә, әткәң әйтә, ял йортына путевка бар, ди. Барыбер нишләргә белми аптырап йөрисең.

Гөлсинә. Әллә нәрсә генә... Быел беркая да барасым килми. *(Разияның артына чыгып, Хуҗинга өйрәтеп тора.)*

Хуҗин. Тукта әле, мин сине менә болай иттерим әле. *(Йөри.)*

Разия. А, әйтте, Гөлсинә әйтте!

Гөлсинә. Юк.

Уйныйлар. Гөлсинә Хуҗинга ишаралар белән өйрәтеп тора.

Хуҗин *(йөри)*. Мат! Ха-ха-ха-ха!

Разия *(Гөлсинәгә)*. Син әйттең.

Гөлсинә. Юк, чынлап юк, әнкәй.

Разия. Әйттең, әйттең. Ул андый комбинация ясый белми иде. *(Фигураларны җыя.)*

Звонок шалтырый.

Хуҗин. Мат, мат! Ха-ха-ха.

Разия. Юк, дөресен генә әйтеп бир әле менә: Гөлсинә әйтте бит. *(Звонок кабатлана, Разия тәрәзә пәрдәсен күтәреп карый.)* Рөстәм килгән!

Хуҗин. Рөстәм?

Гөлсинә чыга башлый.

Чыкма.

Гөлсинә. Әткәй...

Хуҗин. Чыкма, мин үзем.

Өченче звонок.

Гөлсинә. Мин аны хәзер алып китәм, әткәй.

Хуҗин. Беркая китмисең, бар, бүлмәңә кер.

Гөлсинә. Ләкин мин барыбер, әткәй...

Хуҗин. Бар, бүлмәңә кер.

Звонок кабатлана. Гөлсинә бүлмәсенә китә.

Р а з и я. Кара, ачарга кирәк бит инде.

Х у ж и н. Үзем, дип әйттем бит мин сезгә.

Р а з и я китә. Х у ж и н җилкенеп ишеккә килә. Яңадан бик каты звонок шалтырый. Хужин туктала. Һәм, берничә секундлык икеләнүдән соң, Разия артыннан китә.

Бар, син генә ач.

Р а з и я. Ник инде тагын?

Х у җ и н. Мин аны үз кулларым белән ачып кертә алмыйм. Бар, ач. Мин өйдә юк.

Р а з и я. Алайса, мин дә өйдә юк. Баштан ук үзең бутадың. Үзең теләсәң нишлә. *(Бик каты звонок шалтырый.)*

Х у җ и н. Бар, ач, бар! *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Р а з и я чыга. Р ө с т ә м керә. Ул ялгыз. Зур пауза. Г ө л с и н ә бүлмәсеннән чыга.

Г ө л с и н ә. Димәк, син мине тыңламадың, килдең.

Р ө с т ә м. Әйе, килдем, исәнме, Гөлсинә.

Г ө л с и н ә. Ник килдең, ник килдең?

Р ө с т ә м. Әтиең белән сөйләшү өчен.

Г ө л с и н ә. Мин бит синең сабыр итүеңне сораган идем.

Р ө с т ә м. Соң, иттек бит инде, ике атна сабыр иттек.

Г ө л с и н ә. Тагын ике атна үтсен.

Р ө с т ә м. Ә аннан? Тагын ике атна? Юк, Гөлсинә. Артык мөмкин түгел.

Г ө л с и н ә. Нигә син шундый кире?

Р ө с т ә м. Бу бөтенләй кирелек түгел, Гөлсинә. *(Хуҗин бүлмәсенә күрсәтеп.)* Өйдәме?

Г ө л с и н ә. Өйдә... Юк... белмим. *(Рөстәм аның бүлмәсенә бара башлый.)* Рөстәм! Әгәр... әгәр минем белән араны бозасың килмәсә, эшләмә шулай.

Р ө с т ә м. Нәрсә?

Г ө л с и н ә. Ул синең белән сөйләшмәячәк. Ул сине куып чыгарачак.

Р ө с т ә м. Ә син?

Г ө л с и н ә. Нәрсә мин?

Р ө с т ә м. Ә син, әтиең куып чыгарганда, нишләрсең?

Г ө л с и н ә. Белмим.

Р ө с т ә м *(кире килеп)*. Бәлки, чыннан да, сөйләшү кирәкмидер. Бәлки инде син мине әтиең өеннән куып чыгарганчы ук күңелеңнән кугансың.

Г ө л с и н ә. Ничек шулай сөйли аласың, Рөстәм!

Р ө с т ә м *(кулларыннан алып).* Син элеккечә үк яратасыңмы?

Г ө л с и н ә. Сорама шулай. Син бит беләсең. Син бит үзең дә беләсең.

Р ө с т ә м. Моннан бер генә ай элек син минем белән Камчаткага китәргә дә риза идең. Шул сүзләрең хәзер дә көчендәме?

Г ө л с и н ә. Рөстәм! Син бит беләсең!

Р ө с т ә м. Шулай булгач. Әтиең кайда?

Гөлсинә кулы белән этисе бүлмәсенә күрсәтә. Рөстәм аның бүлмәсенең ишеген шакый.

Х у җ и н *(эчтән).* Кем бар?

Р ө с т ә м. Мөмкинме? *(Хуҗин ишекне ача.)* Исәнмесез.

Х у җ и н. Ә, сезгә нәрсә, кем кирәк?

Р ө с т ә м. Миңа сез кирәк.

Х у ж и н. Хуш иттек. Нәрсә әйтерсез?

Р ө с т ә м. Теге вакытны без сөйләшә алмый калган идек.

Х у ж и н. Гафу итегез, минем вакытым юк.

Р ө с т ә м. Гафу итегез, ләкин мин күпкә түгел.

Х у җ и н. Юк, минем сезнең белән сөйләшәсем юк. Минем сезгә дигән кызым юк!

Г ө л с и н ә. Рөстәм!

Х у җ и н. Кызым, бар, бүлмәңә кер.

Р ө с т ә м. Ләкин мин икенче нәрсә турында, профессор.

Х у җ и н. Мин сезгә теге көнне үк әйттем. Минем сезнең белән сөйләшәсе сүзем юк.

Р ө с т ә м. Шулай булсын. Ләкиң бит, сөйләшергә сүз булмау — бу әле кешене куып чыгарырга хокук бирми. Мәсәлән, сез мине бакчадан куган кебек. Әдәп дигән нәрсә бар бит әле...

Х у ж и н. Менә, менә. Сездә ул юк та.

Р ө с т ә м. Мәсәлән?

Х у ж и н. Юк.

Р ө с т ә м. Ә үзегездә?

Х у җ и н. Сез нәрсә, сорау алырга телисезме?

Р ө с т ә м. Бөтенләй юк. Менә мин сезнең белән шул әдәп турында гына сөйләшергә телим. Әйтик, кем дә булса үзенең авыру иптәше янына клиникага килгән икән, биредә, минемчә, хөкем итәрлек нәрсә юк. Ә менә

шул кешене, иптәше белән сөйләшергә дә бирмичә, куып чыгару — бу, минемчә...

Хуҗин. Әдәпсезлек.

Рөстәм. Әдәпсезлек.

Хуҗин. Әдәпсезлек! Һе, ул мине әдәпкә өйрәтергә килгән. Күрәсезме, ул мине, профессор Хуҗинны, әдәпкә өйрәтә. Сүзегез шул гына идеме?

Рөстәм. Нигә ашыгасыз?

Хуҗин. Нәрсә, әллә тагын сезнең тимер кыруыгыз турында сөйләшикме?

Рөстәм. Ул турыда да мөмкин.

Хуҗин. Бик зур рәхмәт. Ул мине кызыксындырмый.

Рөстәм. Ярый, шулай булсын... Алайса сезнең эшегез турында сөйләшик.

Хуҗин. Ә?! Минем эшем турындамы?

Рөстәм. Ә нигә? Мәсәлән, сезнең унбиш елдан артык эшләп тә нәтиҗә күрсәтмәвегез турында ни өчен сөйләшмәскә?

Хуҗин. Һа! Унбиш ел дисезме?

Рөстәм. Әйе.

Хуҗин. Унбиш ел күп дисезме?

Рөстәм. Чиктән тыш.

Хуҗин. Чиктән тышмы?

Рөстәм. Чиктән тыш.

Хуҗин. Ә сез, энем, фән гомере өчен унбиш ел — кеше гомере өчен унбиш секунд белән бер икәнен беләсезме?

Рөстәм. Шулай булсын. Ләкин без секундлар өчен дә көрәшәбез.

Хуҗин. Ә сез, энем, мин эшли торган проблема өстендә галимнәрнең ничә йөз ел баш ватуларын беләсезме?

Рөстәм. Юк.

Хуҗин. Юк шул, белмисез шул!

Рөстәм. Ләкин сез шуны да хәтерегездән чыгармагыз, профессор. Без хәзер шундый чорда яшибез — бездә гасырлар буе хыял булып килгән нәрсәләр бер елда чынга әвереләләр. Тормыш алга бара. Аңа яңа ачышлар кирәк һәм — тизрәк.

Хуҗин *(ишек төбенә утырып)*. Дәвам итегез, дәвам итегез. Речегезне дәвам итегез.

Рөстәм. Менә сез әйтегез әле, үзегезнең унбиш ел эшләгән эшегезнең нәтиҗә китерәчәгенә ышанасызмы?

Хужин. Бу турыда сез Фәннәр академиясендә белә аласыз.

Рөстәм. Мине үз фикерегез кызыксындыра.

Хужин. Сез минем турыда, энем, тиздән ишетерсез. *(Кабинетына керә башлый.)*

Рөстәм. Ышанмыйм.

Хужин. Ышанмыйсызмы?

Рөстәм. Ышанмыйм.

Хужин. Шулай дисезме?

Рөстәм. Шулай дим!

Хужин. Нәтижә китермәс дисезме, иптәш токарь?

Рөстәм. Китермәс. Чөнки сез, профессор, тормышны, кешеләрне белмисез. Әгәр сез кешеләргә файда эшләргә теләсәгез,— алардан качмагыз. Аларның сезнең белән сөйләшергә теләүләрен күреп, кабинетыгызга кереп бикләнмәгез. Ул тар стеналар эченнән чыгыгыз сез. Чыгыгыз. Менә бу пәрдәләрне ачыгыз. *(Гөлсинә тәрәзә пәрдәләрен ача. Булмә яктырып китә.)* Бүлмәгезгә кояш нуры, тормыш яктысы төшсен, профессор.

Хужин тәрәзәгә килә.

Юк, сез тормышны алай тәрәзәдән генә күзәтмәгез, чөнки тәрәзә аша тормышны аңлап булмый. Сез аның эченә керегез. Аның бүгенге интереслары белән кайнагыз, бүгенге кешеләре белән танышыгыз, алар белән бергә көрәшегез. Менә шул вакыт мин сезгә ышанырмын.

Хужин. Аның каравы Хужинга Мәскәү ышана. Фәннәр академиясе ышана!

Рөстәм. Ә сез ул ышанычны нәрсә белән аклыйсыз? Унбиш ел бер урында таптану беләнме?

Хужин. Карагыз әле, пластинкагызның икенче ягын әйләндерә алмыйсызмы? Чөнки, турысын гына әйткәндә, минем фәнни эшем сезнең кебек кешеләрнең тыгылуына мохтаж түгел.

Рөстәм. Кем кебек?

Хужин. Менә сезнең кебек токарьларның.

Рөстәм. Менә сез токарь, дисез. Әйе, мин токарь. Минем белемем юк. Ә менә сез, профессор, минем ни өчен укымый калуымны беләсезме?

Хужин. Юк.

Рөстәм. Белмисез шул сез һәм белергә дә теләмисез. Ә белү зыян итмәс иде.

Хужин. Һе, сөйләп карагыз, тыңлап карыйк.

Рөстәм. Ул вакыт мин кечкенә идем әле. Әти миңа «Укы, улым, безгә укырга туры килмәде, безнең өчен дә укы, халык өчен файдалы кеше бул» дия иде. Ә мин үзем зур галим булырга, кешеләр өчен могҗизалар тудырырга хыяллана идем.

Хуҗин. Соң? Укый башлагач теш үтмәдеме?

Рөстәм. Юк, башка сәбәпләр булды. Мин алтынчы класста укыганда, әти үлеп китте. Без, дүрт бала, бер әни тәрбиясендә калдык. Ә еллар авыр, сугыш еллары иде. Һәм миңа, елый-елый булса да, мәктәпне калдырып, шәһәргә килергә, эшкә керергә туры килде. Менә сигез ел инде, мин эшлим һәм кечкенә сеңелләремне тәрбияләүдә әнигә булышам. Алар укыйлар һәм мин аларга әтинең сүзләрен кабатлыйм. «Укыгыз, сеңелләрем. Сезнең кебек вакытта миңа укырга туры килмәде. Минем өчен дә укыгыз. Зур кешеләр, халкыбыз өчен кирәкле кешеләр булыгыз». Һәм алар укыйлар. Бер сеңелем быел медаль белән урта мәктәп бетерде...

Хуҗин. Йөрәгегезнең җәрәхәтенә кагылганмын икән, гафу итегез, билгеле...

Рөстәм. Юк, гафу үтенергә кирәкми. Иске җәрәхәтләрдән сыкрау егетлек түгел, профессор.

Хуҗин. Ә, ә, әткәгез нәрсәдән үлде?

Рөстәм. Әтиме? Ул каты авырып үлде. Һәм сез әнә шул проблемагызны моннан сигез ел элек чишкән булсагыз, ул исән булыр иде. Ә сез унбиш ел бер нәтиҗәсез таптанасыз.

Пауза.

Профессор! Ни өчен сез безнең мәхәббәтебезгә каршы киләсез?

Хуҗин. Чөнки мин кызымның кияве сез булуны теләмим.

Рөстәм. Ни өчен?

Хуҗин. Ә, чөнки минем кызым укымышлы. Ул киләчәктә фән өлкәсендә эшләячәк. Һәм минем кызымның тормыш иптәше аның идеалларын аңлаучы кеше, интеллигент кеше булырга тиеш. Ә сезнең белән кушылу аның талантын бала-чага арасында күмеп калдырачак.

Рөстәм. Ул яктан тыныч булыгыз. Һәрхәлдә, Разия апа хәленә калмас.

Соңгы сүзләрне әйткәндә кулына тастымал тоткан Разия керә.

Хуҗин. Менә, менә, күрдегезме! Ул бөтенебезне дә сүгеп чыкты. Туктагыз әле, шушындый сүзләрдән соң да кызымны сорарга сез ничек кыюлык итәсез?

Рөстәм. Без бер-беребезне яратабыз.

Хуҗин. Гөлсинә бала әле ул.

Рөстәм. Ләкин ул бала минем белән Камчаткага китәргә риза.

Хуҗин. Ә?! Әйтсә, ул аны элек әйткәндер. Ә менә хәзер, сез безнең бөтенебезне дә шулай мәсхәрәләгәч, ул бу сүзне әйтмәс. Әйтмәс!

Гөлсинә. Юк! Син хаклы түгел, әткәй. Рөстәмнең бер кешене дә мәсхәрәләгәне юк. Һәм мин... һәм мин аны бүгенге вакыйгадан соң тагын да көчлерәк яратачакмын.

Звонок. Алексей Степанович керә.

Хуҗин. О, Алексей Степанович! Уз, әйдә, нихәл?

Алексей Степанович. Исәнмесез.

Пауза.

Безнең препарат дәвалау өчен яраксыз, Әхмәт ага...

Хуҗин. Ә?!!

Алексей Степанович. Кролик үлде.

Хуҗин. Тукта әле, тукта. Сез нәрсә, бу бит минем унбиш еллык хезмәтем юкка чыкты дигән сүз!..

Алексей Степанович. Мин бу хакта сезгә әйтә килдем. Безнең юлыбыз ялгыш, Әхмәт Закирович, без дөрес юлдан бармыйбыз, дидем.

Хуҗин. Соң хәзер нишлибез инде? Туктагыз әле, нәрсә соң бу? Нәрсә соң бу, Алексей Степанович?..

Рөстәм. Менә профессор...

Алексей Степанович. О, иптәш Афанасьев! Исәнмесез, сез ничек монда?

Рөстәм. Гафу итегез, мин Афанасьев түгел.

Алексей Степанович. Ничек?! Туктагыз әле, сез бишенче больницадагы хирург Афанасьев бит. Әхмәт Закирович?

Хуҗин. Таныш булыгыз: бу минем булачак... әә... безнең булачак... безнең Гөлсинәнең.., әәә.. бу ни, әлеге дә-баягы...

Гөлсинә (*алга чыгып*). Бу—минем булачак киявем.

Рөстәм (*Алексей Степановичның кулын кыса*). Рөстәм, токарь.

Пәрдә.

1952 ел

ЗӨБӘЙДӘ — АДӘМ БАЛАСЫ

Өч пәрдәле трагикомедия

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла абый Юсуповка багышлана

КАТНАШАЛАР:

Зөбәйдә
Габдрахман
Җәүһәрия
Фәрит
Булат
Әсхәт
Сөендек
Зөфәр
Сәрия
Мәрвәр Сафина
Кәримә
Сәмигулла
Славик

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сабитовлар өендә зал. Каршыда һәм як-якта берничә ишек. Сулда зур тәрәзә, ул ачык. Зөбәйдә тәрәзә төбенә утырып имтиханга әзерләнә. Тирә-ягында китап-дәфтәрләр. Зал уртасындагы түгәрәк өстәлдә Җәүһәрия күлмәк үтүкли. Келәм эленгән уң стена буенда тахта. Анда битен сөлге белән ураган Фәрит утыра. Ачык тәрәзәдән шау килеп уйнаган бала-чага тавышы ишетелә. Тавыш көчәйгән арада, Зөбәйдә канәгатьсезләнеп тышка карап ала. Ниһаять, тәрәзәдән туп атылып керә, Зөбәйдәнең кулындагы китабын бәреп төшерә.

Зөбәйдә *(кулларын биленә таянып тәрәзә төбенә менеп баса)*. Туктыйсызмы сез, юкмы, шайтан чабаталары?! Өстегезгә бер чиләк су сибәм! Барыгыз, урамга чыгып уйнагыз! *(Ялварып.)* Үзеңә этикетка бирермен, Рөстәмкәем, барыгыз инде! *(Тавыш азрак басылган кебек була. Зөбәйдә идәндәге тупны алып берничә мәр-*

тәбә сикертеп уйный да элекке урынына утырып укый башлый. Ләкин укый алмый, шап иттереп китабын яба.) Уф, минем газиз башкайларым өчен түгел бу математика!.. *(Көйләп.)*

А у нас во дворе
Есть девчонка одна...

Җәүһәрия. Җиңел булса, һәркем инженер булыр иде. Шуңа бит инде әйткәннәр, белем алу энә белән кое казу дигәннәр.

Зөбәйдә.

Я гляжу ей в след —
Ничего в ней нет,
Я гляжу ей в след —
Ни черта в ней нет...

(Теш арасыннан төкереп.) Нәрсәгә миңа кое — водопровод бар ич! *(Тышка карап.)* Яле, Магеллан, тубыңны монда җибәр әле. *(Тыштан туп ыргыталар. Зөбәйдә балалар белән туп атышып уйный башлый.)*

Җәүһәрия. Кайтсын әле әтиең. Уйнатыр әле ул сиңа туп.

Телефон шалтырый. Зөбәйдә тубын кочаклап телефонга килә, трубканы ала.

Зөбәйдә *(трубкага)*. Хелло! Ә, бу әле тагын сезмени? Исәнмесез! Тагын номерны ялгыш җыйдыгызмы? Бик ягымлымыни тавышым? Мин үзем дә ягымлы. Әйе... Чакырыгыз мине кинога — танышырбыз. Яхшы. Ә мин сезне ничек танырмын? Яхшы... Минеке — сары. Сап-сары чәчле, озын толымлы бер кыз булырмын мин. Исемем... Бибибикәбисәгыйдәбанусылугөлҗамал...

Җәүһәрия *(җилтерәп килеп трубканы тартып ала да рычагка куя)*. Кит телефон кырыннан! *(Зөбәйдә әйләнә-тулгана өстәл янына килә, Җәүһәриянең күлмәген утюкләмәкче була. Җәүһәрия утюкне тартып ала.)* Утыр урыныңа!

Зөбәйдә. Шуны гына утюкләп бетерим инде, туган апам!

Җәүһәрия. Бетермә, укы сабагыңны! *(Зөбәйдә һич исе китмичә тәрәзә төбенә менеп утыра.)* Күрмәгән-белмәгән кеше белән кинога барырга җыена, җүләр!

Зөбәйдә. Җүләр шул. Җүләр, җүләр, җүләр! Мин бит бәхәсләшмим.

Җәүһәрия. Акыл керә башларга вакыт.

Зөбәйдә. Нәрсәгә миңа акыл! Егетләр яратса — миңа җитә. Ә егетләр җүләр кызларны ярата төшәләр, ди. *(Тышта бала-чага тавышы көчәя.)* Ну, малайлар, төшсәм — кирәгегезне бирәм!.. О, Славик, привет! Ты на Авеню, да?.. Славка да гуляньега китте — рәхәт кешеләрнең... Әй, Фәридә, кая бардың? *(Арттан тавыш: «Пляжга!»)* Ә... Ә мин математика өйрәнәм. *(Китабын кулына алып өлгерми, күрше бүлмәдә нәрсәнеңдер гөрселдәп ауганы ишетелә. Зөбәйдә йөгереп шунда кереп китә. Анда аның тавышы: «Туган апам, Акмыек тычкан тоткан!»)*

Җәүһәрия *(дулкынланып)*. Кит ичмаса! *(Зөбәйдә янына чыга.)* Тимә! Тимә дим, җүләр, уйнасын!

Зөбәйдә. Качыра бит ул аны, туган апам! Качыра бит ул аны!

Җәүһәрия *(Зөбәйдәне төрткәләп чыгарып)*. Качырмас, качырмас. Уйнасын рәхәтләнеп. Кермә монда! *(Ишек төбендә тарткалашалар.)* Керфегемне күземә керттең, шашкан! Кит әле! *(Шап иттереп Зөбәйдәнең аркасына суга.)*

Зөбәйдә *(аркасын угалап ала да Фәрит янына килә, битенә ураган сөлгесен тартып ала)*. Унбиш минут булды! Акмыегым тычкан тотты, ишеттеңме? *(Фәрит көзге алдына утырып битен сөртергә керешә. Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы ала.)* Хелло!.. Ә минем сине — юк. *(Трубканы куя.)*

Җәүһәрия. Кем әле ул?

Зөбәйдә. Зөфәр. Сагындым, күрәсем килә, ди.

Җәүһәрия. Үзеңне яратып йөргән егет белән шулай тупас сөйләшмиләр инде. Әйбәт кенә иттереп әйтергә дә була бит.

Зөбәйдә. Әй! *(Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы алып тыңлап тора да.)* Ә минем сине күрәсем килми! *(Трубканы ташлый, ләкин шунда ук телефон яңадан шалтырый.)* Ал әнә! Әйбәт кенә иттереп әйт үзенә.

Җәүһәрия *(телефонга)*. Әйе, квартира. Исәнмесез! Кем әле бу? Ә, исәнмесез, Сөендек!.. *(Зөбәйдә кул селтәп китаплары янына бара башлый.)* Зөбәйдә өйдә юк шул. Ни йомыш иде соң? Киноға барырга булган идегезмени?..

З ө б ә й д ә *(йөгереп килә дә трубканы тартып ала)*. Хелло! Ха, ха, кайтмадым, өйдә утырам мин. Математика өйрәнәм.

Җ ә ү һ ә р и я. Иртәдән бирле математика өйрәнәм дип дыңгырдый — өйрәнә башлаганы юк әле. *(Чыга.)*

З ө б ә й д ә *(телефонга)*. Ә имтиханны кем бирер иртәгә? Нинди картина? Юк, бармыйм. Харап булгансың икән — билетларыңны миңа бүләк итәрсең, истәлеккә... Машинада йөреп кайтырга? Ярый. *(Трубканы куеп яңа номер җыя.)* Роза, сәгать җидедә киногa барабызмы? Жан Маре катнашы белән! Беләсеңме, миңа ике билет чиртеп тора. Ха-ха-ха! Тиздән мин машина белән килеп җитәрмен, беркөнгечә. Ха-ха-ха! *(Трубканы куя. Радиола кабызып пластинка уйнатып җибәрә, бөгелә-сыгыла твист өйрәнә башлый.)*

Җ ә ү һ ә р и я керә.

Җ ә ү һ ә р и я. Күр әле моның килешләрен! Аздырма дим кыяфәтеңне, тукта! Тукта диләр сиңа! Туктыйсыңмы, юкмы яхшылык белән!

З ө б ә й д ә *(бии-бии)*. Туктамасам?

Җ ә ү һ ә р и я. Туктамасаңмы? Күлмәгеңне күтәреп, менә шушы каеш белән...

З ө б ә й д ә *(шаяруга юрап күлмәген күтәрә)*. Мә, мә, мә...

Җ ә ү һ ә р и я. Күр әле! *(Урындык аркасына эленгән каешны алып Зөбәйдәгә сыпыра.)*

З ө б ә й д ә. Ни хакың бар синең миңа сугарга?

Җ ә ү һ ә р и я. Мин синең әниең урынына калган туган апаң.

З ө б ә й д ә. Әни мине кыйнамый иде! Ни хакың бар синең мине кыйнарга? Менә кияүгә чык та үз балаларыңны кыйна!

Җ ә ү һ ә р и я. Алла сакласын! Синең шикелле балаң булса...

З ө б ә й д ә. Шуңа күрә аллаһы тәгалә үзеңә кияү бирмәгән дә инде!

Җ ә ү һ ә р и я *(ике арадагы тавышка һичбер игътибар итмәгән Фәриттән ярдәм көтеп)*. Фәрит! Ичмаса, син азрак куркытыр идең шуны. Тәмам чылбырдан ычкынды бит!

Ф ә р и т. Ә син аны чылбырлама. Ул бит эт түгел.

З ө б ә й д ә. Әйе!

Җәүһәрия. Син кыяфәтеңне әнә көзгедән кара әле!

Зөбәйдә *(карап)*. Ни булган? Матур бит.

Җәүһәрия. Искиткеч! Син пумала башны яратып йөргән егетләренә ни әйтим. Шушы да булдымы инде кыз бала! Татар кызы бит әле, җитмәсә.

Зөбәйдә. Синеңчә, татар кызлары, бил тиңентен чәч үстереп, чаршау артында сагыз чәйнәп кенә утырырга тиешме?

Җәүһәрия *(тынычлана төшеп, сукрануга күчә)*. Сугыштан соң китте мондый яшьләр. Без яшь вакытта, сугышка кадәр...

Зөбәйдә. Син яшь вакытта? Кайчан иде ул — япон сугышы алдыннанмы?

Җәүһәрия. Онытма шушы сүземне: менә күрерсең, син җүләрне бер кызык итәләр әле. Әй туган апам, синең акылың белән йөргән булсам — ак сакаллы карт буласы икәнмен, диярсең әле бер.

Зөбәйдә. Әйтмәм! *(Китаплары янына утыра.)*

Җәүһәрия. Әйтерсең!

Фәрит. Калдыр син аны! Ул бит инде кечкенә бала түгел.

Җәүһәрия. Мин дә шуны әйтәм ләбаса! Син инде бала түгел, бер көтү егет белән хихылдап йөрмә, берсе белән генә йөр, дим.

Зөбәйдә. Минем кияүгә чыгарга җыенганым юк ич әле!

Җәүһәрия. Җыенгач кына соң була шул ул.

Зөбәйдә. Ми-ңа ки-яү ки-рәк-ми! Миңа егетләр кирәк — күңел ачу өчен — аңлашылдымы? Ә кияүгә чыгарга җыенгач, кайберәүләр кебек озын толымнар үстерермен һәм ханжа булырмын. *(Фәритнең йөзен карап.)* Менә бит нинди яшәреп киттең! О! *(Фәритнең башыннан ак чәч йолкып ала.)* Никадәр ак чәч!

Фәрит. Йолкы!

Зөбәйдә. Вакытым юк — математика өйрәнәм. Туган апам йолкысын.

Җәүһәрия. Йолкыр туган апаң — йолдызларга карый торган нәрсәне бирсәләр.

Фәрит. Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Бер ак чәч — биш тиен.

Фәрит. Яхшы.

Зөбәйдә аякларын салындырып тәрәзә төбенә менеп утыра да Фәритнең ак чәчләрен йолкый башлый. Кәримә керә.

Кәримә. Исәнмесез!

Зөбәйдә. О, Кәримә, салют!

Җәүһәрия. Әле авылдан кайттың дамы, Кәримә?

Кәримә. Отпускым бетте ич. *(Төенчек бирә.)* Әби җибәрде. Корт белән сөзмә.

Җәүһәрия. Рәхмәт инде. Исән-саулармы? Бик картаймаганнармы?

Кәримә. Яшәрмәгәннәр. Сәлам әйттеләр. Кунакка чакырдылар.

Зөбәйдә. Мине дә чакырдыларммы?

Кәримә. Һәммәгезне дә.

Зөбәйдә *(чәч йолкып).* Биш!.. Язып җибәр үзләренә, Кәримә. Зөбәйдә кайтмый, диген. Ләкин, берүк, һуштан язып егылмасыннар.

Җәүһәрия. Күр әле бу җүләрне!

Зөбәйдә *(Фәриткә төртеп).* Менә кемгә кирәк ул авылга кайту. Бар, кайт! Яхшылап татарча өйрәнеп килерсең.

Фәрит. Бер телдә сөйләшергә дә сүз юк әле монда.

Кәримә. Доцент булачак кеше авыл картлары янына кайтып йөрмәс шул инде.

Зөбәйдә *(кисәтеп).* Кәримә!

Кәримә. Әллә дөрес түгелме? Сез бит шушында бер шәһәрдә яшәп, безгә дә килеп чыкмыйсыз. Кеше туганнары юкка аптырый, ә сез бар туганнарыгыздан качасыз. Зураеп киттегез. Әби белән бабай рәнҗиләр. Без үлгәч, кайтам дисәләр дә кайта алмаслар әле, диләр.

Җәүһәрия. И алла, кайтыр идем, Кәримә, бик кайтыр идем. Әтиләрне дә бик сагындым. Менә бушап булмый. Эшләгән кешенең рәхәт ул — ял аласыз да теләсәгез кая барасыз. Учыгыз тулы акча.

Фәрит. Кайчан син мине, Кәримә, бер матур кыз белән таныштырасың?

Кәримә. Синең шикелле картаеп беткән егетләргә кыз тагын! Әнә Фәйрүзә апа да иргә чыкты. Нинди әйбәт кызны очырдың.

Фәрит. Теге зур колаклы Фәйрүзәме?

Кәримә. Сиңа ярамассың. Әле колагы зур, әле оклады кечкенә... Чынлап әйтәм, Зөбәйдә, кайтып кил

каникулында авылга. Әби бик картайган. Бер чиләк су китерсәң дә файда булыр.

Зөбәйдә (*чәч йолкып*). Ун! Яратмыйм авылны! Кайткан көнне кемнәрне очратсаң, киткәнче шуларны күреп торасың. Шәһәрдә ичмаса күңелле: иртәгә нинди егет белән танышасыңны кичен йокларга ятканда белмисең.

Кәримә. Хәсрәтең шул гына булса, егетләр авылда да күп.

Зөбәйдә. Өченче ел күрдем инде. Бөтен авылга дистә ярым егетләре бар, аның да берсе хатын аерган. (*Чәч йолкып.*) Кияү табып кайтмадыңмы соң?

Кәримә. Эзләмәдем.

Зөбәйдә. Картаясың бит инде, Кәримә! (*Чәч йолкып.*) Унбиш! Телисеңме, бер егет белән таныштырам?

Кәримә. Кеше аркылы таныша-таныша егет эзләргә яшем кырыкка җитмәгән әле.

Зөбәйдә (*баш бармагын күрсәтеп*). Менә! Өч бүлмәле квартирасы, личный «Волга»сы һәм Васильевода салынып бетмәгән дачасы. Дөрес, әлегә болар барысы да әтисенеке. Ләкин әтисе картайган инде, борынгы бабалары янына китәр вакыты җиткән.

Кәримә. Шулкадәр яхшы егет булгач, үзең чык.

Зөбәйдә. Миңа бит әле кияүгә чыгарга иртә. Менә университетка керәм, инженер булам. Укыган кызларга картайгач та кияү табыла.

Кәримә. Мин дә техникумга керәм, читтән торып укыйм.

Зөбәйдә. Әй, эшләп укуны әйтмә инде син аны — халтура! (*Чәч йолкып.*) Егерме... Таныштырыйммы?

Кәримә. Кирәкми.

Зөбәйдә. Турысын гына әйткәндә, минем үземнән дә артмас иде әле ул. Белеме аз.

Кәримә. Яратсаң — белемен тикшереп тормассың әле. Яраткан кеше белән алачыкта да җәннәт, диләр.

Зөбәйдә. Булса булыр инде. Ләкин мин үзем теләп алачык җәннәткә кермәячәкмен. (*Чәч йолкып.*) Егерме ике! (*Фәриткә.*) Башка күренми. Бер сум ун тиенне гони сюда! (*Тәрәзәдән карап.*) Ниндидер бер кыз безнең квартирны сорый.

Фәрит (*карап*). Сәрия бит бу!

Зөбәйдә (*куркуыннан тәрәзә төбеннән шуып төшә*). Сәрия?!

Фәрит. Теге, Буа кызы. Исендәме, миңа хат язган иде. Хатын син дә укыдың.

Зөбәйдә (*куркудан нишләргә белмичә зал буйлап йөгереп китә*). Вай-вай-вай-вай!..

Фәрит. Син нәрсә?

Зөбәйдә. Бетте башым!.. Мин бит аның белән син булып хат алыштым. Ой!

Фәрит. Ничек мин булып?

Зөбәйдә. Син җавап язмагач, мин аңа үзем язган идем. Син булып.

Фәрит. Шуннан?

Зөбәйдә. Шуннан ул миңа тагын язды. Дөресрәге, ул сиңа дип яза, ә хатны мин алам. Алам да синең исемнән җавап язам.

Фәрит. Нәрсә дип язасың?

Зөбәйдә. Яратам дип. (*Звонок.*) Ой!

Фәрит. Ну, Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Мин бит кызык өчен генә шулай эшләгән идем. (*Звонок.*) Ой!

Фәрит. Үзең ботканы пешергәнсең — теләсәң нишлә. Мин өйдә юк! (*Бүлмәсенә кереп бикләнә.*)

Зөбәйдә. Туган апам!

Җәүһәрия. Менә! Үзеннең җүләр икәнлегеңне белдеңме инде? Сөйләш үзең! (*Күрше бүлмәгә китә. Звонок кабатлана.*)

Зөбәйдә (*кинәт батыраеп*). Әллә сөйләшмәммe! Кәримә, ишекне генә ач та, туган апам ягына кер! (*Кәримә ишек ачарга чыга. Зөбәйдә Җәүһәриянең купшы халатын һәм күзлек киеп тахтага сузылып ята. Кулына журнал ала.*)

Сәрия (*ишектә*). Мөмкинме?

Зөбәйдә (*Сәрияне башыннан аягына кадәр карап чыга да*). Мөмкин.

Сәрия (*кыюсыз гына, оялып*). Фәрит Сабитов шушында торамы?

Зөбәйдә (*кыюлана төшеп*). Тора.

Сәрия. Өйдәме ул?

Зөбәйдә. Фәрит Сабитов өйдә юк.

Сәрия (*беравык нәрсә әйтергә белми торганнан соң*). Сез аның кеме буласыз?

Зөбәйдә. Мин аның сеңелесе.

Сәрия. Таныш булыйк: мин — Сәрия. Районнан килдем.

Зөбәйдә. Анысын әйтмәсәгез дә күреп торам.

Сәрия. Нәрсәне күреп торасыз?

Зөбәйдә. Районнан икәнлегегезне.

Унайсыз пауза.

Сәрия. Фәрит тиз кайтырмы икән?

Зөбәйдә. Ул тиз кайтмаячак. Йомышыгызны миңа әйтергә мөмкин, акыллым. Мин Фәритнең әнисе урынына калган сеңелесе.

Сәрия. Әнисе урынына калган?

Зөбәйдә. Әйе.

Сәрия (*гаҗәпләнеп*). Сезгә ничә яшь соң?!

Зөбәйдә. О, мин шактый олы инде. Сез минем битемә карамагыз — шәһәр кызлары тиз картаймыйлар.

Сәрия. Гаҗәп!

Зөбәйдә. Гаҗәп түгел, акыллым. Әни үлгәндә абый бик яшь иде әле... Һәм миңа ана әни булып калырга туры килде. Ир кеше хатын-кыз тәрбиясеннән башка яши алмый бит... Мин сезне тыңлыйм, акыллым. Ләкин баштан ук кисәтеп куям: мин бик гаҗәпләнәм.

Сәрия. Нәрсәгә?

Зөбәйдә. Әрсезләнүегезгә. Кызларның авторитетын төшереп егетләр куып йөрисез. (*Сәрия нидер әйтмәкче була, ләкин Зөбәйдә кул күтәреп аны бүлә.*) Сабыр итегез! Мин сезнең абыйга язган хатларыгызны укып барам — кичерерсез, шаять. Үлеп яратам мәхәббәт хатларын укырга. Ялгышмасам, сез икмәк пешерүче булып эшлисез?

Сәрия. Әйе.

Зөбәйдә. Сезнең шул хакта уйлаганыгыз юкмыни, акыллым: әгәр минем абый — доцент булачак кеше — икмәк пешерүче кызга өйләнергә уйласа, аларны Буадан төяп китерүнең ни хаҗәте булыр икән? Икмәк пешерүче кызлар Казанда да күп бит. Өстәвенә, Казан икмәге Буаныкыннан тәмлерәк.

Сәрия. Күрәсең, абыегызга мин пешергән икмәк ошый төшкән.

Зөбәйдә. Уйламыйм.

Сәрия. Уйламасагыз бигрәк тә яхшы. Фәритнең үз башы бар.

Зөбәйдә. Бер баш яхшы, ике баш — тагы да яхшырак.

Сәрия. И, сеңелем, син бит әле...

Зөбәйдә. Беренчедән, акыллым, «син» түгел, «сез». Авылда яшәсәгез дә азрак культурага өйрәнергә вакыттыр лабаса. Икенчедән, мин сезнең сеңелегез булырга җыенмыйм.

Сәрия. Каенсеңелем булырсыз.

Зөбәйдә. О!

Сәрия. Фәрит кайчан кайта? Миңа ул кирәк.

Зөбәйдә. Ә сез аңа кирәкмисез.

Сәрия. Күрәсең, әнисе урынына калган сеңел белми. Сезнең абыегыз мине ярата. Без аның белән хат алышабыз.

Зөбәйдә. Аһ, хат! Онытa язганмын. Сезнең белән абый булып хат язышучы мин ул. Һәртөрле авантюралар эшләргә үлеп яратам! Гафу итәрсез дип уйлыйм.

Сәрия. Андый хатлар язу өчен башыгыз яшьрәк әле сезнең.

Зөбәйдә (*пафос белән*). «О сөеклем Сәрия! Айлы төннәрдә тын бакчага кереп, йолдызларга карап сине уйлыйм...»

Сәрия (*сагая төшеп*). Күрәсең, чыннан да сез безнең хатларны укып барасыз.

Зөбәйдә. Ә сезнеңчә ничек, акыллым? Мин — абыйның әнисе урынына калган сеңелесе — аның кемнәр белән хат алышуын тикшерергә тиешме, юкмы?

Сәрия. Фәрит бала түгел, аңа утыз яшь.

Зөбәйдә. Егет кешегә утыз күп түгел. Яшьли өйләнергә минем рөхсәтем юк!

Сәрия. Абау, җаным, бу Казан кызларының һәммәсе дә шулаймы?

Зөбәйдә. Шулайрак.

Сәрия. Сезнең белән сөйләшеп файда булмас. Иртәгә килермен. (*Чыга.*)

Фәрит керә.

Фәрит. Ну сине, Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Ярар, ярар. Ап-аек көенчә доцент булачак кешегә кияүгә чыгам дип йөрмәсен. Күр әле җүләрне — тәмам ышанган!

Телефон шалтырый. Җәүһәрия керә.

Җ ә ү һ ә р и я *(телефонга)*. Әйе. Мин бу, абый... Нинди егет?.. Ярый. *(Трубканы куя.)* Әтиең шалтырата. Бер егет алып кайтам, берничә көн бездә торачак, ди. Синең бүлмәне әзерләргә куша.

З ө б ә й д ә. Нинди егет?

Җ ә ү һ ә р и я. Белмим.

З ө б ә й д ә *(телефонда номер җыя)*. Ало, начальник! Син кемне алып кайтасың? Нишләп ул минем бүлмәдә торачак? Кем ул? *(Ачуланып трубканы куя.)*

Җ ә ү һ ә р и я. Нәрсә ди?

З ө б ә й д ә. Әйтмәде. Килгәч күрерсез, ди.

Җ ә ү һ ә р и я. Әзерләргә туры килә инде бүлмәңне.

З ө б ә й д ә. Һы, билгеле, әзерлисең. Начальник сүзе — приказ.

К ә р и м ә керә.

Кая мыштым гына чыгып барасың. Гони бер сум ун тиенне! *(Фәрит Зөбәйдәгә акча биреп чыгып китә.)*

Җ ә ү һ ә р и я. Килде-китте генә кеше түгелдер инде ул, кирәкле кешедер. Пәрәмәч пешерергә кирәк.

З ө б ә й д ә *(сикеренеп)*. Мин дә пәрәмәч ясыйм!

Җ ә ү һ ә р и я. Ясамый гына тор әле. Укы әнә сабагыңны. Кәримә, уң күзем, син пәрәмәчне бик оста ясыйсың, булыш әле миңа! *(Чыга.)*

З ө б ә й д ә. Кәримә, ишеттеңме, начальник бер егет алып кайта. Кем булыр икән?

К ә р и м ә. Мин кайдан белим!

З ө б ә й д ә. Соң, син бит шунда эшлисең!

К ә р и м ә. Исеме ничек?

З ө б ә й д ә. Белмим.

К ә р и м ә. Ярар, килгәч күрербез. Таныган кеше булса — әйтермен. *(Җәүһәрия янына чыга. Зөбәйдә китаплары янына барып утыра. Әсхәт керә.)*

Ә с х ә т. Исәнме, Зөбәйдә! Әзерләнәсеңме?

З ө б ә й д ә. Әһе. Кулыңда нәрсә ул, Әсхәт, картинкалармы?

Ә с х ә т *(биреп)*. Униеч.

З ө б ә й д ә *(картинкаларны карый-карый)*. Рәхмәт, Әсхәт... Әсхәтчик, нигә шундый киң балаклы чалбар киясең? Үзең чибәр генә егет булып киләсең, ә үзеңнең чалбар балагың Тарас Бульбаныкы кебек.

Ә с х ә т *(сүзне икенчегә борып)*. Нәрсә өйрәнәсең?

З ө б ә й д ә. Шул инде, математика.

Әсхәт. Иртәгә стадионда футбол. Ишектә әни торачак.

Зөбәйдә. Әниең стадионда контролер булгач — эшләр рәхәт синең.

Әсхәт. Ә мин тагын бер кеше алып керә алам!.. Кемне дә булса алып керәм әле иртәгә... Беләсеңме нинди матч булачак! Мәскәү «Динамо»сы белән! Билетлар әллә кайчан сатылып беткән.

Зөбәйдә. Ой, Әсхәт, Мәскәү түгел, Бразилиядән Пеле килсә дә барыр хәлем юк. *(Пауза.)*

Әсхәт *(тәрәзәдән карап)*. Ә мин Бүрекле белән Күреклегә яна оя ясадым. Күрдеңме?

Зөбәйдә. Әһе.

Әсхәт. Матур булган бит?

Зөбәйдә. Әй, күгәрченнәргә матур ни дә, ямьсез ни! Аларның аңнары юк ич.

Әсхәт. Булмас сиңа! Ишек алдына чыксам — хәзер танып алалар. Гөл-гөл, гөл-гөл килә башлыйлар... Күрше ишек алдындагы Василий Степановичны беләсеңме? Беләсеңме? Миңа шул Бүрекле белән Күреклегә ун сум бирә!

Зөбәйдә. Нигә сатмыйсың, җүләр?

Әсхәт. Сата ди — көтеп торсын. Беләсең килсә, мин аларны йөз сумга да сатмыйм әле. Бер капчык алтын бирсәләр дә сатмыйм... Алар минем бөтен сүземне аңлыйлар. Сөйләшергә телләре генә юк... *(Пауза.)* Ә мин училищега керергә булдым.

Зөбәйдә. Училищега?

Әсхәт. Электротехник булам. Анда форма бирәләр — шинель, фуражка, ремень... *(Зөбәйдәнең елмаюын күреп.)* Сиңа ошамыймыни?

Зөбәйдә. Ошый, Әсхәт, ошый. Ләкин безнең университет — училище түгел, имтихан белән алалар. Өйрәнәсе бар.

Әсхәт. Мин чыгам. Син өйрән. Өйрән син, Зөбәйдә.

Әсхәт чыга. Зөбәйдә укуын дәвам итә. Сәмигулла керә. Кулында зур кәрзин.

Сәмигулла. Өйдәме хуҗалар? Нихәл, кызым!

Зөбәйдә. Сезгә кем кирәк, бабай?

Сәмигулла. Миңа Җәүһәрия апаң кирәк иде. Син аның кеме буласың?

Зөбәйдә. Мин аның абыйсының кызы. Исемем Зөбәйдә. Ә сез кем, бабай?

Сәмигулла. Бер бик чая сеңелем бар дип сөйләгән иде, син буласыңдыр инде алайса. Мин Сәмигулла Искин булам. Матур апаң өйдәме?

Зөбәйдә *(хәзер бер кызык буласын сизенгәндәй күзләрен уйнатып).* Туган апам! Искин килгән!

Җәүһәрия керә. Сәмигулланы күреп каушап кала. Кулларын алъяпкычына сөртеп, ике куллап күрешә. Зөбәйдә, тәрәзә төбендә укып утырган килеш, каш астыннан гына аларны күзәтә.

Җәүһәрия. Исәнме, Сәмигулла абый! Әйдә, түрдән уз.

Сәмигулла. Ярый. *(Кәрзинен ишек төбенә куеп уза, утыра.)* Нихәл, сау гына торасыңмы?

Җәүһәрия. Аллага шөкер, Сәмигулла абый.

Сәмигулла. Ничек соң, хәзерлисе-нитәсе нәрсәләренне карап бетерәсеңме инде? Мәрхүмә карчыгымның кырыгы җитә бит. Кырыгы тула!

Җәүһәрия *(Зөбәйдә ягына ымлап, акрын гына).* Туй күлмәге тегелде инде, Сәмигулла абый! *(Әле генә үтүкләп бетергән күлмәген алдына куеп күрсәтә. Зөбәйдә астан гына карап елмаеп утыра.)*

Сәмигулла. Кара, кыска җиңле итеп теккәнсең лабаса! Изүләре дә бик ачык төсле.

Җәүһәрия. Туй күлмәге озын җиңле булмый инде ул, Сәмигулла абый. Аның модасы шул.

Сәмигулла. Соң, әкәмәт, мода дип бит инде... Кыскарак та кебек күренә. Мин бит сиңа дүрт метр ефәк алдым. Әрәм иткәнсең ефәкне...

Җәүһәрия. Хәзер күлмәкне озын кимиләр инде, Сәмигулла абый. Модасы шундый.

Сәмигулла. Соң бит инде...

Җәүһәрия *(Зөбәйдәгә ымлап).* Хәзер эшемнең тыгыз чагы, Сәмигулла абый. Рәнҗемәсәң, кичкә таба үзем сугылыр идем.

Сәмигулла. Ярый. Әле үземнең дә базардан карлыган сатып кайтышым гына, өйгә ашыгам. Сәгать ничәләрдә килерсең?

Җәүһәрия. Сигезләр тирәсендә.

Сәмигулла. Иртәрәк килсәң, карлыган җыешыр идең. Коела башлады югыйсә.

Җ ә ү һ ә р и я. Анысына иртәгә, Сәмигулла абый. Иртәгә, алла теләсә.

Сәмигулла. Әнә теге матур кызны да ияртеп кил. *(Зөбәйдәгә.)* Матур апаң белән карлыган җыешырга килерсеңме, кызым?

Зөбәйдә. Имтиханымны бирсәм — килермен, бабай.

Сәмигулла. Бирерсең, ходай боерган булса, бирерсең. Кил! Җизнәң булачак кешегә бер файдаң тияр. Сытылганнарын үзең дә ашарсың.

Зөбәйдә. Ә сытылмаса?

Сәмигулла. Сытыла! *(Әрнеп, Җәүһәриягә.)* Сытыла шул, җыеп өлгереп булмый. Әле егерме биш төпкә кул да тимәгән — мимылдап торалар. Ярый, киттем мин. *(Кәрзинен алып чыга. Җәүһәрия аны озатып керә.)*

Зөбәйдә. Шушымыни инде синең Сәмигуллаң?

Җәүһәрия. Шушы инде!

Зөбәйдә. Плюшкин несчастный! Имтиханымны бирсәм — барып, юри бөтен карлыганын сытып кайтам әле.

Җәүһәрия чыга. Пауза. Зөфәр керә.

Зөфәр. Мөмкинме? Исәнмесез!

Зөбәйдә. Исән әле. Мин бит сиңа килмәскә куштым. Ник килдең?

Зөфәр. Сагындым, күрәсем килде.

Зөбәйдә. Ә минем сине — юк.

Зөфәр. Имтихан алдыннан азрак башны ял иттерергә кирәк. Әйдә Кабан күленә чыгабыз.

Зөбәйдә. Ни калган анда!

Зөфәр. Азрак көймәдә йөрербез.

Зөбәйдә. Батып үләсем килеп тормый әле.

Зөфәр. Син йөзә белмисеңме?

Зөбәйдә. Безнең ишек алдында бер генә кыз йөзә белә иде, анысы да батып үлде.

Зөфәр. Үзем коткарырмын.

Зөбәйдә. Ха!

Пауза.

Зөфәр. Бүген көне матур. Җил дә басылган...

Зөбәйдә. Басылса ни!

Зөфәр. Көймәдә йөрергә әйбәт.

З ө б ә й д ә. Булса ни!

З ө ф ә р. Кабан күленә ике аккош җибәргәннәр.

З ө б ә й д ә. Җибәрсәләр ни!

З ө ф ә р. Зөбәйдә!

З ө б ә й д ә. Мин инде унҗиде ел Зөбәйдә. Зинһар өчен, тирән сулама! Тирән сулап йөрү буенча стажың шактый инде. Пенсиягә китсәң дә ярар.

З ө ф ә р. Син яратуның нәрсә икәнен белмисең шул.

З ө б ә й д ә. Аллага шөкер! Җүләр булсам да, кемне дә булса яратып, айга карап, тирән сулап утырырлык дәрәҗәдә түгел.

З ө ф ә р. Сине шайтан да аңламас!

З ө б ә й д ә. Ә син аңларга тырыш. Син бит аңлы кеше — биш елдан врач булачаксың. Учыңны тутырып аена туксан сум акча алачаксың.

З ө ф ә р. Эш акчада гына түгел бит, Зөбәйдә. Бербереңне яратып яшәсәң — алачыкта да җәннәт. *(Зөбәйдәнең кулына сузыла.)* Зөбәйдә...

З ө б ә й д ә *(кулын тартып ала)*. Кагылма миңа! Мин сине яратмыйм. Яратмыйм! Яратмаячакмын да! Беләсеңме, мин нинди кешене генә яратачакмын? Кимендә ике бүлмәле квартирасы, «Москвич» кына булса да машинасы һәм аз дигәндә ике йөз сум хезмәт хакы булган кешене. Шуларга өстәп дипломы, дәрәҗәсе һәм перспективасы. Бармы синең шулар?

З ө ф ә р. Циник, циник! Мещанка! Син — совет мәктәбен бетергән кыз, комсомолка...

З ө б ә й д ә. Комсомолка булгач та тишек түбәле өйдә торып, алама киенеп йөрергә, тәмле ашау турында хыялланмаска дип уставка язылмаган. Син миңа Кытай теорияләрен өйрәтмә.

З ө ф ә р. Коммунизм, коммунизм дибез, ә үзебез...

З ө б ә й д ә. Коммунизм, коммунизм! Нәрсә соң ул коммунизм? Коммунизм ул һәр кешенең рухи һәм материаль ихтыяҗларын максималь тәэмин итү. Ә минем ихтыяҗларым әнә шундый. Әгәр инде минем ирем бар икән — мине машинага утыртсын да очыртып кына алып керсен коммунизмга. Аңлашылдымы?

З ө ф ә р. Эшли башлагач, боларның барысы да булачак бит, Зөбәйдә. Мин врач, син инженер булсаң, икебез дә эшләсәк...

З ө б ә й д ә. Ә минем коммунизм булгач эшлисем килмәсә? Балалар үстереп өйдә генә утырасым килсә?

З ө ф ә р. Ничек инде өйдә генә, эшләмичә?

З ө б ә й д ә. Шулай. Без хатын-кызлар социализмда җитәрлек эшләдек инде. Коммунизм килгәч, азрак ял итсәк тә хәрам булмас.

З ө ф ә р *(уйлап)*. Син миңа срок бир. Ну, җиде-сигез ел срок бир. Мин ышанам, минем квартирам да, машинам да, башкалары да булачак.

З ө б ә й д ә. Ә мин җиде-сигез ел буе нишлим? Синең лотереяга машина откаңныңны көтеп мич башында утырыйммы? Юк инде, минем бүген машинада йөрисем килә. Менә хәзер! Шуңа күрә Кәримәне көймәдә йөрергә чакыр. Кәримә! *(Кәримә керә.)* Таныш булыгыз: бу — әтинең сеңелесенең кызы. Ә бу — Зөфәр, биш елдан врач булачак. Кәримә, сине Зөфәр көймәдә йөрергә чакыра.

К ә р и м ә. Ничек инде?!

З ө ф ә р. Гафу итегез, Кәримә. Шаяра ул. Сау булыгыз! *(Чыга.)*

З ө б ә й д ә. Нигә син мине уңайсыз хәлдә калдырасың?

К ә р и м ә. Күр әле, син үзең мине уңайсыз хәлдә калдырасың.

З ө б ә й д ә. Характерыңны үзгәртмәсәң, син гомердә кияү тапмассың, Кәримә.

К ә р и м ә. Үземә насыйбы табылыр әле.

З ө б ә й д ә. Табылыр — авызыңны ачып торсаң. Әнә туган апам — насыйбы дип утырган да кырык сигезне тутырган.

К ә р и м ә. Күп сайламасын иде. Турысын гына әйткәндә, танышырга теләгән егетләрдән дә качам әле мин.

З ө б ә й д ә. Кач, кач. Шуннан килеп җитәр бер вакыт — егетләр сине күргәч үзләре кача башларлар.

С ө е н д е к керә.

С ө е н д е к. Рөхсәттер бит? Сәлам кызларга!

Җ ә ү һ ә р и я керә. К ә р и м ә чыга.

Җ ә ү һ ә р и я. Исәнмесез, Сөендек! *(Сөендек Зөбәйдәгә шоколад бирә.)* Үзегез тагын бер дә буш кул белән йөрмисез.

С ө е н д е к. Сезгә дә бүләгем бар, Җәүһәрия туташ. Менә бусы сезгә. Бусы — Зөбәйдәгә. Машина отыгыз! *(Икесенә дә лотерея билетлары бирә.)*

Җ ә ү һ ә р и я. Нишләрмен икән соң ул машина белән?

С ө е н д е к. Утырып йөрерсез.

Җ ә ү һ ә р и я. Йөртә белмәсәм дәме?

С ө е н д е к. Сатарсыз. Биш йөз сум өстәү белән кулга да тидермәячәкләр. Үзем хуҗа табып бирермен.

Җ ә ү һ ә р и я. Миңа калса, берәр шофер отсаң әйбәтрәк кебек.

С ө е н д е к. Ягъни?

Җ ә ү һ ә р и я. Машина отсам — йөртә белмәгәч, барыбер эшсез торачак. Ә менә шофер отсам — мин аңа шул көнне үк эш табам. Ха-ха-ха!

З ө б ә й д ә. Туган апам!

Җ ә ү һ ә р и я. Сезне күргәч, Сафа исемә төшә. Бер егетем бар иде минем сугышка хәтле. Сезнең кебек инженер ук булмаса да, шулай укыган нәрсә иде. Яратып та карады соң инде үземне мескенкәй. Ике ел буенча бер олау прәннек ашаткандыр...

З ө б ә й д ә. Туган апам, кунак килеп җитәр. Пәрәмәчләреңне кара!

Җ ә ү һ ә р и я чыга.

С ө е н д е к *(Зөбәйдә янына утырып)*. Нишләп утырасың?

З ө б ә й д ә. Математика өйрәнәм. Кайда билетларың?

С ө е н д е к. Саттым мин аларны.

З ө б ә й д ә *(шоколадың шап иттереп куя да)*. Бер сум акчам әрәм китә дип курыктың инде, ә?

С ө е н д е к. Син бит киногa бармыйм, дидең. Азрак машинада йөреп килербез дигәч, риза булдың. Әйдә, машина капка төбендә.

З ө б ә й д ә. Бәлки ул билетларны мин истәлеккә калдырырга телимдер. Тизрәк илтеп саткан!

С ө е н д е к. Инде ничә билетны әрәм калдырдың. Әллә син алардан коллекция җыясыңмы? Да, коллекция дигәннән, мин сиңа маркалар китердем. *(Кесәсеннән маркалар чыгара.)*

З ө б ә й д ә. Мин марка җыймыйм. Мин конверт картиналары гына җыям. *(Шоколад ашый-ашый.)* Бар инде, кинога билетлар алып кил инде!

С ө е н д е к. Димәк, барабыз?

Зөбәйдә. Бармыйбыз! Мине машинаңа утыртасың да иптәш кызыма илтәсең. Без аның белән математика өйрәнәбез.

Сөендек. Математика өйрәнү өчен кино билеты кирәкме?

Зөбәйдә. Нинди тәмле шоколад! Ач әле авызыңны! *(Сөендекнең авызына бер кисәк шоколад сала.)* Тәмлеме? Бар инде, киногa билет алып кил инде!

Сөендек. Ну кәҗәләнеп тә карыйсың син, Зөбәйдә!

Зөбәйдә *(шоколадны ашап бетереп, кәгазен тышка ыргыта)*. Алайса шоколадың да кирәкми, машинаңда йөрергә дә чыкмыйм. Бар, кит!

Сөендек. Ярый-ярый, синеңчә булыр. *(Ишек төбенә җиткәч.)* Мин өйгә кереп тормам, гудок кына бирермен. Ишеткәч чыгарсың. *(Чыга. Зөбәйдә тәрәзәдән кул болгап кала.)*

Зөбәйдә *(телефонда номер җыя)*. Роза, син мине көтәсеңме? Беләсеңме, монда эшләр саташып тора бит әле. Беренчедән, теге хайван билетларын сатып килгән. Икенчедән, безгә кунак килә, пәрәмәч пешерәсе бар. Кабатлап бетердеңме әле? Ой, мин бернәрсә белмим, бөтен ышаныч кылый күздә. Ярый, сау бул! *(Трубканы куя. Җәүһәрия керә.)* Туган апам, нинди егет алып килә икән ул?

Җәүһәрия. Әле кем белән сөйләштең?

Зөбәйдә. Бер бик чибәр егет белән, ресторанга барырга булдык.

Җәүһәрия. Шул гына җитмәгән иде, унҗиде яшьтән рестораннарга сөйрәлеп йөрисең генә калган!

Зөбәйдә. Әгәр бер егетнең минем кырыма утырып ризык кабул итәсе килә икән — аның ни гаебе бар?!

Җәүһәрия. Иттерермен әле мин сине! Сөендек киттемени?

Зөбәйдә *(китаплары янына утырып)*. Китсә инде!

Җәүһәрия. Шулай итеп очырырсың әле минә егетне. Икенче андыйны шәм тотып эзләсәң дә таба алмассың.

Зөбәйдә. Табам!

Җәүһәрия. Табарсың, пычагым! Кай җире килмәгән Сөендекнең! Үзе инженер, үзе бай, үзе шундый культурный. Яшькә дә карт түгел.

З ө б ә й д ә. Иллегә җиткән кызлар өчен түгел, билгеле.

Җ ә ү һ ә р и я. Син минем белән авыз чайкама! Яшем кырык сигездә булса да, кайбер яшь кызларга торам әле мин. Әнә Сәмигулла абыең — хатынының кырыгы тулганны күтәреп җиткерә алмый.

Габдрахман белән Булат керә.

Б у л а т. Исәнмесез!

З ө б ә й д ә *(кинәт җанланып алгарак чыга)*. Исәнмесез!

Г а б д р а х м а н. Әйдә, чишен. Плащыңны чөйгә эл. Уз. Таныш бул: менә бу минем сеңел. Бусы — кызым.

З ө б ә й д ә *(кул биреп)*. Зөбәйдә.

Б у л а т. Булат.

З ө б ә й д ә. Очень приятно!

Г а б д р а х м а н. Ашарга бирәр нәрсә бармы, Җәүһәрия?

Җ ә ү һ ә р и я. Пәрәмәч пешерәбез.

Г а б д р а х м а н. Син безгә минем бүлмәгә генә керт. Әйдә, Булат.

Габдрахман белән Булат чыгалар.

З ө б ә й д ә. Симпампони! Нинди кош икән бу?

Җ ә ү һ ә р и я. Я берәр яңа инженер килгәндер. Гостиницада урын юктыр.

Җәүһәрия кухнядан пәрәмәчләр алып керә. Зөбәйдә аның кулыннан тәлинкәне алып, әтисе бүлмәсенә үзе кереп китә. Әйләнеп чыга.

З ө б ә й д ә. Симпампони! Хатыны бармы икән?

Җ ә ү һ ә р и я. Бик яшь күренә ич.

З ө б ә й д ә. Бар әле, берәр сәбәп табып шунда йөр. *(Көзге алдына килеп чәчләрен рәтли башлый.)*

Җ ә ү һ ә р и я *(ишек төбенә килеп)*. Кирәксә тагын китерәм. Яңа пешкәлләре була.

Г а б д р а х м а н *(арттан)*. Китер, китер!

З ө б ә й д ә. Пешкәлләре, пешкәлләре! Ничә ел Казанда яшәп сөйләшә дә белмисең.

Кәримә пәрәмәчләр күтәреп чыга. Җәүһәрия аларны алып Габдрахман бүлмәсенә кереп китә.

З ө б ә й д ә *(Кәримәне ымлап үз янына чакыра).* Төзелешкә яңа инженер килгән. Гостиницада урын булмаган. Симпатичный! Телисеңме, яңа инженерыгызны үземә гашыйк итәм? Ике көндә! *(Чәчләрен төзәтә-төзәтә.)* Синең чәчең матур, Кәримә. Толымнарың гына ямьсез — авыл кызына охшыйсың. Әйдә кисәбез!

К ә р и м ә. Кис үзеңнекен.

З ө б ә й д ә. Минекен кисәсе калмаган ич инде! *(Чәчләрен куперткәләп.)* Ошыймы сиңа минем прическа?

К ә р и м ә. Ярый инде. Алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел.

З ө б ә й д ә. Ә беләсеңме ничек дип атала бу прическа? «Йөгереп кил дә суырып үп» дип атала. Әйдә, карыйк әле тегене. *(Кәримәне ияртеп этисе бүлмәсе янына килә, ярыктан карый. Аннары ярыкка Кәримәнең борынын төртә.)* Матур бит?

К ә р и м ә *(кинәт читкә йөгерә. Дулкынланып).* Булат ич ул!

З ө б ә й д ә. Син аны беләсеңмени?

К ә р и м ә. Камалов Булат ич ул. Бездә шофер булып эшли.

З ө б ә й д ә *(күңеле төшеп).* Точно?

К ә р и м ә. Үзебезнең эшчеләрне беләм ич инде мин. Бездә шофер булып эшли. Самосвалда.

Ф ә р и т керә.

З ө б ә й д ә. Теге егет килде. Шофер гына.

Ф ә р и т. Ну и что же!

З ө б ә й д ә. Нигә борыныңны салындырып кайттың? Әллә капка төбеннән үк борып җибәрдеме?

Ф ә р и т. Ашарга бармы? *(Кухняга чыга.)*

Җ ә ү һ ә р и я керә.

Җ ә ү һ ә р и я. Егетне кичә генә комсомолдан чыгарганнар.

К ә р и м ә. Комсомолдан?

З ө б ә й д ә. О, оригинально!

Габдрахман белән Булатның керүен күреп, Җәүһәрия белән Кәримә тиз-тиз кухняга чыгалар. Зөбәйдә өстәл астына кача. Г а б д р а х м а н белән Б у л а т керә.

Б у л а т. Калсам, сезнең хакка гына калдым инде, Габдрахман абый.

Габдрахман. Кабатлап әйтәм, тормышынның ул ягында минем эшем юк. В конце концов, сиңа инде егерме өч яшь. Мин бит үзем дә ир кеше. Минем дә булды яшь чагым...

Булат. Менә бит, сез дә ышанмыйсыз.

Габдрахман. Ярый, ярый, ышанам. Әмма эштән китәм дигән уеңны бүген үк башыңнан чыгарып ташла. Беркая да китмисең. Мин сине үзем — төзелеш идарәсе начальнигы — җибәрмим. Ә комсомолларның сүзенә карама син. Әлегә бездә торырсың — безнең өй иркен. Аннары комендант белән сөйләшеп, ничек тә булса үзеңне общежитиегә төртермен.

Булат. Әмма хәйләкәр дә хатын икән, Габдрахман абый! Квартир тапкач, мин аннан үзем дә китә идем инде. Югыйсә, килә дә, шаярган булып, минем янга ята. Килә дә, шаярган булып, минем янга ята.

Габдрахман (*кызыксынып*). Шаярган буламыни?

Булат. Әйе! Аякларым тунды, җылыт әле дигән була. Аптырап беттем. Стенага таба борылам да ятам.

Габдрахман (*көлеп*). Стенага таба борылып ятам диген, ә?

Булат. Ә нигә? Үзегез нишләр идегез минем урында?

Габдрахман (*хәйләкәр елмаеп бармак яный*). Син эшләгәнне үк эшләр идем, наян!

Булат. Димәк, һаман ышанмыйсыз!

Габдрахман. Ярый, ярый. Минем алда акланып маташма. Кайвакыт үземдә дә була. Ун ел инде минем хатын үлгәнгә.

Булат. Ә нишләп өйләнмәдегез, Габдрахман абый? Үлгән хатынызга хөрмәт йөзеннәнме?

Габдрахман. Анысы да юк түгел, әлбәттә. Аннары, үзең уйлап кара: минем яшьтәге кешене яратып килүче буламы? Миңа килсә,— шул, тәрбиячесе булмаган яисә балаларыннан уңмаган тол хатын килә. Тамагын туйдыру өчен. Ул бит инде, «Тукта, бу картны тәрбиялим әле», дип килми, үз нужасын нужаларга килә. Аны ашатып ятканчы, мин лучше елына бер курортка барып кайтам.

Җәүһәрия керә.

Ну, мин кушканны эшләдегезме? Күрсәт егеткә булмәне! *(Җәүһәрия Булатны ияртеп чыгып китә. Габдрахман юл өстендә торган урындыкны өстәл астына этәреп куймакчы була, ләкин анда нәрсәдер барлыгын тоеп җәймәне күтәреп карый. Зөбәйдәне күрә.)* А, бу кадәр сабырсызлыгың белән ничек син әниеңнең карынында тугыз ай түзеп утырдың икән?

Зөбәйдә *(йөзе агарынган, өстәл астыннан чыга)*. Кем ул?

Габдрахман. Безнең төзелештә эшләүче бер шофер. Квартир хозяйкасы өеннән куып чыгарган.

Зөбәйдә. Ни өчен куып чыгарган?

Габдрахман. Тыныша алмаганнар. Була бит кайчак шулай.

Зөбәйдә. Гаеп кемдә?

Габдрахман. Хозяйкасында, әлбәттә!

Зөбәйдә. Һы! Гаеп — хозяйкада, ә егетне комсомолдан чыгарганнар. Оригинально!

Габдрахман. Ярый, күп теленә салынма. Кешене урамда калдырып булмый.

Җәүһәрия керә.

Зөбәйдә. Ни өчен комсомолдан чыгарганнар аны?

Габдрахман. Ну, була бит кайчак шулай. Комсомоллар кызу халык. Төпченеп тормаганнар.

Җәүһәрия. Хуҗа хатыны белән чуалгандыр әле.

Габдрахман. Тсс!

Җәүһәрия. Шундый азган-тузган кешене өйгә алып кайттыңмы, абый? Кияүгә чыкмаган сеңелең, буйга җиткән кызың янына?

Габдрахман. Ул сезне ашамас. Бер-ике атнага түзәрсез.

Зөбәйдә. Түзмим! Андый кеше белән бер өйдә яшәргә теләмим!

Габдрахман. Зөбәйдә, син бала түгел! Егетнең критический момент. Ул эштән чыгарга җыенган иде. Мин аны үзем җибәрмәдем. Ул минем иң намуслы шоферым. Югыйсә, бездә беләсеңме нинди шоферлар да бар? Эшкә керә, без биш катлы йортны салып өлгермибез, ә ул үзенә Әмәт тавында биш почмаклы йорт салып керә. Гомумән, хәзер шофер табу җиңел түгел. Ә эшнең кызу чагы...

Мәрвәр керә.

Мәрвәр *(еламсырап)*. Иптәш начальник, мин сездән ялынып сорыйм. Кая куйдыгыз минем иремне?

Габдрахман. Мин сезгә конторада чакта ук әйттем, иптәш Сафина. Мин бүген Булатны күрмәдем.

Кәримә, соңрак Фәрит керә.

Зөбәйдә. Начальник!

Мәрвәр. Ә миңа проходнойда башкача әйттеләр. Сезнең Булат белән киткәнегезне күреп калганнар. Кая куйдыгыз сез аны? Нигә сез, зур кеше була торып, бәхетсезлеккә дучар булган кыз баладан көләсез... Менә бит, плащы да биредә.

Зөбәйдә *(кулы белән күрсәтеп)*. Ул әнә теге бүлмәдә!

Мәрвәр *(Зөбәйдә күрсәткән бүлмәгә таба китә. Ишектә Булат күренә)*. Син мондамыни, бәгырь кисәгем? Нинди дулкынландыргыч очрашу! Газиз балаңны ташлап йөрисең, оятсыз, җир бит!

Булат. Бала минеке түгел! Синең моңа бернинди дәлилең юк!

Мәрвәр. Баланың синеке икәнлегенә шаһит юк дисең инде, ә? *(Башкаларга.)* Әйтегез, зинһар, андый эшнең шаһитлар күз алдында булуын кайсыгызның ишеткәне бар?!

Булат. Габдрахман абый!..

Мәрвәр. Габдрахман абыеңның безгә кирәге юк. Әйдә! *(Булатның кулыннан тарта.)*

Булат *(Мәрвәрнең кулын этәреп)*. Кит әле!

Мәрвәр. Әле син шулай хатын-кызга кул да күтәрә беләсенмени? Унбиш тәүлеккә утырмага барасың киләме, вак-төяк хулиган! Әнә анда кызыл билле машиналар йөреп кенә тора.

Фәрит *(Мәрвәргә)*. Туктале! Сиңа ничә яшь? Утыз биш? Кырык биш? Ә бу егеткә күп булса егерме. Ул — пацан. Ничек ул сине алдасын?

Мәрвәр *(мескенләнеп)*. Алданасың икән шул, җаныкам. Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска дип белмичә әйтмәгәннәр. Без хатын-кызлар ирләрнең иркәләпсыйпап әйткән сүзләренә ышанабыз. *(Мөлаемлык һәм кыланчыклык белән.)* Ә сез, мәхәббәтсезләр, сыйпаганда әйткән сүзләрегезне соңыннан онытасыз.

Булат. Алдаша ул, абый! Безнең арада андый эш булганы юк. Мин квартирант булып кына тордым.

Мәрвәр. Ялганлама, имансыз! Квартирант булып кына тормадың.

Фәрит (*Мәрвәрнең каршысына басып ишеккә ымлый*). Кит шуннан!

Мәрвәр. Күр әле!

Фәрит. Кит шуннан!

Зөбәйдә (*зур канәгатьләнү белән*). Ха-ха!

Мәрвәр. Нәрсә ха-ха? (*Габдрахманга.*) Әле сезнең үз кызыгызга кияү кирәк булдымыни? Шуның өчен минем иремне тартып аласызмы?

Зөбәйдә. Нахалка!

Булат. Ялган!

Җәүһәрия. Абый, нишләп милиция чакырмыйсың?

Фәрит. Да, ыргытырга аны баскычтан! (*Мәрвәргә таба килә.*)

Мәрвәр. Ыргытмый гына тор әле — ыргытучы кушарлар! (*Булатка.*) Ну мин сиңа күрсәтермен әле, алла теләсә!

Фәрит. Бар, бар! Күрсәтәсе нәрсәңне син инде аңа күптән күрсәткәнсең.

Мәрвәр (*Зөбәйдәгә*). Егетнең бит бирнәсе бар! Китереп ташлыйммы бирнәсен?

Зөбәйдә. Ташла!

Мәрвәр (*Булатка*). Билләһи, китереп ташлыйм балаңны! (*Җилтерәп чыгып китә.*)

Фәрит. Что за авантюристка! Тапкансың, парень, бәйләнер хатын! (*Чыга.*)

Булат. Минем гаебем юк, абый! Ул яла яга! Оятсыз хатын ул!

Габдрахман (*утыра*). Ух! Тәкатьне алды, ниһаять, бу хатын. Күренеп тора — ярты юлда туктап кала торганнардан түгел. Иртәгә трестка барып җитәчәк. Берсекөнгә — аннан да югарыга. Ух, туйдым бу эштән. Берсе шешә белән дус. Икенчесе — хатыннар белән... Ә шуларның барысы өчен син җавап бирәсең... Туйдым! Җае гына чыксын, тынычрак урынга күчәм.

Зөбәйдә. Ә син кайда тыныч урын барын беләсеңме?

Габдрахман. Кайда?

Зөбәйдә. Бөек Британиядә. Королева Елизавета посты!

Габдрахман. И тилчә тел! (*Бүлмәсенә чыга.*)

З ө б ә й д ә *(тәрәзәдән карап)*. Нишләп йөрисез анда сарай түбәсендә, ә? Егылып төшсәгез, ботыгызны бәреп сындырам бит! Төшегез! Төшегез дим хәзер үк! *(Чыга.)*

Б у л а т *(бер читтә аптырап басып торган Кәримәне күреп)*. Кәримә?! Син... син ничек монда?

К ә р и м ә. Мин үземнең туганнарымда.

Б у л а т. Син күптәнме монда?

К ә р и м ә. Һәрхәлдә, синең хатының килеп кергәндә, мин монда идем инде! *(Тиз-тиз чыгып йөгерә.)*

Б у л а т *(тәмам югалып Кәримә артыннан бара)*. Ялганлый ул, Кәримә! Мин сиңа сөйләрмен! Мин сиңа аңлатырмын!.. *(Кәримә артыннан чыга. Зөбәйдә керә.)*

Ә с х ә т керә.

Ә с х ә т *(Зөбәйдәнең китап-дәфтәрләрен җыюын күреп)*. Кая барасың? Нигә өйрәнмисең?

З ө б ә й д ә. Әй, кылый күз коткарыр әле!

Ә с х ә т. Кем ул кылый күз?

З ө б ә й д ә. Анда университетта математиканы бер кылый күзле доцент кабул итә. Беләсеңме, матур кызларга белмәсә дә бишле куя икән. Ничек синеңчә, матурмы мин?

Ә с х ә т *(оялып башын читкә бора. Тәрәзәгә карап)*. Самолет...

З ө б ә й д ә. Нәрсә?

Ә с х ә т. Самолет оча, реактивный...

З ө б ә й д ә китапларын күтәреп чыгып китә. Аның артыннан Ә с х ә т чыга. Г а б д р а х м а н белән Ф ә р и т керә. Бераздан тәмам аптыраган Б у л а т керә.

Б у л а т. Инде нишләргә, Габдрахман абый? Әгәр ул баласын да китереп ташласа?

Ф ә р и т. Илтәсең дә милициягә бирәсең! *(Чыга.)*

Г а б д р а х м а н. Әйе!

Б у л а т. Алай жәл була бит инде ул, Габдрахман абый...

Г а б д р а х м а н. Жәл була? Димәк, бала синеке?

Б у л а т. Кояштыр менә, минеке түгел! Шулай булса да жәл. Гөнаһсыз сабый бит ул! Нарасый!.. Өстәвенә, мин аны ярата да идем. Көлә дә башлаган иде инде ул.

Г а б д р а х м а н. Беләсеңме нәрсә, энем. Син күзгә төтен җибәрмә! Болай булгач, хатының да үзеңнеке,

балаң да үзеңнеке! *(Кул селтәп чыгып китә. Булат ялгыз кала.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук бара. Искереп беткән коляска янында Җәүһәрия утыра. Бала елый.

Җәүһәрия *(колясканы селеккәләп)*. Я инде, бераз йоклап ал, ичмаса, бетәшәсе нәрсә!..

Габдрахман керә.

Габдрахман. Ашарга әзерме?

Җәүһәрия. Кайдан әзер булсын! Иртәдән бирле шушы имгәк янында.

Габдрахман. Зөбәйдә арбасымы?

Җәүһәрия. Әйе, сарайдан алып менгән идем лә, селкеп утырырга җайлырак булыр дип. Иртәдән бирле елый. Ашамый да.

Габдрахман *(баланы карап)*. Нигә елыйсың, ә? Ярамый. Егет кешегә елау килешми... Күзләре Булатныкына да охшаган аның үзенең.

Җәүһәрия. Охшамый ни! Үзенеке булмаса, шунда ук илтеп ташлар иде әле.

Габдрахман. Шайтан белә бит! Миңа калса, егеттә гаеп юк. Бөтен хикмәт хатында монда — ул нәрсәнедер болгата.

Әсхәт керә.

Әсхәт. Исәнмесез! Зөбәйдә кайтмадымы әле?

Җәүһәрия. Күрмәдем... *(Әсхәтнең чыкмый торуын күреп, тупас итеп.)* Әйтәм ләбаса сиңа, күренмәде! Кайтканы юк Зөбәйдәнең. *(Әсхәт чыга.)* Бүген августның икесе. Берсекөнгә без загска барабыз, мин китәм. Табыгыз урын балагызга. Таптылар бер опанный нәнке!

Габдрахман. Кызык син, Җәүһәрия. Кирәге булмаса, әллә мин аны өемә китереп тотар идемме? Дөнья бит бу — ата казга да сәлам бирергә туры килә кайва-

кыт. *(Өй эченә күрсәтеп.)* Шуның аркасында бит инде бу тормыш шулай булган. Менә бу йөз сиксән кваргиралы йортны ай азагында тапшырсак — димәк, тагын премия. Расход чыга бит. Синең дә туеңны үткәрәсе бар.

Җ ә ү һ ә р и я. Ун ел асрау булып торган сеңелең турында авыз күтәреп расход дип сөйләргә оялмыйсыңмы син, абый?

Г а б д р а х м а н. Сүз уңаенда гына әйтүем. Димәк, загска барасыз. Бәлки, бераз кичектерерсез, баланы урнаштырганчы сабыр итәрсез?

Җ ә ү һ ә р и я. Мин бик күп сабыр иттем инде — кырык сигезне тутырдым. Көне түгел, сәгате дә кадерле.

Г а б д р а х м а н. Милициягә илтеп тапшырырга күндерсәң дә мәшәкате күп бит әле аның. Артыннан йөрергә, Булатны эштән җибәрергә кирәк. Җиңел генә булса — аны...

Җ ә ү һ ә р и я. Ә миңа җиңел! Бик җиңел миңа! Иртәдән чыгып киттегез дә, теләсәң нишлә, Җәүһәрия!

С ә р и я керә.

С ә р и я. Мөмкинме? Исәнмесез! Фәрит өйдә юкмы?

Җ ә ү һ ә р и я. Юк!

С ә р и я. Кайчан гына өйдә була соң ул?

Җ ә ү һ ә р и я. Булмый ул өйдә, булмый! Кыяфәтеңне аздырып, егетләр куып йөрмә.

Г а б д р а х м а н. Сез кем?

С ә р и я. Ә сез, абый, кем буласыз?

Г а б д р а х м а н. Мин Фәритнең этисе.

С ә р и я. Ә мин Сәрия, Буа кызы. Сезнең киленегез булам.

Җ ә ү һ ә р и я. Күрдеңме бу елдагы кызларны!

Г а б д р а х м а н. Ничек була соң инде бу? Минем ишеткәнем юк иде әле. Узыгыз, утырыгыз. Сөйләгез.

С ә р и я. Рәхмәт. *(Утыра.)* Фәрит бездә еш була бит ул. Әле яз көне генә ике ай командировкада булып китте. Безнең районның бер колхозы яңа сорт бодай үстерә. Фәрит шул турыда диссертация яза. Хәер, анысын үзегез дә беләсез булыр инде...

Г а б д р а х м а н. Анысын беләбез. Ә менә киленебез барлыгын беренче тапкыр ишетәм. Сез нәрсә, Фәрит белән загста да булдыгызмы?

С ә р и я. И, абый җаным, яратуың чын булгач, загс-

ка барып язылу формальность кына бит ул!.. Ә шулай да, ул китқәч шактый борчылган идем.

Габдрахман. Соң?

Сәрия. Хәзер тынычландым инде. Бик җылы хатлар язып торды ул миңа.

Җәүһәрия. Шаярып Зөбәйдә язган хатлар ич ул, җүләр кыз! Мәзәк итеп язган хатлар!

Габдрахман. Ничек, мәзәк итеп язган хатлар?

Җәүһәрия. Фәрит үзе язмагач, Зөбәйдә язган. Абыйсы булып.

Габдрахман. Нәрсә дип язган?

Җәүһәрия. Шаярып язган инде, нәрсә дип язса да.

Габдрахман *(Сәриягә)*. Ул хатлар сездәме?

Сәрия *(оялып)*. Соң бит, абый...

Габдрахман. Мин хатын укымам. Сез миңа аның кулын гына күрсәтегез. *(Сәрия сумкасыннан конверт чыгарып күрсәтә.)* Монда күп нәрсә аңлашылып җитми, кызым. Фәритнең үзен күреп сөйләшү кирәк.

Сәрия. Өйдә туры килми бит! Әгәр институтына барсам?

Габдрахман *(сагаеп)*. Юк, институтта юктыр ул Фәрит. Син анда барып йөрмә. Мондый нәрсәләрне өйдә сөйләшү яхшы! Фәрит командировкага китәм дигән иде ул. Казанда юк Фәрит. Берничә көннән кайтыр. Килерсең. Сөйләшербез. Ә институтка барма, анда юк ул. Сау булып тор бүгенгә! *(Кул суза.)*

Сәрия. Сау булыгыз. *(Чыга.)*

Җәүһәрия Син нәрсә—акылыңдамы?

Габдрахман. Кычкырма әле! *(Папирос каба, ачу белән шырпы сыза)*. Ух, оятсыз! Өйләндерәм! Кыйнап булса да өйләндерәм!

Җәүһәрия. Тәкъдире җиткәч, кыйнамасаң да өйләнер.

Габдрахман. Утыз көн уразаның бер гаете булырга тиеш ләбаса, ниһаять! Күпме сайларга мөмкин!

Җәүһәрия. Гомер итәсе кешене сайлыйсың шул аны!

Габдрахман. Син өйрәтәсеңмени әле аны сайларга? Егетләр сайлый-сайлый кырык сигезгә хәтле утырдың инде, авылның беренче кызы. Юк, әгәр яхшылык белән өйләнмәсә...

Җәүһәрия. Кыз үзе гаепле монда. Сарылмасын иде!

Габдрахман. Аның яшендәге кыз бала, яраткач, уйлап торамыни!

Җәүһәрия. Акыллысы уйлый! Минем дә булды яшь чагым...

Габдрахман. Һәй, син дә сөйләшәсең ичмаса...

Җәүһәрия. Нигә сөйләшмим! Кәрим Сафасын ни яратып йөрдем! Сугышка китәсе кичне үлеп ялынды. Истәлек өчен бер генә үбим лә, диде. Үптермәдем!

Габдрахман. Үлем эченә китүче кешедән шуны да кызгангансың!

Җәүһәрия. Ник кызганмыйм! Ул шуннан башлана.

Габдрахман. Шуңа җимешсез агач шикелле утырып калдың да инде син. Кипкән ботак! *(Ишеккә бара.)* Ярты сәгатьтән мин өйдә булам. Фәрит кайтса, чыгып китмәсен! *(Чыга.)*

Җәүһәрия ялгыз. Трельяж тартмасыннан таушалып беткән өчпочмаклы хат ала, утырып укый. Укып бетергәч, хатны көзге өстенә куя, көзгегә карап уйга чума. Битендәге җыерчыкларны сыпырып ала. Мәрвәр керә.

Мәрвәр. Исәннәрме сез! Ни эш бетереп ятасыз? *(Каранып.)* Өйдә үзегез генәме? Минем юньсез кайда?

Җәүһәрия. Эштәдер.

Мәрвәр. Ничек соң, җаныкам, нәрсәләр сөйли? Өйгә кайтырга исәбе бармы?

Җәүһәрия. Аның исәбен мин кайдан белим!

Мәрвәр. Соң, җаныкам, сөйләшәсез булыр бит инде. Кичә мин чыгып киткәч ниләр булды?

Җәүһәрия. Берни дә булмады. Бала карап утырды — шул булды. Без аңа баланы милициягә илтеп тапшырырга кушкан идек. Илтмәде — жәл, ди.

Мәрвәр. Ээ, жәл булмый ни, җаныкам, жәл шул. Газиз бала бит ул! Шуннан, җаныкам, шуннан?

Җәүһәрия. Менә мин багып утырам хәзер. Бүген елый да елый. Әллә авырый инде.

Мәрвәр. Шуннан, җаныкам, шуннан. Начальнигы ни ди соң? Бала аныкы дип әйтеп әйтеп әйтәме?

Җәүһәрия. Юк. Бала Булатныкы булырга тиеш түгел, ди.

Мәрвәр. Ничек түгел ди?! Кеше күңеленә коткы салып йөрсә, мин аның белән сөйләшә белермен! *(Коляска янына килә.)* И, ничек ята бәгырь кисәгем! Өсте-

нә рәтләп ябу юк, астына яхшылап җәю юк. Шулай кадерсез яткач, авырмый нишләсен бала! *(Баланың урынын рәтли. Култык астына китап-дәфтәрләр кыстырган Зөбәйдә керә.)* И, харап кына иткәннәр бәбәкәчемне. Башы мунча ташы кебек! Җары бар! Чакырдыгызмы врач?

Җәүһәрия. Кайдан чакырыйк әле!

Мәрвәр. Үзе юкның күзе юк, бетмәс әле дисезмени? Танырлык җирен дә калдырмаганнар балакаемның.

Җәүһәрия. Алай бик кадерле бала булгач, китереп ыргытмаслар.

Мәрвәр. Ыргытсам, үзенең әтисенә ыргыттым. Ә сез аңа салкын тидергәнсез. Шуннан үлеп китсә бала?

Җәүһәрия. Беркемгә дә кирәге булмаган баланың үлүе дә хәерле.

Мәрвәр. Эһе! Әле сез аңа юри салкын тидердегезмени? Үлсен дип? Бик җиңел котылырга уйлаган. Күрсәтермен мин аңа күрмәгәнен! Кеше үтерүчеләр өчен закон бар хәзер! *(Тәрәзә янына килә. Анда басып торган Зөбәйдәне бер кырыйга төртеп, тәрәзәне яба.)* Ирем үземә кала дип торма. Үтерешкә катнашучыларга да закон бар, чувиха!

Зөбәйдә. Нахалка! *(Мәрвәрнең битенә китап ыргыта.)*

Җәүһәрия. *(Мәрвәрне ишеккә таба төрткәләп).* Син нәрсә — сугышырга килдеңме? Бар әле чыгып кит моннан!

Мәрвәр. Әле сез шулаймыни? Баламны гына түгел, үземне дә җир йөзеннән юк итмәкче буласызмы?

Җәүһәрия. Алып кит балаңны!

Мәрвәр. Китмим!

Җәүһәрия. Алайса күземнән югал! *(Як-ягына каранып, нәрсә белән кундырыйм икән, дигәндәй.)* Китәсеңме, юкмы башың исән чакта?

Мәрвәр. Яхшы! *(Зөбәйдәгә.)* Мин сине нишләтергә кирәген беләм. Комсомолдырсың әле син. Кайда укыганыңны эзләп табармын мин синең!.. Чыгып китмәгез — хәзер врач чакырам. *(Чыга.)*

Җәүһәрия. Күр әле оятсызны! Монда килеп, болай да кызган канга тоз салып йөри... *(Зөбәйдәнең идәндә тузып яткан китапларын типкәләп.)* Җый бу

китапларынны! *(Зөбәйдә кычкырып елап җибәрә.)* Нәрсә булды тагын?

Зөбәйдә *(үксеп)*. Провалить иттем!.. Шундый яхшы сөйләдем, шундый яхшы сөйләдем! Барыбер икеле куйды кылый!

Җәүһәрия. Әйбәт булган — эченә таман. Икенче яхшырак өйрәнерсең... Үкермә, болай да башым авырта!.. *(Пауза.)* Теге нәмәрсә тагын килгән иде. Кечәге кызны әйтәм. Абый өйдә туры килде. Исе дә китми, мин сезнең киленегез дип шартлатып тора. Синең хатларынны да күрде этиең. Фәритне кыйнап өйләндерәм, дип чыгып китте... Фәритне яклаган өчен эләкте миңа. *(Үксеп.)* Аны син өйләндермисең, җимеш бирмичә корыган агач син, ди...

Зөбәйдә. Дөрес әйткән!

Җәүһәрия. Корымый гына торсын әле! Җимеш бирәсе көннәрем алда әле минем. *(Көзгедән карап.)* Бал ачымый, кыз картаймый, дигәннәр. Бер ак чәчем юк әле минем! *(Бала ыңгыраша. Җәүһәрия бала янына килә.)* Сөтен дә эчми бу имгәк, әллә тамагы авырта инде. Кил әле, тамагын карыйк!

Зөбәйдә. Кара үзең!

Җәүһәрия. Я, кил инде! Мәктәптә медсестралыкка укыттылар лабаса үзегезне.

Зөбәйдә *(тәрәзә төбенә менеп утыра)*. Аптыратма диләр сиңа! Үземнең дә башым бишкә ярыла — сабыйлыгым белән генә йөрим.

Җәүһәрия. Зөбәйдә, дим! Я, кил инде!

Зөбәйдә *(коляска янына килә, үксеп, күз яшьләрен сөртә-сөртә)*.

Елама, балам, елама,
Җылы катык сорама.
Җылы катык мичтә,
Әниең кайтыр кичкә.

(Кашык алып килеп.) Яле, тамагынны карыйк әле, елак малай. *(Баланың тамагын карап.)* Ангина булган бит моңа!

Җәүһәрия. Әйтәм җирле елый да елый.

Зөбәйдә. Менә дигән фолликуляр ангина. Пенициллин бир! *(Балага карап тора, мендәрен төзәтеп куя. Җәүһәрия күрше бүлмәгә чыга. Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы ала.)* Ә, Булат икән. Нияз авырый

әле, Булат, ангина булган. Юк, куркыныч түгел, пенициллин эчкәч бетә. Булат! Теге хатын килгән иде... Ну, Ниязның әнисе. Без аны кыйнап чыгардык. Честное комсомольское!.. Шоколад? Ярый. *(Трубканы куя. Фәрит керә.)* Сезне тәбрикләргә рөхсәт итегез, сударь! Өйләнәсез икән.

Ф ә р и т. Что за глупость!

З ө б ә й д ә. Сәрия тагын килгән. Начальник барысын да белә.

Ф ә р и т. Вот нахалка! *(Оекбашын салып Зөбәйдәгә бирә.)* Мәле, шуны эләктереп бир әле.

З ө б ә й д ә. Тиздән хатының була, яматырсың.

Ф ә р и т. Не ослоумничай!

З ө б ә й д ә *(энә-җеп алып оекбаш ямарга керешә)*. Оекбаш ямаудан котылам инде, алла теләсә! Күлмәкләреңне дә хатының уар. Без уганны яратмый идең. Хәләл җефетегез бик яхшы уар инде!

Ф ә р и т. Перестань пилить!

З ө б ә й д ә. Ха, өйрәнә тор! Әле болай гына пилить итмәс. Килен кила, килен кила, кисап буе теле кила... Ә мин имтиханны провалить иттем.

Ф ә р и т. Молодец!

З ө б ә й д ә. Молодец шул.

Ф ә р и т. Әйттем мин сиңа университетка бирмә дип! Анда конкурс зур. Безнең сельхозга бирсәң — ике экзаменыңа бишлене үзем куйдыртып чыгара идем.

З ө б ә й д ә. Ә мин анда теләмим. Теләмим авылга китәргә!

Ф ә р и т. Укып бетергәч, китмәскә дә була.

З ө б ә й д ә. Барыбер теләмим!

Ф ә р и т. Ну и җүләр!

З ө б ә й д ә. Җүләр икәнлегемне мин синнән башка да беләм. Берәр яңа нәрсә әйт син. *(Ачу белән оекбашны Фәриткә ташлый.)*

Җ ә у һ ә р и я керә.

Җ ә у һ ә р и я. Бөтен дөньяны актардым — бер генә таблетка пенициллин таптым. Мә, бир, сөтенә издем. *(Фәритне күреп.)* Абый сиңа чыгып китмәскә кушты. Ул сине теге нәмәрсәгә өйләндерәм ди. *(Чыга.)*

Ф ә р и т. Нәрсә?

Г а б д р а х м а н керә.

Габдрахман. Кайттыңмы син? Монда бер кыз булды. Исемен оныттым. Син аны беләсеңдер.

Фәрит. Бөтен ыргыткан кызларның исемен белеп бетермәссең.

Габдрахман. Ыргыткан! Ташлаган дип әйтә белсәң иде, ичмасам. Ыргыткан! Әйдәле теге бүлмәгә! *(Фәритне ияртеп үз бүлмәсенә китә башлый.)*

Зөбәйдә Начальник! Сезнең кызыгыз бүген имтихан бирергә тиеш иде. Нишләп кызыксынмыйсыз?

Габдрахман Бирдеңме соң?

Зөбәйдә. Икелегә... бирдем.

Габдрахман. Алайса ник авызыңны җәйдең?

Зөбәйдә. Елыйммы әллә?

Габдрахман. Еласаң да урынлы...

Зөбәйдә. Елап тормыйм әле!

Габдрахман *(Фәриткә)*. Әйдә! *(Фәритне бүлмәсенә кертеп ишекне яба башлый.)*

Зөбәйдә. Начальник! Мин укымаска булдым.

Габдрахман Укыма! Әнә безгә балчык изеп торучылар кирәк. Барып керерсең.

Зөбәйдә. Хәзер, чаптым!

Габдрахман. Чапмасаң, алтмышка җиткән башым белән мин сине ашатып ятмам.

Зөбәйдә. Ашатма!

Габдрахман. Ашатмам шул!

Зөбәйдә. Моңа кадәр ашатмаска да мөмкин иде бит. Хәтта мине тудырмаска да мөмкин иде. Мин бит сиңа: «Начальник, мине дөньяга китерегез әле!» — дип үтенеч язмадым.

Габдрахман. Булыр-булмас кешегә дилбегә буе тел бирер, дигәннәр. Шушыдыр инде ул. Кара аны, мин сине тунеядец итеп асрап ятмам!

Зөбәйдә. Курыкма, синекен ашамам. Кияүгә чыгам.

Габдрахман. Бар, бүген үк чык! *(Фәрит белән бүлмәсенә кереп бикләнә.)*

Зөбәйдә ялгыз. Колясада бала елый. Зөбәйдә, колясканы кочаклаган хәлдә, тавышсыз гына елый-елый, бала тирбәтә.

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия. Ни булды тагын?

Зөбәйдә *(кычкырып елап җибәрә)*. Мин сине ашатам! Мин сине киендерәм!.. Әйтерсең мин үзем теләп тудым...

Җәүһәрия. Юк өчен авызыңны җәеп утырма! Күрмисеңмени, әтиеңнең кәефе начар вакыт.

Зөбәйдә *(әрнү белән)*. Ә минеке яхшы!.. Кызы имтихан бирә алмыйча кайткан. Әти булган кеше бер кеше төсле итеп сөйләшергә тиешме, юкмы, синеңчә?!.

Кәримә керә.

Кәримә. Исәнмесез!

Җәүһәрия. Әйдә уз, Кәримә, ни эш бетереп йөрисең?

Кәримә. Бетергән эш юк. Менә Зөбәйдәне туган көнемә чакырырга килдем. *(Баланы ачып карый.)* Хи-хи-хи! Ничек матур итеп йоклап киткән!

Зөбәйдә. Кагылма балага, авырый ул!

Җәүһәрия. Һай, сиңа да унсигез тулды, Кәримә!

Кәримә. Бер тугач, үсәсең икән шул. Иртәгә сәгать җидедә, Зөбәйдә, яме!

Зөбәйдә. Мин бармыйм, эшем бар.

Кәримә. Нишлисең?

Зөбәйдә. Дуңгыз дагалыйм!

Кәримә. Шулай инде. Без бит сезнең шикелле булачак доцентлар да булачак инженерлар түгел...

Зөбәйдә *(аяныч белән)*. Кәримә!

Җәүһәрия. Бүген кәефе юк аның. Иртәгә хәтле кырык төрле булыр әле, барыр. *(Чыга.)*

Кәримә. Чит кеше берәү дә булмый. Үзебезнең төзелештән берничә кыз гына. *(Баланың башын тотып.)* Бичаракайның башы ут кебек... *(Габдрахман бүлмәсендә нәрсәдер гөрселдәгән тавыш ишетелә.)* Нишлиләр анда?

Зөбәйдә. Начальник үзенең улын өйләндерә.

Әтисе бүлмәсеннән Фәрит атылып чыга.

Габдрахман *(ишектә)*. Кая барасың?

Фәрит. Мин сиңа мальчишка түгел, отчет бирергә.

Габдрахман. Кара нинди зур кеше булган, оятсыз! Әмма мин сине авызлыкларга юл табармын!.. Әгәр шуннан бала булса?

Фәрит. Мало-ли кайларда синең белән минем балалар үсә! Бөтенесенә дә ата була башласаң... *(Габдрахман көч белән Фәритнең яңагына суга.)* Нәрсә, дөрес сүз күзне кадыймы? Әйтерсең, синеке булмады яшь вакыт?

Габдрахман. Синеке төслесе — юк!

Фәрит. Хәзер, ышандылар ди! Әни өчәр ай больницада авырып ятканда, әйтерсең син гулять итмәдең? Тетя Паша белән! Бишәр көн өйгә дә кайтмый идең... И хәзер дә әле син гулять итәсең! Уйлыйсың, мин белмим?

Габдрахман (*тәмам җебеп төшә*). Белсәң, минем арттан өйгә килмиләр.

Фәрит. Еще бы! Син бит карт бүре!

Пауза.

Габдрахман. Җүләр син, улым. Мин синең үз файдаңа әйтәм. Әгәр ул институтка барса, партбюрога керсә! Бөтен карьераңны боза бит ул синең!

Фәрит. Ә син минеке өчен кайгырма. Үзеңне бел!

Фәрит чыга. Габдрахман нишләргә белми бүлмә буйлап йөргәндә Кәримәгә барып төртелә.

Габдрахман. Син монда нишләп торасың, Кәримә?!

Кәримә (*куркып*). Мин... менә Зөбәйдәне туган көнемә чакырырга килдем...

Габдрахман. Барыр, барыр! Аның эше юк хәзер. Кунакка йөрү генә калды.

Зөбәйдә. Бәлки бармам! Нигә минем өчен җавап бирәсең?

Габдрахман (*йомшак тавыш белән*). Кәримә сиңа якын туган. Син аның туган көненә барырга тиеш.

Зөбәйдә. Мин барырга тиеш! Ә Кәримә үзе, гомер эчендә бер генә булса да, минем туган көнемә килергә тиешме?

Габдрахман (*бөтенләй югалып*). Тиеш, әлбәттә. Синекен дә үткәрербез. Кайчан соң әле синең туган көнең?

Зөбәйдә. Белмим! Җүләрлегем аркасында тугач та календарьга каралмаган.

Габдрахман. Ярый, барыр ул, Кәримә. Мин аны җибәрермен.

Зөбәйдә. Ал яңа күлмәк — барам!

Габдрахман. Кияүгә чыгам дисең ләбаса. Кияүең алыр.

Зөбәйдә. Бәлки синең шикелле саран туры килер. Алмас.

Габдрахман (*бармак янап*). Ну синең бу телеңне! Кисеп алам әле бер!

Габдрахман чыга. Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия. Кәримә, үскәнем, ашым соңга калды. Бәрәңге арчыш әле миңа. Син бик оста арчыйсың.

Кәримә. И раббым, бәрәңге арчырга осталык кирәкмени аңа!

Җәүһәрия. Әйдә инде, минем кулым авырта.

Кәримә белән Җәүһәрия кухняга чыгалар. Зөбәйдә ялгыз. Пауза.

Зөбәйдә (*радиола өстендәге курчакны алып тәрәзә төбенә утыра*). Эшләр менә шулай, Ләйлә! Абау, кем буяды синең бу борыныңны! Яле, яле, сөртеп алыйк әле шуны. Менә шулай! Менә тәти булды хәзер Ләйлә. (*Курчакны һавага чөеп.*) Уп-па! Ха-ха-ха! Уп-па!.. (*Колясҡада бала ыңгырашып куя.*) Тсс, Ләйлә, шаулама. Бәби йоклый. Бәбигә бубу булган, тамагы авырта бәбинең. Башы ут кебек булган бәбинең... Апаң имтиханын бирә алмый кайтты шул әле, Ләйлә. Нишләр инде хәзер апаң, ә? Башы да авырта апаның. Тотып кара әле! Кайнармы? Бәбинең дә башы кайнар... Күлмәгең дә керләнгән икән инде синең. Кер уганда әйтерсең, яме! Кызлар чиста булырга, матур булырга тиеш... Ә? Нәрсә, нәрсә? Матур булсаң да икеле куйдылар, дисеңме? Белмәгәч, куялар икән шул, матур дип тормыйлар икән... Нишлибез соң инде хәзер, Ләйлә? (*Курчагын кочаклап.*) Ичмаса, син дә миңа берәр киңәш бирмисең!..

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бер сәгать үткәч.

Зөбәйдә (*телефонга*). Сәлам, Зөфәр, бу — Зөбәйдә. Зөфәр, бер минут торма, безгә кил! Сагындым, күрәсем килә. Килгәч белерсең. Озак торма! (*Трубканы куя. Тәрәзәгә килә.*) Әй, Славик, синең вакытың бармы? Бер йомыш кушсам тыңларсыңмы икән? (*Арттан тавыш:*

«Нәрсә ул?») Миңа магазиннан букет алып кайтып бир әле! Мә акча! *(Ыргыта.)* Беләсеңме, букетны минем сигнал белән кертерсең. Менә курчак. Шушы курчак тәрәзә төбеннән юк булгач та керт. Яме!

Әсхәт керә.

Әсхәт. Я ничек, бирдеңме?

Зөбәйдә Нәрсә ул, Әсхәт? *(Әсхәтнең кулындагы картинкаларны ала.)* О, нинди күп!

Әсхәт. Бирдеңме имтиханыңны?

Зөбәйдә. Браво, Әсхәт! Син миңа ошыйсың.

Әсхәт. Имтиханыңны бирдеңме?

Зөбәйдә *(картинкаларны карап)*. О, нинди матурлары бар!

Әсхәт. Ничәгә бирдең?

Зөбәйдә. Берәү, икәү, өчәү...

Әсхәт. Санап торма. Өч йөз дә җитмеш бер.

Зөбәйдә. Ой, Әсхәтчик, кил шуның өчен бер үбим үзеңне. *(Ике колагыннан тотып Әсхәтнең маңгаеннан үбә.)* Ой, Әсхәтчик, шушы картинкаларны ничек яратуымны белсәң иде син! Дөньяда иң зур куанычым шул. *(Радиола астындагы тумбочкадан бик күп картинкалар чыгара.)* Менә бит нихәтле булды инде! Аларны менә шулай актарып утыруы, санап караулары шундый күңелле! Алар минем тормышымда бер бизәк кебек. Алар белән син минем тормышымны матурлыйсың, Әсхәт...

Әсхәт. Авыр сораулар эләктеме? Ничәгә бирдең?

Зөбәйдә. Әй, аптыратма әле, Әсхәт!.. *(Көзге алдына килеп пудра ягына башлый.)* Кил монда! *(Әсхәт Зөбәйдәгә якынлаша.)* О, чалбар балагын тарайткан! Ничә сантиметр?

Әсхәт. Унсигез.

Зөбәйдә. Таррак. Хәзер иң модный балак егерме сантиметр. Аннан манжет та модада түгел хәзер... Яле, сиңа пудра килешәме икән. *(Әсхәтнең битенә пудра яга.)* Сиңа мыек та чыга башлаган икән инде, Әсхәт... О, нинди матур булдың! *(Көзге өстендә Җәүһәрия онытып калдырган хатны күреп.)* «Икенче сентябрь, 1941 ел». Нәрсә бу? «Туган илләрдә яшәүче язгы таң күбәләгем, күктәге кояш кебек, ай кебек түгәрәгем! Табигать кочагында, кояш нурлары астында, кара урманда, яшел аланда үскән хуш исле гөлләргә тиңләмәслек гүзәл ярым... *(Укуын бүлеп.)*

О, бу бит мәхәббәт хаты, Әсхәт! *(Көлә-көлә укуын дәвам итә.)* ...Челтерәп аккан салкын чишмә буенда, нечкә тал чыбыкларында канат кагынып сайраган сары сандугачлар саныннча булган сагыну сәламнәремне шушы кәгазьгә язып, сезнең якка искән иркә таң җилләре белән синең үзеңә, нурлы йөзеңә, серле күзеңә...» *(Хат укыганда Җәүһәрия керә. Ул азрак тыңлап тора да тиз-тиз килеп хатны тартып ала.)* Укып бетерим инде, туган апам!

Җәүһәрия. Бетерми генә тор әле! Бар әнә, аптекттән пенициллин алып кайт!

Зөбәйдә. Әсхәтчик, уң күзем, чалбар балагың да бик модный икән, чәчләрең дә көдрә — бар, йөгереп пенициллин алып кайт! *(Җәүһәрия Әсхәткә акча бирә. Әсхәт йөгереп чыгып китә.)* Туган апам, укыйм инде шул хатны!

Җәүһәрия. Укымый тор әле! Күпне белсәң тиз картаерсың.

Кәримә керә.

Кәримә. Ярый, мин китәм.

Зөбәйдә Юк әле, юк, китмисең!

Кәримә. Ашыгызны өлгерттем. Бәлки ашатып та китәргәдер?

Зөбәйдә. Юк, чынлап. Хәзер бер кызык эш булачак! *(Куеныннан хат чыгара.)*

Җәүһәрия. Берәрсеннән хат бармы әллә? Кайда, укыйк әле!

Зөбәйдә *(хатны яшереп)*. Укымый гына тор әле! Күпне белсәң, тиз картаерсың. Аннары Сәмигуллаң да яратмас үзеңне.

Булат керә.

Булат. Исәнмесез, кызлар!

Кәримә Исәнмесез!

Булат *(балага якынлашып)*. Хәле бик начар түгелме?

Зөбәйдә. Туена хәтле терeләчәк!

Булат. Врач чакырырга соңдыр инде хәзер...

Зөбәйдә. Мин куйган диагнозга ышанмыйсызмыни?

Булат. Ышанам да...

Зөбәйдә. Беләсегез килсә, мәктәптә безне медсестралыкка өйрәттеләр. Мин бишлегә бирдем.

Булат Алайса, нигә медсестра булып эшләмәдегез?

Зөбәйдә. Яратмадым. Була бит шулай: эше ошамый.

Булат. Ә, минемчә, ул сүзне ялкаулар уйлап чыгарган — үзләрен аклар өчен. Кеше ялкау булмаса, хезмәт сөйсә — минемчә, һәр эштән кызык табарга мөмкин.

Зөбәйдә. Сез шулай уйлыйсызмы?

Булат. Әйе. *(Кесәсеннән ике плитка шоколад чыгарып Кәримә белән Зөбәйдәгә бирә.)*

Зөбәйдә. Мондый игътибарлы булгач, кызлар сезне яраталардыр, Булат.

Булат. Сезне дә егетләр читләтеп үтми бугай.

Зөбәйдә *(бармаклары белән санап)*. Унбер егет аяк очымда.

Булат. О, тиздән дюжина була, димәк!

Зөбәйдә. Ихтимал!

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия *(Булатка)*. Сәгать өч тулгач, балага сөткә керерсең, Булат. *(Зөбәйдәгә.)* Мин Сәмигулла абыенга карлыган җыешырга киттем. *(Чыга.)*

Зөбәйдә. Сез тәнкыйть күтәрәсезме, Булат?

Булат. Тәнкыйтьне яратабыз инде аны.

Зөбәйдә. Нигә шундый киң балаклы чалбар киясез? Нәкъ юбка!

Булат. Чалбарны сез кигәнсез бит! Мина юбка калган. *(Күрше бүлмәгә уза.)*

Зөбәйдә. Серкәсе су күтәрми икән.

Кәримә. Ничек, синеңчә, Зөбәйдә, бу бала чыннан да аңыкымы икән?

Зөбәйдә. Кайгың шул гына булса, Кәримә, өеңә кайт та ят та йокла. Юк белән башыңны катырма.

Булат керә.

Булат. Ул бүлмәнең стеналарын кем обойлаган иде, Зөбәйдә?

Зөбәйдә. Әллә начармы?

Булат. Киресенчә! Кәримә, синең игътибар иткәнең бармы? *(Кызлар бер-берсенә карап елмаешалар.)* Нигә без үзебез салган йортларның квартираларын шулай көлеп тора торган итеп буямыйбыз? Кайсы гына квартирага килеп кермә, күңел болгаткыч соры төс тә көрән төс.

Кәримә. Әйт начальникка, җибәрсен яхшы буяулар.

Булат. Үз кызының бүлмәсен әйбәт буяткан ул.

Зөбәйдә. Беләсегез килсә, ул бүлмәне Кәримә белән без обойладык шул. Начальникның катнашы юк анда. *(Чыга.)*

Булат *(сүз юктан сүз булсын итебрәк)*. Әмин синең Габдрахман абыйның туганы икәнеңне белми идем.

Кәримә. Кайчак шулай да була икән шул. Мин дә бит кайбер нәрсәләрне белми йөргәнмен.

Булат. Димәк, син миңа ышанмыйсың?

Кәримә *(балага ымлап)*. Ул сиңа охшаган.

Булат. Яшь баланың кемгә охшавын белеп буламыни әле аның! Ә ничек, синеңчә, бу бала купмелек?

Кәримә. Дүрт-биш айлыктыр.

Булат. Алтынчы ае. Ә минем ул хатында тора башлавыма бер ел.

Кәримә. Бәлки сез элек таныш булгансыз.

Өстенә матур күлмәк киеп Зөбәйдә керә.

Зөбәйдә. Иртәдән бирле слыйсым килеп йөргән иде, ачуын чыгарыйм әле! *(Булат коляскасы бүлмәсенә алып китә.)*

Кәримә. Матур да инде син, Зөбәйдә! Артисткалар кебек. Нигә мин дә шулай матур булмадым икән!

Зөбәйдә. Ә мин сиңа күптән әйтәм, чәчеңне кисик, дип.

Кәримә. Чәч кисеп кенә матур булсалар иде!.. *(Пауза.)* Зөбәйдә! Кичә син аны икс көндә үземә гашыйк итәм, дигән идең.

Зөбәйдә *(Булат бүлмәсенә ымлап)*. Монымы? Аның миңа нигә кирәге бар!

Кәримә. Уйласаң уелып китәрлек эшләр бар дөньяда! Нишләтә инде ул хәзер бу баланы?

Зөбәйдә. Хафаланма. Өйләнгән төшкә эше кими торыр. Шундый оригиналь калымы булган егеткә чыгучы кыз табылса, әлбәттә.

Кәримә. Мине шундый егет яратса иде әле...

Зөбәйдә. Кәримә! Гашыйк булдыңмы?

Кәримә. Китсәнә, я үзе ишетер!

Зөбәйдә. Телисеңме, үзем яучы булам? *(Звонок.)* Керегез!

Сөендек керә.

Сөендек. Хәерле көн! Сәлам, Зөбәйдә! Сәлам, Кәримә! *(Зөбәйдәгә бер тартма монпансье бирә.)* Нәрсә белән котлыйбыз үзеңне? Отличномы?

Зөбәйдә. Бу монпансье унөч тиен тора. Саран син, Сөендек! Шуңа өйләнә дә алмыйсың.

Сөендек. Син бернәрсәне аңламыйсың, Зөбәйдә. Кайбер егетләр буш өйгә дә хатын алып кайталар. Хәтта кеше почмагына да. Ә мин алай теләмәдем. Мин башта булачак хатыным өчен шартлар тудырдым. Квартира, обстановка, машина һәм, әгәр теләсәң, запас на черный день. Шуларга өстәү итеп саф йөрәгем.

Зөбәйдә. Утызга җиткән саф йөрәгең сөрсеп бетмәдеме икән синең!.. *(Звонок. Зөфәр керә.)* Менә Зөфәр чын кавалер ичмаса. Ул мине унөч тиенлек монпансье китереп мыскылламый. Таныш булыгыз: Сөендек — инженер-конструктор. Бусы — Зөфәр, врачлыкка укый. *(Зөфәр белән Сөендек кул кысышалар.)* Я, Зөфәркәем, эшләр ничек? *(Әсхәт керә.)*

Әсхәт *(Сөендек белән Зөфәргә каш астыннан карап)*. Кая куйыйм пенициллинны?

Зөбәйдә. Алып кайттыңмы, тәтием. Бир монда! *(Әсхәт чыга башлый.)* Кая барасың әле? *(Тәрәзә төбеннән курчакны ала.)*

Әсхәт. Бүрекле белән Күреклегә җим бирәсем бар, чыгам.

Зөбәйдә. Чыкмыйсың, чыкмыйсың! Син миңа кирәк. Утыр! *(Сабырсызланып ишеккә карый.)*

Зөфәр. Бу нәрсә — мәҗлесме соң?

Зөбәйдә. Сабыр ит, Зөфәр, күрерсең. *(Булат керә.)* Ә сез кая барасыз?

Булат. Сәткә.

Зөбәйдә *(Булатның шешәсен тартып ала)*. Әле сәгать өч тулмаган, өлгерерсез... *(Зур букет күтәреп Славик керә.)* О, Славик! *(Каршы килеп Славикның колагына.)* Артык бер сүз әйтмә. *(Кычкырып.)* О, шушындый матур букет миңамы бу? Рәхмәт! Уз әйдә, Славик, утыр! *(Пауза. Бернәрсә аңламаган егетләр бер-берсенә карапалар.)* Ух алла! Әллә ниләр әйтергә теләгән идем — Славикны күргәч, уйларым таралды да китте... Кыскасы, егетләр, бүген мин имтиханны провалить иттем. Университетка керү очты.

Әсхәт *(шаккатып)*. Ничек провалить иттең?!

Зөбәйдә. Аһ, Әсхәт, ничек булуын күрерсең әле,

башың яшь... Менә шулай, егетләр. Сезнең килүегездән файдаланып, мин киңәшмә үткәреп алырга уйлыйм. Киңәшмәне ачык дип белдерәм. Утырышыгыз! Кәримә, син дә утыр!.. Булат, әнә шул үзегез алып кайткан шоколадны китереп бирегезче! *(Булат өстәлдәге шоколадны китереп бирә.)* Көн тәртибендә бер мәсьәлә: Ленинград диңгезчесе Абдуллин Әнәснең хатын уку һәм фикер алышу. Белмәгән кешеләр өчен берничә сүз әйтеп китәм. Абдуллин Әнәс диңгез училищесын тәмамлаган егерме биш яшьлек егет. Хәзерге көндә Ленинградта яши һәм чит илләргә йөрүче зур корабта хезмәт итә. Күптән түгел генә үзен капитанның беренче ярдәмчесе итеп билгеләделәр һәм инде капитан посты да чиртә башлаган. Бүген мин аннан менә шушы хатны алдым. *(Кесәсеннән хат чыгара.)* Башладык, егетләр. Хат уку өчен сүз Әсхәткә бирелә. *(Хатны Әсхәткә биреп тахтага менеп утыра. Шоколад ашый-ашый әле бер, әле икенче егетне күзәтә.)*

Әсхәт *(укый)*. «Кичә Лондоннан кайтып төштем. Лондон зур шәһәр, ләкин диңгезчеләр аны яратмыйлар, чөнки Лондонда һәрвакыт диярлек томан була. Юл шактый мәшәкатьле булды. Лондон порты акваториясеннән чыгып китүгә көчле шквал башланды. Аннары йомшак норд-вест куәтле норд-ост белән алышынды һәм җидесигез баллы шторм кузгалды... Май бәйрәменә өч бүлмәле квартира алдым, Кырым күпере янында...»

Зөфәр. Кырым күпере янында?

Зөбәйдә. Әһе!

Зөфәр. Ләкин Ленинградта андый күпер юк!

Зөбәйдә. Ничек юк?

Зөфәр. Әйе, юк! Мәскәүдә ул Кырым күпере, ә Ленинградта андый күпер юк.

Зөбәйдә ни әйтергә дә белмичә кыбырсынып як-ягына карана.

Сөендек *(Зөбәйдәгә карап серле елмаеп куя да)*. Гафу итегез, Зөфәр, сез Ленинградта күптән булдыгызмы?

Зөфәр. Узган җәй. Быел да барам. Мин Ленинградны яхшы беләм!

Сөендек. Ә сез ишетмәдегезмени — күптән түгел генә Ленинградта яңа күпер суктылар. Һәм аңа Кырым күпере дип исем бирделәр.

З ө ф ә р. Кайсы елгага?

С ө е н д е к. Невага, әлбәттә.

З ө ф әр. Невага? Кайсы җиргә?

С ө е н д е к. Әә... өскәрәк. Өскәрәк!

З ө ф ә р. Бәлки мин ишетмәгәнмен...

З ө б ә й д ә *(ролена кереп)*. И, тормыштан артта каласың да кешегә бәйләнәсең. Бүлдермә! Укы, Әсхәт!

Ә с х ә т *(укый)*. «...Кырым күпере янында. Кухня, кладовой, ванна бүлмәсе һәм... һәм башкалары».

З ө б ә й д ә *(егетләргә чертеж биреп)*. Менә монда квартираның схемасын да ясап җибәргән.

Ә с х ә т *(укый)*. «...Чикләвек агачыннан эшләнгән диван-кровать белән тахта, шундый ук шифоньер, сервант-комбайн һәм дүрт почмаклы өстәл, язу өстәле белән кухня өстәле, унике урындык, бер тирбәлә торган кресло — бусы сиңа, радиола «Фестиваль», холодильник «Орск», кер уа торган машина һәм пылесос алдым. Шушы арада китап стеллажлары белән секретер алырга җыенам. Көзге мәсьәләсе әле хәл ителмәгән. Син ничек уйлыйсың, трюмо алсам яхшы булырмы, әллә трельяжмы? Безнең белән илле яшьлек тутам торачак. (Өй эшләрен эшләр өчен.) Әти белән әни борынгы саксон фарфорыннан аш һәм чәй сервизы, шуңа кушып көмеш прибор бүләк итәчәк. (Егерме дүрт персоналык.) Туйда кәләшкә ас мехыннан тегелгән манто...»

Б у л а т. Нәрсә мехыннан?

З ө б ә й д ә. Ас! Ас — горностай. Ишеткәнегез юкмыни — Николай патшаның шундый бер туны булган.

Ә с х ә т *(укый)*. «Ас мехыннан тегелгән манто һәм алтын сәгать салырга уйлыйлар. Әнинең абыйсы (отставкадагы генерал) пианино «Рига», әнинең энесе персидский ковер вәгъдә итә. Әтинең апасы — хрусталь люстра, әтинең энесе — телевизор «Рубин», апа белән җизни — фил сөягеннән ясалган нәфис шкатулка һәм энҗе муенса, Ташкенттагы кардәшебез — мамык юрган, авылдагы әби белән бабай — каз мамыгыннан дүрт мендәр салачак. Минем капитаным Көньяк Америкадан алып кайткан ике попугай бүләк итәчәк. (Көмеш читлеге белән.) Мин үзем сиңа туй күлмәге, Париж мастерлары эшләгән кадак үкчәле туфля (атаклы актриса Брижжит Бордо үзенең аяк киемнәрен шул фирмада эшләтә) һәм бриллиант кашлы алка бүләк итәргә уйлыйм. Моннан тыш Франциядән йөз бутылка шампанское, илле бутыл-

ка коньяк, бер мичкә утыз ел сакланган бургунд виносы алып кайттым. Шушы арада Америкадан ике йөз бутылка пепси-кола кайтып җитәчәк».

Булат *(көлә-көлә)*. Шәп кияү, шайтан алгыры! *(Бүлмәсенә китә.)*

Әсхәт *(укый)*. «...Ун килограмм кызыл икра, биш килограмм кара икра, өч килограмм...»

Зөбәйдә *(Булат киткән бүлмәгә карап тора да хатны тартып ала)*. Кыскасы, егетләр, диңгезче өйләнергә тели. Менә шушы байлыкларга өстәп, миңа үзенең кулын һәм йөрәген тәкъдим итә. Һәм, анысы үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, хезмәт хакын. Өч йөз илле, дүрт йөз тирәсе. Нишлим икән, егетләр? Шушы егеткә кияүгә чыгыйм микән?

Зур пауза. Булат керә.

Сөендек *(хәйләкәр елмаеп)*. Да!..

Булат. Кияү дисәң дә кияү!

Зөфәр. Овчаркасы гына юк!..

Зөбәйдә. Тсс! Ягез, кем нәрсә әйтергә тели, иптәшләр? *(Әсхәт кул күтәрә.)* Сүз Әсхәткә бирелә.

Әсхәт *(тотлыга-тотлыга)*. Ә үзең, Зөбәйдә, яратасыңмы ул егетне?

Зөбәйдә. Ну, Әнәс миңа ошый. Ул озын буйлы, кара көдрә чәчле... Мыегы да бар!

Булат. Тәгаен бармы мыегы?

Зөбәйдә. Билләһи, бар!

Булат. Алайса чыгарга кирәк ул егеткә, Зөбәйдә. Менә әгәр мыегы булмаса — ул вакыт икенче эш. *(Бүлмәсенә китә.)*

Сөендек. Тәмәке тартамы?

Зөбәйдә. Заграничныйны гына!

Сөендек. Аракы эчәме?

Зөбәйдә. Чамасын белеп кенә!

Зөфәр *(мыскыллап)*. Әйе, тәкъдимне кабул итмәсәң, никадәр байлыктан колак кагачаксың!

Булат *(бүлмәсеннән)*. Һәм магазиндагы трельяж белән секретердан да!

Зөбәйдә *(Булат бүлмәсенә карап торганнан соң кинәт Зөфәргә)*. Ну, Зөфәр, китереп тә карыйсың ачуымны!

Зөфәр. Үземә үзем гаҗәпләнәм. Нәрсә өчен яраттым икән мин сине?!

Зөбәйдә. Зөфәр, сиңа сүз бирелмәде!

Зөфәр. Сиңа безнең фикер кирәк түгел бит. Син бит бу комедияне үзеннең бәяңне күтәрү өчен генә уйныйсың. Янәсе, минем менә нинди егетләрем бар! Һәм без ни генә дисәк тә, син бу егеткә чыгачаксың. Ул синең кем булуыңны бик яхшы аңлаган. Хайван шикелле аша да эч, йокла һәм ирецнең диңгез аръягындагы илләрдән бүләкләр алып кайтуын көт. Ә ул кайтканчы койрыгыңны теләсәң ничек болга...

Әсхәт чалт иттереп Зөфәрнең яңагына суга.

Булат *(араларына кереп)*. Егетләр, егетләр!

Зөбәйдә *(тахтага сикереп менеп баса)*. Молодец, Әсхәт, син миңа ошыйсың!.. Берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез, иптәшләр. Монда, иптәшләр, Зөфәр мине койрыклы хайван һәм мещанка дип мыскыл итте. Ләкин ул ялгыша, иптәшләр. Мин саксон фарфоры белән ас мехыннан тегелгән манто кебек әйберләргә алданучы арзанлы мещанка түгел. Мин аларга кызыкмыйм. Кыскасы, тантаналы рәвештә белдерәм, иптәшләр, Абдуллин Әнәснең тәкъдимен мин кире кагам!

Зөфәр. Шундый зур корбанның кем өчен һәм ни өчен икәнен дә әйтерсең, бәлки?

Зөбәйдә *(ачуыннан нишләргә белмичә)*. Ни өченме?.. *(Еларга җитеп бер Зөфәргә, бер Булатка карап торганнан соң.)* Ни өчен дисеңме? Чөнки аның машинасы юк — менә ни өчен!.. Ә хәзер — киңәшмә бетте, таралыгыз! *(Шап итеп тахтага утыра. Зөфәр кискен борылып чыгып китә. Сөендек Зөбәйдә янына килә.)*

Сөендек. Бәлки бераз машинада йөреп керербез!

Зөбәйдә. Вон моннан! Бөтенегез дә вон! Вон! Вон!

Әсхәт, Славик һәм Сөендек бер-бер артлы чыгып китәләр. Зөбәйдә үкереп елый-елый тахтага каплана. Булат стакан белән су китерә.

Булат. Салкын су эчегез.

Зөбәйдә. Эчмим!

Булат. Мин сөткә кереп чыгам, Кәримә. Нияз уянса...

Кәримә. Бир, үзем алып чыгам. *(Булатның шешәсен тартып ала да чыгып йөгерә. Пауза. Зөбәйдә ярсып-ярсып елый).*

Булат. Монда бик бөркү. Бәлки тәрәзәне ачу кирәктер?

З ө б ә й д ә *(үкси-үкси торып утыра)*. Миңа нәрсә кирәген мин үзем дә белмим... Нишләргә инде хәзер! Нишләргә инде хәзер?!

Б у л а т *(ирония белән)*. Егет шәп бит. Тәкъдимен кабул итәргә кирәк.

З ө б ә й д ә. Мин бит ул турыда түгел!

Б у л а т. Шулай да мин бернәрсәне аңламыйм. Ни өчен сез егетләрне шулай мыскыл иттегез?

З ө б ә й д ә. Шул кирәк аларга!

Б у л а т. Үзеңне яратып йөргән кешедән көлү, минемчә, яхшы түгел.

З ө б ә й д ә. Ярату тагын! Беләсезме, алар ни өчен минем тирәдә йөриләр? Матур булганым өчен. Берсенең минем белән көймәдә йөрисе килә. Икенчесенең — машинада. Ә мин ничек яшим, нинди кайгым бар — анда аларның эшләре юк.

Б у л а т. Ә Әсхәт?

З ө б ә й д ә. Нәрсә — Әсхәт?

Б у л а т. Ул да яратмыймы?

З ө б ә й д ә. Малай гына ич ул!

Б у л а т. Күрәсең, сез әле беркемне дә яратмыйсыз, Зөбәйдә.

З ө б ә й д ә. Белмим. Бәлки яратамдыр. Ничек була соң ул ярату? Сез үзегез берәр кызны яратасызмы?

Б у л а т. Яратам.

З ө б ә й д ә. Торырга өегез юк, ә үзегез... Нәрсә, йортка керәсезме?

Б у л а т. Тиздән минем үз өем булачак.

З ө б ә й д ә. Бүлмә бирәләрме?

Б у л а т. Бүлмә түгел, квартирам булачак минем. Мин чиратта торам.

З ө б ә й д ә. Туган апам әйтмешли, эрләмәгән, сукмаган — Шыгаем, сиңа ыштанлык! Яхшымы соң кызыгызның квартирасы?

Б у л а т. Белмим.

З ө б ә й д ә. Ничек инде?

Б у л а т. Шулай. Яратсаң, андый нәрсәләрне сорап тормыйсың бит аны.

З ө б ә й д ә. Соң, өйләренә кергәнегез бардыр бит инде!

Б у л а т. Юк. Мин әле аның кайда торганын да белмим.

З ө б ә й д ә. Әй, бернинди кызыгыз юктыр әле, мактанасыз гына булыр. *(Пауза.)* Медсестра булып керер идем — эшен яратмыйм.

Б у л а т. Ә, сез ул турыдамыни. Бәлки, безнең төзелешкә керерсез, Зөбәйдә?

З ө б ә й д ә. Кем булып?

Б у л а т. Безгә анда төрле эшчеләр кирәк. Штукатурчылар да җитешми, малярлар да аз. Штукатурчы булып керсәгез — үзегезне Кәримә өйрәтер. Ул безнең алдынгылардан санала.

З ө б ә й д ә. Юк, штукатурчы буласым килми. *(Уйлап торып.)* Ә мин обой ябыштыра беләм. Сезгә андый кешеләр кирәкме?

Б у л а т. Андыйлар да кирәк.

З ө б ә й д ә. Ә эшкә керү өчен иң башта кем янына барырга? Начальникка булса —мин бармыйм.

Б у л а т. Габдрахман абыйның катнашы юк монда. Кадрлар бүлегенә генә керәсез. Телисезме, иртәгә үзегезне үзем алып барам.

З ө б ә й д ә. Йөрергә ерак булачак.

Б у л а т. Автобус йөри бит. *(Зөбәйдә тахтада аунап яткан хатны ерта башлый.)* Димәк, диңгезчегә отказ!

З ө б ә й д ә. Әнәскәме?

Б у л а т. Әйе.

З ө б ә й д ә. Юк бит ул Әнәс!

Б у л а т. Ничек — юк?!

З ө б ә й д ә. Шулай. Мин аны үзем уйлап чыгардым. Егетләрдән көләр өчен!

П ә р д ә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Коляскада кычкырып бала елый. Җәүһәрия моңа игътибар итмичә көзге алдында бизәнә. Эш киемнәре кигән **З ө б ә й д ә** йөгереп керә.

З ө б ә й д ә. Нигә инде шуны елатасың? *(Колясканы селкн башлый, бала елаудан туктый.)* Я, тәтием, елама. Әлли-бәлли! У, тәтием, көлеп тә җибәрде! *(Баланы үбә башлый.)* Яле-яле, шушы җиреңне үбеп алыйм әле. Үбәм! Егет кеше дип куркып тормыйм — үбәм. *(Үбеп.)*

Уп-па! И, туган апам, кайчан минем дә шундый бәбием булыр икән!..

Җ ә ү һ ә р и я. Без хәзер загска китәбез. Булат кайтканчы бала янында утыр.

З ө б ә й д ә *(тәрәзәне ачып җибәрә дә тәрәзә төбенә менеп утыра)*. Әллә кайсы җирләре генә сөйкемле аның. Күзләреме шунда. Туган апам, син аның күзләренә игътибар иттеңме?

Җ ә ү һ ә р и я. Әллә тагын!

З ө б ә й д ә. Сөйкемлеме соң ул, синеңчә?

Җ ә ү һ ә р и я. Сөйкемле шул! Мин бит сиңа әйтә киләм.

З ө б ә й д ә *(хискә бирелеп)*. Һәм нинди олы йөрәкле! Туган апам, синеңчә ничек, матурмы ул?

Җ ә ү һ ә р и я. Ирләргә матурлык кирәкми. Миңа аның акылы булсын.

З ө б ә й д ә. Юк, матурлык та кирәк, туган апам. *(Ояла-ояла.)* Туган апам, әйт әле, сиңа ошыймы ул?

Җ ә ү һ ә р и я *(бизәнүен дәвам итеп)*. Ошамаса, мин аңа әйләнеп тә карамас идем.

З ө б ә й д ә *(канатланып)*. Миңа да! Миңа да ошый, туган апам! *(Тагын да ояла төшеп.)* Туган апам, ә син ничек уйлыйсың, ул мине яратыр микән?

Җ ә ү һ ә р и я. Нигә яратмасын — яратыр.

З ө б ә й д ә. Ә башка берәр кызы булса?

Җ ә ү һ ә р и я. Кемнең? Син кем турында сөйлисең?

З ө б ә й д ә. Ә син кем турында?

Җ ә ү һ ә р и я. Сәмигулла җизнәң турында.

З ө б ә й д ә *(кул селтәп)*. Әй!..

Ә с х ә т керә.

Ә с х ә т. Исәнмесез!

З ө б ә й д ә. Исәнме, Әсхәт, уз.

Җ ә ү һ ә р и я. Әйдә, утыр, Әсхәт. Мин Мәликә карчыкка кереп чыгам.

З ө б ә й д ә. Ник?

Җ ә ү һ ә р и я. Тормышыбыз бәхетле булсын дип бөтен корьән чыгарга кушкан идем. Садакасын кертәм.

З ө б ә й д ә. Туган апам, бир әле миңа уң сум акча?

Җ ә ү һ ә р и я. Шаштыңмы әллә син? Кайдан миндә шул кадәр акча булсын, эшләмәгән кешедә! Нишлисең шул кадәр акча белән?

З ө б ә й д ә. Кирәк иде. *(Җәүһәрия чыга. Әсхәт Зөбәйдәгә картинкалар суза.)* Ничә?

Ә с х ә т. Илле сигез генә... Син бүген эштән иртә кайткансың?

З ө б ә й д ә. Ха, апаң шул персональ машина белән генә йөри. Булат абыеңның шофер икәнлеген оныттыңмыни?

Ә с х ә т. Ул бит самосвалда!

З ө б ә й д ә. Самосвалның кабинасы да була ич.

Ә с х ә т. Ничек соң, авыр түгелме?

З ө б ә й д ә. Бер дә авыр түгел. Барыбыз да минем кебек яшьләр. Эшлибез, шаярабыз. Тиздән бу йорт бетә. Беренче катта балалар библиотекасы булачак. Без бүген шуның уку залын обойлап бетердек. Шундый матур булды!

Ә с х ә т *(чалбар балакларын тарткалап)*. Синең линейкаң бармы?

З ө б ә й д ә. Нигә ул сиңа?

Ә с х ә т. Менә тагын азрак чалбарны тарайткан идем. Манжетын да алып ташладым.

З ө б ә й д ә *(шаркылдап көлеп тәрәзә төбенә менеп утыра)*. Ой, Әсхәт, син мине көлдереп үтерәсең!..

Ә с х ә т. Ә нәрсәгә кирәге бар аның, манжетның! Барыбер тузан гына җыела бит аңа... *(Пауза.)* Әйдә, Бүрекле белән Күреклене очырабызмы?

З ө б ә й д ә. Икенче вакыт, Әсхәт, хәзер минем вакытым юк. *(Тәрәзә төбенә сузылып ятып тышка үрелә.)* Ой, бүген көн шундый матур! *(Арттан Шопенның до-диез минор экспромт фантазиясенең салмак өлеше ишетелә.)* Ой, Әсхәт, нинди матур музыка! *(Тыңлыйлар.)*

Ә с х ә т *(тәрәзәдән караган килеш)*. Әнә күрәсеңме, ничек моңаеп утыралар. Чөнки очар вакытлары җиткән, мине көтәләр.

З ө б ә й д ә. Әгәр шуннан ояларына кире кайтмасалар? Очып әллә кая китсәләр?

Ә с х ә т. Китмиләр шул алар.

З ө б ә й д ә. Җүләр алар синең күгәрченнәрең! Мин булсаммы, әгәр канатларым булсамы — әллә кайларга очар идем! *(Пауза.)* Әсхәт! Әгәр кемне дә булса яратсаң, ничек була икән?

Ә с х ә т *(башын иеп)*. Аны сөйләп биреп булмый.

З ө б ә й д ә. Ничек инде?

Ә с х ә т. Әгәр кемне дә булса яратсаң, син әллә ниш-

лисең. Үзгәрәсең. Сиңа бөтен дөнья әллә нишләгән булып күренә башлый...

З ө б ә й д ә. Нишләгән булып күренә?

Ә с х ә т. Әллә нишләгән, матурланган булып күренә. Син үзең дә үзгәрәсең...

З ө б ә й д ә *(тыпырчынып)*. Ой, Әсхәтчик, ничек үзгәрәсең? Сөйлә, сөйлә!

Ә с х ә т. Ну, әйтик, син нәрсәнедер яратмыйсың. Ну... ничек дип аңлатыйм инде сиңа... Ну, әйтик, берәү маркалар җыя. Син үзең җыймыйсың... бу эшкә көлеп карыйсың. Була бит шулай... Ә яратсаң!.. Ну, әйтик, синең яраткан кешең маркалар җыйса... Мин моны мисалга гына әйтәм...

З ө б ә й д ә. Шуннан! Шуннан, Әсхәт!..

Ә с х ә т. Һәм кинәт... син үзең дә маркалар җыя башлыйсың. Аңа китерәсең... Моны эшләү шундый күңелле!.. Мин моны мисалга гына сөйләдем, билгеле. Башка берәр нәрсәне дә шулай яратырга мөмкин...

З ө б ә й д ә *(Әсхәтне кочаклап ала да тәрәзә төбеннән шуып төшә)*. Ой, Әсхәт, мин яратам бит! *(Әсхәт, авызын ачкан хәлдә нәрсә дияргә дә белмичә, бүлмә тирәли чабып йөргән Зөбәйдәгә карый.)* Мин яратам, Әсхәт! Мин дә ярата беләм икән, ой! *(Аякларын салындырып тәрәзә төбенә менеп ята.)* Ой, тышта нинди күңелле бүген! *(Тәрәзә төбеннән сикереп төшә.)* Мин яратам, Әсхәт.

Ә с х ә т *(шатлыгыннан нишләргә белмичә)*. Минеме?!

З ө б ә й д ә. Сине дә яратам, Әсхәт! Ой, кайдан берүн сум акча табарга икән?!

С ә м и г у л л а керә.

С ә м и г у л л а. Хуҗалар өйдәме, керергә ярыймы? Саумы, кызым!

З ө б ә й д ә. Исәнмесез, бабай!

С ә м и г у л л а. Матур апаң кайда?

З ө б ә й д ә. Ул хәзер керер, бабай. Утырыгыз.

С ә м и г у л л а. Шулаймы. *(Утыра.)* Нигә беркөн карлыган җыярга килмәдең, шаян?

Җ ә ү һ ә р и я керә.

Ә с х ә т. Карап тор, хәзер күгәрченнәремне очырам! *(Чыга.)*

С ә м и г у л л а *(кулларын сузып Җәүһәриягә каршы килә)*. Сөбханалла, бу модный күлмәкне кигәч фәрештә

күк булгансыз лабаса! Кил әле, кил, кил. *(Җәүһәриянең кулыннан алып үзенә таба тарта.)*

Җәүһәрия *(качынып)*. Нихәл, Сәмигулла абый, исән-сау гына йөрисеңме? Утыр.

Зөбәйдә чыга.

Сәмигулла. Утырып та торсак, соңга калмабызмы соң?

Җәүһәрия. Бер дә күңелем тыныч түгел әле, Сәмигулла абый...

Сәмигулла. Кияү куенына керергә йөргәндә күңел тыныч була димени ул! *(Кеткелдәп көлеп).* Әле менә үземнең дә... Менә, тотып кара әле йөрәгемне. *(Җәүһәриянең кулын йөрәге өстенә куйган булып кочаклап ала.)*

Җәүһәрия. Алла! Алла, кытыгымны китерәсең, Сәмигулла абый!.. *(Ычкынып китә дә йомшак кына итеп Сәмигулланың кулына суга.)* Әдәпсез!

Сәмигулла. Әйдә, киттек! Пашпыртыңны алдыңмы?

Җәүһәрия. Әллә ничек кенә, Сәмигулла абый.

Сәмигулла. Аһ алла, без бит эшне качып-посып эшләмибез, законный итеп эшлибез. Башта загска барып хөкүмәт каршында эшне беркетеп куябыз. Аннан ары, аллаһы теләсә, күчеп үк килерсең дә, алла каршында да эшебезне законный ясарбыз. Никах укытырбыз.

Җәүһәрия. Улларыңнан уңайсыз.

Сәмигулла. Һи, кызык кына икәнсең син, әкәмәт! Әллә кайларда зимагур булып йөргән малайларның миндә чуртым эше бармы? Солдаттан монда кайтырга уйласа, кечкенәсен дә кертмим әле мин аның. Абыйлары янына Сверлауга китсен. Икәүдән-икәү гөлдерәп кенә яшәрбез, аллаһы теләсә! *(Зөбәйдә керә.)* Кара инде бу баланың чәчен! Акыл юк шул хәзер яшьләрдә, акыл юк...

Зөбәйдә. Акыл чәчтә түгел бит, бабай, башта.

Сәмигулла. Баштасын башта ул. Әмма ләкин менә шулай пумала баш булып йөрү акыл зәгыйфьлек галәмәте. *(Җәүһәриягә.)* Һәйбәтләп үргән чәч толымнарыннан да күркәм ни бар инде хатын-кызга!

Җәүһәрия *(толымнарын алдына чыгарып салып).* И, хәзерге яшьләрдән син аны көтмә инде, Сәмигулла абый!

Зөбәйдә. Ә син пумала башлардан көлмә, бабай!

Бил тиңентен толым үстереп йөргән хатыннар ни эшләделәр? Ирләренә аш пешереп торудан уза алмадылар.

Сәмигулла. Хатын-кызның эше шул инде аның!

Зөбәйдә. Ә хәзер әнә пумала башлы кызлар космоста очалар!

Сәмигулла. Кайда?

Зөбәйдә. Космоста дим, галәмдә! Озакламый Айга да менәчәкләр.

Сәмигулла. Йөрсеннәр инде. Шундый матур Айны китеп төшерерләр әле, имансызлар... *(Җәүһәриягә.)* Әйдә, киттек! Тукта, утырып бер дога кылып алыйк. *(Дога кыла. Җәүһәрия әдәпле генә итеп битен сыпыра.)* Амин тотмыйча бик зур хата эшлисең, кызым. Амин тоту үзең дога кылу кебек үк саваплы булыр дигән китап.

Зөбәйдә. Мин аллага ышанмыйм шул, бабай. Мин — комсомолка.

Сәмигулла. Заманасы шул булгач, комсомол да бул син, кызым, комунис та бул. Әмма ләкин алланы да абнжайт итмә. Пушчай кеше, алла юк, дисен, ә син эчеңнән генә булса да, бар, дип йөр. *(Кошелёгыннан ун тиен акча чыгарып, әйләндерә-әйләндерә карый да Зөбәйдәгә суза.)* Бисмиллаһи рәхман иррахим. Мә, кызым! Маруэ алып ашарсың.

Зөбәйдә. Ун тиенгә бер генә мороженое килә бит, бабай. Анда да иң арзанлысы. Мин аның белән генә туймыйм.

Сәмигулла. Туярсың, бисмилланы әйтеп аша.

Зөбәйдә. И, бер мороженоега инде, бисмилла әйтү түгел, бөтен корьән чыксаң да туймыйсың, бабай.

Сәмигулла. Карале, кара. Кайдан килеп мин сиңа бабай булыйм! Җизни дип әйт, җүләр! Мә!

Зөбәйдә. Алай бик җизни дә булсаң, син миңа ун тиен бирмә, ун сум бир, бабай!

Сәмигулла. Кара, кара, кара! Күрәсеңме бу елдагы яшьләрнең чаялыгын!

Зөбәйдә. Син курыкма, бабай, мин синнән бурычка гына сорыйм.

Сәмигулла. Ээ. Шулай дисеңмени?

Зөбәйдә. Әйе, җизни. Зарплата алгач та түләрмен.

Сәмигулла. Түләрмен, дисеңмени? *(Кошелёгын чыгара.)*

Зөбәйдә. Түлим, түлим. Үлеп кирәк иде бүген ун сум акча. *(Колагына.)* Концертка барабыз.

Сәмигулла. Шулаймыни... Алайса инде, кызым, син аны минем күк пенсе акчасына яшәгән карт-корыдан сорама. *(Кулындагы ун тиенне салып, кошелёгын кесәгә яшерә.)* Жалунья алган кешедән сора. Атаңнан!

Зөбәйдә. Минем әти саран шул, бабай. Ул миңа акча бирми, бозыласың, ди.

Сәмигулла. Дөрес әйтә. Акча яшьләрне боза. Боза яшьләрне акча! *(Зөбәйдә чыга.)* Пашпыртыңны онытмадыңмы? Әйдә!

Җәүһәрия. Әллә азрак сабыр итик микән, Сәмигулла абый? Әти-әниләр белән киңәшим микән?

Сәмигулла. Киңәшеп торасы юк! Һич үкенмәссең, аллаһы теләсә. Пенсе акчасына яшим дигәч тә, әллә син... Әлхәмделиллаһи шөкер! Дварис хәтле йортым бар. Сад бакчасы. Кара карлыган сатып кына да өч йөз файда итәм быел. Шуның янына кыяры-суганы, башка чурт-чурамасы. Квартирант кызлар... Әлхәмделиллаһи шөкер, һәр җирем житеш. Малайлардан гына уңмадым. Аталарына ярдәм итмәс өчен читкә качып беттеләр.

Җәүһәрия. Син ул оятсызларны судка бирәсең бар, Сәмигулла абый. Алимент түләтәсең бар.

Сәмигулла. Хе, хе, хе. Сәмигулла абыеңны җүләр дип беләсең ахыры син. Сәмигулла абыең законнарны бик яхшы белә. Яши белеп яшәсәң, сәвитски влач картларны абижайт итми. Әлхәмделиллаһи шөкер, бишесе дә алимит түләп тора. *(Кесәсеннән саклык кенәгәсе чыгарып, кулыннан ычкындырмый гына Җәүһәриягә күрсәтә.)* Менә монда карале! Хе, хе, хе! Күпме дигән, өч мең дә сигез йөз дигәнме? Яңа акча белән бит бу!

Җәүһәрия *(күлмәк изүеннән саклык кенәгәсе алып кирәкле битен генә ача да)*. Менә монда да яңа акча белән!

Сәмигулла *(кенәгәгә ябышып)*. Сөбханалла! Дүрт мең!..

Җәүһәрия *(Сәмигулланың авызын кулы белән томалап)*. Шулай булгач, синең карлыган саткан акчаңа кызыкмыйм мин, Сәмигулла абый.

Сәмигулла *(кызып)*. Минем тагы бар! Акча бетсә дә бетми торган җирдә бар...

Җәүһәрия. Тсс!..

Зөбәйдә керә.

Сәмигулла. Әйдә, киттек! Пашпыртыңны онытмадыңмы?

Сәмигулла белән Җәүһәрия чыгалар. Зөбәйдә аларны тәрәзәдән елмаеп карап кала.

Зөбәйдә. Бүген көн шундый матур! Өйдә утырасы да килми. Әллә кайларга чыгып китеп, әлләниләр эшләп йөрисе килә!.. *(Җырлый.)*

Без яна йортлар салабыз
Казанның кырыенда,
Мин — маляр, ул самосвалда
Буяу китереп тора.
Самосвалын бушата да
Кул болгап китеп бара.
Кайтыр юлларына карап
Күз керфекләрем тала.

Фәрит керә.

Юл өсте булганга түгел,
Өзелеп яратканга,
Эш беткәч илтә өемә
Утыртып самосвалга.
Самосвал кабинасында
Утырып барулары!
Өемә кайтып житкәнче
Онытыла аруларым.

Фәрит *(ясалма көлеп)*. Ха, ха, ха! Әле кимендә «Москвич»ы булган егетне генә яратам дип йөри идең. Инде казенный самосвал булса да ярыймы?

Зөбәйдә *(елмаеп Фәриткә карап ала да дәвам итә)*.

Өйләнгәч дип, көтеп торсак —
Сонгарак калырбыз, ди.
Язылдым әле чиратка,
«Москвич» алырбыз, ди.
Агыйдел камышлары,
Йөрәгем сагышлары,
Таратты сагышларымны
Самосвал тавышлары!..

Фәрит чыга. Габдрахман керә.

Габдрахман *(коры гына)*. Булат кайттымы?

Зөбәйдә. Юк әле. *(Коляска янына килгән Габдрахманны куып.)* Юмаган кулларың белән балага кагылма!

Габдрахман. Ярый, күп газапланасыгыз калмады. Бүген ул бездән китәчәк.

Зөбәйдә. Ничек — китәчәк?

Габдрахман. Әллә мин аны мәңге үз өемдә тотыйммы?

Зөбәйдә. Бала белән кая барсын ул?

Габдрахман. Анысы инде минем эш түгел...

Зөбәйдә чыга. Елый-елый Җәүһәрия керә.

Габдрахман. Нәрсә булды?

Җәүһәрия. Үлде!

Габдрахман. Кем үлде?!

Җәүһәрия. Загска барып житкәч, кулларыбызны куйгач, егылды да үлде. Алып киттеләр... машинага төяп...

Габдрахман. Язылышкач булдымы шул хәл?

Җәүһәрия. Башта кулымны мин куйдым. Аннары ул... Сәмигулла Искин дип язуы булды, егылып үлүе булды... *(Чыга.)*

Сәрия керә.

Сәрия. Исәнмесез!

Габдрахман *(каушап)*. Син килеп тә життеңмени?.. Мин Фәрит белән сөйләшә алмадым бит әле. Өйдә юк Фәрит, командировкада.

Фәрит керә. Ул шактый исергән. Бернәрсәгә игътибар итмичә тахтага барып ята.

Габдрахман. Син командировкадан кайттыңмыни?

Фәрит. Син нәрсә — артыны салып кайттыңмы әллә? Минем беркая киткәнем юк.

Габдрахман. Син гафу ит, кызым. Мин аның белән сөйләшкән идем инде. Ләкин син артык бетерешмә...

Фәрит *(күзләрен Сәриягә текәп торып утыра. Габдрахманга)*. Кит шуннан! *(Габдрахман чыга. Фәрит чайкала-чайкала Сәрия янына килә, кул суза.)* Исәнме! Тыңлама син ул карт дуракны. Килүең яхшы булды. Мин үзем синең янга җыена идем. Мин бит... Син минем соңгы хатны алдыңмы?

Сәрия. Сеңелең язган хатнымы?

Фәрит. А, чепуха! Да, миндә яңалык бар. Мин институттан китәргә булдым. Мин аңладым. Агроном

кешенең урыны авылда. Югары уңыш өчен көрәш барган җирдә.

Сәрия. Син мине элеккеге кебек бала акылы чыгып бетмәгән кыз дип уйлыйсың ахыры. Ләкин мин инде олыгайдым, Фәрит.

Фәрит. Берничә айда?!

Сәрия. Олыгаю яшь белән йөрми икән шул. Соңгы бер атнада мин үземне бик күп олы итеп сизә башладым.

Фәрит. Чепуха!

Сәрия. Мин әле генә институтыгызда булдым. Синең эштән куылуыңны мин беләм. Сәбәбен дә әйттеләр.

Фәрит. Алайса ник килдең?

Сәрия. Болай гына. Сиңа карыйсым килде.

Фәрит. Ну кара инде алайса, кара!

Сәрия. Синең эштән чыгарылуыңны ишеткәч, мин сине кызганган идем. Сине нахакка рәнҗеткәннәр, аңламаганнар төсле тоелды. Һәм мин, бөтен нәрсәгә күз йомып, сиңа кул сузарга теләгән идем. Кызганычка каршы, институтта сине дөрес аңлаганнар. Син иң соңгы чиккә кадәр алдашасың.

Зөбәйдә йөгереп керә, Сәрияне күреп кинәт туктап кала.

Фәрит. Слушай, төкер син институтка! Мин синең янга Буага кайтам. Матур итеп яшәрбез. Син бит мине яратасың. Яратасың бит син мине?

Зөбәйдә. Яратмый! Яратмый ул сине! *(Сәриягә.)* Шулай бит, яратмыйсыз бит?

Сәрия. Яратуын яратам мин сине. Ләкин бу ярату хата булган, Фәрит. Ә хатаны иртәме-соңмы төзәтү тиеш.

Зөбәйдә. Сез мине кичерегез, мин сезнең алда бик зур гаепле...

Сәрия. Сез шул бик яшь әле, сеңелем. *(Ишеккә таба бара.)*

Фәрит. Карале...

Сәрия. Карадым, күрдем.

Фәрит. Юк, мин дөрес әйтәм. Мин эшкә сезнең районга барам.

Сәрия. Рәхим ит, безнең районның кырлары киң!

Сәрия чыга. Габдрахман керә.

Габдрахман. Ул нәрсә, чынлап сөйлиме?

Фәрит. Нәрсәне?

Габдрахман. Эштән чыгару турында?

Зөбәйдә көлә-көлә телефонда номер җыя башлый.

Г а б д р а х м а н. Нигә шул кадәр авызыңны җәйден, җүләр баш?

З ө б ә й д ә. Үзең гаепле. Акыллы итеп тудырырга хәлеңнән килмәгән.

Г а б д р а х м а н *(өстәлгә сугып)*. Бу нинди оят белмәс кыз бу, ә? Унҗиде яшьтәниләр генә белми!

З ө б ә й д ә *(киткеч тыныч кыяфәт белән)*. Һо, андый нәрсәләрне мин инде күптән беләм. Әйтимме кайчаннан бирле? Әни бар вакытта мине кинога йөртә идең бит әле. Мине кинога кертеп җибәрә идең дә үзең әллә кая китә идең. Соңыннан әнигә кинода икәү булдык дип әйтә идек...

Г а б д р а х м а н. Җитте!

З ө б ә й д ә. Берсендә мин кинога кермичә артыңнан ияреп бардым. Җиде-сигез яшьлек бала бит — кызык...

Г а б д р а х м а н *(Җәүһәриягә)*. Ашатасыңмы, юкмы син мине бүген?!

Җәүһәрия белән икәүләп кухняга чыгалар.

З ө б ә й д ә *(Габдрахман артыннан кычкырып)*. Ә мин барыбер күрдем! Мин карап тордым! Мин барысын да беләм! *(Фәриткә.)* Нигә шулай кайгыга баттың? Күңелеңне төшермә, сударь, нык бул! Шулай өйләнә алмый калсаң, картлык көннәрегезне туган апам белән үткәрерсез. Барырсыз авылга. Агроном дипломы булган кешегә авылда да эш табыла бит!..

Бала тавыш чыгарып куя. Зөбәйдә коляска янына килә. Ф ә р и т чыга.

Уяндыңмы, тәтием! Нәрсә кирәк? Яле, үсик әле. Үсте, үсте, үсте — уппа! Менә нинди зур булып үсте Нияз. Кил кулыма. *(Баланы кулына ала, үбә.)*

Кояш кебек йөзләре,
Шомырт кара күзләре,
Сары ефәк чәчләре,
Тик чыкмаган тешләре,
Бите әнис алмасы —
Бу кемнәрнең баласы?
Кемнеке? Безнеке!

Б у л а т керә. Зөбәйдә баланы тиз-тиз коляскага сала. Булат бала белән кайнаша башлый.

З ө б ә й д ә *(тәрәзәгә килеп)*. Бүген көн шундый матур! *(Пауза.)* Булат! Мексика балеты концертына барасыңмы?

Б у л а т. Мексика балетына?

З ө б ә й д ә. Әйе.

Б у л а т. Кайчан?

З ө б ә й д ә. Бүген барабыз, хәзер.

Б у л а т. Син дә барасыңмы?

Зөбәйдә. Әһе, икәү барабыз. Бүген соңгы концерт! Күрмичә каласың!

Булат. Рәхмәт,. Зөбәйдә. Мин бара алмыйм.

Фәрит керә. Булат белән Зөбәйдәне күреп тыңлап тора.

Зөбәйдә. Нишләп бара алмыйсың?

Булат. Вакытым юк.

Зөбәйдә. Минем белән барырга хурланасың, шулаймы? Минем чәчем дә кырыккан, тырнакларым да буяулы. Курыкма, бүген буямаган. Менә кара!

Булат. Кызык кына син, Зөбәйдә...

Зөбәйдә. Акланма, зинһар. Син бит мине җүләргә саныйсың. Чөнки мине бу өйдә бөтен кеше җүләр ди.

Булат. Мин сине җүләргә санамыйм, Зөбәйдә...

Зөбәйдә. Алайса нигә бармыйсың?

Булат. Минем чыннан да вакытым юк. Бүген мин сездән китәргә тиеш. *(Чыга.)*

Зөбәйдә *(йөзен яшерү өчен читкә борыла)*. Ай, гөл ничек кояшка тартылган!

Фәрит. Синең сюрприз чыкмый бит әле.

Зөбәйдә. Нишлим икән, абый? Әллә яратканлыгымны әйтимме икән?

Фәрит. Син нәрсә, чынлапмы?

Зөбәйдә. Әһе. Нишлим икән? Нишлим икән, абый?! *(Фәрит көлә.)* Мин бит синең белән чынлап сөйләшәм! *(Фәрит шаркылдап көлә.)* Көләргә хакың юк! Хакың юк синең көләргә!..

Ф ә р и т. Җүләр син!

Зөбәйдә. Менә ничек! Мин сине абый дип йөрим тагын. Сине аңларга тырышып йөрим. Ниһаять, мин сине аңладым. Йөрәксез син! Синең беркайчан да яратканың юк. Синең һичкайчан яратачагың да юк! Беләсеңме, син кем? Син — ничтожество! Иң саф хисләремнән көлгәч, син мина абый түгел. Минем абыем юк!.. *(Фәрит чыга. Булат керә.)*

Булат. Син мине гафу ит, Зөбәйдә. Теләсәң, без синең белән концертка икенче вакыт барырбыз.

Зөбәйдә. Кит дип начальник әйттеме сиңа?

Булат. Юк, ул әле бу хакта әйтеп өлгермәде. Ләкин миңа хәзер үк китәргә кирәк. Габдрахман абый белән конфликт чыкты безнең.

Зөбәйдә. Нинди конфликт?

Булат. Синнән соң участокка Габдрахман абый килде. Балалар библиотекасы өчен эшләнгән помещениены җимереп квартира ясарга куша. Чертежлар да китергән.

Зөбәйдә. Бәлки ул хаклыдыр. Квартира кирәк кешеләр күп бит.

Булат. Анысы шулай ул. Ләкин бу бит тресттагы ниндидер шишка өчен! Йөз егерме метрлы библиотекадан махсус аның өчен квартира ясарга чамалыйлар.

Зөбәйдә. Нинди дуңгызлык!

Булат. Менә шул шул. Шуның өчен без, комсомол яшьләр, приказга буйсынмаска булдык. Җимермибез библиотеканы!

Габдрахман керә.

Габдрахман. Кайттыңмы син, герой!

Булат. Кайттым.

Габдрахман. Иптәшләрең битенә төкергәндә мин сине яклап калдым. Торыр урының калмагач, мин сине үз өемә алып кайттым...

Булат. Болары өчен рәхмәт...

Габдрахман. Ә син бөтен бригаданы миңа каршы котырткансың. Син беләсеңме ул кеше кем? Яков Борисович бит ул, тресттан. Безнең бөтен эшебез шунардан бәйле — син шуны аңлыйсыңмы, юкмы?

Булат. Юк. Без ул йортларны үзебезнең менә шушы кулларыбыз белән салабыз. Күпчелегебез общежитиеда тора. Кайсыларыбызның ул да юк. Шулай да сабыр итәбез, чиратыбыз җиткәнне көтәбез. Ә ниндидер Яков Борисовичка башкаларга яраган квартиралар гына ярамый. Аңа мәйданы өч квартира хәтле булган библиотека кирәк!

Габдрахман. Шәһәрдә шул кадәр йорт салдырып, күңеленә ошаганча квартира ясатып керергә хакы юкмыни аның!

Булат. Юк! Безнең комсомол яшьләр бригадасы бу эшне эшләмәячәк.

Габдрахман. Эшләмәсәгез — ялынучы да юк. Иртәгәдән объектка бишенче бригада күчә.

Булат. Без жалоба язачакбыз!

Габдрахман *(ирония белән)*. Кая язачаксыз? Тресткамы? Горисполкомгамы? Языгыз, яз.

Зөбәйдә. Жалобага мин дә кул куям!

Габдрахман. Безнең эшкә синең нинди катнашың бар!

Зөбәйдә. Турыдан-туры. Таныш булыгыз. Алдыгызда комсомол яшьләр бригадасының обой ябыштыручысы Зөбәйдә Сабитова.

Габдрахман. Син?!

Зөбәйдә. Әйе, мин. Дөрес, әлегә минем стажым биш кенә көнлек. Ләкин библиотеканың стеналарын мин дә обойлаштым. Мин дә жалобага кул куям.

Габдрахман. Куй, куй.

Мәрвәр керә.

Мәрвәр. Исәнмесез!.. Исәнмесез, иптәш начальник! *(Зөбәйдәгә.)* Акыллым, исәнме! *(Булатка.)* Нихәл!.. Мин Ниязны алырга килгән идем, Булат. Әә... ничек дип әйтеп әйтеп әйтим инде... Синең балаң түгел икән ул, Булат. *(Коляскага иелеп.)* Яле, сеңелем, алыйк әле Ниязны.

Булат. Кагылма балага.

Мәрвәр. Соң, җаныкам, Ниязның үз әтисе табылды.

Булат. Кайдан табылды ул?

Мәрвәр. Синең аны күргәнең юк, җаныкам. Син кергәндә ул читтә иде. *(Габдрахманга.)* Тырнак очы кадәр генә дә гаебе булмаса да биш елга төрмәгә утыртканнар иде Мөбәрәгемне. Төнәген кайтып төште — амнистиягә эләккән. Китер, җаныкам, Ниязны!

Булат. Кагылма балага! Бала минеке!

Мәрвәр. Әй, синеке түгел лә инде! *(Балага үреләә.)*

Зөбәйдә. Нияз безнеке!

Мәрвәр. Күр әле, кайдан килеп сезнеке булсын ул?! Шаштыңмы әллә син!

Булат. Якын килмә балага. Бала минеке!

Мәрвәр. Син нәрсә, күз тегәп көтеп алган ирем белән арабызны бозмакчы буласыңмы? Бирәсеңме, юкмы баланы?

Булат. Бирмим!

Мәрвәр. Яхшы! Мин синең белән генә сөйләшә белермен. Кешенең газиз баласын тартып алырга бирәү дә юл куймас сиңа! *(Чыга.)*

Булат тиз-тиз баланы төрә башлый.

Габдрахман. Син миңа әйт, наконец. Бу бала синекеме-түгелме?

Булат. Түгел!

Габдрахман. Алайса ник бирмисең?

Булат. Кем очрады аңа ыргытырга туп түгел бит ул. Ул бит — адәм баласы.

Габдрахман. Ыргыта бирсен — анда синең ни эшең бар!

Булат. Ничек эшем булмасын!.. *(Уйлап.)* Безнең авылда бер карт бар иде. Шуның бер сүзе хәтердә калган: адәм баласын адәм иткән дә — ата-ана, әрәм иткән дә — ата-ана. Дөрес ул. Кемдер төрмәдән кайткан. Каракмы, бандитмы. Ярый ла ул төзәлеп кайтса. Шундый кешеләргә ничек бала бирәсең! Алар аны кем итеп үстермәсләр!

Габдрахман. Дурак! Нинди закон сиңа бала бирсен! Үз балаң булса да сиңа бирмиләр әле аны. Закон буенча бала һәрвакыт анада кала.

Булат. Әгәр ул ана баласына дөрес тәрбия бирерлек кеше булмаса дамы? Әгәр ул ана үзенең баласын туп шикелле типкәләп, бүген бер, иртәгә икенче кешегә ыргытып йөртсә дәме? Юк! Андый законның булуына мин ышанмыйм. Баласына карата шундый мөнәсәбәттә булган ана — ана түгел. Андый ата-аналарның ата-ана булу хокукларын алырга кирәк! *(Баланы төреп күтәрә.)*

Зөбәйдә *(аяныч тавыш белән)*. Булат!! *(Нишләргә белми беравык торгач.)* Ә син аны арбасы белән алып кит! Ул мин үскән арба.

Булат. Рәхмәт. *(Баланы кире коляскага сала.)* Ярый, рәхмәт, Габдрахман абый. *(Җәүһәриягә.)* Сезгә дә рәхмәт, апа. *(Фәриткә.)* Сезгә дә. Мин сезне шактый борчыдым — гафу итегез. Зөбәйдә, сиңа да бик зур рәхмәт.

Габдрахман. Шулай да син минем киңәшне тот. Жалоба язып йөрмәгез. Ул шәһәр Советының ризалыгы белән эшләнә торган эш.

Б у л а т. Шәһәр Советыннан югары оешмалар да бар бит. (*Колясканы этәреп ишеккә бара.*)

З ө б ә й д ә (*йөгереп килеп колясскага ябыша*). Мин синең белән, Булат!

Б у л а т. Бик ерак бит, Зөбәйдә. Кайтырга куркырсың.

З ө б ә й д ә. Ә мин кайтырга түгел! Бөтенләйгә!

Г а б д р а х м а н. Зөбәйдә!

З ө б ә й д ә. Калдырма мине, Булат, ал үзең белән! Мин син уйлаганча ук начар кыз түгел. Мин яратам сине!

Г а б д р а х м а н (*Зөбәйдәне аралап алып Фәриткә бирә*). И җүләр баш! (*Булатка.*) Ярый, бар, юлыңда бул!

Б у л а т. Гафу ит, Зөбәйдә. Син бик әйбәт кыз. Ләкин мин башканы яратам... Гафу ит... (*Ишек төбенә килеп җиткәч Фәриттән*). Абый, сез миңа Кәримәнең адресын бирә алмассызмы?

Ф ә р и т. Кәримәнең адресын? Минем аларга барганым юк. Зөбәйдә! Әйт шуңа Кәримәнең адресын!

З ө б ә й д ә (*елаудан чак кына тыелып*). Нәриман урамы, сиксән беренче йорт. Унбишенче квартира. Ишек алдына кергәч тә уң якта...

Б у л а т (*уңайсызланып*). Рәхмәт. Гафу итегез... (*Колясканы тартып чыгып китә. Артта мәче тавышы.*)

З ө б ә й д ә. Ачып чыгарыгыз әле шул мәчене, акырмасын!..

Ф ә р и т. Бәхетең юк синең, Зөбәйдә...

З ө б ә й д ә. Заткнись, пожалуйста! Беләсең килсә, мин үземнең бу бәхетсезлегемне синең миллион бәхетеңә дә алыштырмыйм әле.

Г а б д р а х м а н. Күр әле бу җүләрне! Берәүгә дә хөрмәт юк. Абыйсына да! Әтисенә дә!

З ө б ә й д ә. Әтисенә? Син минем әтиеммени?!

Г а б д р а х м а н. И җүләр баш!

З ө б ә й д ә. Алайса нигә син миңа бервакытта да кызым димисең?

Г а б д р а х м а н. Ә кем сине ашата, җүләр баш?! Кем сине киендерә? (*Булмәсенә уза.*)

З ө б ә й д ә. Ашата, киендерә! Синең бар белгәнең шул гына да инде... Әнә гөлне күрәсеңме — гөл булып гөл кояшка үрелгән... Адәм баласы да шулай бит! Аңа да җылы, ягымлы сүз кирәк. Ашатам! Киендерәм! Ул

гына житәмени адәм баласына! Кайчак башыңны кемнеңдер күкрәгенә куеп, бер җылы сүз ишетәсе дә килә бит! Хәтта ул баш җүләр булса да!.. *(Тәрәзәгә килә.)*

Әсхәт керә.

Әсхәт *(Зөбәйдә янына узып ун сум акча суза)*. Син ун сум акча эзләгән идең.

Зөбәйдә *(кинәт исенә килеп)*. Кайдан алдың бу акчаны?

Әсхәт. Таптым.

Зөбәйдә. Кайдан таптың?

Әсхәт. Таптым инде.

Зөбәйдә. Әниеңнекен урлагансың, әшәке малай!

Әсхәт. Юк!

Зөбәйдә. Ә мин әйтәм, урлагансың!

Әсхәт. Юк! Юк!..

Зөбәйдә. Әйдәле әниең янына, карак малай! *(Елый-елый Әсхәтне ишеккә таба сөйри.)*

Әсхәт *(елый-елый)*. Юк! Мин карак түгел! Юк! Бу акча минем үземнеке! Үземнеке!..

Зөбәйдә. Кайдан килде сиңа ун сум акча? Урлагансың! Урлагансың!

Әсхәт. Юк!.. *(Бераздан.)* Мин күгәрченнәремне саттым...

Пауза.

Зөбәйдә. Гафу ит, Әсхәт. Мин сине аңладым... Ләкин син күңелеңне төшермә. Ярата һәм газаплана белү — ул инде зур эш, дустым. Яратуның нәрсә икәнлеген дә белмәүче, таш йөрәкле кешеләр дә бар бит дөньяда. Син әле бик яшь, дустым. Син әле бәхетле булырсың!.. *(Тезләрен кочаклап тәрәзә төбенә менеп утыра.)*

Габдрахман керә.

Габдрахман. Кечкенә бәби кебек тәрәзә төбендә утырма инде. Үзең кияүгә чыгам, дисең!..

Зөбәйдә *(тәрәзә төбеннән төшә-төшә)*. Чыкмыйм мин кияүгә! Чыкмыйм! Чыкмыйм!.. *(Йөгерә-йөгерә чыгып китә. Артыннан Әсхәт бара.)*

Пәрдә.

1961

ӘНИЕМНЕҢ АК КҮЛМӘГЕ

(Әни килде)

Өч пәрдәле драма

КАТНАШАЛАР:

Ана — 75 яшьтә.
Максуд — Ананың беренче улы, 53 яшьтә.
Саймә — Максудның хатыны, 51 яшьтә.
Альфред — аларның улы, 32 яшьтә.
Ислам — Ананың икенче улы, 51 яшьтә.
Расиха — Исламның хатыны, 35 яшьтә.
Рәйхан — аларның кызы, 7 яшьтә.
Инсаф — Ананың өченче улы, 47 яшьтә.
Сәяр — Ананың төпчек улы, 27 яшьтә.
Римма — Сәярнең хатыны, 21 яшьтә.
Гөлчирә — Ананың кызы, 35 яшьтә.
Зөләйха — Сәярнең квартира хуҗасы.
Әлмөхәммәт — Зөләйханың каенатасы, 89 яшьтә.
Гөлсем — авылдан килгән кыз.
Баянчы егет — сүзсез.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ике бүлмәле квартираның аркылы киселеше. Сулда — зал, ул сәхнәнең өчтән ике өлешен биләп тора. Зал төрле елларда төрлечә эшләнгән мебельләр белән җиһазландырылган. Уңдагы бүлмә бик кечкенә. Андагы бар җиһаз — иске тимер караван, тумбочка, ике урындык, ак пәрдә белән капланган кием элгеч һәм иске этажерка. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Бераздан бер-берсенә уралып Сәяр белән Римма керә. Икесенең дә өсләрендә туй киемнәре. Римманың куены чәчәкләр белән тулы. Ишек төбендә үк туктап, озак итеп үбешәләр.

Сәяр. Ниһаять, без үзебез генә! Син минеке! Минем законлы хатыным! *(Римманы үбә.)* Яратасыңмы?

Р и м м а. Яратам! *(Тагын үбәргә килгән Сәярны читкә этәреп.)* Хозяйкаң кая киткән?

С ә я р. Хозяйка бүген өйдә булмаячак! Үзебез генә булабыз бүген өйдә! *(Үбәргә үрелә.)*

Р и м м а *(тайпылып)*. Чәчәкләрне суга куйыйк!

С ә я р. Әйдә үзебезнең бүлмәгә!

Бер-берсенә уралып зал аша узалар, үндагы бүлмәгә керәләр, бусагадан атлауга кочаклашып үбешәләр.

Р и м м а. Чәчәкләрне суга куйыйк!

С ә я р кухня ягына чыгып сулы ваза күтәреп керә. Икәүләп чәчәкләрне суга утырталар.

С ә я р. Туй күлмәге нинди килешә сиңа! Яле, утыр әле менә шунда! Туйганчы бер карыйм әле үзеңә! *(Римманы урындыкка утыртып, ашардай булып карый.)*

Р и м м а. Рестораннан ашыгыбрак киттек. Иптәшләр гаеп иткәннәрдер.

С ә я р. Итсәләр инде!

Р и м м а. Тагын бераз утырасы калган. Тагын берәр сәгать.

С ә я р. Җүләркәем! Тагын бер сәгать түгел, бер минут та көтәр хәлем калмады! Берәүне дә күрәсем килми! Гомеремнең иң бәхетле көнендә синең белән икәү генә буласым килә! Бүген дөнья безнеке, Римма! Хозяйка да кайтмаячак! Өйдә үзебез генә булабыз! *(Тумбочка өстендәге тастымалны ача, анда бер шешә шампан шәрабе һәм алмалар. Үбешәләр.)*

Залга З ө л ә й х а керә. Ул аны-моны уйламастан, үндагы бүлмәгә уза, үбешеп торган яшьләрне күреп кире чыга башлый, ләкин Сәяр аны тотып кала.

З ө л ә й х а. Исәнмесез!

Р и м м а. Исәнмесез!

З ө л ә й х а. Берәр хәл булмагандыр бит?

С ә я р *(шампан шешәсен ача-ача)*. Берни дә булмады, Зөләйха апа! Үзебез шулай тиз тоттык. Язылышып чыккач иптәшләр белән азрак ресторанда утырдык та кайттык. *(Бокалларга эчемлек сала.)*

З ө л ә й х а. Мин сезне соң гына кайтырсыз дип тора идем, бигрәк тиз... Ярый, никахыгыз котлы булсын!

С ә я р
Р и м м а } Рәхмәт!

Зөләйха. Рестораннан ияреп кайтучылар булса дип, пәрәмәчлек камыр куйган идем, хәзер өлгертәм...

Сәяр. Кирәкми, Зөләйха апа! Мин бит әйттем сиңа, туй дигәннең «т» хәрефе дә булмый дидем. Гомернең иң бәхетле көнендә эчеп-исереп утыруны аңламыйм мин. Бүген мин болай да исерек! Берәүне дә күрәсем килми!

Зөләйха. Өйләнештек дип, әллә инде хәзер ашамый да, эчми дә яшәргә уйлыйсызмы? Мин кич кунарга сеңелем янына китәм, өйдә үзегез генә каласыз. Иртә торуга ашханәгә чапмассыз бит! *(Чыга.)*

Сәяр. Ошыймы сиңа минем хозяйкам? Искиткеч апа! Менә күрерсең, бу өйдә безгә яхшы булачак!.. Яратасыңмы? *(Римма яратуын аңлатып баш селки.)* Юк, син телең белән әйт, яратасыңмы?

Римма. Я-ра-там! Приходи к воротам!

Сәяр. Ә нишләп к воротам? Безнең капка төбендә йөргән чаклар узды. Менә өебез! Менә — син! Менә — мин! Я, ничек итеп яратуыңны күрсәт миңа! *(Римма тумбочка өстендәге курчакны алып, күзен йомып торган Сәярнең иреннәренә кагыла.)* И, шулай начар яратасыңмы? Ә мин сине менә ничек яратам! Менә ничек яратам!

Римманы күтәреп алып, иреннәреннән, битләреннән, чәчләреннән үбә башлый. Озак итеп звонок шалтырый. Яшьләр үбешүдән туктап, ал яктагы аяк тавышларына колак салалар. Артта шау-шу, көлешү. Залга Максуд, Саймә, Альфред, Инсаф һәм баянчы егет керә. Максудның кулында зур кәрзин, аннан берничә шешә муены күренеп тора. Саймә чәчәкләр тоткан. Альфред пирог куелган поднос күтәргән. Инсаф таякка таянган һәм ике аягы да протез булу сәбәпле шактый аксый.

Максуд. Вәт безобразие хәзерге яшьләр! Кая качтылар әле? *(Ике бүлмә арасындагы ишектә Сәяр белән Римма күренә.)* Ха-ха-ха! Әле сез бездән яшереп өйләнешеп йөрисезмени? Барып чыкмады! *(Ишек төбенә килеп кычкыра.)* Әйдәгез, әйдәгез, бирегә кертегез! *(Ике кеше диван-караватны күтәреп керәләр.)* Куегыз шунда! *(Ике кеше диван-караватны идән уртасына куеп, чыгып китәләр.)* Ха-ха-ха! Туйларыгыз котлы-мөбарәк булсын, законлы никах белән! *(Көлешә-көлешә яшьләрне котлыйлар.)*

Саймә. Әтисе урынына калган абыйсына да әйтмәгән, ай-һай! Оялмыйсыңмы, энем, бер дә? Максуд,

әйдә тотып кыйныйбыз үзен! *(Шаярып Сәярга суккалап алалар.)*

Сәяр *(аптырап)*. Кайдан белдегез сез?!

Максуд. Әйтмибез!

Саймә. Әйтмә, әйтмә, Максуд! Зурайган, зурайган! Институт бетергән, янәсе, инженер булган! Ай-һай!

Сәяр. Мин бит гел әйтә килдем, Саймә җиңги, туй ясамыйм, дидем! Егерме җиде яшькә җитеп, бик күп туйларда булдым, күрдем. Җыелалар да эчәләр, эчеп исерәләр дә «Алмагачлары» көенә җырлыйлар. Нәрсәсе кызык шуның?

Максуд. Җүләр! Бер җырлашып та утырмагач, өйләнеп тә тормыйм мин аны! Өйләнү көн саен булып тормый лабаса ул! Шул, күп булса, гомер эчендә берике була инде ул өйләнү!

Сәяр. Синеке ничә булгандыр — белмим, ләкин минеке бер генә булачак!

Саймә *(кабаланып)*. Шаяра ич ул, энем! Абыеңны белмисеңмени инде?

Сәяр. Урынын белеп шаярсын!

Максуд *(тиешсезрәк сүз ычкындыруын аңлап, гаепле елмая)*. Ха-ха-ха!.. *(Диван-караватка тотынып.)* Ягез, кая куябыз?

Зөләйха. Әнә теге якка! Аларның бүлмәсе әнә тегендә!

Күмәкләшеп диван-караватны күтәреп алалар да ундагы бүлмәгә узалар, андагы тимер караватны җыеп алып, урынына диван-карават куялар.

Максуд *(диван-караватка утырып)*. Тирбәлеп кенә торачак инде бу!

Саймә *(Максудның аркасына сугып)*. Я, оятсызланма!.. Утырып карагыз инде, энем! Сеңелем, утырып карагыз!

Римма *(диван-караватка утырып)*. Рәхмәт сезгә, зурлагансыз! Гафу итегез безне, уңайсызрак килеп чыкты!

Сәяр. Чыннан да, кем әйтте сезгә?

Максуд. Әйтмибез!

Сәяр *(Инсафка)*. Ә син, абый, ничек Казанда?

Инсаф. Туйга килдем!

Максуд. Туйга килгән, сезнең туйга!

Сәяр. Бөтен планны бозып йөрисез шунда!

Максуд. Әле тагын кунаклар була!

Сәяр. Кемнәр тагын?

Максуд. Ислам белән Расиха!

Сәяр. Тьфу, черт! Соң, мин бит әйтә килдем сезгә, өйләнсәм туй ясамыйм, дидем! Безнең бернинди сыебыз юк! Үзебез дә ресторанда гына ашап чыктык.

Максуд. Оятсызлар! Бүләкнең өстенә менеп утырдылар да бер чынаяк чәй дә кызганалар. Үпкәләдек! *(Килүчеләрне зал ягына куалап чыгарып, ишекне бикләп ала.)* Кияү келәте! Саймә, юкмы шунда берәр таяк? *(Саймә Инсафның таягын тартып алып Максудка бирә. Максуд таяк белән ишекне бикләп куя.)* Кияү келәте! Менә, утырыгыз шунда!

Сәяр *(ишекне тартып)*. Абый, ач!

Максуд. Абыең ач булмас ул, абыеңның ризыгы үзе белән. Саймә, бушат кәрзиннәрне!

Көтелмәгәндә килеп чыккан ситуациядән килүчеләр бик канәгать. Көлешә-көлешә, үзләре алып килгән кәрзиннән өстәлгә ашамлыклар чыгаралар. Зөләйха савыт-саба һәм приборлар китерә.

Сәяр *(ишекне тартып)*. Абый, дим, кара!

Максуд. Карамыйм, энем, карамыйм! Кияү келәтенең ярыгыннан карап йөргәп чаклар узган инде. Оятсыз, абыйсын каратып тормакчы!

Сәяр. Абый!

Максуд. Абыең булсам, туеңа чакырыр идең. Бәлеш исе чыккач кына куштанланма!

Саймә. Ачыйк мәллә, Максуд?

Максуд. Ачмыйбыз!

Саймә. Киленнән яхшы түгел!

Звонок. Ислам, Расиха, Рәйхан керә.

Расиха. Исәннәрмесез!

Максуд. Бик озак җыендыгыз, бүләкнең хәтәрен сайладыгыз, ахры!

Ислам. Чакырмаган туйга нинди бүләк ди аңар!

Расиха. Өй сакларга кеше табып булмады. Рәмзияне барып алып кайттым, Каравайдан.

Зөләйха. Бикләп кенә килергә ярамадымыни?

Расиха. Кайткан төшеңә бөтен өеңне утап куярлар! Безнең поселок шпана оясы бит ул! Җыен каракбандит төрмәдән чыга да шуннан йорт ала. Менә шуның кебек малаена хәтле шпана! Чын! Әле кичә ипи

кибетенә барып килгән арада өч алманы шартлатып өзеп алдылар!

Максуд (*тәрәзәдән үрелеп нидер күзәтүче Исламнан*). Сез нәрсә, машинагыз беләнме?

Ислам. Шулай иде лә. Янында ике малай маташа... (*Тәрәзәдән йодрык селки.*)

Зөләйха. Тимәсләр лә, тимәсләр! Безнең тирәдә караклар юк!

Расиха (*тәрәзәдән үрелеп карап*). Киттеләрме? Халык бик әшәке хәзер. Әле беркөн капка төбендә өч минут торган арада, кадак белән тырнап, машинаның өстенә оятсыз сүз язып киттеләр. Чын! (*Сайманең колагына әйтә, Саймә шаркылдап көлеп җибәрә.*) Яшьләр кайтып җитмәдемени әле?

Максуд. Кайттылар, кайттылар!

Расиха. Чын, яшьләр кайда соң? Әй, Максуд абый сүзенә ышанып йөрсәң — мыскыл итеп чакыргандыр әле! (*Сәяр ишек дөбердәтә.*) Ай алла, бу ни хәл бу?

Сәяр. Безне Максуд абый бикләде, Расиха җиңги! Ач әле!

Максуд (*ишеккә бара башлаган Расиханың юлын бүлеп*). Сабыр ит! Безнең белән утырасылары килсә, чакырсыннар иде...

Ислам. Абый, инженер булгач, понимаешь, туганнарыннан хурланадыр ул, бәлкем! Тик без хатынны кеше почмагына алып кайтмаган идек, кесәдә диплом булмаса да. Я булмаса, хатынымны күреп туймам дип куркадыр!

Максуд. Яшь шул әле, тәҗрибә юк. Хатынның күзгә пәри булып күренгән чакларын белми... Әйдәгез, утырышыгыз! Альфред! Ачыгыз шампанскийларны!

Сәяр (*ишекне кагып*). Ачмасагыз, ватып чыгабыз!

Максуд. Борынына шампанский исе керде тегенең — нинди ярсый! Кычкырма, энем, кычкырма! Менә үз өсң булгач ватарсың, кеше ишеген вату егетлек түгел ул!

Расиха. И, болай күңелле түгел лә, Максуд абый!

Максуд. Бик күңелле! Илле өч яшькә җитеп, мондый кызык туй күргәнем юк иде әле.

Бокалларга эчемлек салалар.

Саймә (*Рәйханны кочаклап*). Һай-һай-һай, бу тиклем матур күлмәкне кайдан алдыгыз, Рәйхан?

Рәйхан. Әни кибеттән алды! Сигез сум житмеш ике тиенгә!

Саймә. Һай, жаным!

Максуд. Ярый, сөйләшүне туктатабыз! Тотыгыз бокалларыгызны! *(Зөләйха салат кертә.)* Зөләйха ханым, тотыгыз! *(Барысы да аяк өсте басып бокалларын күтәрәләр.)* Барыгызга да мәгълүм, жәмәгать, бүген безнең төпчек энебез Сәяр үзенең кәләше белән язылышып кайтты...

Сәяр *(ишек кыйнап)*. Абый, ничек оялмыйсыз!

Максуд. Оялып торырга, энем, без бит синекен эчмибез, үзебез алып килгәнне эчәбез!.. Әйдәгез, жәмәгать, әнә шул юньсезләр саулыгына күтәрик әле!

Эчәләр. Көлешә-көлешә капкалыйлар.

Зөләйха. Салатыннан авыз итегез, кунаклар! Хәзер пәрәмәч өлгертәм! *(Чыга.)*

Максуд. Анасы, син нигә эчеп бетермәдең?

Саймә. Әй, әллә ничек шунда, әче...

Альфред. Баллы түгел, ди!

Максуд. Баллы түгел? Хәзер балландырабыз аны! *(Яшьләр бүлмәсенең ишегә төбенә килеп.)* Ишетәсезме, яшьләр, кунаклар эчә алмый утыра, әче, диләр!

Альфред. Горько!

Күмәкләп. Горь-ко! Горь-ко!

Максуд. Әйдәгез, яшьләр, балландырыгыз шампанскийны! *(Уң яктагы бүлмәдә Сәяр белән Римма үбешәләр.)* Әллә йоклап та киттеләр инде? Яшьләр, дим, кунаклар эчә алмый утыра, баллы түгел, диләр!

Сәяр. Балландырдык инде, балландырдык! Эчегез, эчегез күпсен!

Максуд. Ишеттереп балландырыгыз! *(Сәяр ишек төбенә килеп берничә мәртәбә авызын чупылдата.)* Менә булды! Менә балланды хәзер!.. Равил, сайрат әйдә сандугачыңны! *(Баянчы «Алмагачлары» көен уйный.)*

Әй икегез, икегез лә,
Икегезнең битегез,
Икегез дә пар килгәнсез,
Чукынышып китегез!

Күмәкләп.

Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Р а с и х а. Пар килгәннәрдерме, юкмы — киленне күрмәгән бит әле!

С а й м ә. Килен чибәр!

Р а с и х а. Эшлиме, укыймы?

С а й м ә. Укый! Сәяр бетереп чыккан институттан! *(Җырлый.)*

Минем энем бик зур булды,
Һич килмәгән төше юк —
Дипломы бар, хатыны бар,
Туганнарда эше юк!

К ү м ә к л ә п: Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Р а с и х а. Сөбханалла, күз тимәсен
Зифа буйларыгызга,
Тагын шулай чакырырсыз
Бәбәй туйларыгызга!

К ү м ә к л ә п: Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

М а к с у д. Ай-ли, метро,
Шулай утыру ни тора!

Көлешү, шау-шу. Пәрәмәчләр күтәреп З ө л ә й х а керә.

З ө л ә й х а. Шаярдыгыз, җитәр. Чыгарыгыз инде яшьләрне!

М а к с у д. Чыгармыйбыз!

С а й м ә. Чыгар, чыгар, Максуд!

А л ь ф р е д. Әти, чыгар!

М а к с у д. Тавышка куям! Кем дә кем... *(Сүзен әйтеп бетерми, төрле яктан «Чыгар!», «Чыгар!» дигән тавышлар ишетелә.)* Равил, музыка! *(Баянчы туш уйный.)*

Максуд ишекне ача. С ә я р белән Р и м м а чыга.

С а й м ә. Менә, кызык иттеме абыегыз үзегезне?!

Р а с и х а. Ярар инде, җитәрегез! Утырыгыз, сеңелем! Энем, утыр! Яшьләргә эчемлек салыгыз!

Яшьләрне түргә утырталар. Альфред бокалларга эчемлек сала.

М а к с у д. Әйдәгез, җәмәгать, пәрәмәч алдыннан берәрне тотабыз! *(Бокалын күтәреп.)* Яшьләр исәнләгенә!

Р а с и х а. Озын гомерле булсыннар!

И н с а ф. Өй тулы балалары булсын!

С а й м ә. Әче.

А л ь ф р е д. Горько!

Р а с и х а. Ярарыгыз инде, оялтмагыз яшьләрне!

М а к с у д. Оялтырсың син хәзерге яшьләрне! *(Аяк тибеп кычкыра башлый.)* Горь-ко! Горь-ко!

К ү м ә к л ә п. Горь-ко! Горь-ко!

Сәяр белән Римма үбешәләр. Барысы да эчәләр.

М а к с у д. Вәт безобразие! Менә шулай гөрләтеп туй итәсе урында, качып йөриләр!

А л ь ф р е д. Между прочим, Швециядә шулай. Әгәр кыз кияүгә чыкканда намуслы булса, ул кызны хөрмәт итмиләр.

М а к с у д. Ничек инде ул алай?

А л ь ф р е д. Шулай! Намуслы кызларны санга да санамыйлар анда, гадәт шундый.

М а к с у д. Эх, шунда барып, шул кызларны санап йөрсәң иде!

С а й м ә. Я, тиешле сүз генә сөйләшеп утырыгыз әле!.. Пәрәмәчләре бик тәмле икән, нишләп ашамыйсыз?

И с л а м. Без ашап килдек. Сез әнә яшь киленне сыйлагыз, бик ябык икән!

Р а с и х а. Ябык түгел лә! Хәзер мода шундый — юан кызларны егетләр яратмый. *(Саймәгә.)* Модадан артта калгансың, Саймә апа!

С а й м ә. Калсам инде тагын, мода дип, ач утырыр хәлем юк әле! Ирләр дә эт түгел, сөяккә ташланмыйлар. Ийе бит, Максуд?

М а к с у д. Башка ирләрне белмим, әмма мин үзем хатын-кызның шундыен яратам: арт ягына бер китереп суккач, сәгать ярым дерелдәп торсын ул миңа! *(Зөләйханың кемнедер каршы алуын күреп.)* Кем бар анда. Зөләйха ханым?

З ө л ә й х а. Әткәй ул. Туганнарны күрергә дип, авылга кайтып киткән иде, шул кайтты.

М а к с у д. Табын янына чакырырга кирәк!

З ө л ә й х а. Килешерме икән соң?

С а й м ә. Нишләп килешмәсен! Сәяр, бар, алып кер бабайны!

Сәяр чыга. Ә л м ө х ә м м ә т картны ияртеп керә.

Сәяр. Әйдә, утыр, бабай! Берәрне җибәрәсеңме?

Әлмөхәммәт *(утырып)*. Килен рөхсәт итәрме икән соң?

Зөләйха. Рөхсәт, әткәй, рөхсәт!

Әлмөхәммәт. Ярый, алайса, яшьләр исәнлегенә булсын, бәхет-тәүфыйк белән гомер итсеннәр! Бисмилла рахманрахим *(Эчә.)* Әйбәт булган, яхшы. Сәярның бәхете бар аның. Укып бетергәч, Казанда да калдырдылар үзен. Әнә безнең малай, җир читенә китте дә, ялга да ике елсыз кайтып булмас, дип яза. *(Зөләйхадан.)* Хаты бармы?

Зөләйха. Бар, әткәй, бар! *(Башкаларга.)* Минем улымны әйтә. Узган ел геологическийны бетергәч, Чукоткага киткән иде.

Максуд. Башы исән булсын, бабай! Исән булса, бер кайтыр.

Әлмөхәммәт *(кинәт уйга калып)*. Анысы хак сүз. Исән кеше бер кайтмаса да бер кайта. Үлгәннәр кайтмый...

Зөләйха. Пәрәмәчләрне суытып бетерделәр инде! Кунаклар, ашап утырыгыз инде!

Альфред. Между прочим, кунакны кыстау культурно түгел! Менә, мәсәлән, Парижда нишлиләр? Кунаклар җыела. Ну, өстәлдә һәммәсе дә бар, конечно. Коньяк, төрле-төрле винолар һәм бер-ике генә төрле закуска. Хуҗа кеше беренче рюмканы эчәргә генә тәкъдим ясый да, шуннан соң кем ни теләсә, шуны эшли. Эчәсе килгән кеше — эчә, ашыйсы килгәне — ашый. Ә кыстау юк. Кунакны кыстау некультурно санала.

Зөләйха. Саналса саналыр тагын! Без Парижда түгел бит әле, Казанда. Ә безнең халыкта әүвәл-әүвәлдән килгән бик матур бер гадәт бар: кунакны аяк өсте басып сыйлыйлар. *(Тәрәзәдән урамга карап торган Исламга.)* Машинагызны күтәреп китмәгәннәрме?

Ислам. Күтәреп китә алмыйлар аны! Аның бит авырлыгы ике мең сигез йөз килограмм!

Әлмөхәммәт *(Альфредка)*. Карале, энем, син ул Париж дигән җирдән күптәнме кайттың?

Кунаклар пырхылдап көлеп җибәрәләр. Сәяр кесәсеннән сигарет чыгарып тарта башлый. Альфред та тарта.

Саймә. Тотындылар инде пыскытырга! Агуламагыз әле һаваны, башыма ярамый!

Сәяр. Бу зарарлы сигарет түгел, Саймә жиңги. Бу — фильтрлы сигарет! *(Әлмөхәммәткә.)* Берәрне тартып жибәрәсеңме, бабай?

Әлмөхәммәт. Рәхмәт, улым. Кырык ел тарттым, житәр.

Сәяр. Ничек ташлый алдың, бабай? Мине дә өйрәтсәң икән!

Әлмөхәммәт. Ничек дип, ташлыйсың килсә, тотасың да ташлыйсың инде, аның өчен курсы бетерү кирәкми. Утыз сигезенче елны ашказанымда язве таптылар минем. Апиратсыга салдылар. Прафисыр Думбрачев әйтә,— хәзер үзе дә мәрхүм инде, рәхмәт төшкере,— апиратсы ясыйм, брат, ди. Но түлке тәмәке тартуны ташлыйсың, ди. Ташладым!

Сәяр. Шуннан бирле бер дә тартканың юкмы, бабай?

Әлмөхәммәт. Юк. Сестра кереп, бабай, апиратсыга дигәндә, берне чорнап кабызган гына идем. Шул сүзне ишетүгә, тарта башлаган тәмәкемне ташлап, апиратсыга йөгердем. Тартуны ташлавыма үкенмим. Но түлке апиратсыга чакыргач, тартып бетермичә ыргыткан шул төпчегемне әле дә булса жәлләп торам. Тартып бетерәсем калган икән шуны апиратсыга кергәнче.

Альфред. Ха! Ха! Ха! Бу өйдә туалет бармы? Булса — кем аны миңа күрсәтә? *(Сәяр Альфредны туалетка озата.)*

Әлмөхәммәт *(Альфредның артыннан)*. Шәм тотып торучы да кирәкмиме, энем?.. Хуш! Бу кемнәрең була соң инде синең, Сәяр?

Сәяр. Туганнарым, бабай. Менә бусы — иң олы абыем, заводта мастер булып эшли. Монысы — аның хатыны Саймә жиңги, трамвай йөртүче.

Әлмөхәммәт. Ничәнче трамвайда эшлисең?

Саймә. Сигезенче маршрутта, бабай, нәкъ мәчеткә илтә торган трамвай!

Әлмөхәммәт. Мәчеткә барганда билет алып тормыйбыз икән болай булгач.

Саймә. Бик алмый торгансың әле, бабай! Мәчеткә йөрүче картлардан бик билет алдырып булмый алардан!

Максуд. Ник?

Саймә. Алмыйлар! Менә шундый мулла шикелле картлар жомга саен вагонга кереп тулалар — ник берсе

билет алсын! Кычкырышып бетәм мин алар белән. Чукынган картлар, мин әйтәм, ичмасам, алла юлында йөргәндә хөкүмәтне алдамагыз!

Сәяр. Менә ,бу — минем икенче абый, бабай. Әле күптән түгел генә пенсиягә чыгып, Магадан өлкәсеннән кайтты. Йорт алып Казанда тора хәзер.

Әлмөхәммәт *(Исламга)*. Бик яшь күренәсең түгелме соң?

Ислам. Минем стаж горняцкий, бабай, подземный. Шахтерлар пенсиягә илле яшьтән чыгалар.

Сәяр. Бусы — аның хатыны Расиха җиңги. Ә менә монысы, бабай, өченче абыем — Инсаф абый. Ватан сугышы инвалиды. *(Инсафка.)* Абый, син чыннан да минем туйга килдеңме?

Инсаф. Әйе!

Саймә. Әй, юк ла! Бу туганыбыз бик авырый безнең, бабай. Сугышта алган яралары төзәлеп бетми. Больницага ятарга килгән.

Әлмөхәммәт. Туганнарың күп икән, Сәяр...

Сәяр. Әле монда барысы да түгел, бабай. Без тугызау! Унау булганбыз да, бер абый сугыштан кайтмады.

Әлмөхәммәт. Сөбханалла, бай егет икәнсең! Туганнар — байлык ул, туганнарның күп булуы яхшы. Менә бит, нинди зур байлык бүләк иткән үзегезгә әтиәниегез!

Рәйхан *(алгарак чыгып)*. Ә мин — Рәйхан!

Альфред керә.

Альфред. Ә шулай да дөньяда яшәү күңелле!

Саймә. Монысы минем улым, бабай! Исеме Альфред!

Әлмөхәммәт. Исеме матур икән егетнең. Чын мөселманча исем — Әлфәрит.

Саймә *(хихылдап)*. Әлфәрит түгел, бабай, Альфред!

Расиха. Я, карт кеше белән сүз көрәштереп утырма, киртәсенә керсә ярар!

Әлмөхәммәт. Дөрес итеп әйтсәң — Әлфәрит ул. Бу дөньяда тиңдәше булмаган, бердәнбер нәрсә дигән сүз. Минем үз исемем дә шулайрак — Әлмөхәммәт. Ә менә Фәрит сүзе белән Мөхәммәт алдыннан килүче «Әл»— гарәпләрдә тәгъриф дип йөртелгән бер нәрсә ул.

Безнең татар теле белән урыс телендә андый хикмәтле нәрсә юк. Гарәпләрдә бар! Немечләрдә дә бар! Унбишенче елны плен төшеп, дүрт ел буе бер немеч маржасының сыерларын карап тордым мин. Унике сыер! Менә немеч халкының да телендә тәгъриф кебек нәрсә бар. Әнә укыган кешеләр беләдер. Ничек була немеччә икмәк? Дас брот?

Сәяр. Дөрес, бабай!

Әлмөхәммәт. Менә шуның «брот» дигәне икмәк дигән сүз инде аның. «Дас» дигәне — гарәпләрдә тәгъриф дип йөртелүче бер хикмәт. Их эшпрәйхен дойч бит!

Саймә. Һай, бабай дигәнебез бездән галимрәк булып чыкты ич!

Альфред. Эссе! Барыгыз да күрдеме минем пиджакны? Күрсәгез, салып куям! *(Пиджагын салып урындык аркасына элә.)*

Әлмөхәммәт. Алай дисәң, ыштаныңны да күрдек инде, энем!

Расиха. Иптәшләр, тыңлагыз! Хәзер сезгә Сабирова Рәйхан җыр җырлап күрсәтә! Яле, кызым, теге җырны җырлап бир әле үзләренә!

Рәйхан *(урындык өстенә менеп басып җырлый)*.

Әрнемә, сызлама, юксынып, йөрәгем,
Сагынып, саргаеп, өзелмә, үзәгем.
Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә
Карлыгач шикелле талпынып һәр язда!

Көлешү, кул чабулар. Кунаклар җырны күтәреп алалар. Звонок, Зөләйха ишек ачарга чыга. Бераздан ишектә Ана белән Гөлсем күренә.

Саймә *(абына-сөртенә Анага каршы йөгерә)*. Һай, җаным, әни килде ич! Әни килде, Максуд!

Барысы да ишек төбенә җыелалар. Ананы уратып алалар. Гаҗәпләнү авазлары, исәнләшү.

Зөләйха. Бәхетленең кунагы да дөрен-дөрен булыр ди — менә бит!

Саймә. Сәярың өйләнде ич, әни! Менә бу синең кече киленең була! Белеп килдеңме соң син, әни, белмичә генәме? Һай, җаным, күр әле бу тамашаны!

Максуд. Төпчегең өйләнде бит, әни! Туй бүген!

Сәяр *(алгарак чыгып)*. Юк-юк, әни, туй мәҗлесе түгел бу!.. Мин туйсыз гына өйләнергә булган идем дә,

әни... менә алар әллә кайдан ишеткәннәр дә бәреп керделәр! Син рәнҗемә инде, әни, туй түгел бу!.. Менә, таныш бул, әни, бу минем... бу синең киленең була. Исеме — Римма... Рәнҗемә инде син, әни, мин бит шаушусыз гына өйләнәсе булган идем... *(Риммага.)* Я, таныш инде — әни бит!

Ана акрынлап үзен кулга ала. Алгарак узып, Сәяр белән Римманы күкрәгенә кыса. Яшьләрне аралап, Ананың итәгенә Рәйхан сарыла.

А н а *(Рәйханны күтәреп алып).* Кызым Рәйхан лабаса бу! Нинди зур булып үскән минем кызым!

З ө л ә й х а. Үрә каттылар! Табын янына чакырыгыз әниегезне!

С ә я р. Әни, менә бу апа — минем квартир хозяйкам!

З ө л ә й х а. Исәнмесез! Танышу качмас. Башта әниегезне табын янына утыртыгыз!

А н а *(Инсафны күреп).* Син дә Казандамы, улым? Үзең генәме соң?

И н с а ф. Үзем генә, әни!

А н а. Килен белән балалар исән-саулармы?

И н с а ф. Исән-саулар, әни!

С а й м ә. Әйдә, утыр, әни, утыргач сөйләшербез!

А н а. Өстемне алыштырам.

С а й м ә. Соңыннан алыштырырсың, әни, соңыннан!

А н а. Юк, соңыннан түгел, хәзер алыштырам! Улымның туенда бу килеш утырырга, мин соң...

С ә я р. Туй түгел бу, әни! Монда ничек тә ярый!

А н а. Юк, ярамый! Өстемне алыштырам! *(Саймә белән бергә чыгалар.)*

М а к с у д *(Сәярдән).* Әнигә дә хәбәр итмәгән идеңмени?

С ә я р. Юк дип әйттем бит инде!

М а к с у д *(Гөлсемгә).* Бик озак эзләп йөрмәдегезме соң, сеңелем?

Г ө л с е м. И, сорамагыз инде, абый! Көне буе Казан буйлап чаба-чаба әбине үтерә яздым. Башта әбинең олы малаена барган идек...

М а к с у д. Менә мин ул әнинең олы улы.

Г ө л с е м. Адресыгыз белән барып төшсәк — унбишенче йорт юк!

М а к с у д. Безнең йортларны сүттеләр бит, сеңелем!

Гөлсем. Шуннан әбинең поселоктагы малаен эзләп киттек...

Максуд (*Исламга күрсәтеп*). Анысы менә ул була инде!

Гөлсем. Көч-хәл белән эзләп тапсак — аларның да капкалары бикле, ишекләрендә ат башы хәтле йозак.

Расиха. Йозак?!

Гөлсем. Әйе!

Расиха. Теге чукынган кыз ишеккә йозак салып чыгып киткән икән! Ислам!

Максуд. Я, өегезне күтәреп китмәсләр инде! Сон, шуннан, сеңелем!

Гөлсем. Шуннан әби әйтә, Казанда минем тагын бер улым бар бит әле, кызым, янымда адресы гына юк, ди. Киттек справочный эзләп. Шунда әйтеп бирделәр тагын...

Ананы култыклап Сайма керә. Ананың өстендә озын итеп тегелгән ап-ак ефәк күлмәк, зәңгәрсу камзул, башында ак ефәк яулык белән ефәк шәл, аякларында чигешле читек. Бу киемнәрдә Ана бөтенләй яшәреп, матурланып киткән.

Саймә. Әйдә, әни җаным! Урынның иң мәдехлесе синә бүген, әни! Утыр әле менә шунда! (*Ананы өстәлнең иң түренә, Сәяр белән янәшә утырта.*) Күрегез әле, күрегез әле безнең әнинең матурлыкларын! Кызлар кебек ләбаса безнең әни, һай, җаным, күз тимәсен! Һай!.. Сәяр, син тагын әнине бикәчең белән бутама!

Максуд. Вәт безнең әни! Әни нинди дә, без нинди! (*Корсагын бәргәләп көлә.*)

Саймә (*соклануында дәвам итеп*). Һай, кыз чагында нинди әк булдың икән син, әни?! Яман да чибәр булгансың син кыз чагында, сөйләп тә бетерерлек булмагандыр. Тирә-як авылларның егетләре сиңа гыйшык тотып үлгәннәрдер!

Ана. Әллә тагын, алай үлгәннәре үк ишетелмәде.

Саймә. Үлгәннәрдер, үлгәннәрдер, әни, әйтмисең генә. Ничәдә кияүгә чыккан идең?

Ана. Егерме бердә.

Саймә. Ә, менә бит! Ул заманда унбиш-уналтыдан чыга булганнар, син күпме сайлап утыргансың!

Ана. Сайламадым! Әти рөхсәт бирмәде!

Саймә. Иртә чыгаргамы?

Ана. Атагызга чыгарга. Ахрысы, чыннан да чибәр булганмын, яучылар күп килде. Әти гел үзенә ошаган

якка тартты, хәллерәк кешегә бирәсе килде. Мин үзем теләгән якка тарттым. Менә шулай, әти белән тарткалаша-тарткалаша үземнекен иткәнче, егерме бер тулды да куйды.

Зөләйха. Ярый, кунакны сүз белән сыйламыйлар. *(Гөлсемгә.)* Сеңелем, нигә анда басып торасың? Кил, утыр!

Ана *(үз кырыннан урын биреп)*. Кил, кызым, үземнең янга!

Саймә. Ә, юк, әни янында үзем утырам! Синең белән янәшә утыру — бик зур дәрәҗә бит ул, әни! Мин синең олы киленең, синең кырында мин утырырга тиеш! *(Ана янына утырып, Гөлсемгә урынны Альфред кырыннан күрсәтә.)* Менә шунда утыр, сеңелем! *(Гөлсем утыра.)* Чибәр кызны улым янына утыртыйм әле. Белмәссең!

Максуд. Утырма, сеңелем, моның янына, утырма! Бу инде хатын аерган татар!.. Әни, безнең Альфредны хатыны куалап чыгарды бит әле!..

Уңайсыз пауза.

Саймә. Чыгарса тагын! Әллә минем улыма кызлар беткәнме!.. *(Максудка.)* Үз улының гайбәтен чәйнәп утырган була тагын, о!..

Ана *(сүзне икенчегә бору кирәклеген аңлап)*. Бик сусадым, кызым, берәр чынаяк чәең булмасмы?

Расиха. Чәй! Әнигә чәй китерегез, чәй!

Ислам. Әнигә чәй ясап китерегез инде, понимаешь!

Зөләйха чыга.

Ана. Ягез, исән-сау торасызмы, балалар, авырмыйсызмы?

Максуд. Юк, әни!

Расиха. Авырмыйбыз, әни! Барыбыз да тап-таза, ат кебек!

Ислам. Сабан туенда батыр калырлык куәт бар әле, әни, пенсиядә булсак та!

Расиха. Әни, ничек болай бер дә хәбәр итмичә киләсе булдың?

Ана. Иптәш булгач, борчып тормадым инде. Киләсе дә түгел идем. Бүгенле-иртәгәле уракка төшәргә торалар — эш өстендә кем йөри Казан буенда! Менә Гөлсем. Әйдә булгач, әйдә, дип, күземне дә ачтырмады.

С а й м ә. Яхшы булган! Шулай итеп кенә алып килмәсәң, китереп буламыни безнең әнине! Рәхмәт сиңа, сеңелем, әнине алып килгән өчен!

Р а с и х а. Бик әйбәт булган, бик әйбәт булган...

Зөләйха Анага чәй кертеп бирә.

С а й м ә *(куштанланып, шул ук вакытта азрак иркәләнеп тә)*. Әни! Яшь киленне яраттыңмы соң, әни, нигә бер дә дәшмисең?

А н а *(акланган кебегрәк)*. Ул хакта сөйләшергә вакыт юк лабаса әле... *(Торып басып.)* Төкле аягы белән килсен! Улымны яраткан кешене мин яратырмын. Минем улымны яратып килгән ләбаса ул, шундый кешене ничек яратмыйсың! *(Муеныннан гәрәбә муенсасын салып Риммага кидерә.)*

Р и м м а. Рәхмәт!

А н а. Киленнәрдән бәхетем бар минем, берегездән дә авыр сүз ишеткәнем юк!

М а к с у д. Бергә тормаганга күрә генә шулай ул, әни!

А н а. Нишлисең бит, улым, бергә торырга насыйп булмаган. Лачындай җиде малай үстердем — җидесе җиде якка очты да таралды. Канат чыгарганнарын да сизми калдым. Өч кыз бала үстергән идем, алары да туган ояларын ташлап очып китте... Карасана, абыстай шикелле җәелдем дә утырдым! Күчтәнәчләремне чыгарырга оныткланмын лабаса! *(Гөлсемгә)*. Кызым, әйдә, булыш әле миңа! *(Гөлсем белән коридорга чыгалар.)*

С а й м ә. Һай, җаным, бигрәк күңелле көн булды ич бу!

Г ө л с е м чемодан кертеп куя. А н а зур кәрзин күтәреп керә.

М а к с у д *(Исламга)*. Әни әйтә, киленнәрдән бәхетем бар, ди. Безнең генә хатыннардан бәхет булмады!

С а й м ә. Өйгә кайтасың барын онытма! Өйгә кайтасың барын онытма! *(Ана күчтәнәчләрен чыгара башлый)*. Һай, бу тиклем җиләкне кем җыеп бетергән моны?

А н а. Үзем җыйдым. Кәрим тугаенда җиләк бик күп быел. Менә, кусгыз әле шунда табынга. Берсендә каен җиләге вареньесы, икенчесендә — җир җиләгенеке.

С а й м ә. Һай, бу тиклем дә хуш исле итеп кайната белерсең икән, әни! *(Варенье савытларын иснәп.)* Исен

күрегез әле, исен!.. *(Ананың колагына иелеп.)* Әни, күчтәнәчләреңнен барысын да чыгарып бетермә, безгә дә алып барырсың!

Ана *(төргәк биреп)*. Менә монысы каклаган каз. Берәрегез кайтмасмы дип саклаган идем, кайтмадыгыз да быел... Әллә ни күчтәнәчем юк, кызым. Сыерны сатканнан бирле, килә башласаң аптыраш — ни алып килергә белмисең.

Ислам. Безгә монда берни дә кирәкми, әни! Безнең барысы да бар!

Расиха. Әйе, барысы да бар! Аллага шөкер, ач ятмыйбыз!

Ана. Ач ятмасагыз да, ана булган кешенең алып килеп авыз иттерәсе килә шул. *(Чемоданга күрсәтеп.)* Әнә, өчегезгә өч йөз күкәй, санап алырсыз. *(Инсафка.)* Синең Казанда икәнеңне белмәдем инде, улым...

Саймә. Шаярып әйткәнне чынга алма тагын, әни. Синнән күчтәнәч көтмибез. Син үзең безгә күчтәнәч!

Ана *(Рәйханга күкәй биреп)*. Мә, кызым пешкән күкәй сиңа!

Ислам. Ашамый ул күкәй, әни! Безнең үзебездә егерме тавык, коеп кына торалар!

Рәйхан Ананың итәгенә менеп утырып муенына урала, колагына нидер пышылдый.

Саймә. Нәрсә серләшкән булалар соң болар?

Рәйхан. Әбием! Без утырткан алмагачларның алмасы бармы инде?

Ана. Юк әле, кызым! Алмагач өч-дүрт елсыз җимеш бирми әле ул.

Зөләйха. Бигрәк ярата икән инде бу кыз әбисен!

Саймә. Яратмаска — әни үстергән Рәйхан ич ул! Сигез айлык чагында әнигә кайтарып аттылар да, алты ел буе әбисендә үсте ич ул Рәйхан! Әбиеңне яратасыңмы, Рәйхан?

Рәйхан *(Анага уралып)*. Яратам!

Саймә. Әбиең картайган ич инде, аның кай җирен яратасың?

Рәйхан. Картаймаган!

Саймә. Картайган шул! Әнә бит, чәчләре ап-ак!

Рәйхан. Синең үзеңнеке ак, гел буятып йөрисең!

Максуд. Ярый, сүзне туктатыйк! Мәҗлес дәвам итә! Менә яшьләр! Менә нур өстенә нур булып әни

килеп төште — тагын да күнелле булып китте. Әни, син гаеп итмә инде, без берәрне тотыйк!

Әлмөхәммәт. Әбигә салмыйбызмыни?

Максуд. Чыннан да, әни, әллә бераз авыз итәсенме, кызылдан гына? Актык туең бит бу, әни! Кызларын барысы да кияүдә. Инде менә малайларың да өйләнеп бетте. Башка туй булмаячак, әни!

Ана. Кыстама, улым. Менә алдымда чәем.

Зөләйха. Салып куегыз сез ана, эчмәсә дә тулып торсын!

Максуд. Дөрес! Әнинең бәхете тулып торсын әле! *(Ана алдына тулы бокал куялар.)* Ярый, җәмәгать! Яшьләр саулыгына эчтек. Инде хәзер дөньяда иң якын кешебез булган, барыбыз өчен дә кадерле әни саулыгына эчәбез!

Эчәләр.

Саймә. Әни! Улларың күзеңнең алдында эчеп утырганга рәнжемисеңдер бит?

Ана. Шушындый көнне дә эчмәгәч, ул ни була ди инде аннары! Аллага шөкер, ул яктан мактанычым зур — эчми минем улларым! Җиде малай үстердем, җидесенең берсе аракы эчеп, ил күзендә рисвай булып йөрмәде. Эчми минем улларым! Эчмиләр дә, тартмыйлар да!

Саймә. Сәярың тарта, әни!

Сәяр *(Ананың йөзе кинәт үзгәреп китүне күреп).* Юк, әни, юк, тартмыйм! Саймә җиңги юри генә әйтә!

Саймә *(хихылдап).* Тартасың! Тартасың!

Расиха. Тарта, тарта, әни!

Альфред. Ну, тартса?!

Уңайсыз пауза.

Зөләйха. Картаеп беткән кешене үчекләп утырырга бер дә оялмыйсызмы? Тартмый, әби, тартмый. Малаең елга якын миндә тора, тартканын күргәнем юк.

Саймә *(хатасын аңлап).* Юк-юк, әни, тартмый, шаярып кына әйттем... *(Тәрәзә янына килеп.)* Уф, әллә яңгыр яварга җыена — авыраеп торам!

Максуд. Син авырайган саең яңгыр ява башласа, җир йөзен әллә кайчан су баскан булыр иде инде!

Көлешү.

С а й м ә. Чынлап менә! Аз гына ашадым исә, авыраям да китәм. Ятасым гына килеп тора.

Әлмөхәммәт. Симеребрәк киткәнсең шул, авырайсаң да гаҗәп түгел.

С а й м ә. Симерәм ич! Юньләп ашавым да юк инде үземнең. Әллә саф һава симертә — без торган җирнең һавасы яхшы бит.

Әлмөхәммәт. Саф һава белән генә симереп булмый...

С а й м ә. Әй, юк ла, хатын-кыз иллегә җиткәч шулай юаная инде ул... Алай дисәң, менә әни бер дә симерми. Әни, нишләп син симермисең икән? Сигезенче дистә белән барасың — фигураларың кызларныкы кебек!

Р а с и х а. Чын! Бер дә картаймый безнең әни!

С а й м ә *(Ананың күкрәкләрен капшап)*. Күрегез инде, күрегез! Кем әйтер инде моны ун бала табып үстергән хатын дип! Күзләре дә утлы күмер кебек елтырап кына тора безнең әниның! Әллә картаймауның берәр серен беләсеңме син, әни? Өйрәт әле безне дә, ничек шулай сакландың?

А н а. Ашагач түл җыеп ятып торырга вакыт булмады, кызым. Шуңадыр.

С а й м ә *(Инсафка)*. Син нишләп сөйләшми утырасың — телеңне йоттың мәллә! Әни, бөтен балаларың ядрә күк чәчрәп торалар, нишләп бу Инсаф кына мондый юаш булган?

А н а *(Инсафның башыннан сыйпап)*. Кечкенәдән шулай оялчанрак булды шул ул Инсаф. Оялчан булса да, батыр йөрәкле иде үзе. Бервакыт Инсаф белән Ислам, янә дә Кәрим Иделгә су коенырга төшеп киткәннәр. Кәрим бата башлаган. Ислам җан-фәрманга чабып кайтып керде. Кәрим Иделгә төшеп батты, ди. Шуннан олылар Идел буена йөгереп төшсәләр — Инсаф Кәримне яр кырыена сөйрәп чыгарган. Ничә яшьтә булгандыр инде ул чакта, унөч-ундүрттән артык түгелләр. Кәрим үзеннән зуррак бит әле, ул Ислам белән бер елгы... *(Исламга ымлап.)* Монысының шунда иптәшен коткару өчен суга сикереп төшәргә йөрәге җитмәгән, үкереп авылга кайткан!..

Көлешү.

И с л а м. Ярый инде, әни, үткән эшкә салават! Син менә шуны әйт: кайчан үзеңне Казанга алып киләбез?

Берүзенә генә анда күңелсездер бит синең. Яшең дә шактый. Әйдә, Казанга күчеп кил, әни! Үземдә торырсың!

Р а с и х а. Шулай шул, әни, чын! Үзебезгә кил!

И с л а м. Сине әллә кайчан аннан алып китү тиеш иде дә, понимаешь, миннән башка моны эшләүче булмады. Инде менә мин кайттым, әни. Күп акча белән кайттым, баеп кайттым!

С а й м ә. Малаеңның байлыгын сөйләп тә бетерә торган түгел, әни, яман да баеп кайтты малаең. Өйләренә барып керсәң, әйләнеп чыга торган түгел — шул тиклем байлык!

И с л а м. Житкән, әни, сиңа тирестә казынып яту! Алып киләм мин сине, әни!

А н а. Белмим шул, улым. Атагызны ташлап китү авыр.

И с л а м. Әллә кайчан череп беткән кешенең каберен берәү дә саклап утырмый, әни. Каберне күтәреп китмиләр аны.

А н а. Нигезне дә нәүмиз калдырасым килми. Ничә бабкә типкән, күпме гомер иткән нигез бит ул!

И с л а м. Синең ул чалышаеп беткән нигезеңне, әни, ут төртеп яндырасы гына калган!

Р а с и х а. Чын! Ут төртәбез дә яндырабыз!

И с л а м. Бер ялгызың яшәп, акылдан шашарга мөмкин бит анда, понимаешь! Әгәр теләсәң, әни, үзеңне менә хәзер үк машинама утыртам да выжт иттереп өемә алып кайтып куям! Түр башына менгезеп утыртам! Машина әнә тәрәз төбендә генә тора!

С а й м ә. Кара боларны! Сездән алда әниеңең олы малае белән олы килене бар шул әле монда, алар нәрсә әйтер бит. Ийе бит, Максуд? Юк-юк, әни, киләсе булсаң, беркемгә дә түгел, үзебезгә киләсең!

Р а с и х а. И ходаем, үзләренең кеше сараенда яшәгәннәрен белми!

С а й м ә. Яшәсә! Яңа йорт салынып беткәнче генә ич ул, көзгә хәтле генә! Тиздән безгә яңа квартира бирәчәкләр, әни. Җәй өчен бакчабыз да күңелле. Алмагачлар арасында җырлап кына йөр!

Р а с и х а. Һа, бөтен бакча эшен әнидән эшләтеп ятар иде бугай!

С а й м ә. Ятса! Җиләк жыешканнан гына әллә ни булмас әле әнигә. Ийе бит, әни?

А н а. Эштән курыккан юк ла анысы.

И с л ам. Алып киләсе булгач, әллә кайчан алып киләләр аны! Нигә мин кайтканчы суздыгыз?

И н с а ф. Әти үлгәч, мин аны Чистайга алып китмәкче идем — бармады.

С а й м ә. Әйе! Үзе теләми ич ул! Юк-юк, әни, киләсе булсаң, олы малаеңа киләсең, үзебезгә!

И с л а м. Абыйга килсәң, рәтле тормыш булмаячак сиңа, әни! Саймә ул ашаган табагын юарга да иренә!

С а й м ә. Иренсә! Син килеп юмыйсың ич аны! Икенче ашарга кирәк булгач юыла ул шунда... Синең Расихаң аш та пешерә белми әле!

Р а с и х а. Белмәс инде!

С а й м ә. Белмисең шул! Әллә әнине чи өчен үзегезгә китерәсегез килгәнне белмиләр дип уйлыйсызмы? Бөтен йорт эшен әнигә ташлап, эшкә кермәкче була ич ул Расиха! Картайган төшкә стажы юк ич аның!

И н с а ф. Үзебезгә кил, әни! Бездә сиңа бер эш тә булмаячак.

Р и м м а. Туктагыз әле, абыйлар, апалар! Әнине безгә кил дә, безгә кил, дип тарткалыйсыз, ә безне санга да сукмыйсыз. Без дә бар ич әле монда! Әллә сез әнине бездән артыр дип уйлыйсызмы? Шулай бит, Сәяр?

С ә я р. Шулай булмыйча! Күңелсезләнә башласа, үзенә кибеттән бер бәби алып кайтып бирербез — тик уйнап утырсын!

И с л а м. Анысын булдырырсыз ла!

Р а с и х а. Әнидән бала каратып ятмакчы — хитрый!

С а й м ә. Әй, юк ла, булмаганны! Сез әле үзегез дә кеше өендә торасыз.

Р и м м а. Кеше өендә дип, алай кимсетеп ташламагыз әле сез, апа. Гел кеше өендә булмабыз, үзебезгә дә бирерләр.

А н а. Тәмле сүзләрегез өчен рәхмәт, балалар! Бәхәсләшмәгез, килмим. Турысын гына әйткәндә, кирәгем бар әле минем анда.

И с л а м. Кемгә кирәк син анда?!

А н а. Кемгә булсын — колхозга! Тизрәк кайт, әби, дип өзгәләнеп калды бригадир әле менә хәзер дә. Районнан берәр кеше килсә, я булмаса Казаннан, барысы да кич кунарга миңа килә.

И с л а м. Әти шул колхоз, колхоз дип үлгәнче йөр-

гән иде, инде син! Ни кырдыгыз соң гомер буе шул колхозга эшләп, баедыгызмы?

А н а. Баедык шул!

И с л а м. Кайда ул сезнең байлыгыгыз? Книжкедәме?

А н а. Менә бит, барыгыз да шул колхоз икмәген ашап үскән балалар! Шуннан да зуррак нинди байлык бар?!

М а к с у д. Ярый, житте, жәмәгать, туктатыгыз! Аптыратмыйк әнине! Үзе теләгәнчә яшәсен. Инде бер үземә генә авыр дип әйтә икән — килсен. Без тугызау. Тугызыбыз өчен дә әни — кадерле кунак. Әйдәгез, бер биеп алабыз! Равил, музыка!

Баянчы вальс уйный. Сәяр белән Римма, Альфред белән Гөлсем вальс әйләнә башлыйлар. Ана алдагы планда утырып калган Әлмөхәммәт янына килеп утыра.

А н а. Син кем буласың соң, бабай?

Ә л м ө х ә м м ә т. Мин Зөләйханың каенатасы. Зөләйха синең улыңның фатир хуҗасы. Әле менә синең язмышыңа сокланып утырам. Улларың әйбәт, әни дип өзелеп торалар.

А н а. Минем улларым алтын шул, бабай!

Ә л м ө х ә м м ә т. Бәхетле ана булгансың шул син. Картлык көнендә газиз балаларыңның таза-сау булуларын күрүдән дә зуррак ни бәхет бар!

А н а. Дөрес, бабай!

Ә л м ө х ә м м ә т. Без дә мәрхүмә карчыгым белән арыслан-арыслан дүрт малай үстергән идек, дүртесе дә сугыштан кайтмады... Чыдаса да чыдый икән ата-әнкә бәгыре!

А н а. Ата-әнкә чыдый инде ул, бабай. Безнең дә бер улыбыз сугышта югалды. *(Инсафка ымлап.)* Икенчесен әнә гомерлек гарип итеп кайтардылар... Карчыгың үлдемени инде, бабай?

Ә л м ө х ә м м ә т. Күптән! Унсигез ел инде килен белән икәү генә торабыз. Ул тол, мин тол. Ике сабый белән утырып калган иде, бергә-бергә шуларны үстердек. Кызыбыз буйга житте дә кияүгә чыкты. Улыбызны укуын бетергәч ерак жибәрделәр, кайтып кына житә торган да түгел. Шулай итеп, тагын без ике ятим үзебез генә калдык...

А н а. Башы исән булсын диген, бабай. Башы исән кеше әйләнә дә бер кайта ул.

Ә л м ө х ә м м ә т. Анысы хак. Исән кеше әйләнә дә бер кайта. Үлгәннәр кайтмый!..

Вальс бетә. Баянчы бию көе уйный. Зөләйха белән Гөлсем савыт-сабаны җыеп чыгалар. Максуд бии. Башкалар урындыкларны читкәрәк тартып зал уртасын бушаталар. Максуд Саймәне чакыра. Саймә алпан-тилпән бераз бии дә Ананы чакыра. Ана урыныннан күтәрелеп җай гына биеп китә. Аның хәрәкәтләрендә искиткеч матурлык һәм грация, күзләрендә яшьлек шаянлыгы.

С а й м ә *(бии-бии)*. Һай, җаным, безнең әни гомердә дә картаймас та, үлмәс тә!..

Килен белән Ана икәүләп биләр. Яшь аралары шактый булган бу ике хатынның биюендә күзгә ташланып торган контраст. Саймә килбәтсезлек, биюнең табигатен аңламау һәм тупаслык мисалы булса, аның янында биегән Ана — матурлык һәм шигърият гәүдәләнеше. Шуңа булса кирәк, Ананың күзләрендә шук елмаю. Ул берсеннән-берсе нәзакәтлерәк хәрәкәтләр ясап бии дә бии — әйтерсең лә безнең алда җитмеш биш яшьлек карчык түгел, яшь бер сылу кыз.

С а й м ә *(көчкә бии-бии)*. Ух! Уф! Һай, җаным, үтерәсең ич, әни! Уф, үләм!.. Расиха, тор тизрәк, монда киленнәрне биетеп үтереш китте!..

Түгәрәккә Расиха сикереп чыга. Саймә хәлдән таеп урындыкка егыла. Ана белән Расиха бии.

Ниһаять, Расиха үзенең Ана белән ярышырга чамасы юклыгын аңлап, кул селти дә утыра.

С а й м ә. Күр әле, җен икән безнең әни! *(Сикереп торып яңадан Ана белән бии башлый.)* Барыбер сине ардырам, әни! Барыбер ардырмыйча туктамыйм!..

Бию иң кызып житкән моментта Г ө л с е м йөгереп керә һәм Ананы кочаклап ала.

Г ө л с е м. Туктатыгыз! Хәзер үк туктатыгыз! Акылдан язмагансыз лабаса! Төне буе йокламаган карчыкны үтермәкче буласызмы әллә?

С а й м ә. Үтерерсең безнең әнине! *(Яңадан бии башлап, баянчыга.)* Әйдә, туктама, Равил!

Г ө л с е м. Апа, дим, туктагыз! Әбигә урын җәеп бирегез, пароходта төне буе йокламый килде бит ул!

С а й м ә. Шулаймыни. Ярый, алайса, бераз ятып ал, әни! *(Ананы култыклап сулдагы бүлмәгә алып чыгалар, диван-караватка утырталар. Сәяр мендәр китереп сала.)*

Менә бу диван-караватны без салдык, әни, туй бүләге итеп. Яртысын Инсаф түләде. Әле беркемнең дә йоклаганы юк биредә. Матурмы?

А н а. Рәхмәт, кызым... Сез миңа карамагыз, күңел ачыгыз. Мин менә шунда азрак башымны гына терәп торам...

Сәхнә әйләнә. Сул яктагы бүлмә тамашачы күз алдыннан югала. Залда күңел ачу дәвам итә. Баянчы шейк уйный. Альфред белән Римма бөгелә-сыгыла шейк бииләр. Максуд белән Ислам, күрәсең, тагын берәрне төшереп алганнар — шактый кәефләнеп, ниндидер көй сузалар. Ана яныннан **Гөлсем**, **Саймә**, **Расиха**, **Рәйхан** чыгалар. Гөлсем Максуд янына килә.

Г ө л с е м. Абый, бер генә минутка бире килегез әле!.. *(Максудны ияртеп алгы планга чыга.)* Әйтсәм дә уңайсыз инде, абый, әйтмәсәм дә... Вакытсызрак чакка туры килдек... Әбинең эш начар бит, абый. Бик начар авыруы бар әбинең. *(Сумкасыннан бер кәгазь чыгарып бирә.)* Менә.

Пауза.

М а к с у д *(кәгазьне укып)*. Ислам! Инсаф! Сәяр! Килегез әле!

Туганнар Гөлсем янына җыелалар. Кәгазь кулдан-кулга күчә. Төркемгә Саймә, соңрак Расиха килеп кушыла.

С а й м ә. Нәрсә серләшәләр болар? *(Максуд колагына нидер әйткәч, шып булып кала.)*

И н с а ф. Кем куйган диагноз бу?

Г ө л с е м. Район больницасында куйдылар. Быел җәйгә чыкканнан бирле инде ул үзен начар хис итте.

С а й м ә. Ходаем!

М а к с у д *(шейк биегән Альфред белән Риммага)*. Маймылланмагыз әле, пожалыста! *(Бию туктый.)*

Г ө л с е м. Ул инде ай буе морфий эчеп кенә тора.

И н с а ф. Морфий?!

Г ө л с е м. Әйе. Авыртуны баса торган шундый бер дару бар.

Пауза.

С а й м ә *(кулларын угалап, еларга җиткән хәлдә әрле-бирле йөренә)*. И ходаем, нишлибез инде менә хәзер? Нишлибез инде менә хәзер? Үлем хәлендәге карчыкны биетеп аптыратабыз бит, җүләр тәреләр! *(Гөл-*

семгә.) Әйтмисең дә, ичмаса шуны! Әни үзе беләме соң?

Гөлсем. Үзендә шундый авыру барлыгын әбигә әйтергә ярамый, апа.

Саймә. И ходаем, бик көлгән идек шул, күп көлүнең азагы хәерле булмый аның...

Инсаф. Операция ясатсаң?

Гөлсем. Операция ясаудан узган, абый... Авылга җибәрмәгез инде сез аны. Берүзе бит ул анда, су алып бирер кешесе дә юк.

Ислам *(гаять дәрәҗәдә уйга калып).* Йогышлы түгелме бу авыру?

Расиха *(Рәйханны итәгенә кысып, елар дәрәҗәдә).* Рәйхан кич буе әбисенең итәгеннән төшмәде — харап кына булдык лабаса!..

Гөлсем. Бу авыру йогышлы түгел, курыкмагыз.

Пауза.

Максуд. Нишлибез соң инде хәзер?

Саймә. Әни башына көлгәнбез икән! Әни башына көлгәнбез!

Максуд. Ислам! Булмаса, син бүген әнине машинаңа утырт та үзеңә алып кайтып тор, ә иртәгә...

Саймә *(идәннән кәгазь тастымал алып).* Кем ташлаган идәнгә бу салфетканы? Бу салфетканы идәнгә кем ташлады?

Зөләйха. Сабыр итегез! Тыңласагыз, мин дә бер киңәш әйтим әле. Әниегез арып, юл килгән, йокласын. Әллә ни зур кеше булмасам да, егерме биш ел больницада медсестра булып эшлим, гозерем төшкәндә кире какмыйлар иде. Каршы килмәсәгез, заведующий белән сөйләшеп, мин аны иртәгә үк больницага салып куйыйм. Тагын бер тикшергәннән зыян булмас дип уйлыйм.

Расиха *(уксеп).* И ходаем!..

Максуд. Булдыра алырсыз микән?

Зөләйха. Мин ике сөйләшә торган хатын түгел.

Саймә. Рәхмәт инде сезгә, Зөләйха ханым!

Зөләйха. Рәхмәте качмас. Инде яшьләр турында уйларга кирәк. Ни генә булмасын, аларның беренче кичләре. Минемчә, кайсыгыз да булса яшьләрне үзенә алып китсә, яхшырак булыр.

Саймә. Максуд! Әйдә, яшьләрне үзебез белән алып китеп, бакча өендә урын әзерлик! Римма! Сәяр!

С ә я р. Без беркая бармыйбыз.

Р а с и х а. Ай алла, сәгать унынчы киткән! Ислам, безгә кайтырга вакыт! Ислам, дим!.. Кайда, үзебезнең өлеш күкәйләрне ала китим әле!.. *(Ананың чемоданы янына тезләнеп утыра.)* Ислам, сумкамны китер!.. Сәяр, берәр иске гәзитең юкмы?.. Рәйханның кофтасын кидерә тор инде, Ислам!.. *(Чемоданнан сумкасына күкәй тутыра башлый.)*

С а й м ә. Бик кызык ягың белән ачылып киттең бит әле син, Расиха!

Р а с и х а. Ник, Саймә апа?

И с л а м. Күкәйләрне үзенә бирмәгәнгә ачуы килә аның. Тутыр, тутыр! Эрерәкләрен сайлап тутыр! Саймәгә ваклары да ярар, ул болай да симез!

Р а с и х а. Сөйләштермәгез әле, саташтырасыз!

С а й м ә. Саташсаң, санап азапланма, ал да кит бөтенесен!.. Бик кызык ягыгыз белән ачылып киттегез бит әле сез...

И с л а м. Ә без кайсы ягыбыз белән ачылсак та курыкмыйбыз. Теләсә кайсы ягыбызны ачып күрсәтергә можем! *(Рәйханны җитәкләп.)* Әйдә, кызым!

Р а с и х а. Ярый, сау булыгыз... Безгә дә килеп утырыгыз, Сәяр!

Ислам, Расиха, Рәйхан чыгалар.

Г ө л с е м. Миңа да китәргә вакыт. Сау булыгыз!

С а й м ә. Бик зур рәхмәт инде сиңа, сеңелем! Туганнарың бармы соң Казанда?

Г ө л с е м. Бар!

М а к с у д. Рәхмәт, сеңелем! *(Гөлсем чыга.)* Сәяр, әйдәгез безнең белән!

С ә я р. Без беркая да бармыйбыз!

С а й м ә. Болай уңайсыз була ич инде...

С ә я р. Барыгыз инде, барыгыз, китегез! *(Инсафка.)* Ә син, абый?

И н с а ф. Мин бүген больницага кереп ятарга тиеш идем...

С ә я р. Ярый, ят. Без монда синнән башка да эшләрбез, ят!.. Барыгыз, китегез... Я, китәсезме инде сез, юкмы?!.

Максуд, Саймә, Инсаф, Альфред һәм баянчы егет чыгалар. Зөләйха белән Әлмөхәммәт аларны озаткан арада Сәяр тәмәке тартып җибәрә, стена буенда моңаеп басып торган Риммага карап ала да коридорга чыга. Бераздан кире әйләнеп керә. Римма янына килә.

Сәяр. Син бик борчылма әле, Римма. Күңелем һич ышанмый. Ышанасым килми. Минемчә, врачлар ялгышканнардыр...

Римма. Синең башка сүзең юкмы?

Сәяр. Бәлки әле операция ясарлар. Терелер. Кайгырма, Римма, тынычлан!

Римма башындагы фатасын салып алып Сәярнең битенә ыргыта, ике кулы белән йөзен каплап, кычкырып елый башлый.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Вакыйга шунда ук бара. Сәяр, өстенә җиңел пальто кигән хәлдә, тәрәзәдән карап тора. Күрәсең, ул кемнеләр көтә. Әлмөхәммәт керә.

Әлмөхәммәт. Азрак ашап ал, улым, бәрәңге пешердем!

Сәяр. Ашыйсы килми лә, бабай. Больницадан әнине алып чыгасы бар, Римма кайтып җитми.

Әлмөхәммәт. Син ашаган арада Риммаң да кайтып җитәр. Әйдә! Әтүсәк, син болай да бик ябык. Абыйларың әнә нинди, ә син кечкенәрәк булып калгансың.

Сәяр. Бакыр тәңкә зур булса да, казан төбе ямыйлар, ди, бабай. Көмеш тәңкә кечкенә булса да, энҗеле калфакка кадыйлар.

Әлмөхәммәт. Бакыр тәңкә белән казан төбе ямауларны кайдан беләсең әле син?

Сәяр. Әни сүзе ул, бабай. Иптәшләрем озын-озын булып үсеп киткәч, «Әни, мин нигә үсмим икән? Шулай кечкенә булып калсам, нишләрмен?»— дип, әнине аптырата идем. Шул чакта әни мине шулай юата торган иде. Бакыр тәңкә зур булса да, казан төбе ямыйлар, көмеш тәңкә кечкенә булса да, энҗеле калфакка кадыйлар...

Әлмөхәммәт. Мөгаен, кечкенә чакта манный ботка ашарга яратмагансың.

Сәяр. Тәтеде микән соң безгә манный боткалар, бабай!

Әлмөхәммәт. Сугыш еллары баласы шул син, бик тәтемәгәндер дә. Самай үсә торган вакытта адәм рәтле ризык эләкмәгән.

Сәяр. Син хаклы, бабай, бала чак азрак эләкте безгә. Уйласаң көлке, мин әле менә хәзер дә сабын куыгы очырып уйнаучы балаларга кызыгам. Зур кеше икәнлегемне онытып, шул аллы-гөлле куыкларны очырып уйныйсым килә. Чөнки үз вакытында уйнап булмады — сабын юк иде!..

Римма керә.

Әлмөхәммәт. Менә килен дә кайтты. Әйдәгез, ашап алыгыз, бәрәңге суына, әтүсәк! *(Чыга.)*

Сәяр. Римма! Әнине бүген больницадан чыгаралар. Әйдә, тиз генә барып алып кайтыйк әнине!

Римма. Ә ни өчен моны без эшләргә тиеш?

Сәяр. Без илтеп салдык, без алып та кайтырга тиеш?

Римма. Без карарга тиеш түгел аны. Аңлыйсыңмы шуны — без карарга тиеш түгел! Без әле өйләнештек кенә. Син юньләп эшли башламаган! Кеше өендә торабыз! Безне берәү дә гаепли алмый.

Сәяр. Безне гаепләүче юк. Ләкин әнине больницага без илтеп салдык. Димәк, алып кайтучы да без булырга тиеш. Соныннан күз күрер. Әйдә!

Римма. Мин бармыйм.

Сәяр. Римма, җүләр булма, зинһар: Әнине алып кайтырга кирәк. Мин моны, әлбәттә, синнән башка да эшли алам, ләкин мин алай теләмим. Икәү барып алабыз, аңлыйсыңмы?

Римма. Мин бармыйм! Каравын да миннән башка эшли аласың икән — бар, алып кайт!

Сәяр. Римма!

Римма. Мин инде егерме ел Римма! Нәрсә, әниеңә нянька кирәк булган өчен өйләндеңмени миңа?

Сәяр. Ничек оялмыйсың син, Римма?! Син мине җәберлисең! Син мине яратмыйсың!

Римма. А, яратуның монда ни катнашы бар! Сүз авыру карчыкның чүпрәкләре турында бара...

Сәяр. Ләкин ул карчык минем анам! Анам, Римма! *(Кискен хәрәкәт белән ишеккә юнәлә. Римма йөгереп килеп аның юлын бүлә. Пауза.)* Беләсеңме, мин зур булып беткәч тә имә идем. Хәзер дә күз алдымда. Урамда уйнап арыгач, әнине эзләп табам да күлмәк изүенә ябышам. Күрше хатыннар әнине сүгәләр. «Шул үгез хәтле малайдан нигә каныңны суыртасың, нигә тибеп

очырмыйсың?» — диләр. Ләкин әни тибеп очырмый иде. Мин моның сәбәбен үсеп житкәч кенә белдем. Мин бәләкәй чакта ачлык булган. Алабута, юкә яфрагы, кычыткан — барысын да ашаганнар. Әни мине кызганган. Яшь балага үлән генә аз, карынына аз булса да сөт керсен, дип, мине дүрт яшькә хәтле имезгән. Үзе ач йөргән хатынның күпме сөте булгандыр — хәтерләмим. Тик шунысы исемдә — имә идем!..

Р и м м а. Без карарга тиеш түгел аны.

С ә я р. Әнинең күп яшисе калмаган, Римма.

Р и м м а. Берәү дә бу дөньяга мәңгегә килми, сөеклем, барыбыз да үләчәк.

С ә я р. Римма!

Р и м м а. Без әле бәлки аның яшенә хәтле яши дә алмабыз.

С ә я р. Римма!

Р и м м а. Ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән. Үкенече калмаган...

С ә я р. Римма!!!

Р и м м а. Нәрсә шул кадәр кычкырасың — синең генә әниең үләме соң?! *(Сәяр чалт иттереп Римманың яңагына сугып җибәрә.)* Менә син нинди! Синең әле мондый һөнәрең дә бармыни? *(Сәяр яңадан Римма өстенә килә башлый.)* Ааа!..

Ә л м ө х ә м м ә т керә.

Ә л м ө х ә м м ә т *(Сәярны тотып)*. Ярамый, улым, ярамый, сабыр бул!

С ә я р *(боерган тавыш белән)*. Әйдә!

Р и м м а. Юк!

Ә л м ө х ә м м ә т. Бар инде, бар, үзең генә алып чык әниеңне! Ә без сез чыккан төшкә килен белән чәй куеп торырбыз.

С ә я р чыга.

Р и м м а *(чемоданга әйберләрен тутыра башлый)*. Барыбер мин моны болай гына калдырмыйм! Алдыма тезләнеп гафу үтенәчәк ул моның өчен!

Ә л м ө х ә м м ә т. Чын ир булса, тезләнмәс. Чүпрәк булса — тезләнер дә бәлкем. Бар ул шундый идән мунчаласы кебек ирләр. Катырак сүз әйтсә дә тезләнеп гафу үтенә, хыянәт итсә дә. Хатын, җүләр, шуңа юанып

яши. Янәсе, ирем хатасын аңлады. Ә ул тагын хыянәт итә, тагын тезләнеп гафу үтенә. Нәрсә дип беләсең соң син аны тезләнүне? Бер өйрәнгәч чүп тә түгел ул! Юк, син иреңнең андый булуын теләмә! Ир булсын ул! Ә син хатын була бел!

Р и м м а. Ир суккан җир тәмугта янмас, мә, жаныем, бу янагыма да сук! Шулмы, синеңчә, хатын була белү?

Ә л м ө х ә м м ә т. Гаеп үзеңдә ләбаса синең. Болай да кая барып бәрелергә белми йөри бит ул бала. Газиз әнкәсе ләбаса ул аның! Нигә син аны шулай рәнҗетәсең? Ярату ул бер юрган астында йоклау гына түгел. Бер-береңне хөрмәт итәргә, авыр минутларда бер-береңә терәк булырга кирәк. Ир йөрәге чыдам. Әмма без дә таштан яралмаган. Шуны аңларга тырыш син, кызым, кеше булсаң!

Звонок. Әлмөхәммәт ишек ача. М а к с у д белән С а й м ә керә.

М а к с у д. Исәнме, бабай! Сәяр өйдәме?

Ә л м ө х ә м м ә т. Әбине алырга китте. Киленегез өйдә. *(Кухняга чыга.)*

С а й м ә. Нихәл, сеңелем!.. Нәрсә булды сиңа, авырмыйсыңдыр бит?

Р и м м а. Тугыз бала арасында тормышының иң рәте-чираты булмаганы без. Кеше өендә торабыз! Сәяр институтны бетереп юньләп эшли башламаган! Көз җитте — өстенә пальтосы юк!

С а й м ә. Булмаса тагын! Нигә соң ашыгып чыктың, пальто тектереп кигәнен көтмәдең?

Р и м м а. Ни өчен без карарга тиеш ул карчыкны? Ни өчен без карарга тиеш?!

С а й м ә. Ни өчен, дип, сезгә карарга кушкан кеше юк ич әле. И, курыкма, сеңелем, безнең әни бик кадерле кеше ул, синнән башка да караучы табылыр. Аның тугыз баласы бар! Барысына да хәбәр бирелгән. Кайтырлар, җыелышырбыз, киңәшербез!

Р и м м а. Киңәшсәң дә, киңәшмәсәң дә, без карарга тиеш түгел аны!

С а й м ә. Түгел, дип, нишләп? Син дә әниеңнең килене ич! Без инде үзебез картаеп барабыз, акыллым, үзебезне карар вакыт җитеп килә.

Р и м м а. Әгәр бүген үк берәрегез алып китмәсә, мин тормыйм! Китәм! *(Сулдагы бүлмәгә кереп китә.)*

С а й м ә *(беравык аптырап торганнан соң).* Китсәң тагын! Әллә безнең энебезгә хатын табылмасмы! Синең кебек кызлар Бауман урамы тулы!

Әлмөхәммәт керә.

М а к с у д. Вәт киленнәр нинди, бабай! Егетләрне яраталар, ә шул егетләрне табып үстергән аналарны — юк!

Ә л м ө х ә м м ә т. Киленнәрнең дә төрлесе була. Менә безнең Зөләйха. Ул килен булып төшкәндә минем әни исән иде әле. Шуның өстенә карчык белән мин. Ире сугышта үлгәч ике яшь бала, өч без карт имгәк белән утырып калды. Бер уйласаң, без кем аңа? Башта әнине карап җирләде. Аннары карчыкны. Минем карчык урын кастасы булгач та җиде ел ятты!

Артта аяк тавышлары. Ананы култыклап С ә я р белән З ө л ә й х а керә.

С а й м ә *(каршы килеп Ананы култыклап ала).* Кайттыңмы, әни-җаным?!

А н а *(кулларын бушатып).* Тотмагыз мине, тотмагыз, мин үзем дә йөри алам!

Ә л м ө х ә м м ә т. Әйдә, әби, әйдә! Хуш киләсең! *(Ананы өстәл янына кадәр озата.)* Утыр! Хәзер чәй эчәрбез!

А н а. Эчәсем килми лә минем. *(Карангалап.)* Яшь килен кайда соң әле?

С а й м ә. Ә, юк, өйдә, әни... яшь килен теге якта... Яшь килен бит ул, әни, синең янга матурланыбрак чыгасы килә торгандыр...

Ә л м ө х ә м м ә т. Яшь килен, әби...

С а й м ә *(бүлеп).* Хе-хе, бу бабай бүреген бер дә башыннан төшерми! Салып куй, бабай, шул бүрегеңне, эссе ич!

Ә л м ө х ә м м ә т. Эссе, дип, өч айлык җәй инде ул. Өч ай өчен бүрек салып торасым килми!

С а й м ә. Эээ... я, җәефең ничек, әни? Тереләсеңме инде?

А н а *(сулдагы бүлмәгә карангалап).* Зыянлы түгел, кызым. Кайтырга кирәк инде авылга.

З ө л ә й х а. Авылга кайтырга өлгерерсең әле, әби! Ике-өч ай да кунак булмагач, мин аны шул тикле җирдән килеп тә тормыйм!

Ана. Ике-өч ай!

Саймә. Тиздән, алла теләсә, әни, яңа квартир алабыз. Яңа квартирны күрсәтмичә җибәрү юк инде сине!

Сәяр Римманы алып керә.

Ана. Исәнме, кызым!

Римма. Исәнмесез!

Саймә *(Римма янына килеп)*. Хе-хе, чәчемне матурлыйм дип, әнине каршыларга соңга калды! Яшь килен әнине каршыларга соңга калды!.. Юк-юк, әни, сине тиз генә җибәрмибез әле!

Максуд. Тәмам терелеп житмичә сине җибәрмибез, әни!

Ана. Шуннан артык булмас инде, улым. Яшь кеше түгел бит.

Саймә. Юк-юк, әни, тереләсең, алла теләсә! Врачың шулай ди. Тәмам терелеп җиткәч кенә авылга кайтасың. *(Артта ыгы-зыгы.)* Кемдер бар!

Сәяр. Гөлчирә апа тавышы!

Ана һәм Риммадан башкалар ишеккә юнәләләр. Гөлчирә, Ислам, Расиха керә.

Расиха. Менә бит әни кайда!

Гөлчирә берсүзсез туктап кала, үзен Ана килеп кочаклап алгач, елап җибәрә.

Ана *(Гөлчирәнең аркасыннан сөеп)*. Я, булды, булды, кызым! Үзең генәме соң? Исән-сау кайттыңмы? Кайчан кайттың?

Расиха. Әле хәзер генә кайтып төште, әни, самолет белән! Безгә килеп керүгә, машинага төялеп больницага киттек! Больницага барсак — син анда юк!

Ана. Алып кайтты шул мине Сәяр. *(Гөлчирәгә.)* Булды, кызым, җитте, җитте! Булды! Утыр, сөйлә! Балалар исән-саулармы? Кияү нишләп йөри?

Гөлчирә *(азрак тынычланып)*. Гәрәйне өч айга командировкага җибәрделәр, әни, Афганстанга. Балалар үсә.

Максуд. Афганстанга? Ну баеп та кайта икән инде, алайса!

Ана. Былтыр да кайта алмадыгыз, балаларны бик сагынган идем. Кияү өйдә булмагач, кем белән калдылар соң алар?

Гөлчирә. Олысын лагерьга җибәргән идек, әни,— лагерьда. Илдус атналык садикта. Рөстәм күрше карчыкта калды.

Ана. И, кызым, бигрәк кансыз икәнсең инде! Соң инде, берсеннән-берсе кечкенә сабыйларның өчесен өч җиргә ташлап кем йөри!

Гөлчирә. Алар өйрәнгәннәр инде, әни! Кечкенәдән шулай бит, үсләреннән биклибез дә эшкә китәбез. Син алар өчен борчылма, әни, аларга берни дә булмас!

Ана (*Сәярга*). Улым, нигә бик моңаеп утырасың?

Сәяр (*елмайган булып*). Юк, әни!

Ана (*Гөлчирәгә*). Кечкенәсе сөйләшә торгандыр инде?

Гөлчирә. Сөйләшә, әни, авызы һич ябылып тормый! Аңарда булган сораулар хәтле бөтен дөньясында да җавап юк... Авылны бер дә онытмыйлар. Аз гына ачуландың исә, әби янына китәбез, дип куркыталар. Әле кичә олысына лагерьга передача илткән идем. Синең янына кайтасымны әйткәч, үзенә дип алып барган шоколадны ашамыйча, сиңа җибәрде. (*Сумкасыннан шоколад чыгарып.*) Менә! Менә бу куянны да сиңа җибәрде, әни. Пластилиннан үзе ясаган! (*Сумкасыннан пластилиннан ясалган куян чыгарып Ана алдына куя.*)

Ана (*уенчыкны алып*). Бәбкәм!.. Озакка кайттыңмы, кызым?

Гөлчирә. Өч кенә көнгә шул, әни! Эш бит! Сотрудникларның күбесе ялда, җибәрмиләр шуннан артыкка...

Ана. Расихалар нигә утырмый?

Максуд. Алар, әни, үзләренең машиналарын саклыйлар!

Расиха. Юк ла! (*Йөткергәләп.*) Грипп булган миңа, әни! Янына барсам, сиңа да грипп иярер дип куркам!

Ана. Авыруга авыру иярми лә ул.

Әлмөхәммәт (*хәйләкәр елмаеп*). Җәй житсә, халыкта шул грипп башлана инде!

Саймә. Әйтмә дә, бабай! Быел күренмиләр әле. Узган ел медсестра килеп, борынга вакцин тамызып киткәч, унөч кенә мәртәбә авырган идем!..

Ана. Рәйханны ник алып килмәдегез?

Расиха. Рәйхан... Рәйханны, әни, күрше кызына ияртеп Каравай кибетенә җибәргән идем. Форма табып

булмый! Рәйхан зур үсте бит инде, әбисе, быел мәктәпкә керә!..

Ана *(Сәярдан)*. Улым, апаңны бикәчең белән таныштырдыңмы соң?

Сәяр. Апа, менә таныш булыгыз, бу — минем хатын!

Гөлчирә *(Римма белән күрешеп)*. Гөлчирә!

Римма. Римма.

Гөлчирә. Қайтасым да кичә генә билгеле булды, юньле бүләгем дә юк. *(Бераз уйлап торганнан соң бармагындагы йөзеген салып Риммага кидерә.)* Бәхетле булыгыз!

Римма. Рәхмәт!

Гөлчирә. Сәяр, кәрзинемне генә кертеп бирче! *(Сәяр коридордан зур кәрзин кертеп өстәлгә куя. Расиха ирексездән өстәлгә таба бара башлый, Ислам аны туктатып кала.)* Менә, әни! Җиләк-җимештә витамин күп, барысы да сиңа файдалы ризыклар, ашарсың!

Ана. Рәхмәт, кызым! *(Берничә алма алып Зөләйхага.)* Зөләйха, менә шуларны теге Люсә дигән кызга алып барып бир әле, кызым! *(Башкаларга.)* Мин яткан бүлмәдә бер детдом баласы ята анда, аякларына салкын тигән. Үлдем инде шул баланы җәлләп. Бик сызлый буыннары. Йокысы тынычсыз тагын үзенең, гел өстен ача. Төнене әллә ничә торып өстен ябам шуның. *(Зөләйхага.)* Өйгә кайткач, йон оекбаш бәйләп җибәрәм әле алла теләсә, шул балага!

Гөлчирә елый башлый.

Саймә. Җитте сиңа!

Зөләйха. Артыккарак китә башлады шул!

Ана. Бу кызым кечкенәдән шулай елаграк булды инде минем, гаеп итмәгез инде сез аны.

Сәяр. Әни, ятып аласың килмиме?

Ана. Юк, улым!

Сәяр. Сине күп сөйләштереп арытырга ярамый, әни, врач шулай кушты. Бераз ятып ал!

Ана. Соң тукта инде, улым! Килгәнемә ай тулды — үзегезне туйганчы күргәнем дә юк!

Максуд *(кәрзиннән груша алып)*. Ташкент күчтәнәчен ашап карыйк әле! *(Гөлчирәгә.)* Қыйбатмы инде Ташкентта шуның килосы?

С а й м ә. Син бик хаптырдама әле, сиңа дип алып кайтмаган ул аны!

А н а. Ашагыз, ашагыз, барыгыз да авыз итегез! *(Кәрзиннән алмалар, грушалар алып барысына да өләшеп чыга.)*

Р а с и х а *(үзенә груша сузып якын ук килгән Анадан читкәрәк тайпылып)*. Юк-юк, әни, без ашамыйбыз, үзең аша!

С а й м ә. Әни, малайларыңа күп бирмәсәң дә ярар! Тәмле ризыкны ирләргә бирергә ярамый аны. Алар аның барыбер ләззәтен белеп ашамыйлар — хаптыр-хоптыр иттерәләр дә йотып җибәрәләр.

А н а *(Максуд алдына иң зур грушаны сайлап куя)*. Болай булгач, хатыныңнан сиңа тәмле нәрсә күп эләкмидер. Мә, улым, анаң янында сыйланып кал әле!

М а к с у д. Кирәкми, әни, булды. Груша безнең өйдә дә бар. Кичә генә алып кайттым.

С а й м ә. Һай, җаным, кичә таш шикелле өч кило груша күтәреп кайткан, авызга кабарлык та түгел! Бер әйбер ала белми инде безнең Максуд!

Р а с и х а. Ашап карап алырга кирәк!

С а й м ә. Ашау әйберен генә түгел! Әле бөркөн миңа халатка дип штапель күтәреп кайткан — капчык тегәргә генә яраулы. Бер әйбер ала белми, вкусы юк! Әни, малаеңның вкусы юк, әйбер ала белми малаең!

А н а. Малаем әйбер ала белми? Бу кадәр уңган, бу кадәр белдекле хатынны ничек ала белде икән соң?!

Көлешү.

С а й м ә. Безнең әни малайларына сүз тидерми ул!

А н а. Улым, Максуд, Хафиздан хат юкмы?

С ә я р. Хафиз абый шушы көннәрдә үзе кайтып җитәргә тиеш, әни!

А н а. Кайта алмас ул. Ул якларда дөньялар тыныч түгел ләбаса, җибәрмәсләр. Телеграм сук, исәнлеген белдереп хәбәр бирсен.

С ә я р. Ярый, әни!.. Әни! Сине ялыктырырга ярамый! Әйдә, ятып ал!

А н а. Ятасым килми минем, улым! Бер рәхәтләнеп янызызда утырыйм инде! Гөлчирә апаң да кайткан, бакчи!

С ә я р *(Гөлчирәгә күз кысып)*. Гөлчирә апа да азрак ял итсен, юл килеп ул да арган!

С а й м ә. О, бик яман арыта ул, әни, самолетта очу!

А н а. Алайса, ул ял итсен, мин сезнең янда утырам!

С ә я р. Юк, әни, юк, син дә ял итәсең! *(Ананы култыклап ала.)*

А н а. Кара, нигә тотасыз мине? Мин үзем дә йөри алам лабаса!

Кулларын тартып ала. А н а, С ә я р, Г ө л ч и р ә, С а й м ә ундагы бүлмәгә чыгалар.

М а к с у д *(Исламга)*. Син нигә тәресен җуйган кяфер шикелле утырасың? Алтын кадерен генә беләсең шул син. Алтыннарны аны җир астыннан казып табып була. Әниләрне җир астыннан алып булмый бит бер илтеп күмгәч!

З ө л ә й х а. Кухняга чыгып сөйләшегез, әнә тегендә! Әниегез азрак ял итсен!

М а к с у д, И с л а м, Р а с и х а кухняга таба китәләр. Сәхнә әйләнә. Безнең алда Зөләйха квартирасының кухнясы.

М а к с у д. Ишеттегезме, Сәярнең хатыны китәм, ди!

Р а с и х а *(гаять кәефе килеп)*. Ник?

М а к с у д. Әнине карыйсы килми!

И с л а м. Хы-хы-хы!

С а й м ә керә.

С а й м ә. Нәрсәдән көләсез?

М а к с у д. Римма китәм дип әйтә, дигән идем, шуннан көләләр.

С а й м ә. Аның ниеннән көләсең! Көлке түгел ул, еларга кирәк!

И с л а м. Хы-хы-хы! Кем инде хатын киткәнгә елый! Менә шуннан син китсәң, абый елармы? Еламыйсың бит, абый? Хы-хы-хы!

С а й м ә. Нәрсә син танавыңны җәеп хихылдыйсың, хайван?!

И с л а м. Кем хайван? Минме хайван?

С а й м ә. Син түгел, син түгел, мин!

И с л а м. Шулай дисәң генә. Хы-хы-хы!

С а й м ә. Бик килешә инде! Әнисе үлем түшәгендә, ә ул...

И с л а м. Әни үлә дип үлеп булмый бит инде!..

Г ө л ч и р ә керә. Өстәл янына килеп утыра да битен кулы белән каплап елый башлый. С ә я р белән Р и м м а керә.

Саймә. Я, Гөлчирә, тынычлан! Кирәкми! Елап була торган эш түгел. Тынычлан, кеше елаганга карый алмыйм мин, үземнең дә елыйсым килә башлый.

Гөлчирә. Диагнозы дөрес булып чыктымы? *(Сәяр баш селки, Гөлчирә кабат елый башлый.)*

Саймә. Тынычлан, сеңелем!

Гөлчирә. Үләсен үзе сизә микән?

Саймә. Аңа әйткән кеше юк ич!

Сәяр. Әйткән кеше юк. Тик әни врачына әйткән. Миңе тикшереп азапланмагыз, кызым, мин барыбер үләм, бу минем әҗәл авыруым, дигән.

Саймә. Сәяр! Ул бит хәлем әйбәтләнә дигән була!

Сәяр. Безне борчымас өчен! Сез әнине белмисез, аның табигате шундый. Үзенә авыр икәнлеген ул бервакытта да безгә әйтмәячәк.

Гөлчирә. Күпме яшисен әйтмәделәрме?

Сәяр. Өч ай. Күп булса — ярты ел.

Расиха. И, алай гына тормый әле ул! Ул әле авыртуга чыдый алмыйча кычкырып ята башлагач та әллә ничә ай үтә!

Саймә. Безнең әни кычкырмас, Расиха. Ул бик сабыр хатын.

Расиха. Кычкыра!

Гөлчирә. Туганнарның барысына да яздыгызмы? Кайталармы?

Сәяр. Менә Хафиз абый кайтып җитәргә тиеш иде дә, юк бит! Җибәрмиләр, күрәсең. Ул хезмәт иткән чик буе тыныч түгел бит.

Саймә. Ходаем, үзең сакла!..

Максуд. Ярый, туганнар! Әни юкта сөйләшеп алыйк әле. Нишлибез? Авылга җибәрәбезме әнине?

Гөлчирә. Ю-у-к, авылга җибәрергә ярамый!

Максуд. Ә кая куябыз?

Гөлчирә. Ничек инде кая куябыз?

Максуд. Шулай. Без карый алмыйбыз. Без үзебез кеше сараенда торабыз. Өебезне сүттеләр.

Саймә. Болай ул, Гөлчирә. Май аенда безнең өйне сүттеләр. Безгә квартир биргәннәр иде дә, ерак булгач, безнең күченәсебез килмәде. Шуннан горисполком безгә гарантия бирде, октябрьның беренче ятрысында безгә квартир бирәбез дип. Без шуңа риза булып, танышларыбызның сараена күчеп торган идек. Кем белгән бит аның болай килеп чыгасын!..

Максуд. Яшь киленнең карыйсы килми. Китәм, дип куркыта!

Римма. Без карарга тиеш түгел аны!

Гөлчирә. Сабыр итегез, сеңелем!

Максуд. Исламнар алмый!

Гөлчирә. Ни өчен?

Ислам. Чөнки мин үзем пенсионер. Хатын — чирле.

Гөлчирә. Ни булган синең хатыныңа?

Ислам. Ашказаны авырта. Ашаганы кире кила.

Гөлчирә. Минемчә, абый, әнине сез карарга тиеш.

Ислам. Ни өчен без?

Гөлчирә. Башка юл юк чөнки. Сәярлар карарга тиеш түгелдер, дип уйлыйм инде мин. Алар кеше почмагында яшиләр. Яңа гына өйләнештеләр. Тормыш итә башлау ул әле авыру карчыктан башка да читен була. Сез карарга тиеш әнине, абый.

Ислам. Ә ни өчен син карарга тиеш түгел? Син дә бит әнинең кызы!

Гөлчирә. Мин еракта!

Ислам. Кайтып кара!

Расиха. Әйе! Кайт та кара!

Гөлчирә. Туктагыз әле, кычкырышмагыз!.. Минемчә, хәзер без бер генә нәрсәне уйларга тиеш. Без тугыз бала. Ләкин кайсыбызда әни өчен уңайлырак? Кайсыбыз берничә ай гомере калган әни өчен максималь удобстволар тудыра ала?

Максуд. Ислам! Өйләре зур! Бөтен шартлары бар! Хатын яшь, эшләми!

Ислам. Син дә эшләтмә хатыныңны!

Максуд. Акчам синеке хәтле булса, эшләтмәс идем дә бит...

Ислам. Ә син кеше акчасын санама!

Расиха. Әйе! Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәген санар, ди. Дөп-дөрес!

Гөлчирә. Туктагыз әле! Кычкырышмагыз әле, зинһар, базар хатыннары шикелле!. *(Исламга.)* Абый! Минемчә, әнине карау ул бик зур честь, дәрәҗә...

Ислам. Алай бик зур дәрәҗә булса, ал да кит үзең белән Ташкентка! Честы да, дәрәҗәсе дә үзеңә булыр!

Расиха. Әйе! Алып кит тә кара!

Гөлчирә *(бераз уйлап)*. Алып китәм. Алып китәм! *(Максудтан.)* Самолетта бара алыр микән?

Р а с и х а. Ник бара алмасын!

С а й м ә. Әй, юк ла, шунда тиклем җибәрмибез инде аны!

С ә я р. Әни бармаячак.

Г ө л ч и р ә. Ни өчен?

С ә я р. Сәламәт чакта йөрмәгәнне, нишләп барсын инде ул шунда кадәр!

М а к с у д. Юк, Казаннан ары җибәрергә ярамый аны...

С а й м ә. Аның шунысы да бар бит әле, Гөлчирә. Бәлки ул авылга кайтарып җирләүне сорар, әти янына. Белмәгән бит әле аныкын.

Пауза.

Г ө л ч и р ә. Бөтен союзга таралган бит аның туганнары да!.. Инсаф абыйны санап булмый инде...

М а к с у д. Инсафның башы больницадан чыкмый. Әнә тагын Казан больницасында ята.

Г ө л ч и р ә. Нәрсә булган?

М а к с у д. Яралары ачылган! Тәнендә исән төше юк лабаса аның!

И с л а м. Ә хатынына ни булган?

Р а с и х а. Әйе! Ат хәтле хатынына ни булган?

С а й м ә. Әй, юкны сөйләп утырмагыз ла, зинһар! Гомере буе авыру туганыгызны карау гына җитмәгән...

Г ө л ч и р ә. Дөрес! Инсаф абыйны санап булмый. Апалар еракта. Хафиз абый белән Таһир абыйны да санап булмый...

Р а с и х а. Тегесен дә санап булмый, бусын да санап булмый, бер безне санап була! Ничава не знаю, бөтенесен дә санарга! Кайтып карасыннар, чиратлашып! Кайтмасалар — кеше яллап каратсыннар, акча түләп! Үзебезнең чират җиткәч, кемне дә булса без дә ялларбыз.

Г ө л ч и р ә. Акыллы сүз түгел, Расиха...

Р а с и х а. Син генә бик акыллы!

Г ө л ч и р ә *(Исламга, ялварып диярлек)*. Абый! Әнине сез карарга тиеш!

И с л а м. Ни өчен без? Ни өчен без? Сезнең карарга хәлегездән килмәгән өченме? Ярый ла мин хәзер Казан-

да! Ә кайтмаган булсам? Магаданский областьта калган булсам, нишләр идегез соң сез?

Гөлчирә. Менә мин дә шуны уйлап торам. Тормышларның иң авыр вакытында син ун ел төрмәдә утырдың. Сугыш вакыты, сугыштан соңгы еллар. Әти үлеп китте! Без биш бала әни кулында калдык! Ул чакта Сәярга ике яшь. Коточкыч еллар иде ул! Әни бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле колхозда эшли, ә хезмәт көненә бер грамм бирмиләр! Әни коры сөяккә калды. Ачлыктан гына түгел, семьяга син китергән хурлыктан да! Ләкин ана — ана шул. Кайчакта ул берничә кадак он табып алып кайта да шул оннан икмәк пешерә иде. Ох, ул икмәк! Ул икмәкнең исен мин әле хәзер дә онытмыйм. Хуш исеннән башлар әйләнә торган икмәк иде ул!.. Әни шул икмәктән сохари ясый иде дә сиңа җибәрә иде... Беләсеңме, әни синең өчен күпме яшь түкте? Хурлыктан урамга чыгарга оялган көннәре дә күп иде аның...

Ислам. Минем өчен хурланасы юк! Минем документларым чиста! Минем судимость снята!

Гөлчирә (*катгый*). Шулай, абый! Язмыш синең кешелегеңне сынар өчен тагын бер имтихан куя. Теге вакытта абынгансың, инде дә абынма! Әйдә, машинаңа утыртабыз да алып кайтабыз әнине сиңа!

Саймә. Ислам, җаным, без квартир алганчы гына! Үзем килеп карашырмын!..

Ислам (*мескенләнеп*). Шәфкатьсез кешеләр сез! Йөрәксез кешеләр! Мин ничә ел төрмәдә утырдым, понимаешь. Төрмәдән чыккач, унбиш ел шахтада эшләдем! Якты кояшны күрмәдем! Инде, понимаешь, кайтып, бер кеше төсле яши генә башладым дигән идем — мә сиңа! Башка берәүләр булса, әйтерләр иде, абый, син инде болай да рәхәт тормыш күрмәдең, тынычлап яшә инде, диярләр иде!.. (*Үкереп елый башлый.*)

Расиха (*елап*). Тынычлан! Тынычлан!..

Гөлчирә. Ә кем гаепле? Кем гаепле синең рәхәт күрмәвеңә?

Зөләйха керә.

Расиха. Алып кайтмаска иде аны больницадан! Ник алып кайткан? Кем алып кайткан — әнә шул карасын!

Зөләйха. Оятсызлар! Өч ай гомере калган әниегезне карамас өчен талашасыз! Кеше гомере буе карый! Куалап чыгар үзләрен, Сәяр, тормасыннар монда ачу китереп!

Сәяр (*ишеккә бара башлаган Римманың юлын бүлеп*). Римма!

Римма. Болай булгач мин принципиально китәм!

Зөләйха. Әй, китсәң — китсәнә! Салып җибәрермен, китәрсең атылып! (*Ишекне ачып.*) Бар, кит! Инкубатор чыгарган кияү эзлә! (*Римма чыга.*) Мин карармын әниегезне! Мин әштә чакта карый торырга әнә туксан яшьлек карт бар. Гомерем буе авыру карадым, үлмәдем. Тагын бер карчыкны караганнан гына үлмәм әле!.. Тормагыз монда өелеп! Ярып чыгарганны көтәсезме әллә?

Расиха. Әйдә, Гөлчирә, кайтасыңмы?

Гөлчирә. Рәхмәт. Мин сезгә кайтмыйм.

Ислам белән Расиха чыгалар. Үзалдына җыр көйләп Әлмөхәммәт килеп керә.

Әлмөхәммәт. Төркем-төркем куйлар бара,
Арасында чем-кара.
Егет, мескен, ни хәл итсен,
Кызлар чакыргач, бара...

Саймә. Менә шушы ай ярымы бар аның. Ходай кушып, квартир алсак, берсенә дә бирмим мин аны, үзем карыйм!.. Максуд! Әллә горисполкомга барып карыйсыңмы, әшнең нәрсәдә икәнен сөйләп бирәсеңме?

Максуд. Безгә квартир салына торган йорттан бирелгән бит инде. Шул йорт өлгермичә булмаячак.

Әлмөхәммәт. Синең исеңдә микән, Зөләйха, үләргә өч көн калгач, әни мәрхүм, Зөлхиҗҗә чишмәсенең суын эчәсем килә, диде. Оренбург ягында безнең авыл янында шундый бер чишмә бар. Энем кайтып та киткән иде дә, алып килеп өлгертә алмады шул. Эчерә алмадык әнигә Зөлхиҗҗә чишмәсенең суын. Гомерлек үкенеч булып калды!..

Римма керә. Кухнядан нидер эзли башлый.

Сәяр (*катгый*). Римма, дим! (*Чыга башлаган Римманың кулын тота.*)

Римма (*елап*). Тотма мине, җибәр. (*Чыгып китә.*)

Г ө л ч и р ә. Алай ярамый бит инде, сеңелем!.. Сәяр, бар инде тизрәк артыннан!

З ө л ә й х а. Барма! Утыр урыныңа! Юньле хатын булып чыкмады, китеп куркыта торган хатын булып чыкты. Акылы булса кайтыр. Утыр!

П ә р д ә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

ыйга шунда ук бара. А н а ике кулы белән тәрәзә төбенә тотынган хәлдә урамга карап тора, өстендә туйда кигән ак ефәк күлмәк. Ә л м ө х ә м м ә т алгы планда намаз укый.

А н а. Быел кыш үзен иртә күрсәтә, бабай,— кар ява! Урам ап-ак булды!

Ә л м ө х ә м м ә т. Ап-ак булып озак тормый ла ул. Бездә монда кар җиргә төшеп өлгерми, пычракка әйләнә. Авылдадыр инде ул чын кар.

А н а. Авылда кар күп! Узган кыш бер төн эчендә бөтен өемне күмеп китте, кичкә хәтле чыга да алмадым. Рәхмәт, кешеләр килеп казып чыгардылар... Почта ящигын карап кермәдеңме, бабай?

Ә л м ө х ә м м ә т. Берәрсе кесәсенә салып киткән, ахры, ачкычын таба алмыйм... Син азрак ятып ал! Көне буе тәрәзә төбеннән китмисең — нәрсә күрәсеңдер аннан!

А н а. И, бабай, балаларымның берәрсе кайтып килмиме, дип карыйм!.. *(Көч-хәл белән, чайкала-чайкала креслога килеп утыра, Әлмөхәммәт аңа утырырга булыша.)*

Ә л м ө х ә м м ә т. Тәрәзә төбенә хәтле кайтып җитсәләр, кире китмәсләр инде, алла теләсә, керерләр... Сәгатьтә туктаган икән безнең, радиосы да эшләми — ни булгандыр... *(Урындыкка басып стенадагы сәгатьне боргалый.)* Сәгать ничәләр бар икән соң инде хәзер?

А н а. Дүрт тулып бишенче китте, бабай.

Ә л м ө х ә м м ә т *(гаҗәпләнеп).* Кайдан карап әйтәсең әле син аны?!

А н а. Сәгать минем эчемдә, бабай. Уколны вакытында ясамасаң, хәзер келтери башлый.

Ә л м ө х ә м м ә т. Озаклады шул бүген Зөләйха... Нәрсә, авыртамы? Алай булгач, Зөләйхага әйтергә кирәк,

иртәрәк чыгып салсын уколны. Укол салгач тынычланасың лабаса син, азрак йоклап та аласың. Чирен яшергән үлгән, ди. Тилмереп утыру ярамый, әйтү кирәк!.. Күрше йортта берәүләр аталарының елын уздыралар, корьән укырга чакыралар. Үзеңне генә калдырсам, куркып бетмәссең микән?

Ана. Нәрсәдән куркыйм! Ялгыз яшәп мин өйрәнгән инде, бабай.

Әлмөхәммәт. Үлгәч, аллаһы тәгалә каршысына барасылар булса, кирәге булып куяр, дим. Үләселәр бар бит әле! Хикмәт, син ул хакта бер дә әйтмисең.

Ана. Үлемнән курыкмыйм мин, бабай. Кыямәт көненнән дә курыкмыйм. Дөрес, намаз укулар күп эләкмәде. Яшь чакта яшь булынды, үлем турында уйланмады. Аннары дөнья мәшәкате басты. Булдымыни соң безгә намазлар укып торырга вакыт, бабай? Шулай да үлемнән курыкмыйм. Дөрес яшәдем. Гөнаһ кылмадым, кешегә начарлык теләмәдем.

Әлмөхәммәт. Ничек, синеңчә, алла бармы икән?

Ана. Барып күреп кайтучы булмагач, кем белгән инде, бабай!

Әлмөхәммәт. Шулай шул. Тегендә менеп очып йөрүчеләр дә күреп төшмәгәннәр. Гагариннарны әйтәм, Әндрияннарны... *(Тирән сулап.)* Адәм баласының гомере кыскарак шул! Аз да яшәмәдем кебек — исән булсам, быел яз туксанны тутырам. Шулай да гомер тиз узып китте. Сизми дә калдым!..

Ана! Дөрес! Мең дә бер кичә әкиятендәге кебек. Әле менә мин дә кичә генә бер ишектән кергән идем, инде икенчесеннән чыгар вакыт та житте... Шулай булса да, мин үлгәндә ясин чык, бабай! Кешечә булсын!

Әлмөхәммәт. Кайдан килде әле бу искә авыздан яңа сүз?!

Ана. Яңа түгел. Җыясы ризыгым күп калмады.

Әлмөхәммәт. Чыкмаган җанда өмет бар! Кем белә, бәлкем терелеп китәрсең. Чайкама башыңны, чайкама! Терелерсең дә авылыңа кайтырсың. Ә мин, ходай боерган булса, сиңа кунакка барырмын. Сезнең якларда бер дә булганым юк минем. Матурмы сезнең яклар?

Ана *(кинәт җанланып)*. И, безнең якларның матурлыкларын сөйләп кенә бетерә торганмы соң, бабай! Ул Идел буйлары! Ул урманнары! Ул исәпсез-хисапсыз чиш-

мәләре!.. И, бар иде яшь чакларым, бабай! Яшь идем. Таза идем! Ут идем! Йөрәгем бик зур иде шул минем, бабай. Кайчакларда өйгә генә сыеша алмыйча, бер йомышсыз, урманнарга чыгып китә торган идем. Тиле кеше шикелле иләсләнеп аланнарда йөрим. Ул аланнардагы мең төрле чәчәк исе, кошлар тавышы!.. Әле менә шушы хәлемдә дә күңелем белән әллә кайларга барып киләм. Көненә әллә ничә кат кызларым янына да барып кайтам, улларым янына да. Авылда да булып киләм. Күңел — канатлы кош, оча да китә. Аяклар гына йөрми!..

Әлмөхәммәт. Йөрер әле, ходай боерган булса, йөрер! Үзең дә сизми калырсың йөреп киткәнеңне.

Ана. Үз хәлемне үзем генә беләм, бабай. Килеп житә!

Әлмөхәммәт. Сезнең як урманнарында чикләвек тә бармы?

Ана. Күп! Җыеп кына бетерә торган да түгел! *(Звонок.)* Кемдер килә! Сөйләшеп күрми калдым — кемдер килә! Тизрәк ач, бабай, Хафизым кайтып киләдер бәлкем!

Альфред керә.

Альфред. Исәнме, әби!

Ана. Яхшы, улым. Үзең нихәл?

Альфред. Нормально!

Әлмөхәммәт. Ярый, мин тегеләрнең бәлешләрен ашап чыгыйм әле. Тәмле булса, сиңа да алып чыгармын.

Ана. Хәерле юл, бабай!

Әлмөхәммәт чыга.

Альфред *(кесәсеннән берничә конфет чыгарып куя)*. Мә, конфет аша, әби!

Ана. Мин конфет яратмыйм, улым, үзең аша! Әтиәниең таза-саумы?

Альфред. Нормально!

Ана. Хафиз абыеңнан хат-хәбәр юкмы? *(Альфред иңбашын сикертеп куя.)* Үзең ни эш бетереп йөрисең?

Альфред. Нормально! *(Машина тавышы, Ана торып тәрәзәгә бара башлый.)* Ул мин утырып килгән такси, әби!.. Әби! Синең бер биш сум акчаң юкмы? Әнә шул таксига түлисе бар иде.

А н а. Трамвайлар йөрмимени бүген?

А л ь ф р е д. Әй, ашыгыч булгач, такси алган идем шул. Беләсеңме, бер бик чибәр генә кыз бала бар, әби. Сәгать алтыда киногa барырга булган идек. Синең янга да килеп өлгерәсе бар!.. Утыруын утырган идем дә, инде менә төшеп калып булмый — түләргә акча юк. Акча кошелегым өйдә онытылып калган! *(Ана мендәр астыннан төенчек алып чишә башлый.)* Ну, хәлләр ничек соң, әби, тереләсеңме инде?

Звонок.

А н а *(төенчеген учына яшереп ишеккә күрсәтә)*. Улым!

А л ь ф р е д. Әби, дим!

А н а. Бар инде, тизрәк ач, улым! Хафиз абыең кайтып килмиме?

Альфред ишек ача. И н с а ф керә. Кулында гади генә сумка. Ана белән кочаклашып исәнләшә.

А н а *(Инсафка урындык этәреп)*. Утыр! Утыр, улым, утыр!.. Озак яттың ла инде, улым, бальниста!

И н с а ф. Туеп беттем, әни, үзем дә! *(Сумкасыннан берничә ак хризантема чыгарып Анага суза.)* Менә, әни! Син чәчәк яратасың бит, чәчәк алып килдем әле сиңа...

А н а. И, салкын тидермичә кайларда гына саклаганнар!

А л ь ф р е д. Бу безнең як чәчәкләре түгел, әби! Моны грузиннар китереп сата, Кавказдан!

А н а *(иснәп)*. Әрем исе килә! *(Гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнеп чәчәкләрне Инсафка суза, тагын иснн.)* Әрем исе килә! *(Бик кадерле нәрсә кебек итеп тотып, йотылайотыла чәчәкләрне исни.)* Үзебезнең яклар исе!.. *(Кинәт күңеле тула, башкаларга сиздермичә генә күз яшьләрен сөртеп ала. Альфредка.)* Улым, берәр савытка су салып кертсәнә! *(Альфред чыга.)* Рәхмәт сиңа, улым!

И н с а ф. Я, нихәл соң инде, әни, терелмисеңме әле?

А н а. Зыянлы түгел, улым, зыянлы түгел!.. *(Альфред сулы ваза күтәреп керә.)* Сәярның хатынын практикага җибәрделәр! Яна елсыз кайтып булмас, дип яза инде ул!.. *(Чәчәкләрне суга утырта.)*

А л ь ф р е д. Кемне — Римманымы?!

А н а. Әйе!

Альфред. Син нәрсә, әби, Римманы мин әле генә капка төбендә күрдем!

Ана *(бәхәсләшергә урын калдырмаучы тон белән)*. Син башка берәр кешене күргәнсең! Римма Казанда юк ул, Римма практикада! *(Инсафка.)* Өеңә кайчан китәсең соң инде, улым?

Инсаф. Азрак кибетләрдә йөреп кирәк-яракны алырмын да, кайтырмын инде, әни. Бик озакка китте бит, югыйсә, өч ай тула! *(Альфредка.)* Ну, синең эшләр ничегрәк соң әле, егет? Миңа акча кирәк булыр бит.

Ана *(Альфредның аптырап калуын күреп)*. Нәрсә, синнән дә алып тормагандыр бит?

Инсаф. Әллә синнән дә сорыймы?!

Ана. Таксига түлисе бар, ди бит!

Инсаф. Акчасы булмагач, таксига утырмасын! Минем кырык җидегә җитеп тә таксига утырып караганым юк, агач аякларым белән дә!

Альфред. Юк, болай килеп чыкты ул, Инсаф абый...

Инсаф. Эшкә кердеңме әле?

Альфред. Менә эш эзләп йөрим шул!

Инсаф. Таба алмыйсыңмы? Казан хәтле Казанда сиңа яраулы эш юкмы? Әнә анда урамга чык та кара — почмак саен язып куелган. Мең җиргә кирәк кеше!

Альфред. Аз түлиләр!

Инсаф. Тик яткан өчен күп түлиләрме соң? Болай хөрәсән ялкавы булып йөрсәң, картайгач пенсияң дә булмас әле синең. Атаң белән анаң да булмас ул вакыт сине ашатып ятарга!

Альфред. Мин картайганчы әллә нинди законнар чыгар әле!

Инсаф. Чыкты, ди, көтеп тор! Эшләмәгән кешегә беркайчан да почет булмаячак аңа!

Ана. Шушындый баһадир хәтле гәүдәң белән эшләми йөрисеңме, улым?! Көненне ничек уздырасың соң син? Әле менә мин булып мин тик ятканга күрә көнемне уздыра алмыйча аптырыйм!

Алфред. Хәзер яшьләр сезнең кебек түгел шул, әби. Без башкачарак яшәргә яратабыз.

Ана. Ничек яратасыз?

Альфред. Ну, ничек дип аңлатыйм инде сиңа...

Инсаф. Синең кебекләр әнә тегендә очып йөриләр. Космоста!

Ана. Күңел ачуны һәркем ярата аны, әмма күңел ачып булсын өчен эшләү кирәк. Кешедән алып торган биш тәңкә белән генә ерак китеп булмый... *(Төенчеген чишеп Альфредка акча бирә башлый.)*

Инсаф. Бирмә, әни, син аңа! Бирмә!

Ана. Бирә алмыйм шул, улым, рәнҗемә. Ашарыңа булмаса бирер идем, таксига бирмим. Йөрмә болай җан көеге булып, эшкә кер! *(Инсафка күрсәтмичә генә Альфредка акча төртә.)*

Альфред *(акчаны тиз генә яшереп)*. Сау булыгыз! *(Чыга.)*

Ана. Кемгә генә охшап мондый буш чәчәк булып үскән бу бала? Әтисе дә кечкенәдән эш яратып үсте, олы бала булгач, эшнең иң авыры аңа эләкте...

Инсаф. Эх! Моңарда булган саулык миндә булса!

Ана. Терелтеп чыгардылармы соң инде, улым?

Инсаф. Азрак ремонтлаган булдылар, әни, тагын күпмегә җитәр. Йөрергә ярамый миңа, әни. Аз гынә йөрдең исә, протез астыннан тишелә дә чыга. Йөрмичә дә булмый — яшисе бар.

Ана. Килениән хат бармы?

Инсаф. Бар, әни! Исән-саулар. Минем балалар әйбәт, әни! Кыз сәгать заводында эшли, кичке техникумда да укып йөри. Илдус быел унны бетерә, инженер булам, ди. Исән булсам, укытырга исәп. Балалар үсеп бетте инде, әни! Кечкенәсе дә быел алтынчыга керде!

Ана. Үзең һаман шул эшеңдә эшлисеңме?

Инсаф. Шунда, әни. Фотолабораториядә.

Ана. Эшең әйбәт синең үзеңнең, җиңел!

Инсаф. Әй, төкерим лә мин аның җиңеллегенә, әни!.. Авыр булсын иде ул! Сөякләрне шытырдатып, җиде кат тиргә манчый торган эш булсын да, ир-егеткә лаек эш булсын иде! Иртәдән кичкә кадәр баз шикелле караңгы бүлмәдә проявительгә фото-кәгазь тутырып утырасың. Шул кәгазьләрдә кемнәрнеңдер йөзләре килеп чыкканны көтәсең. Бүген дә шулай, иртәгә дә шулай, бер елдан соң да шулай. Гомер буе шулай!.. Шул турыда хыялланган идеммени соң мин, әни! Саулыгым булса, әнә тегендә очып йөрисе кеше идем бит мин!.. Самолет тавышын ишетә алмыйм. Ишетсәм — бөтен йөрәкләрем әллә нишли башлый!.. *(Җирәнү белән таягын атып бәрә, егылып китмәс өчен стенага тотына.)* Туналмаган җирең калмагач, минем хәлне сорама инде син, әни! Тәнемне

кеше күрүдән куркып, су коенырга да төшмим бит мин — оят чөнки!

А н а. Ә син оялма! Ватан өчен сугышканда алган гариплек — хурлык түгел ул, балам! Күкрәгеңдә орденнарың, йөрәгеңдә намусың — нәрсәдән ояласың! Башыңны югары тот, улым! Син минем йөз аклыгым! Горурлыгым син минем! *(Инсафның таягын алып бирә. Артта аяк тавышлары.)* Кемдер килә! Тынычлан, улым!

М а к с у д белән С а й м ә керә.

Үзегез генәме? Кайтучылар юкмы?

С а й м ә. Шушы көннәрдә Мәйсәрә кайтып төшәргә тиеш, әни! Отпускамны алам да бер айга әни янына кайтам, дип язган!

А н а. Хафиз турында хәбәрегез юкмы, дип сорыйм минем! Сәяр телефонга чакырам, дип киткән иде, кайтмый да кайтмый...

С а й м ә. Тоташтыра алмыйлардыр, әни, ерак җир бит... Хафиз өчен син борчылма, әни! Менә күрерсең, погоннарын елкылдатып кайтыр да төшәр, алла боерса! *(Инсафка.)* Син чыктыңмыни?

М а к с у д *(кесәсеннән кәгазь чыгарып)*. Әни, безгә яңа квартирга ордер бирделәр! Иртәгә күченәбез! Берничә көннән сине үзебезгә алып китәбез, әни!

А н а. Барып күрдегезме соң әле, әйбәтме?

С а й м ә. Яман да әйбәт квартир, әни, искиткеч! Ике бүлмәле, тәрәзәләре кояшка карап тора! Инде сине үзебезгә алып китәбез, әни! *(Сумкасыннан целлофан капчык чыгарып.)* Әни, менә ашарсың, сиңа кош теле китердем. Сары майда гына пешердем, бик тәмле булды!.. *(Сумкасыннан ап-ак ефәк яулык чыгарып Ананың башына каплый.)* Менә монысы, әни, сиңа туган көн бүләге!

А н а. Туган көн бүләге? Кемнең туган көне соң бүген?

С а й м ә. Синеке, әни, бүген синең туган көнең!

А н а. Үзем дә белмәгән туган көнемне кайдан белдең әле син аны?

С а й м ә. Белдек шул менә, әни!

М а к с у д. Исеңдә юкмыни, әни? Әби сине урысларның Пукрау бәйрәме көнне таптым, дип сөйли торган иде. Бүген Пукрау көне! Шулай булгач, синең туган көнең була бит инде!

С а й м ә. Әйе! Бүген синең туган көнең, әни! Бу сиңа туган көн бүләге!

А н а. Рәхмәт, кызым! Кул-аягың сызлаусыз булсын!

С а й м ә. Башыңда тузсын, әни, җаным! *(Ананың чәчләрен төзәткәләп.)* Әле нигә бу ак ефәк күлмәгеңне киеп куйдың, әни, туган көн икәнен белдең мәллә?

А н а. Юк! Әүвәл-әүвәлдән туган көннәрен үткәреш булмагач, уйлаган да юк инде аны, кызым. Юк иде бит ул безнең заманда. Болай гына кигән идем, берәрсе кайтып килсә, дип...

С а й м ә *(Ананың башына үзе алып килгән яулыкны бәйләп)*. Максуд! Инсаф! Күрәсезме, әни нинди матур булып китте! Ак төс бик килешә сиңа, әни!

А н а *(Сайманең соңгы сүзеннән сагаеп, ләкин аны-моны сиздермичә)*. Алты килен арасында синнән тәмлерәк теллесе юк, рәхмәт, кызым. Шулай да беркөн бер авыр сүз ычкындырдың.

С а й м ә. Минме, әни? Кайчан?

А н а. Гөлчирә кайткан көнне. Тәмле ризыкны ирләргә бирергә ярамый, алар аның тәмен белеп ашамый, дидең.

С а й м ә. Шаярып әйткән сүз иде ул, әни!

А н а *(Сайманең кулын кысып)*. Улымны тамактан аерма!

С а й м ә. Мәзәк итеп сөйләшкән сүз иде ул, әни! Безнең Максуд авызыннан тартып алып ашый ул. Әнә иде авызын ерып тора!

А н а *(Максудның башыннан сыйпап)*. Кечкенәдән тәмлене яратучан булып үсте шул ул. Кайчак әтисе сорый торган иде. Улым, нигә бу хәтле тәмлене яратасың, тәмле ашап ни була? — ди торган иде. Авызга рәхәт була, ди торган иде Максуд. Ул конфеттыр, җимештер кебек нәрсәне тотмады инде. Кая гына яшерсәм дә эзләп табар иде!

С а й м ә. Хәзер дә шулай ул, әни! Эзләп тә таба, ашап та куя!

А н а. Яшергән урыннан тапкач, әйтә торган иде тагын үзе. Әни, фәлән җиргә яшергән фәлән нәрсәңне эзләп таптым. Инде икенче җиргә алып яшер, югыйсә, чыдап тора алмыйм, ашап бетерәм, ди торган иде.

С а й м ә. Һай, җаным, ни гомердән бирле шуларны онытмыйсың син, әни! Бутамыйсың да тагын! Бик күп булганнар бит алар, унау булганнар!

А н а. Унысы ун төрле шул аларның.

Сайм ә. Ул бер көтү баланы ничек үстереп бетердең икән син, әни? Безнең монда берсе белән дә башлар катып бетә. Ун баланың унысын да кеше иткәнсең бит, һай, җаным!

Ана *(тирән сулап)*. Унысын да булмады шул, кызым!

Сәйм ә. Кемне әйтәсең, әни? Исламнымы?.. И, әни, үз балаң булгач, нинди генә булса да яратыладыр күк ул миңа. Менә безнең Альфред. Чукынган малай, кайчак шул хәтле ачуларымны китерә, әни! — барыбер яратам шуны. Әллә балаларың күп булгач башкачамы ул, әни?

Ана. Әй, кызым! Менә ун бармак — кайсын гына тешләсәң дә авырта!..

Посылка күтәреп Сәяр керә.

Сөйләштеңме абыең белән?

Сәяр. Әһе!

Ана. Соң?

Сәяр. Хафиз абый өйдә юк, Халисә җиңги белән сөйләштем... Менә, әни, Рәшидә апа сиңа посылка җибәргән!

Ана. Күземә кара әле! *(Сәяр Ананың сынаулы карашын күтәрә алмыйча, күзләрен читкә бора.)* Алдашасың!

Сәяр. Юк, әни!

Ана. Алдашасың! Әйт дөресен! Ни булган абыеңа? Авырыймы?.. Әллә яралаганнармы?.. Үтергәннәр!

Сәяр. Юк, әни!

Ана. Үтергәннәр! Үтергәннәр! Харап кына иткәннәр икән бәбекәчемне!..

Сәяр. Әни, сөйләп бетергәнне көт!

Ана. Үтергәннәр! Күңелем сизгән иде! Бальниста чакта ук күңелем сизгән иде!..

Сәяр. Хафиз абый исән-сау, әни!

Ана. Алайса, нигә күземә туры карый алмыйсың? Ни булган абыеңа?

Сәяр. Берни дә булмаган!

Ана. Икмәк белән ант ит! Хафиз абың исән-сау, диген!

Сәяр *(беравык икеләнеп торганнан соң)*. Ялганласам, икмәкнең чыраен күрмим, Хафиз абый исән! Командировкага җибәргәннәр аны.

А н а. Командировкада гына булгач, нигә хаты юк?

И н с а ф. Армиядә дисциплина каты, әни...

А н а. Сөйләмәгез! Ул инде унике ел армия хезмәтендә, ун көннән ун көнгә хаты килмичә бер генә тапкыр да калмады!

И н с а ф. Армиядә төрле чак була, әни!

М а к с у д. Сәдәп кадарга да вакыт булмый, әни, анда кайчак!

А н а *(азрак үзен кулга алып)*. Ерак җибәргәннәрме?

С ә я р. Ерак. Чит илгә!

А н а. Озаккамы?

С ә я р. Бер... биш айга!

А н а *(өметен җуеп)*. Биш ай!..

С а й м ә. Биш ай, дип, биш ай күп түгел инде ул, әни, хәзер үтә дә китә... *(Сәяр алып кайткан посылканы караган булып.)* Һай, җаным, нинди бәхетле карчык син, әни! Посылканы яудырып кына торалар бит үзеңә!

А н а. Берни ашый алмаган әниләрен посылка белән күмделәр, үзләре кайтмыйлар!

С а й м ә. Кайтмыйлар, дип, әни-җаным, җае чыкмый торгандыр...

А н а. Мин аларга бөтен гомеремне бирдем. Алар әниләре өчен бер көннәрен кызганалар!..

Ислам, Расиха, Рәйхан керә. Рәйханның өстендә мәктәп формасы. Исәнләшү.

А н а *(Рәйханны кулы белән чакырып)*. Кил, кызым!

Р а с и х а *(Анага таба бара башлаган Рәйханны тотып)*. Юк-юк, әбисе, Рәйханга синең янга барырга ярамый! Грипп булган Рәйханга! Әбисенә грипп иярер, дип курка ул! Шулай бит, кызым?

А н а. Грипп булгач, баланы урамга алып чыгасың калмаган. *(Сәярга.)* Улым, азрак су агызып кертсәнә! *(Сәяр чыга.)*

Р а с и х а. И, әллә әнигә коры су эчерәләр инде?! Кем инде авыру кешегә коры су эчерә! Варенье болгатып бирергә кирәк! Менә бит кара карлыган вареньесы алып килдем, витамин гына! *(Сумкасыннан бер банка варенье чыгарып өстәлгә куя. Сәяр су алып керә.)*

А н а. Кирәкми, кирәкми, шул көе генә эчәм!

Р а с и х а *(йөткергәләп)*. Үзем дә йөткерәм, нинди бетмәс грипп булгандыр инде бу!..

М а к с у д *(Расиха алып килгән банканы карап)*. Да,

витамин күп инде монда — сигез ел тому назад ясалган!

А н а *(су эчеп)*. Рәхмәт! *(Расиханың Рәйханга сугып җибәрүен күреп.)* Әллә балага суктың инде, Расиха?

Р а с и х а. Сүз тыңламый, әни, үләм инде мин бу бала белән! Әбисе иркәләп бозып бетергән! *(Рәйханга тагын бер сугып җибәрә.)* Җитте, диләр сиңа! *(Рәйхан кычкырып елый башлый.)*

А н а. Йодрык хәтле балага сугарга ничек кулың бара синең?!

И с л а м. Суксын, суксын, әни! Бик иркәли башласаң, әнә абыйларның Альфреды кебек була ул аннары!

С а й м ә. Ник, ни булган безнең Альфредка?

И с л а м. Булмаган! Миннән биш сум акча сорап кергән, таксига түлисе бар, ди. Ничә сәгать инде малаегыз таксидан төшеп китә алмыйча Казан буйлап чаба, хы-хы-хы!

Р а с и х а. Хә-хә-хә!

С а й м ә. Бирденме соң?

И с л ам. Нишләп бирим!

С а й м ә. Котың очкан икән, мескен! Биш сумыңны алып Казаннан чыгып качар, дип курыккансың шул! Бурычка сорау гаеп түгел ул, кеше кесәсенә генә кермәсен!

И с л а м. Сорап-сорап та таба алмаса, кеше кесәсенә керә башлый инде ул!

С а й м ә. Шуның шулай икәнен дә белгәч, нигә биш сумыңны кызгандың соң?

И с л а м. Йөрмәсен дуңгыз дагалап! Аңа бит утыз тулган!

С а й м ә. Тулса! Утызны тутырып, законга сыймаслык эш эшләгәне юк ич әле аның! Син үзеңне бел! Утыз яшьтә чагында кайларда булганыңны оныттыңмыни?

А н а. Кызым!

М а к с у д. Барып чыкмады, әни, безнең малай! Институтка кереп укый алмады. Утыз ике яшькә җитеп юньләп эшләгәне дә юк. Бер-ике генә атна эшли дә ташлый, бер-ике генә атна эшли дә ташлый. Хатыны куалап чыгарды, алимент түләп тора!

И с л а м. Хы-хы-хы! Алимент түләп торабыз, диген син, абый! Аны бит Альфред түләми, Саймә белән син түлисең! *(Анага.)* Милиция килеп эшкә керергә кушкач, Альфредны дворник итеп урнаштырган булганнар, әни!

Ә Альфред себерми ишек алдын, эшкә киткәче абый белән Саймә себереп китә. Менә шул акчадан Альфредның малаена алимент тотып калалар инде, хы-хы-хы!

Р а с и х а. Хә-хә-хә!

С а й м ә. Бик килешә инде, о! Балалы кешегә кеше баласыннан көлү ярамый ул. Әнә үзегезнеке үсә, аның кем буласын белгән юк әле! Шулай түгелме, әни?

А н а. И, кызым, ана кешенең күңеле бик күпне сыйдыра. Кайчак баланны ярамас эш өстендә тоткач та тизрәк итәгең белән каплыйсың, кеше-кара күрмәсен, дисең. Тик кайчак балалар итәк астына гына сыйдырып булмаслык эшләр дә эшләп ташлыйлар.

М а к с у д. Әнисе яклап бозып бетерде, әни, Альфредны!

С а й м ә. Бер дә бозмаган! Бер дә бозмаган! Аңа карап кына бозылмый ул бала! *(Елый-елый.)* Тик кенә торыгыз! Үзем дә беләм ич мин, сездән башка да!.. Аның бит башында бер уе бар!

И с л а м. Хы-хы-хы!

Р а с и х а. Уе бар! Хә-хә-хә!

С а й м ә *(тәмак чыгырыннан чыгып)*. Һай, җаным, менә сине кем бозды икән! Сугышның беренче көнендә дүрт туган повестка алдыгыз. Абыең белән ике әнең китте, Закир әнә әйләнеп тә кайтмады, ә син сугышка бармыйча качып яткансың! Кем өйрәтте соң сине шуны эшләргә? Әниме?!

А н а *(битен куллары белән каплап)*. Аһ!..

С ә я р *(Ананы кочаклап)*. Кухняга чыгып талашыгыз, әнә тегендә! *(Максуд, Саймә, Ислам, Расиха, Рәйхан кухня ягына узалар. Аларга Инсаф иярә. Пауза.)* Мин тәмәке тартуны ташладым бит, әни!.. Исеңдәме килеп төшкән көнең? Син минем улларым аракы да эчми, тәмәке дә тартмый, дип, мактанып торганда, Саймә җиңги: «Сәярың тарта!» — дип кычкырды. Шул сүзне ишеткәч синең йөзең куырылып китте, әни. Һәм мин аңладым. Ана кеше өчен балаларының тәүфыйклы булуыннан да зуррак мактаныч юк икәнлеген аңладым. Шул көннән бирле минем тәмәке тартканым юк, әни, ташладым! Шул вакытта сине уңайсыз хәлдә калдырган өчен гафу ит мине, әни, кичер! Икенче мин һичкайчан синең йөзеңә кызыллык китермәм! Кичер!..

А н а *(Сәярны күкрәгенә кысып)*. Балам ла соң инде минем!..

Сәхнә әйләнә. Зөләйха квартирасының кухнясы.

Инсаф. Кешедән оят! Тугыз баласы була торып, әни кеше өендә үлеп ята! Бөлүдән курыксагыз, түләгән булыр идек үзегезгә, акчалата!

Ислам. Төкерәм мин сезнең акчагызга! Акча минем үземдә дә менә моннан! *(Муенын күрсәтә.)* Теләсәм, мин әнине үлгәч кабергә куймыйча, акча белән күмеп куя алам!

Саймә. Һай, жаным, акча да акча, дип үлде бит шушы бәндә! Акчадан кыйммәтлерәк нәрсәләр дә бар бит бу дөньяда!

Ислам. Нәрсә ул акчадан кыйммәт нәрсә?

Саймә. Әнә әни!

Инсаф. Бик күп ул акчадан кыйммәт нәрсә, аны син генә белмисең.

Саймә. Тәре урынына куеп чукына бит шул акчага, нишләп буладыр аның белән?

Ислам. Акча беләнме? Акча белән барысын да эшләп була, аны без бик яхшы беләбез!

Саймә. Булса! Терелт менә әнине, нигә терелтмисең? Терелт тә, бер егерме яшькә яшьрәк ясап куй!

Максуд. Менә әни рәнҗеп үлсә, эзләп кара син үзеңнең акчаңа әнинең хәер-фатихасын — табарсынмы икән!

Ислам. Сез минем өчен борчылмагыз! Әни миңа фатиха бирәчәк. Соңгы елларда, понимаешь, аңа миннән дә күп акча җибәреп торган кеше булмады. Менә мин төрмәдән чыккач унбиш ел шахтада эшләдем. Шул унбиш ел эчендә син, абый, әнигә күпме акча җибәрдең?

Саймә. Тагын акча!

Ислам. Күпме җибәрдең?

Максуд. Санамадым.

Ислам. Ничә посылка салдың?

Максуд. Анысын да санамадым.

Ислам. Былтыр Рәйханны алырга кайткач, карап йөрдем мин анда. Лапаста посылка ящиклары аунап ята. Күбесе, понимаешь, Магаданнан мин салган посылкалар!

Максуд. Без якын торабыз, үзебез еш кайттык.

Ислам. Анысын булдырасыз! Кайтып әнинең итләрен, бәрәңгеләрен төяп килергә сезне куш! *(Инсафка.)* Ә син, герой, күпме җибәрдең?

И н с а ф. Санап бармадым.

И с л а м. Ә менә мин санап бардым! *(Кесәсеннән бер төргәк почта квитанцияләре чыгара.)* Менә! Менә болар бөтенесе соңгы унбиш ел эчендә әнигә мин салган посылкалар һәм акчалар. Менә, ай саен унбишәр, егермешәр сум салып барылган!

С а й м ә. Барсаң! Рәйханны әнигә кайтарып аткан-да сигез ай да тулмаган иде, әни шуны алты яшькә тиклем тәрбияләп үстерде. Бала караучы нәнкеләргә аена алтмышар сум түлиләр. Җибәреп бардыңмы соң әнигә алтмышар сум?

И н с а ф. Әнигә язган хатларыңны да санап барасың калган. Аларның да бит һәркайсына дүртәр тиенлек марка киткән!

С а й м ә. Җитте! Туктатыгыз акча турында сөйләшүне, башыма капты!

М а к с у д *(Расиханың Рәйханга шап иттереп сугуын күреп)*. Нишләп көйсезләнә соң шул бала?

Р а с и х а. Әби янына керәм, дип аптырата! Кереп, әбинең башыннан гына сөеп чыгыйм әле, ди!

С а й м ә. Керсен!

Р а с и х а. Кермәсен!

С а й м ә. Һай, җаным, бала әбисе янына керим, дип тилмерә, әбинең башыннан гына сөяр идем, дип — шуны кертмиләр! *(Расихага.)* Йогышлы авыру түгел ич ул, нигә котыгыз чыкты!?

Р а с и х а. Йогышлымы-түгелме — белгән кеше юк, врачлар үзләре дә белми! Саклану зыян итми, Саймә апа!.. *(Рәйханга.)* Бар, әнә урамга чыгып уйный тор, кайтышлый кычкырырбыз! Кара аны, әбиең янына керәсе булма! *(Рәйханны төрткәләп чыгарып җибәрә.)*

М а к с у д *(Инсафтан)*. Син Казанда озак буласыңмы әле?

И н с а ф. Министр янына керәсе бар әле, коляска алып булмый.

М а к с у д. Синең коляскаң бар лабаса!

И н с а ф. Ватылып бетте инде ул! Яңасын сорап язган идем дә, чират җитми.

И с л а м. Ничек инде чират житми, понимаешь! Ватан сугышы инвалидларына почет зур лабаса аларга, хы-хы-хы!.. Әле менә гараж түбәсен капларга калай кирәк булды. Бер җирдә юк калай! Шуннан, военторгка кереп, биш-алты орден колодкасы сатып алдым да,

күкрәккә кадап, киттем райсобеска. Хы-хы-хы! Анда бер яшь кенә малай утыра икән. Бер кулны менә болай асылындырып барып кердем мин монын янына. Алдына пенсия книжкесен чыгарып салдым. Анда язылган инде, аена йөз егерме сум пенсия ала, дип. Шуннан бу бер минем кулга, бер орден колодкаларына, бер книжкегә карап торды-торды да, заявлениемә кул куеп, базага жибәрде. Мине сугыштан кайткан берәр полковник дип уйлады бугай. Хы-хы хы!

Р а с и х а. Хә-хә-хә!

М а к с у д. Андыйга син оста!

И с л а м. Яши беләм!

С а й м ә. Кайда соң бу дөньяда справедливость?! Менә син, Инсаф, сугышның башыннан ахырына кадәр йөреп, ике аягынны өздереп кайттын — инвалид машинасы ала алмый йөрисен. Ә сугышка бармыйча дезертир булып йөргән кеше «Волга» машинасына утырып әйттерә!

И с л а м. Справедливость? Тапкан сөйләргә сүз — справедливость! Юк ул справедливость, эзләмәгез сез аны! Менә син ничә яшьтә инде, абый? Илле өчтәме? Пенсияга чыкканчы тагын жиде ел бөкреңне үстереп эшлисең бар икән әле. Күпме булачак инде синең пенсиян?

М а к с у д. Күпме булса да үземнеке булачак!

И с л а м. Житмеш сумнармы? Ул житмеш сумны сиңа әле жиде ел эшләгәч кенә бирәчәкләр. Ә үзен сугышта булдың! Мин бармадым сугышка, шунын өчен төрмәдә утырдым. Төрмәдән чыккач унбиш ел шахтада эшләдем дә горняцкий стаж белән илле яшьтән пенсияга чыктым. Үзем шул унбиш ел эчендә бер мәртәбә дә шахтага төшеп карамадым! Хәзер менә аена йөз егерме сум пенсияны алып, түшәмгә төкереп ятам, понимаешь! Менә сиңа справедливость! Юк ул справедливость! Эзләмәгез сез аны!

И н с а ф. Нигә булмасын — бар ул справедливость.

И с л а м. Бар, хәзер китереп тоттыралар сиңа! Көтеп утыр әле син аны, ә мин ул арада яшәп калам!

И н с а ф. Ә мин әйтәм, бар ул справедливость! *(Көч белән Исламга китереп суга.)* Менә ул справедливость! *(Тагын суга.)* Менә ул справедливость, гад!.. *(Ислам идәнгә ава, Инсафны Максуд белән Саймә ки-*

леп тота.) Бөтен ил, бөтен халык ил өстенә ташланган дошман белән сугышканда дезертир булып йөрүең генә җитмәгән, әле син без фронтовиклардан көлеп маташасыңмыни? Без анда илнең бер карышы өчен кан коеп йөргәндә, син монда нәрсә уйлап яттың? Син бит, сволочь, безнең җиңелүне теләп яткансың!

Ислам *(чигенә-чигенә)*. Син кара, авызыңны үлчәп ач!..

Инсаф. Ә нәрсә? Дошманны тизрәк җиңеп, үзеңне кулга алуны көттем, дияр идең мәллә? Юк, син безнең җиңелүне теләп яткансың! Шулай булмаса үзеңә көн булмаячагын анларлык кына синдә баш бар! Әгәр дошман Казанга килеп җитсә, син бит фашист ялчысы булачак кеше идең, падла!

Ислам. Әйтәм ләбаса, танавыңны чамалабрак ач, дип. Минем судимость снята! Минем документларым чиста! *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә күрәсеңме? Укы да танавыңны үлчәп ач! Юкса, мин сине бу сүзләрең өчен җавапка тарттырырга да күп алмам!

Инсаф *(Исламның кәгазен ертып)*. Тарттырып кара! Тарттырып кара мине җавапка!

Ислам *(идәндәге кәгазь кисәкләренә ташланып)*. Минем судимость снята дип яздырып алган справкамны ертты! Үтерәм бит мин сине моның өчен, галах!

Максуд. Кычкырма, әни ишетер!

Расиха. Кычкырсын, кычкырсын! Аңа врач шулай кушкан! Ачуың килгәндә ачуыңны чыгарып бетер, шулай итмәсәң, ачуың чуан булып бөтен тәнеңә тарала, дигән! Кычкыр, кычкыр!

Ислам. Үтерәм! Валлаһи, үтерәм мин син галахны!

Инсаф. Әтәчләнмә! Син мине үтерә алмыйсың! Мине үтерсәң, синең үзеңә үлем җәзасы булачак бит, ә син моннан куркасың! Ох, ничек куркасың син үлемнән! Сугышта үлүдән куркып, үзеңнең менә моның хәтле җаныңны саклап калу өчен Ватанны саткан сволочь бит син!

Сәяр керә.

Максуд. Безнең тавыш әнигә ишетелмиме анда?

Сәяр. Әни йокыга китте... Бүген мин Халисә җиңги белән сөйләштем. Сугышчан заданиены үтәгән вакытта Хафиз абый һәлак булган...

Сәхнә әйләнә башлый. Залда Рәйхан күренә. Ул курка-курка артына карангалап, Ана яткан бүлмәгә таба бара. Безнең алда Ана яткан бүлмә. Рәйхан керә. Ул акрын гына Ана янына килә дә тиз генә Ананың башыннан сөеп ала. Йөгереп ишеккә бара, ишекне ачып кухнядагы тавышларга колак салып тора. Янадан Ана янына килә, янадан Ананы сөя башлый. Ана күзләрен ача, Рәйхан тиз генә читкә йөгерә.

Ана. Кызымны төшемдә күрәм дип торам, өнем икән ләбаса! Ник анда качтың, кызым? Кил яныма! Кил инде, бер сөйим әле үзеңне!

Рәйхан. Синең янга барырга ярамый!

Ана. Ник?

Рәйхан. Синдә рак бар!

Ана. Нәрсә? Нәрсә бар?

Рәйхан. Рак бар!

Ана. Кем әйтте?

Рәйхан. Әти әйтте. Әни дә әйтте. Әбиең янына барсаң, үләсең, диделәр. Син биргән әйберне дә ашарга ярамый.

Ана *(үзен кулга алып)*. Миндә рак юк, кызым! Әтиең сиңа дөрес әйтмәгән. Дөрес әйтмәгән сиңа әтиең! Кил!

Рәйхан *(кулларын җәеп йөгерә-йөгерә)*. Әбием, алайса син үлмисең! *(Ананың итәгенә сикереп менеп, муенына урала.)*

Ана. Үләм, кызым!

Рәйхан. Үлмисең, әбием, үлмисең! Терeләсең! Миңа Саймә апа әйтте! Терeләсең, әбием! Терелгәч бергә авылга кайтабыз!..

Расиха йөгереп керә.

Расиха. Рәйхан! *(Йөгереп Рәйхан янына килә башлый, ләкин Ананың Рәйханны күтәреп тора башлавын күреп, коты чыгып кире йөгерә.)* Ислам! Ислам! Кер әле тизрәк, Ислам!..

Бүлмәгә Ислам, Максуд, Саймә, Сәяр һәм Инсаф керәләр.

Расиха. Нәрсә карап каттың — ал инде тизрәк баланы!

Ана *(Рәйханны күтәргән килеш)*. Минем йогышлы авыруым юк, мин врачтан сорап чыктым. Артыграк кыланасыз.

Р а с и х а. И, эни, карт кешедә йогышлы авыру булса да гаеп түгел инде. Саклаганны саклармын, дип әйткән, ди бит алла да. Шуңа дип инде Рәйханны синең янга җибәрмәвебез иде. Бала җәл бит!..

А н а. Бала җәл була шул ул. Егерме беренче елның көзендә балалар арасында тамак чире чыкты, минем дә бер балама йокты. Укымаган дога, ясатмаган им-том калмады. Бу бала кеше булачак түгел, кәфенлек әзерлә, диде абыстай. Килешмәдем. Эт тә чыкмаслык бер кичтә баламны төреп күтәрдем дә авылдан илле чакрымдагы Тәтеш бальнисына киттем. Мин барып җиткәнче таң атты. Бальниска барып керсәм — бөтен бальнисларына бер сестра. Күп-күмгәк булган баламны ачып кына карады да, бу баланың җаны чыгасы гына калган, ярдәм күрсәтүдән узган, диде. Синең баланда дифтерит, кара аны, берәр җиргә кермә, югыйсә, башкаларга да дифтерит ияртерсең! — дип кычкырып калды. Нишлим? Баламның суына башлаган гәүдәсен күкрәгемә кыстым да кайтырга чыктым. Каршыдан ачы җил исә, өстән юеш кар ява, аяк асты бозлавык. Кайта-кайта аягымдагы оек-чабатам тузып төште, аяк табаннарым бозга суелып канга батты... Ярты юлга җиткәч, балам гаргарәгә килде. Ичмасам, җир-әнкәнең куенында үлсен инде, дип, башымдагы шәлемне салдым да, бозга җәеп, баламны шунда куйдым. Ә балам көчкә тын ала! Бу авырудан шулай буылып үлгәнне күргәнем бар иде. Нишләп болай авыр сулый соң бу бала, әллә тын юлына берәр нәрсә кергәнме? — дип авызын ачып карасам — авызы тулы лайла! Менә ни өчен!.. Аптырагач, баламның авызына авызымны куйдым да шул лайланы суырдым!.. Ничек өйгә кайтып җиткәнемне белмим. Үпкәм кабарудан савыга башлап аңыма килгәндә, балам инде йөгереп йөри иде!

Р а с и х а. И, менә бит! Кайсы балаң иде ул, эни?

А н а. Ул бала — синең ирең. Башка балаларыма бер генә тапкыр яшәү бирсәм, аңа мин ике мәртәбә тормыш бүләк иттем. Шуңа ул әнә шулай яхшы булып чыкты, тугач та мендәр каплап үтерәсе нәрсә!..

И с л а м башын түбән иеп чыгып китә.

Р а с и х а. И, алай димә инде, эни! Вакыты җиткәч барыбыз да үләрбез!

А н а. Ул инде минем өчен күптән мәет. Аналар өчен балалар шулай. Кайберләре вафат булсалар да, мәңге исән, чөнки алар намус белән үлгән балалар. Кайберләре икмәк черетеп яшәсәләр дә — мәет!

И н с а ф. Әни, сиңа борчылырга ярамый! Ятып тор, әни!

А н а. Мин бик күп яттым инде, улым, алда — ятасыларым тагын да күп. Азрак басып торасым килә. Менә сез өч айдан бирле минем белән курчак уены уйныйсыз. Әни карчык кеше, янәсе, ничек ялганласак та ышана. Ә мин сезнең ялганнарыгызны белеп торам, сезне борчымас өчен әйтмим генә. Сәярнең хатыны нинди практикага киткәнен дә, ни өчен кеше өендә ятуымны да, авылга ник җибәрмәвегезне дә — барысын да беләм бит мин. Ана кешенең колагы ишетмәсә, йөрәге ишетә... Үзегез миннән яхшырак беләсез, минем күп яшисем калмады. Васыятем шул: кеше булыгыз! Куркак җан булудан сакланыгыз! Кеше куркак булса, үзенең җанын саклап калу өчен теләсә нинди түбәнлеккә бара. Атасын да, анасын да, хәтта Ватанын да сата!..

П ә р д ә.

1968

ЭЧТӘЛЕК

Драматургның геройлары. *Туфан Миңнуллин* . 3
Бирнәле кыз 5
Чулпан 23
Егерме ел үткәч 68
Туган көнең котлы булсын, Кадрия! . . . 78
Профессор кияве 100
Зөбәйдә — адәм баласы 164
Әниемнең ак күлмәге 227

Хусаинов Шариф Нургалиевич

ПЬЕСЫ

(на татарском языке)

Редакторы *М. Шабаев.* Художнигы *И. Субаев.* Художество редакторы *Л. Ибраһимова.* Техник редакторы *Ә. Трофимова.* Корректорлары: *М. Мирсаликова, Р. Хәмидуллина*

ИБ № 1513

Наборга бирелде 31/X-1978 ел. Басарга кул куелды 29/III-1979 ел. Типография кәгазе № 1, 84×108¹/₃₂. Учетно-изд. табагы 15,23+ рәс. 0,03. Якынча басма табагы 15,12 + рәс. 0,1. Тираж 15 000. Заказ Х-899. Бәясе 1 сум 30 тиен.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19.